# КАЗАН УТЛАРЫ

12. 1994



# КОТЛЫЙБЫЗ!




Татар матбугаты күгендә яна йолдыз кабынды: Уфада «Тулпар» исемле әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси яшьләр журналы чыга башлады. Матур бизәлешле һәм бай эчтәлекле булачак бу журналның беренче санын кулга алу ук күңелдә якты хисләр кузгата — XX гасыр башында әдәбият-мәдәниятыбыз тарафларындагы киңлек, ярыш, һәр төбәктә татарча төрле газета-журналлар дөнья күргән чорлар хәтергә кайта: киләчәккә өмет, ышаныч тойгылары ныгый.

Журналны гамәлгә куючы — Башкортстан җөмһүриятенең Яшьләр эшләре буенча дәүләт комитеты. Мөхәрририятендә — танылган язучылар, галимнәр; авторлары — Башкортстанда да яшәүче татар әдипләре, шагыйрьләр, журналистлар, сәнгать белгечләре... Баш мөхәррире — Римат Кашапов.

«Казан утлары» журналы бу сөенечле вакыйга уңае белән яшь «Тулпар»ны чын күңелдән котлый, Башкортстан татарларының күптәнге хыялы тормышка ашуын хуплап, журналга алга таба халыкка хезмәт итү һәм уртак максатлар юлында зур уңышлар теләп кала.

**«Казан утлары» журналы редакциясе һәм редколлегиясе.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**12**

**(866)**

**1994**

КАЗАН


## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Я. ЗӘНКИЕВ. Иртеш таңнары. *Роман* . . . 3

Х. МӨДӘРРИСОВА. Кырык яшьтә. *Шигырьләр* . . . 84

Ә. ГАБИДИ. Була төрле чаклар. *Шигырьләр* . . . 88

Ф. ӘМӘК. Чытырманда кош оясы. *Повесть* . . . 92

Р. СУЛТИ. Шүрәле. *Шигырьләр* . . . 135

ИДЕЛБИКӘ. Ашыктырма, гомер. *Шигырьләр* . . . 141


ПУБЛИЦИСТИКА


Ф. ИБРАҺИМОВ. «Ике йөз елдан соң инкыйраз булырмы?» *(Яки урыс-татар мөнәсәбәтләренә карата)* . . . 143


ҺИБӘТУЛЛА САЛИХОВНЫҢ ТУУЫНА 200 ЕЛ


Һ. САЛИХОВ. Шигырьләр . . . 162


ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНА 75 ЕЛ


Х. ӘШРӘФҖАНОВ. «Китап тотып ант итәм...» . . . 164


М. УКМАСИНЫҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ


М. МӘҺДИЕВ. Кара тарихтан бер ләүхә . . . 167


КИТАП КҮЗӘТҮ


М. ӘХМӘТҖАНОВ. Фикер хәзинәсен барлаганда . . . 171


БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ


Муса Акъегет . . . 174


ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕНДӘ — ТАТАР ШӘХЕСЛӘРЕ


Б. СОЛТАНБӘК. Данлы еллар авазы . . . 175

Татарстан Язучылар берлеге төзелүгә 60 ел . . . 176

1994 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге . . . 185

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 190

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Б е з н е ң  а д р е с: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа Я. ЗАНКИЕВА «Зори Иртыша»; окончание повести Ф. АМАК «Птичье гнездо в дебрях»; стихи Х. МУДАРРИСОВОЙ, А. ГАБИДИ, Р. СУЛЬТЕЕВА, Л. САДЫКОВОЙ.
«Публицистика»: статья Ф. ИБРАГИМОВА посвящена русско-татарским отношениям.
«К 200-летию Х. Салихова»: стихи Х. САЛИХОВА.
«К 75-летию татарского книжного издательства»: статья Х. АШРАФЗЯНОВА посвящена к современным проблемам издательства.
«К 140-летию М. Укмаси»: статья М. МАГДЕЕВА о жизни и творчестве М. Укмаси.
«Книжное обозрение»: Марсель АХМЕТЗЯНОВ рецензирует книгу Р. Амирханова «Татарская общественно-философская мысль в средних веках».
«60 лет писательской организации Татарстана».
«Наш календарь»
Дневник общественно-политической жизни
На наших обложках: «Мелодия» картина художника А. Абзгильдина; известный поэт Харрас Аюпов.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: the end of Ya. Zankiev's novel «Irtish's daybreaks»; the end of Ph. Amak's novel «Bird's nest in the dense forest»; the verses of Kh. Mudarrisova, A. Gabidi, R. Sulteev, L. Sadikova.
«Publicism»: Ph. Ibragimov's article devoted to the russian-tatar attitudes.
«To the 200 anniversary of Kh. Salikhov»: Kh. Salikhov's verses.
«To the 75 anniversary of Tatar book publishing house»: Kh. Ashraphzyanov's article devoted to the modern problems of publishing house.
«To the 140 anniversary of M. Ukmasi»: M. Magdiev's article devoted to the life and creative work of M. Ukmasi.
«Book review»: Marsel Akhmetzyanov reviews R. Amirkhanov's book «Tatar sosial and philosophical thought in the middle ages».
«To the 60 anniversary of the writers's Organization of Tatarstan».
«Our calendar».
«The diary of the social and cultural Life».
In our corvers: A. Abzgildin's picture «Melody», wellknown writer Ch. Aupov.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Марсель Галиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 3.11.94 ел. Басарга кул куелды 16.12.94 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70 \times 108\ ^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 862. Заказ А-524. Бәясе 1100 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1994 ел.



**Якуб Зәнкиев**

# ИРТЕШ ТАҢНАРЫ

РОМАН

## 24

Җир шары — олы бер йомгак ул, тарих әнә шул йомгакка елларны урый. Кайларда нинди сугышлар, күтәрелешләр, бәрелешләр булган да, кайларда яшәп илләрне шаулаткан бөек шәхесләр дөньядан киткән. Кайсы илләрдә хакимнәр алышынган, кайларда илләрне су баскан, зилзиләләр кубып шәһәр-авыллар балчык астында калган, кайсы айларда янар таулар ут төчкереп, халыкларның котын алган. Кайсы илләрдә хан-корольләрнең сылу бичәләре нинди күлмәк киеп бүтәннәрне сукырайткан да, кайсы гарәп илләрендә нефть бәреп чыккан... Кыскасы, күзгә ташланырлык вакыйгаларның эресе-вагы тарихтан ычкынып төшеп калмый, йомгак һәммәсен җыя, эрли, урый, онытмаслык итә.

Һәр авылның, һәр төбәкнең үз йомгагы була. Татар авылларында тарих ел исәбе белән йөрми, анда күп очракларда тарих аерым вакыйгаларга берегеп, сеңеп кала.

— Ә, син аны әйтәсең икән! Борчак уңган иде ул елны!

— Юк ла, мин теге, боз ташып ярларны җимереп, кантарларның бәрәңге бакчасына менеп җиткән елны әйтәм.

— Син карабодай чәчкә аткан дәвердә тудың!

— Теге, фәләннәрнең, мунчасы янып киткән елны булган иде бу хәл!

— Үләт чыгып, мур таралып терлек-туар егылып үлгән идеме? Шул елны иде ул!

Авыл йомгагы шул хәлләрне җыеп килә-килә дә берзаман буыннар алышына, һәм «тәгәри китте йомгагым!» ди татар. Һәм авылның яңа йомгагы төрелә башлый.

Кырык дүртенче ел Ялан авылын дәү йомгак итеп төрде, бик түгәрәк түгел иде бу йомгак, төрле куллар чорнаган, аннан-моннан бүселеп чыккан яклары да күзгә бәрелеп тора иде, әмма йомгак Ялан авылының хас үзенеке иде. Бу елда Булат Омскига барып самавыр булып инрәп

---

Ахыры. Башы журналыбызның 10—11 нче саннарында.

яткан Шәүкәтне алып кайтты. Быел Миңнурый Ялан авылын ташлап китәргә мәҗбүр булды. Быел Ташкәй каты сугышларда катнашып «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнде. Быел Мөхәммәт Уразаев озак вакытлар госпитальдә иза чигеп, ниһаять, туган төягенә кайтып төште. Кырык дүртнең декабрендә, чатнама зәһәр салкыннарда егерме гаилә калмыкларны китереп ташладылар. Быел, быел... Әле сугыш бетмәгән, ләкин күңелләрдә «тиздән бетәр», дигән ышаныч ныгыган...

Хәзер, хөрмәтле укучым, синең белән икәүләп Ялан авылы ураган йомгакны сүтә башлыйк, җепнең очын сиңа тоттырам!

Әгәр тормыш адәмнәр теләгәнчә генә барса! — Алай түгел шул. Адәм уллары берчакта да үз язмышларына үзләре хуҗа була алмадылар. Быел да аларны бәхетсезлек дулкыннары йотып кына алды. «Егылган өстенә йодырык», дигәндәй табигать усалланды, бөтен җәй буена бер-ике тапкыр яңгыр сибәләп узды да — вәссәләм! Үлән калкынмады, болыннар кабармады, башта кашлак урыннар, тау битләре саргаеп кипте. Начар эшкәртелгән, сыер җигеп кенә җылытып сөрелгән басуларда язга саран дым белән калкынган арыш-бодайлар кашык сабы буе калкындылар да шыкыраеп каттылар. Бүтән елларда ат биленнән печән үсә торган болыннар да куандырмады, июль үтте, август, кешеләр өметләнебрәк элегрәк күккә карап болыт килгәнне көтсәләр, хәзер бер Аллага табына башладылар: «Ярабби, нигә шул кадәр җәфалыйсың үзеңнең тугыры улларыңны?»

Башка җәйләрдә Иртеш буйларындагы ярларда котырып юа үсә торган иде, чык та чабып ал! Чабып ал да аша! Урман авызларында нинди генә чәчкә-үләннәр үсми иде, иел дә өз, өз дә аша! Быел какылар да үсә алмады, чыкты да катты, кузгалакларны эскәк белән генә өзәрлек булды. Әрсез кычыткannar да тыкырыкларның коры кабыргаларын тишеп борын тыктылар да, шулай кәрлә килеш калдылар. Авыл арасында «елына күрә инде», дигән сүзләр ныгыды. Гектарыннан ике центнер ярым уңыш алдылар. «Елына күрә» диделәр. Сыер кәҗә хәтле, кәҗәләр песи яларлык кына сөт бирделәр — «елына күрә», диделәр. Бер нәрсә бар: сугыш чыккан елларда халык зарлана белә иде, кырык дүрттә зарлануның да файдасыз икәнен аңлады адәмнәр. Гомумән, адәм балалары аз сөйләшә, күбрәк уйлый башладылар.

Беркөнне Булат Шәгъбикәдән сорап куймасынмы:

— Минем сугышка кадәр үк бер чемоданым бар иде. Кайда икән ул, беләсеңме?

— Чумадан белән кая бармакчы инде син? — Шәгъбикәнең әзрәк тынычлана башлаган йөрәге дерт итеп куйды.

— Кирәк иде.

— Чормада түгелме?

Булат чормага менеп китте, колакларына пәрәвез элеп, муенына, чәчләренә тузан җыеп, капкачы каеш белән беркетелгән, җәлпәк почмаклары күгәреп калҗайган чемоданны алып төште. Сөйләшмәделәр, алай да Шәгъбикә сагайды. Булат чемоданны юды, тазартты, кояшка чыгарып элде.

— Кипсен, — диде ул хатынына карамыйча гына.

Икенче, өченче көннәрдә хатын иренең каядыр әзерләнүен чамалады. Булат чемоданга алмаш күлмәк-ыштан салды, бритвасын урнаштырды, шырпы кабы хәтле генә сабынны да шунда тыкты.

— Ник әйтмисең? Кая барасың син? — дип бәйләнде Шәгъбикә.

Булат ашыгып җавап бирмәде, элеккечә кашларын җыерып, иреннәрен ныгытып кысып хатынына үз янынннан урын күрсәтте:

— Утыр әле, сөйләшик, — диде. — Мин, Шәгъбикә, Шәүкәтне алырга барам.

— Мәүлиха куштымы? — дип сорады Шәгъбикә җәһәт кенә.

— Ул кушарлык булса, үзе баргач алып кайткан булыр иде.

— Кая алып кайтмакчы инде син аны, Булат җаныкаем?

— Үзебезгә алып кайтам. Теге вакытта әйткән идем ләбаса, оныттыңмыни?

— Мин онытмадым аны, Булат бәгырем, әмма синең тилелеген үтәр дип уйлап йөрдем. Син бит аны контузияле башың белән ычкындырдың. Хәзер терелдең, исәрлегең үтте.

Булат башын чайкады һәм хатынына үз ниятенең ныклыгын тагын бер тапкыр ышандырырлык итеп кабатлады.

— Мин монда ике кешене кызганам! — диде ул уйчан кыяфәт белән.

— Мәүлиханымы?

Булат кызып китте:

— Нинди Мәүлиханы?.. Аны кызганырга кирәк түгел, тәпәләп акылга өйрәтергә кирәк ул шәфкатьсезне!.. Үз ире бит, ире! Баласының атасы... Мин Шәүкәтнең үзен һәм улын кызганам? Менә шул!.. Мин анда булдым, күрдем, күпме ир-егетләр ятып калды. Сугышта дим! Без бит меңнән бер — исән калганнар! Шәүкәт исән, яхшымы-яманмы — балага ата! Беләм, уйлыйм, бәлки аның әткәсенә карыйсы да килмәс, куркыр... Мин үзем дә Шәүкәт белән очрашудан шүрлим... Валлаһи, шулай. Тик мин исән калдым, меңнәр арасыннан Ходай мине саклады. Мин өйдә синең бот араң белән кысып җыйган байлыгыңны ашап ятам!.. Күпме иптәшләрем гүрдә, ә мин өйдә! Төшләремә керәләр, «Нинди яхшылыкларың өчен сиңа Ходай гомер бирде?» — дип сорыйлар. Чыннан да, нинди яхшылыклар хакына яшим мин?.. Ашаган ризыгым — харам, эчкән суым агу булып тоела кайчакта. Мәүлиха димәктән, мин аңа әйтеп, төшендереп карадым. Миңа ышанмады, көлде генә! Менә син дә ышанма, әлләә ниләр әйт, тик көлмә ниятемнән, минем уемнан көлмә. Әле сугыш бетмәгән, мине тагын алып китәрләр. Аңынчы мин Шәүкәтне үз түремә алып кайтам.

Шәгъбикә күзләрен шарландырып, ияген чак-чак кага-кага ирен тыңлап торды һәм аның йомарланган йодрыкларыннан күзен ала алмыйча каршы сүз әйтергә кыймады.

— Ни күрсәк тә күрербез инде, — дип кенә куйды.

Озак барды Булат Омскига, юлның һәр минуты ел булып тоелды. Вокзаллар халык белән тулган, бөтен ил урыныннан купкан, ары таба да, бире таба да хәрби эшелоннар нинди-дер яшерен серләр сөйрәп йөреп торалар, расписаниесез генә йөреп маташкан хәлсез пассажир поездлар аларны үткәреп җибәрә. Кайда вагон түбәсенә менеп, кайда вагон баскычларына ябышып, җил күзендә ыжлап-ыжгырып бара-бара, Булат үзенә салкын тидерде, ютәлли башлады. Тик аңа фронтовик язмышын яхшылыкка борып җибәрергә ниятләп сәфәр чыккан фронтовикка бүген чирләргә дә, йомшарырга да ярамый иде. Булат бер йодрык булып йомарланырга тиеш! Ул шулай эшләде дә, станцаларның берсендә, зарыгып поезд көтеп торганда медсанчастька барып керде, «суык тигәннән» дарулар сорады. Бик ялынып сорагач, кая, нинди йомыш белән йөрүен белдергәч аңа бер кап ак төймәләр тоттырдылар тоттыруын. Булат даруларны учына салды да һәм бөтенесен берьюлы йотып җибәрде. Ходаның хикмәте, даруның файдасы тиде, ютәлен юып алгандай булды, бетте...

Булат белән Шәүкәтнең очрашуын тасвирларга сүзем җитми. Бу очрашуны сурәтләргә корыч сүзләр, кургаштан койган фикерләр кирәк булыр иде. Ике авылдаш, ике чордаш, ике фронтовик! Янәшә басарлар иде — аяклар юк, кочаклашырлар иде — дөнья куллардан да мәхрүм иткән. Бер мәлгә сөйләшер сүзләр дә булмый торды, сүзләр табылмады. Дүрт күздән аккан кайнар яшьләр генә очрашуны җилемләп тордылар. Шәүкәт, инде дөньядан өметен өзгән егет, Булат әйткән сүзләргә ышанмады, ышана алмады.

— Йәле, йәле, Булат! Тагын бер генә кабатла әле сүзләреңне, — дип ялварды.

Булат күз яшьләреннән оялмады, җылый-җылый:

— Сине алырга килдем. Мин сине үзебезгә алып кайтам,— диде. Шәүкәт күзләрен Булаттан читкә алып озак кына дәшмичә ятты, аннары суык, төшенке тавыш белән:

— Юк, дускаем, юк. Кая ул! Мондый мәшәкатьне өстенә алып син яхшылык түгел, җүләрлек кенә кыласың,— диде.— Ярый, кайттык, ди. Ярты елдан син мине шифаханәгә тапшырачак бит! Юк, юк... Өстәмә хәсрәт китермә син миңа, Булат! Мине карауның бүтәннәр өчен җәһәннәм икәнен аңла. Ята-ята Мәүлиханы аңладым мин, башта үтә нык рәнҗесәм дә хәзер бәхиллим, рәнҗемим... Юк, Булат, мине шушы палатадан куып чыгармасалар, рәхмәтлемен, шөкерана итеп ятам. Бу палата минем соңгы станциям. Алай да... Рәхмәт сиңа! Көтмәгән идем!

Булатның Шәүкәтнең туганы түгеллеген, гап-гади авылдашы икәнен белгәч, госпиталь хадимнәре ышанмадылар. Госпиталь башлыгы — юантык, йомыры бүксәле Моисей Израилевич аның кулын озак кысып торды: «Татарларда туганлык, яхшылык хисе көчле икәнен белә идем, мәгәр бу дәрәҗәгә җиткәнен күргән дә, ишеткән дә юк иде!» — диде.

Күндерделәр Шәүкәтне, бөтенесе җыелып, кат-кат үгетләп: «Әгәр анда яшәргә риза булмасаң, җайсыз тоелса, кире килерсең, борып чыгармабыз!» — дип вәгъдәләр бирделәр.

Шәүкәткә бер носилка җайладылар, вокзалга кадәр төшереп куйдылар һәм Яланга кадәр озата барырга бер кызыкайны беркеттеләр. Бу бер күзе сизелер-сизелмәс кенә чагыр булган сылукай Омск татары кызы икән, Шәүкәтне бик хөрмәтләп баккан, төннәрен дә янына кереп йөргән Мәрзия исемле әүлия иде. Хагы шул: әгәр Мәрзия булмаса, Шәүкәтне исән-аман, ватмый-нитми алып кайтып җиткерәчәк түгел икән Булат. Әйтергә генә ансат, ун көн дәвамында алып кайттылар алар Шәүкәтне туган төягенә. Булатның хәлсезләнеп, иреннәрен канатканчы кысып, югалып калган мизгелләрендә дә Мәрзиянең кәефе үзгәрмәде, ул һәрчак ачык чырайлы, тәмле телле, җитез һәм пакъ булып кала алды. Мең бәла белән азык-төлек таптылар, станцалардагы комендатураларның ишеге кай якка ачылганын өйрәнеп остарган Булат та чаяланды, аяк терәп ярдәм сорады, булышмасалар үгетләде, үгете дә үтмәгәч ачуланды, хәтта каргады да. Сугыш еллары адәмнәрне изеп, җаннарын тырышыптырышып карага буяса да, әле җирдә шәфкать-мәрхәмәт калган икән. Ай милләттәшләрнең булуы! Татар татарга барыбер якын шул! Инде өметләр чартлап өзелә дигәндә, Булат станцалардагы кеше кайнаган урыннарда: «Татарлар бармы монда? Якташлар бармы?» — дип татарча кычкырып йөрде. Табылды татар, ярдәмгә килеп җитте. Омскидан өенә кайтып җиткәнче Шәүкәт йөзләгән кешеләр кулы аша үтте...

Ун көн буе бергә, бер мәшәкатьләр сынавын кичереп, вакыт сыйдырганча үзара сөйләшеп, Шәүкәт бичараны кайгыртып кайта-кайта Булат белән Мәрзия якынайдылар, юлга чыгар алдыннан бер-берсенә шигәебрәк карасалар да шикләре күккә очты. Мәрзия шунда, Омскида туып үскән кыз икән. Әтиләре сугышта вафат булган, әнкәсе дүрт бала белән калган, иң зурысы шушы Мәрзия икән. «Әнкәй таза түгел, буыннары сызлау, эшләве заводта, төнге каравылда тора. Булган терәкләре мин!» — диде кыз. «Балаларны ташлап ерак юлга ничек чыгасы иттең алайса?» — диде, гаҗәпләнеп Булат. «Ә Шәүкәт абый? Аны миннән башка кем карасын! — диде Мәрзия һәм өстәп куйды:

— Без барыбыз да эшләп үстек. Сеңлем карый. Аңа да унбиш тулды инде.

Мәрзия берара сорап-белешеп алды:

— Сезнең җәмәгатегез бармы соң? — дип кызыксынды. Булат нигәдер икеләнеп торды, җавап бирәсе, хакны әйтәсе килмәде.

— Бар шул,— диде салкын гына.

— Сездәй ирне яратадыр инде, кадерлидер?.. Мондыен да шәфкатьле җаннарны кадерләргә кирәк! — Соңра Мәрзия шаяртып та куйды.—

Хатыныгыз булмаса, мин Омскига өйләнеп кайтмас идем. Шәүкәт абыйны карап калыр идем! — диде.

Мондый фикер, мондый уй Булатның әсәренгән башына да килеп киткән иде инде юлда. Станцаларның берсендә туктап поезд көткән арада, Булат белән Мәрзия Шәүкәтне юындырып алырга булдылар. Шунда Булат Мәрзиянең кулларының осталыгын, аның һәр хәрәкәтенең назын, иркәләвен карап торып сокланган, шаккаткан иде...

Шәүкәтне урнаштырырга Булат юлга чыкканчы ук урын хәстәрләгән иде. Йомыш-юлына йөртергә дә чиләгән, комганын әзерләп куйган иде. Шәүкәтне күтәреп торган ятакка — шул йомшак урынга кертеп салганчы Шәгъбикә беркавым ишегалдында йөреп торды, өйгә керергә, Шәүкәткә төбәп карарга курыкты. Булат та аны кыстамады, кер димәде. Мәрзия барында, әлегә Шәгъбикәнең керәге юк иде.

Шәгъбикә йортка нинди мәшәкать өстәлгәнен, алда бу гаиләне ни көткәнен аңлады. Аның шушы хәтле авыр уйлар чоңгылына тап булганы юк иде. Кая барырга? Кемгә зарланып дәшергә? Кире беткән ире Булатны ничекләр җиңәргә?.. Гобәйдә буйдакка барырга һич ярамый, анда барсаң, үзеннән-үзе аракы эчелә. Һәм ул барыр-бармас атлап, чирле кеше сыман аякларын сөйрәп, урам тузаныннан нидер эзләгән төсле Мәүлиха янына китте. Барды, керде, артсыз урындыкка җәелеп утырды, Мәүлихага карады, дәшмәде. Бераз көттереп кенә:

— Алып кайттылар,— диде.

Тынлык. Озакка сузылды бу авыр тынлык!

— Бер хатын да иярә килгән.

— Шәүкәткәме? — дип Мәүлиха атылып торды.

— Шуңа ияргәнме, озатып кына килгәнме, белмим.

— Ничегрәк соң? Шәүкәтне әйтәм.

— Синең янга килеп сыенган икән, чамала үзең! Карарлык түгел инде, куркыныч!

Мәүлиха җиңел сулады, Шәгъбикәдән башка уй көтмәсә дә, ул әзерәк шигәеп утыра иде. Мич тирәсендә мәрәкәләнеп, үзенә уен табып уйнап йөргән малай, борынын тартып килеп чыкты да, әнкәсенең итәгенә башын куйды.

— Әни, әллә атамны алып кайтканнармы? — дип сорады.

— Юк ла,— диде Мәүлиха улын читкә куып.

— Кайтканнар, кайтканнар,— диде бала үртәлеп.— Аны Рәхимҗан әкә миңа әллә кайчан әйтте инде. Син генә әйтмисең. Син атамны яратмыйсың.

Шәгъбикә белән Мәүлиха бер-берсенә караштылар.

Малай сыктаудан туктамады, тузанлы йодырыклары белән кайгы сарган күзләрен шатырдатып уды, күз яшьләре иягенә хәтле агып төште. Менә ул капылт кына сикереп торды һәм:

— Мин атам янына барам, мин аны яратам! — дип кычкыра-кычкыра чыгып йөгерде. Мәүлиха:

— Бар, ку аны, тот! Атасын күрсәтмә берүк! Болай да төннәрен саташып, куркынып уяна. Астына сия! — дип тезеп киткәч, Шәгъбикә дә итәген җыеп малай артыннан чыгып йөгерде. Шулай бер-берсен куалап урам буйлап йөгерешеп кайттылар. Үз йортында шактый чая күренгән малай, чит ишегалдына бәреп кергәч, юашланып калды, борын тишегенә имән бармагын тыгып, йөгерүдән кызарган, шактый калын Шәгъбикәгә карап җавап көтеп торды.

— Кермә, кайт! — диде аңа Шәгъбикә. Аннары малайны җитәкләп, җилтерәтеп өйгә барып керде. Керсә... исе китте: Мәрзия юл киемнәрен салып ташлаган, Шәгъбикәнең алъяпкычын бәйләп җибәргән, нәзек билен кыскан, имиләре калкып күтәрелгән. Ак яулыгы читеннән кара бөдрәләре сибелеп тора. Каян онын тапкандыр да, каян җаена төшенгәндер, чыжлатып төче коймак пешереп ята. Коймаклары түмтүгәрәк. Шәгъбикә кайтып кергәндә ул киң тәлинкәгә коймак чүмәләсе

өеп Шәүкәт янына килеп утырды һәм бичараны кулдан ашата башлады. Керүчеләргә иң әүвәл Булат игътибар итте, ул малайның башыннан сыйпап:

— Ә, килденме, балам,— диде.

Шәүкәтне мендәр-ястыклар арасына салганнар, кул төпләрен ак чүпрәк белән каплаганнар, аяклары юклыгы беленми дә диярлек Малай ишек катында торды-торды да җыларга кереште. Шулвакыт Шәүкәт күзеннән ике эре бөртек — борчак хәтле күз яше сыгылып чыкты.

— Кил, улым. Исәнме. Әйдә, сыйлан, коймак аша,— диде ул.— Менә Мәрзия апаң бик тәмле коймак пешергән.

Күрде Шәгъбикә, Мәрзия дигән кызның нәзек билен дә күрми калмады, буй-сынын кат-кат үлчәде, Булатның гашыйклар күзе белән сәфәрчесенә карап торуын да аңлады. Һәм беренче мәртәбә суыксып калтыранып алды: үз йортында ят иде ул бүген. Моңа кадәр ул Мәүлихадан гына көнләшә иде, ул елгыр хатын Булатын тартып алырдай тоела иде. Мәүлиханың юлына аркылы төшәрлек көче булганлыгына да ышана иде. Менә бу, керер-кермәс өйдә хуҗа булып алган сылу хатынны бөтенләй көтмәгән иде ул...

Шәгъбикә бер карады, ике, күзен Шәүкәттән алып читкә карарга тырышты. Кая караса да күзе ял итәр почмак калмаган иде аның үз өендә...

Коймакка карап тамагына су утырса да, малай атасына бик якын бармады, кырт кына борылды да чыгып китте. Шәүкәт күкрәк тавышы белән:

— Улым! — дип кычкырып калды.

Шәгъбикә малайны куып бармады, ул аны бу юлы күрмәде дә, аның күзе алдында хәзер өч кеше шәйләнә иде: салкын карашлы Булат, ике күзе дә мөлдерәп тирән чокырларга баткан Шәүкәт һәм бөдрә чәчле, ниндидер сихри яктылык сибеп йөргән Мәрзия...

Ул үзенең хәзерге мәлдә шулар арасына сыя алмаслыгын аңлады, дөп-дөресен әйткәндә, сыярга да теләмәде. Мәрзия китәр, алдыннан арты матуррак. Булатын да армиягә алырлар. Юкка гына өзмәс чакырып йөрмиләр ләбаса аны! Һәм шушы «самавыр», шушы адәм имгәге белән генә калып гомерен заяга уздырырмы?.. Нигәдер ул үзен Шәүкәтне мунчада юа дип күз алдына китерде... Кулы гарипнең нәзек җиренә тиеп китсә... Абау.

Һәм ул, бу юлы инде ашыгыч, нык адымнар белән Гөбәйбәләргә китте. Гөбәйбә буйдак ике дә уйлап тормады, аны кочагын җәеп каршылады.

## 25

Ерак та түгел өскә аварга әзер кедр урманнары җәелеп ятканда Ялан халкының, тирә-яктагы авылларның ачыгуына ышануы да кыен кебек. Әмма ул шулай булды, алдагы елларда чикләвек уңмады диярлек. Ходайның каргышы төштеме, әллә табигать үзе адәм балаларына үпкәләдеме, сугышка кадәрге елларда ишелеп уңыш биргән агачлар рәттән өч ел кысыр калдылар.

Әле шунысы бар, булган чикләвекне дә җыеп ала алмады Ялан халкы. Ир-атлар юк дәрәҗәсендә, ә хатын-кызлар урман ешлыгына карап алалар да: «Аллам сакласын»,— дип көрсенәләр. Урманда качкыннар ята. Җитмәсә, соңгы елларда бүреләр азынды. Алар кыш буе урман авызларына чыгып сузып-сузып улыйлар, җаннар өшеп китә. Иртәләрен аларның зур-зур эзләрен авыл башында да, фермалар тирәсендә дә күрәләр.

Бериш комсыз бәндәләр качкыннар, бүреләр турындагы куркыныч имеш-мимешләрне бик теләп үзләре үк тараталар. Халык әзрәк йөрсә,

урман хәзинәсе — чикләвек аларга мулрак эләгәчәк. Бар шундыйлар, алар чикләвекне ерак калаларга илтеп сата да күз күрмәгән, колак ишетмәгән мал җыеп кайта, дип сөйлиләр.

Чикләвек дип барып бүре өне тирәсенә юлыксаң?.. Әнекәй генәм!

Быел Чырык Абдрахманы да җанланды, Шәгъбикә белән Гөбәйбә буйдак та учларын бер-берсенә ышкыйлар, кич утырып капчык ямыйлар. Чикләвек өлгерә, чикләвек! Бара-бара Шәгъбикә белән Гөбәйбә теләкләренә ирештеләр, ничарадан-бичара, өйдәш булдылар. Булат хатынына өзеп әйтте:

— Сиңа бер сүзем юк, әмма син дә, мин дә Шәүкәтне Мәрзия кебек карый алмыйбыз, әлегә ул бездә кала,— диде.

Шәгъбикә:

— Ул калса, мин монда тормыйм! — дип пыр тузып чыгып киткән иде, әлегәчә кайтып кергәне юк. Мәрзия Омскига кайтып, эшенә үзе урынына сеңлесен урнаштырып килде. Ни әйтерсең, кыз җитез булып чыкты, колхоз эшенә дә чыга, авыл арасындагы өмәләргә беренче булып барып җитә, Шәгъбикәнең түшәмнәре каралган өен ялт иттереп юып чыкты.

Шәүкәт белән күрешергә Яланнан гына түгел, күрше-тирә авыллардан да килеп йөриләр, татар бәхетсезләр янына буш кул белән киләме?.. Кем бәрәңгесен китерә, кем бер янчык он кыстырган була. Аерата истәлекле вакыйга шул булды: Сәрвәр, Мәүлия, Миңнурый Шәүкәтне кул арбасына салып мәктәпкә, укучылар белән очрашырга алып бардылар. Шәүкәт башта карышса да соңрак ризалашты. Ул яткан килеш кенә фронтта күргәннәрен, фашистларның явызлыгын, үзе белән бергә булган татарларның батырлыгы хакында сөйләп балаларның һушын алды. Бу хәбәрне башта район гәҗитендә, азакта Төмән өлкә гәҗитендә дә бастырып чыгардылар. Гәҗитләргә Шәүкәтнең үзеннән бигрәк Мәрзия сөенде, ул Шәүкәтнең күз төбенә китереп:

— Менә күр, күр! Сине «Ил батыры» дип атаганнар. Сине хәзер бөтен өлкә, ил белә! — дип кабатлады.

— Эх, Мәрзия сеңел! Ичмасам сыңар кулны гына кайтарсыннар иде алар! Сул кулны гына. Әнә Булат, арба ясап бирәм, ди...

Булат, чыннан да, лапас астында нидер мәтәштерә, ап-ак итеп такталар юна, алачыкка төшеп тимер кисәкләре бөгә. Эзли, таба, мавыга.

Мәрзияне, аерата нык яраткан тагын ике кеше табылды Яланда. Аларның берсе Миңнурый булса, икенчесе нәни Фаягөл иде.

— Мәрзия апа, син минем әниемә охшагансың! — дип, Мәрзия апасының кочагына керә дә чума иде кызыкай. Мәрзиясе дә төче тел, ясап куйган, нинди генә тәмле-татлы сүзләр белән сыйламый Фаягөлне.

— Колыным минем, бәләкәчем! Ефәгем минем, карлыгачым! Кошчыгыбыз безнең, матурыбыз!..

Фаягөлгә шул гына кирәк тә, әнисе югалды, әтисе һаман лазареттан кайтып керә алмый, бала күңеленә шифалы яңгыр ул татлы сүзләр! Зарыккан бала андый йомшак, канатлы сүзләргә. Гыйззәтбану түти дә ярата Фаягөлне, ярата да Мәрзия апасы әйткән сүзләрне бөтенләй белми. Сәрвәр, Мәүлия, Миңнурый апалары да ярата кызны, ә Мәрзия апасы барыбер якынрак... Мәрзия апасы гарип кешене, Шәүкәт абыйны карый. Дөрес, Фаягөл Шәүкәт абыйсы янына ук барырга курка, ул бер читтәрәк Мәрзия апасының көлмәк итәгенә чолганып карап тора. Ә Мәрзия апасының көлмәгеннән тәмле исләр генә килә. «Син чәчәкме әллә, Мәрзия апам?» — дип сорый Фаягөл. Бу сорауны ишетеп калган Булат сөенә: «Чәчәк ул, чәчәк! Болындагы ак чәчәк!» — дип, Фаягөлнең сүзен хуплый.

Миңнурыйның мәшһүр сыеры да исән-сау, чиләкләп бирмәсә дә сөт бирми калмый, бозавы да күзгә күренеп исәеп килә. Фаягөл бозауга исем дә тапты, аны «Гөлем» дип атый. Сөтне бүлешеп ашыйлар, Шәүкәткә дә

өлеш чыга, Булатка да. Фаягөл бозауны яратып, муенына тасмалар тагып, колагына әллә нинди тәмле сүзләр әйтсә дә сөтне яратмый.

Булат башта читләтеп, аннары турыдан-туры, Мәрзияне яратуын белдерде, мәхәббәт тирәсендә сүзгә оста булмаса да, берчак:

— Алдагы тормышым Шәүкәт белән бәйләнгән, һәм мин ул алдагы тормышны синнән башка күз алдына да китермим,— диде. Мәрзия кыланмады, назландырып машатмады:

— Булат абый! Мин сине беренче күргәннән үк үз иттем. Мин сиңа сөенә-сөенә кияүгә чыгар идем, Шәүкәт абыйны бергәләп карар да идек. Мәгәр син өйләнгән кеше. Шәгъбикә апа усал, көннәрнең берендә кайтып керер дә безнең татулыкны пыр туздырып ташлар, дип куркам.

Көз якынлашты, кедр урманнарында быел мул чикләвек өлгерде. Аны җыеп, хәстәрләп киптереп, быелгы дәһшәтле кышка әз-мәз өмет салып керәсе иде. Фронтлардан көн саен диярлек яхшы хәбәрләр килә. Дошманны бөтен тарафларда куалар. Кайда йөри икән Ялан егетләре? Кайтыгыз, кайт! Исән-аман йөреп кайтыгыз да җирдә тереклекнең дәвамы итеп өйләнешегез!..

Урманнарга кереп карасаң, хәйран каласың! Һәрбер агачтан өч-дүрт капчык чикләвек җыеп алырга була. Һәрбер агачтан! Ә агачлар Иртеш тайгасында сансыз-исәпсез! Яман хәбәрләр дә ишетелә: ниндидер әрсез бәндәләр кедр чикләвегенең тулганын-тулышканын да көтмичә биек-биек агачларны балта чабып егалар да чикләвек күркәләрен ашык-пошык капчыкларга тутырып, хәзинәне олаулап-олаулап кайларгадыр алып китәләр!

Быел урманга барып керүләре үк рәхәт! Кай якка карасаң да каракучкыл куе яшел ылыслар арасыннан ботак очларында йодырык-йодырык зурлыгындагы йөзләрчә күркәләрнең тезелеп киткәнен күрәсең. Табигать гамәлләренә исең китәрлек: кошлар очлы томшыкларын батырып, тиеннәр ал тәпиләре арасына күркәләрне кыстырып тиз-тиз чүплиләр, кимерәләр. Варапкошлар һәм тиеннәр чикләвек-йодырыкларны читкәрәк алып китеп тә «сүтәләр», тиеннәр ризыкны кышка яшереп тә калдыралар, он илгәндә онны чәчмичә иләп булмаган кебек, таза, ядрә кебек тыгыз орлыклар төрле урыннарга төшеп калалар. Карыйсың, шушы ноктада берничә елдан соң кедр агачы, себер тайгаларының патшасы шытып чыга. Калка, үсә, бәрәкәтле, юмарт могҗизага әверелә.

Сезон ачылды, яхшы хәбәрләр яшен тизлеге белән ерак-еракларга таралды, урманнарга кеше агылды, алар җилдән, салкыннардан сакланырга куышлар, алачыклар корып шунда яттылар.

Дәүләтшә әкә туплап оештырып алып килгән Ялан кешеләре бер тирәдәрәк булырга тырышалар, янында авылдашыңның булганын тою рәхәт тә, куркынычсыз да. Кедр чикләвеген җыю — үзенә күрә бер бәйрәм дә ул! Карының тук, аша чикләвекне егылганчы!

Ялан кешеләре йодырык-күркәләрне нәни чүмәлә итеп кояш төшә торган алан читенә өеп куйдылар, ул күзләрне рәхәтләндереп балкып утыра. Дәүләтшә әкә өем янына килә дә, елмаюын сеңдерергә теләп мыекларын өзмәс сыпырып тора. Дәүләтшә әкә мыегына тотынган икән, эш пешә дигән сүз! «Шөкер, нихәтле ризык җыелды»,— дип кабатлый ач колхозның рәисе ач кешеләренә карап. Чикләвек туклыклы азык, егерме беренче елда да бик күп адәмнәрнең җанын саклап калган ул. Кай тарафлардадыр адәм балаларын саклап калган, олы һәлакәтләрдән коткарган затларга — этләргә, казларга, үсемлекләргә һәйкәлләр куялар, хәтта бакага да һәйкәл бар җирдә. Әгәр Төмән-Тубыл якларының рәхмәте итеп тарихта билге калдырырга уйласалар, әйдә, кедр чикләвегенә һәйкәл койсыннар. Бу бик хаклы гамәл булыр!

Өч елдан артык дәвам иткән сугыш тирә-як адәмнәрен тәмам бөлдерде, азык запаслары арасында чикләвекнең булмавы, аларның аңын томалады, яшәү рәвешләрен үзгәртте.

Быел эш башка, дәү-дәү кедр агачларына ялганып адәм балаларының өмете дә үсте, тармакланды. Әле язын гына күзгә чеби сыман йөргән ак чырайлы, җеп беләкле малайлар ике-өч көн эчендә күзгә күренеп үзгәрделәр, беләкләре ныгыды, унбиш-егерме метр биеклектәге агачларга үрмәләп менеп кенә китәләр. Әллә житез тиеннәрдән өлге алалар инде, шулардан өйрәнәләр? Ә тиеннәр быел — бихисап! Тиеннәр кайсы урманда чикләвек уңганлыгын әллә нинди кодрәт белән ишетәләр, йөзәр, меңәр чакрым араларны үтеп килеп җитәләр. Аларның отряд-отряд булып төйнәлеп күчеп килүләрен күрсәң, ул үзе бер тамаша. Тере елга булып ага җитез җәнлекләр.

Сәрвәр, Мәүлия, Миңнурый, Зиләләр монда, алар үзләренә өлкән класс укучыларын да ияртканнәр. Фаягөлне дә үзләреннән калдырмыйлар кызлар, кичләрен, Фаягөлне — җылы йомгакны — кочаклап йоклар өчен нәни генә бәхәсләр дә булып ала. Фаягөл матур йоклый, тыны тигез, апаларының муеннарын кочып ала да кузгатып та карамый. Кызлар житкән, аларның күптән бала сөяр, ир иркәләр чаклары, муеннарына сарылган нәни куллар да аларда әллә нинди хисләр уята.

Дәүләтшә әкә кичке учак яннарында, ай яктысында аларга гел бер сүзне әйтеп куя:

— Ну, кызлар! Сугыш бетәргә бара. Сугыш артыннан, гадәттә, бәхетле еллар килә. Сезнең бәхетегез үзегезгә ияреп йөри икән. Чикләвеге булгач, егете дә табылыр! Кайтырлар лачыннарыбыз! Күп калмады түзегез, янкәләрем.

— Әйткәнең килсен, авызыңа май, кадерле әткәбез.

Чәй эчәргә утырганда ипекәйне үбеп алу гадәте чыкты. Өч ел күргәннәре юк бит аларның чын икмәк йөзен. Өч ел! Юа, кычыткан, ләпәтәй, юкә яфрагы тутырып шырчай эчеп гомер иткән кешеләргә икмәк ашаудан да олырак бәхет бар микән? Быел, шөкер, Дәүләтшә әкә, шул җылап кына чәчкән кырлардан җыелган арыш уңышының нәни генә өлешен районнан килгән буржуйлардан яшереп алып калып, өй борынча кисәтеп чыкты да бөртекне бүлеп бирде. «Телегезне биктә тотыгыз, зинһар. Бала-чагаларга белдермәгез, үткән-сүткәнгә сиздермәгез, югыйсә, мине алып китеп атарлар, алган ризыгыгызны сыпырып алып чыгарлар!» — дип кисәтте.

Хәерле булсын, яши-яши Дәүләтшә әкә авыл арасында яхшы ат казанды, ил агасы булды. Менә бүген дә сылу кызлар, өметле киленчәкләр аның авызыннан нинди акыллы сүз чыгар икән, дип көтеп сагайдылар. Ил агасының авызыннан бары тик мәгънәле сүз чыгарга тиешлеген чамалый иде Дәүләтшә әкә!

— Кызлар, сезнең йөгенеч ястык турында ишеткәнегез бармы? — диде ул күзләрен хәйләкәр генә кысып.

— Син дә инде, Дәүләтшә әкә, гел әкә кызларга атап эндәшәсең.

— Сезнең арага керергә куркам, тереләй тотып ашарсыз! — дигән булды рәис, күзен һаман кызлар тирәсендә йөгертеп йөртеп. — Без яшь чагында яңа төшкән киленнәрнең башын йөгенеч ястыкка ике тапкыр орып алу гадәте булган. Килен төшкәч, кияве белән йокларга тиешле сәкегә, яшьләрнең аяк очына махсус әзерләнгән йөгенеч ястык салалар икән. «Сезгә, ата-анама, бер вакытта да тел тидермәм, гомер буе хезмәт итәрмен һәм хөрмәт күрсәтермен!» — дигәнне белдереп, иртән яшьләр татлы йокыдан торгач, сәкедә тезләнеп, шул ястыкка ике тапкыр рәттән баш орып ала торган булган. Аннан соң сер, вәгъдәләр сеңдергән теге истәлекле ястыкны киленгә бүләк иткәннәр. Ул аны йоклаганда баш астына куеп яткан һәм ястык гомер буе иренең атаанасына биргән антын исенә төшереп торган. Сугышның аргы очы күренә башлады, бәлки, кемдер сезгә атап йөгенеч ястыгын әзерли башлагандыр?

— Безнең телләр озын бит, Дәүләтшә әкә, — диештеләр кызлар, — аны йөгенеч ястык кына кыскарта алмас.

— Тел озынлыгының зыянын күрмим, мәгәр кулларыгыз җитез, күңелләрегез саф! — дип җорланды Дәүләтшә әкә. Кызлар янында аның мондый кыю сүзне ычкындыра алганы юк иде әле.

Кызлар тагын нидер өстәделәр, көлешеп алдылар, рәис аларга карап тагын сорау бирде, тиз генә кызлардан аерылып йокы белән кочаклашып ятасы килми иде аның.

— Ә картларга хөрмәт шулай да кирәктер бит?

— Анысы дөрес инде,— дип килеште кызлар.

— Дәүләтшә әкә, тагын берәр гыйбрәт сөйлә инде,— дип ялынды кызлары. Чикләвек белән сыйланып күңелләре күтәрелгән кызларның да тәмле сүзләрдән, җанлы әңгәмәдән аерыласы килми иде.

— Ярый, күңдердек дип санагыз...

Малайлар сүрелә башлаган учакка коры ылыс кисәкләре, ботак-сатак китереп салдылар, ут гөлт кабынды һәм сылу кызларның күзләрендә шаян очкыннар бии башлады.

— Шактый җор бер шәкерт, ә җор кеше хәйләкәр дә була ул, анысын беләсез, мәдрәсәне тәмамлап кайтып килешли бер авылда кунарга туктаган. Һәм йорт хуҗасына: «Син, агай мине таңнан уят инде!» — дигән. «Нигә таңнан, йокла рәхәтләнеп!» — дигән тегеңә хуҗа. «Мин гыйлемлекнең барчасын алып бетердем, инде йортыма ашыгам», — дигән шәкерт. Аксакал моны тыңлаган да: «Ай-һай, улым, бер фәнне өйрәнеп җитмәгәнсең икән шул, күренә», дигән. «Теләсәң ул гыйлемгә мин сине үзем өйрәтә алам»,— дип өстәгән. Егет уку җәһәтеннән бик комсыз икән, кызыксынган бит, «Белгеч барында белергә кирәк», дип бабайда торып калган.

Көн үткән, атна үткән, егет йорт арасында уралып йөри, ә бабай берни дә өйрәтми икән. «Бабай, мин ашыгам тизрәк укыт сабагыңны!» — дип аптырата башлаган шәкерт. Карт моңа гел бер төсле: «Сабыр ит, улым, сабыр ит!» — дип җавап кайтарган. Кайчан гына сорамасын, «Сабыр ит, егет!» — дип кабатлаган. Шулай ай үтә, ел уза. Шәкерт үз хәленә күнегеп, сабыр итә башлый. Көннәрдән бер көнне аксакал шәкертне үз янына дәшеп ала, «Инде, балам, укымышың тәмам җитте, кайтырга мөмкин» — ди. «Ничек?» дип гаҗәпләнә шәкерт. Карт төшендереп бирә: «Син минем янда торып төп тормыш сабагын алдың, сабыр итәргә өйрәндең. Сабыр төбе — сары алтын! Хәерле юл, балам. Әткә-әнкәңә сәлам күндер»,— дип, аксакал шәкертне озатып җибәрә, хәер-фатихасын бирә. Менә сезгә гыйбрәтле хикәят шул булыр.

Дәүләтшә әкәнең бу хикәятне юкка гына сөйләмәгәнен аңлаган кызлар тынып калалар, тагын да ныграк уйчанланалар. Әйе, бу авыр сугыш заманында сабырлык иң зур байлык, дип бер-берсенә баш кагалар. Сугыш еллары төрле төбәкләрдәге, шул төбәккә хас үзенчәлекләре булган ерак авылларны да байтак җәһәтләрдә бүтәнчә яшәргә, бүтәнчә уйларга өйрәтте. Халык үз тарихына, тарихы тудырган батырларга әйләнеп кайтты. Онытылып торган Күчем хан турындагы риваятьләр, бәетләр телләрдә яңарды. Урысның бөтен сугышларына чакырылган, урыс данын күтәреп төрле җирләрдә һәлак булган татар солдатларын догалы сүзләр белән яңача яд иттеләр. Ялан якларыннан Наполеонга каршы сугышка бик күп асыл ирләрне озатканнар. Арадан берәү, Миңнулла әкә, шул орышларның берендә вафат булган. Аңа багышлап авылдашлары «Миңнулла бәетен» чыгарганнар. Бу бәетне Ялан авылы кешеләре гасыр дәвамында телләрдән-телләргә күчереп тапшыра килгәннәр. Соңгы елларда аны авыл белән «онытып» торалар иде, бүген шунда, Күбек чикләвеге урманында, учак яктысында, учак жылысында Дәүләтшә әкәнең теле язылды. Ул әле аның көен дә белә икән. Соңгы сүзе итеп шул бәетне әйтте:

Наполеон әйтә икән, минем теләгем диеп,
Русиянең җир-сулары илгә бүләгем, диеп.
Әй, Наполеон, мәкерле җан, явыз икән теләгең:

Ятимнәрнең күз яшьләре — шулмы иләнә бүләгең?
Наполеонны кызыктыра Русиянең маллары,
Шул малларны алыр өчен басып керде яулары.
Наполеонга каршы китте безнең авыл Миңнулла,
Канлы көрәш кырларында ул газиз башын сала.
Миңнулланың балалары әткәләрен көтәләр,
«Кайтыр әле әткәбез!» — дип, ихлас өмет итәләр.
Әй, балалар, көтмәгез сез, әткәгез юк инде,
Русияне саклаганда ул корбан булган инде.

Башта бәетне әйтте, аннары көйләп бирде. Көйгә ияләнгәч, кызлар картка ияределәр, җырга кушылдылар. Зилә үзе янында һәрвакыт кәгазь-каләм йөртә, ул шунда учак уты яктысында бәетне язып та алды...

Чатырларга таралыштылар, Дәүләтшә әкә егет-малайларны барлап алачыкка кереп кунаклады. Учак янындагы әңгәмәләрдән шактый җанланган иде, озак кына йоклый алмыйча ятты.

* * *

Көндезен агач башыннан үсмернең шат тавышы ишетелде:

— Әй, Дәүләтшә әкә! Кызлар! Атлар килә, атлар!

Зарыгып көткән атларның килү хәбәре бер мәлгә Фаягөлнең юклыгын да оныттырып торды. Шунда уралып йөргән бала кая китсен. Менә атларның килеп җитүе шәп булган! Чикләвекне вакытында келәтләргә алып кайтып җиткерергә кирәк. Инде Әссәт тә агач башыннан төште, юл борылмасында атның дугасы, башы күренде, арба шыгырдады, күзләр шул якка төбәлделәр. Әссәт «Атлар!» дип урманны яңгыратса да, берәү генә булып чыкты һәм арбада бөтенләй ят, чит кешеләр утыра иде. Аты таныш, дилбегәсен тез өсләренә ташлаган Туктасын әкә дә Яланныкы. Иллә мәгәр аның янында утырган ят кешеләрне күргәч, чикләвек җыючылар нидер көтеп югалып калдылар. Туктасынның ясалма тавыш белән юри кычкырып биргән сәламен дә алмадылар.

Ат, «Күркәләр» чүмәләсе янына килеп җитәр-җитмәс туктады, тегеят адәмнәр икесе ике якка шома гына сикереп төштеләр һәм Дәүләтшә әкә каршысына килеп бастылар. Туктасын арбада утырып калды.

— Рәис синме? — дип сорады килүчеләрнең берсе, планшетыннан кәгазь кисәге чыгарып.

— Мин — Дәүләтшә әкә күзгә күренеп каушады.

— Без сине кулга алабыз. Менә ордер.

Җыелганнар ах иттеләр. Читтәрәк баскан, ваемсыз гына торган яшь-җилкенчәк «ордер» сүзен дә юньләп аңлап бетермәде, мәгәр Дәүләтшә әкә дә, Миңнурый да бу кыска сүзгә никадәрле бәхетсезлек сыйганын яхшы беләләр иде. Дәүләтшә әкә ык-мык торган арада, аның каршысына Миңнурый чыгып басты.

— Ни өчен? Аның ни гаебе бар? Яланның карап торган бер әүлиясен нигә алып китәсез?

Тегеләр ашардай булып Миңнурыйга карадылар да бер-берсеннән:

— Кем бу? Кем рөхсәте белән койрык күтәрә? — дип сораштылар.

Миңнурый кыю гына:

— Укытучы мин, Миңнурый...

Ордерны җилфердәтеп кулында тоткан кеше, ул килүчеләрнең башлыгы иде булса кирәк, усал карашын рәистән алып Миңнурыйга кадады.

— Ә сиңа нәрсә кирәк? — дип сорады.

— Беләсем килә. Нигә алып китәсез аны?

Ниһаять, Дәүләтшә әкә дә һушына килде, Миңнурыйның иңбашыннан сөеп:

— Бер-бер аңлашылмау килеп чыккандыр, кызым. Барырмын да әйләнеп тә кайтырмын.

Бүтәннәрнең дәшми-тынмый торуларына ачуы килгән Миңнурый укытучы кызларга карап:

— Бер гаепсез кешене күрәләтә биреп җибәрәбезме? — дип сорады. Кызлар сүз эзләп таба алмыйча гасабиланып авызларын да ачарга өлгермәделәр, теге ике кеше, Миңнурый белән әрепләшеп торуны файдасыз санап, рәисне арбага утырттылар да, үзләре арбаның ике ягына басып, олаучыга:

— Әйдә, кузгат! Киттек! — дип боердылар.

— Ә чикләвек? — дип кычкырды нәзек тавышлы Әссәт. — Аны кая куябыз?

— Балалар, — диде Дәүләтшә әкә, утырган җиреннән. — Шәт, мине авылга кайтаралардыр башта. Ул ягын үзем карармын. Сез борчылмагыз, бар да көйләнер. Күрмәгән баш түгел.

Килүчеләрнең башлыгы ат кузгалгач арбага ияреп ике-өч атлады да борылып килде. Миңнурый каршысына басып:

— Ә синең исемең таныш безгә, — диде. — Хәбәрләргә ышанмаган идем. Дәүләтшә әкәң янына утыртып сине дә алып китәсе булган. Телең бик озын икән, кыскартырга кирәк аны, кыскартырга! — дип янады.

Ат китте, арбадагылар да күздән югалды, безнең чикләвекчеләр ни кылырга, ни уйларга, ни әйтергә белә алмыйча, нәүмиз хәлдә, туплаудагы сарыклар кебек, сүзсез-өнсез бер ноктага җыелдылар. Шулчак Әссәт әлерәк кенә төшкән озын-озын кедр башыннан бер күркә очып төште дә аяк астында тәгәрәп китте. Шулчак Мәүлия:

— Фаягөл! — дип кычкырып җибәрде.

Әле аның әйткәнен аңлап, кабул итеп бетермәделәр. Күңеленнән теге явыз карашлы кеше белән бәхәсләшеп торган Миңнурый, уйлаганын кычкырып тышка чыгарды:

— Хәзер үк торага китәм, прокурорга керәм. Лапиковны күрәм. Әгәр Дәүләтшә әкәне йолып алмасаммы?..

— Ә Фаягөл? Фаягөл? — дип кабатлады Мәүлия.

Туплау кинәт таралды, малайлар: «Фаягөл! Фаягөл!» дип як-якка йөгерделәр. Ләкин урман җавап бирмәде. Урман да, яланлылар сыман, каушап телсез калган иде.

## 26

Фаягөл, күп нәрсәне аңлап бетермәсә дә, ятим калганлыгын сизенә иде. Аны үз араларына алган укытучы апалар бер чакта да телдән әйтмиләр, Фаягөлнең әти-әнисен искә алганда аларны исән итеп, саулар итеп сөйләшәләр. Бер Гыйззәтбану түти генә кызның җылы чәчләрен сыйпаганда ни өчендер яулык чите белән күзләрен сөртеп-сөртеп ала да: «И балакаем минем, моңлы кызым», — дип кабатлый. Фаягөлгә мондый минутларда ямансу була, җылыйсы килә, ә Миңнурый апасы аны җыламаска өйрәтә. «Күз яше белән күзнең нуры агып бетә», — ди ул.

Җыламый Фаягөл, әтисе госпитальдә ята, әнкәсенең эзе-тавышы юк, алай да кыз өметен өзми. «Әткәсе менә-менә кайтып житәргә тиеш!» — Монысын мөгаллимә апалар да шулай ди, Гыйззәтбану түти дә шул сүзләрне куәтләп юата.

Аерылганнарына байтак вакыт үткәндер шул, Фаягөл әти-әнисенең йөз-кыяфәтләре төсмерен оныта башлаганын да тоя. Фотоларына карап кына исенә төшерә ала. Гыйззәтбану түти аның фотолар ябыштырылган альбом өстенә иелеп уйланып утырганын күрсә: «И, балакаем, балам! Киткәннәренә күпме вакыт үтте, үзгәргән инде алар, күрсәң танымассың да!» — дип куя.

Быел яз анын күнеленә бер уй килде, җәйге каникулларга, иркенлеккә чыккан бу уе ныгыды. «Мин — ятим»,— диде көннәрдән бер көнне, альбомын тәрәзә төбенә куеп карап утырганда. «Мин ятим, атам да, анам да илгә кайтачак түгел».

Бу сүз бик таныш иде Фаягөлгә, сугыш елларында телгә кергән иң нык кулланышта булган сүзләрнең берсе иде ул. Авылның бик күп балалары белән анын арасында тигезлек куелды. Ятимлеген белгәч, шуны ачыклагач, Фаягөл йомылыбрак калды, урам уеннарына сирәгрәк чыкты. Уенга катнашсаң шаярасы була, көлергә кирәк анда, ә ятим балага артыгын көлергә дә, шаярырга да ярамый. «Гөнаһ була». Моны да ишеткәне бар Фаягөлнең.

Җәй әнә шулай, яңарак халәттә үтеп бара иде инде, тиздән мәктәпкә барасы булыр...

Күбек урманына чикләвеккә барабыз дигәч, иң нык сөенгән кеше Фаягөл булгандыр. Анын җаны бер урында торырга яратмый, ул каядыр тартыла, аны бу, күнегелгән урыныннан әз-мәзгә генә булса да ычкынып торасы, иркенәясе килә. Элек, бик бәләкәй чакларда ул тайгага әти-әнисе белән баргалый иде. Печән чапкан чаклар әле дә хәтердә. Йонтәс аю белән очрашканы бар кызның! Анысы да онытылмый. Печән теземнәре өстенә чәчелеп яткан, кояшта кызган кып-кызыл җиләкләр тәмле дә иде соң!..

Бу юлы ул Күбек чикләвеге урманына әти-әнисеннән башка гына килеп керде. Алар бу килүләрендә күбәү иделәр, мөгаллимәләр монда, классташлар, югары сыйныфларда укучылар. Әти-әнисеннән башка килгәч Фаягөл үзендә нииндидер моңарчы татылмаган иркенлекне тойды. Урман бүтән иде бүген, анын белән килүчеләр дә бүтән иде. Мәсәлән, Фаягөл моңарчы авыл урамнарында аягын артка сөйрәбрәк йөргән Дәүләтшә әкәнең бөтенләй үзгә кеше икәнен урманда гына күрә алды. Шук икән ул, җор икән ул, сөйли-сөйли дә көлдерә...

Бераз утырып торды Фаягөл. Уйларыннан аны бер сорау айнытып җибәрде. Тукта! Каян килеп керде соң әле ул бу аланчыкка? Кайсы яктан? Моннанмы? Әллә әнә теге биек-биек кедрлар уртасындагы каеннар арасыннан үттеләрме? Һәм Фаягөл «Әни!» дип кычкырганын абайламый да калды. Тик тынлык кочагына чумган урман кызның әрнеп кычкырган тавышын ишетмәде, ишетсә дә җавап бирмәде. Балалар бәхетсезлеккә тарыганда, якындамы ул, еракта мы, беренче итеп әнкәләренә дәшәләр. Әнкәсе җавап кайтармагач Фаягөл «Гыйззәтбану түти!» дип кычкырды. Аннан: «Мәүлия апа!», «Миңнурый апа!», «Сәрвәр апа!», «Зилә апа!» дип рәттән тезеп санап чыкты. Мөгаллимәсенең исемен атаган саен ул үз тирәсендә, аны тыгызлап урап алган зифа кедрларга карады. Кедрлар да эндәшмәделәр, алардан җавап ала алмагач, дәү агач кәүсәләре арасында тагын да бәләкәйрәк булып калган кыз үксеп, үрсәләнә-үрсәләнә җылый башлады һәм басып торган урында кала алмыйча торып йөгерде.

Кая барганына бәя бирмәде, уйламады, аңа хәзер барыбер иде, ул тик торырга тиеш түгел иде. Тик тора алмый иде.

Беркавым баргач Фаягөл арды, ботакларга абынып ике тапкыр мәтәлеп китте һәм чалкан барып төшеп күтәрелеп карады. Кояш баткан, агач очларына эленгән юка кара пәрдәләр әкерен генә тирбәләләр иде.

Агачларның тыгыз күләгәсендә ятып, көндезләрен дә әллә ни җылына алмаган җир кинәт салкынайды, кыз туңа башлады. Ул, корырак бер агач төбен сайлап алды да, утырып, як-ягындагы ылысларны, шиңгән үлән сабакларын ике куллап җыя, итәгенә тарта башлады. Инде ылыс дулкынына чумам дигәндә генә якында гына сәер кыштырдау ишетте. Күтәрелеп караса... анын әзер ятагыннан ерак та түгел аю шәүләсе селкенде. Артаякларына баскан да кызга ачуланып карап тора... Шул эңгер-меңгердә дә кыз аюның ачулы күзләрен күрде шикелле. Өстенә ябарга җыенган ылысларны, яфрак-үлән калдыкларын учына җыйды да аюга таба чәчеп ыргытып җибәрде. Кызга таба атлый башлаган тайга

хуҗасы әллә шушы сәер бураннан туктап шигәеп, тыелып калды. Ул арада Фаягөл сикереп торды да, агач араларыннан йөгерергә тотынды. Борылып карады, аю аның артыннан килә! Тагын чапты кыз, тагын егылды, куллары, тез башлары, бите сыдырылды. Җыламады кыз, куркудан узган иде.

Аюлардан куркырга кирәклеген Фаягөл бик яхшы белә иде, аю — ерткыч, көзләрен, тук чагында да урман хуҗасының, бары шуклык өчен генә гөмбә, җиләк-җимеш җыярга килгән хатын-кызларны тотып ботарлаганын ишеткәне бар иде кызның. «Куркырга кирәк алардан, сак булырга»,— дип сеңдерделәр. Ничек сакланырга, урман уртасында кая качарга кирәклеген әйткән кеше генә булмагандыр шул, югыйсә Фаягөл ул әмәлләрне хәзер исенә төшерер иде...

Байтак йөгерде шикелле Фаягөл. Аю беразга күздән югалып торды да тагын күренде. Тагын йөгерде Фаягөл, җан-фәрманга чапты. Су эчәсе килгәнгә чыдый алмыйча үлән сабакларын чәйнәде, аңкаулары яргаланып канады. Башта кедр чикләвекләрен туймас сымак ашаган иде, хәзер күрәсе дә килми аларны Фаягөлнең, кулына тотуга укшый башлый. Эх, пар атып торган кайнар бәрәңге булсын иде хәзер! Гыйззәтбану түти каз канаты белән майлап арыш кабартмаларын өеп китереп утыртсын иде. Башка чактагы кебек назланып, кыстатып утырмас иде Фаягөл, тау кадәр өеп китерсәләр дә бөтенесен сыпырып бетерер иде...

Фаягөл, кояштан кодрәтле әмер көткәндәй, күккә текәлеп баскан урынында әйләнгәләде, тик күк тә, җир дә, урманнар да өнсез иде. Шулчак кызның күзе сизелер-сизелмәс кенә салынган эз-сукмакка төште. Моңарчы күпме урман үтеп бер урында да кеше эзен күрмәгән иде кыз, ә бу чын сукмак, әнә, балта белән чабып каенның башын кыеп төшергәннәр, әнә ылыс келәме купшакланып калкынган. Ул сукмакны күздән югалтмаска тырышып йөгерә башлады. Бара-бара ап-ак сөяк өеме күзенә чалынды. Тукталып, курка-курка гына сөяк таучыгы янына килде. Дәү бер сөяктән мөгезләр чыгып тора иде. Сыер сөякләре! дип уйлады кыз һәм бер читтәрәк дәү генә учак урыны күрде. Учакны кеше якканлыгы мәгълүм иде кызга, ул сукмакны күзеннән югалтмаска тырышып тагын йөгерде. Эченә җылы керде. Тик сукмак та аны кара төнгә генә китереп җиткерде. Агач очларына эленгән моңсу ай урагы күренеп калды, тик Фаягөл аны күрмәде. Ул дымлы ылысларга төренеп арып-талып йокыга талган иде...

Сукмак аны үлән-камышлар белән капланган күлгә китереп җиткерде. Аяклары чыланганын да сизмәде кыз, туп-туры суга кереп китте. Су тезенә җитте дигәндә иелеп су эчәргә тотынды. Су шактый җылы һәм тонык иде. Ул күл уртасына шопырдап килеп кунган үрдәкләрне күреп сискәнеп китте. «Әни!»— дип кычкырып җибәрде. Үрдәкләр аңа карапкарап тордылар да, җан иясенең бала гына икәнен чамалап, үзара нидер сөйләшә-сөйләшә чума-калка йөзә башладылар. Фаягөл үрдәкләрне ачыграк күрергә теләп эчкәрәк атлады һәм ике аягының да сазга батып керүен абайламый да калды. Җылы, йомшак саз аны түбәнгәрәк суырды, су күкрәккә менеп житте. Хәлсезләнгән кыз терсәкләре белән суга таянырга теләде, хәле китте. Фаягөл тәүге тапкыр: «Үләм икән инде!»— дип уйлады. Артына борылып карады, яр да якында гына, әнә генә! Фаягөл үткән сукмак та моннан ап-ачык шәйләнә икән. Хәзер борыласы да... Карана торгач Фаягөл янында гына су өстендә йөзеп йөргән шактый юан таякны күреп алды, ике куллап шуңа ябышуы белән, таяк шартлап сынды, чергән, суда ятып муртайган икән. Ә саз һаман аска тарта, сөйри, әкрен-әкрен су муен тирәсенә үрмәли башлады. Астагы саз салкын, аяусыз салкын иде. Аякларны, балтырны куырып алды. Чарасыз калган кыз пырылдап очкан үрдәкләр артыннан күзен күтәрде һәм баш очына ук килеп җиткән каен ботагын күреп алды. Ботак шактый юан каеннан күл өстенә сузылган иде. Бер талпынды кыз, төпкәрәк китте, ике талпынды һәм бармак очларын белән ботакны эләктереп алды. Бер эләктергәч

ныграк ябышты, әкерен-әкерен саздан суырылып чыга башлады. Кыз күтәрелгән саен ботак иелде һәм аңа көч биреп өскә тартылды. Менә бу билдән түбән төште, тезләр дә ачылды һәм кыз соңгы көче белән ботакка ябышып ярга шуды. Үрдәкләр божра ясап әйләнделәр дә тагын шыбырдашып күл өстенә коелдылар. Кыз бу юлы аларга карап тормады инде, ярга чыгып ятты, күкрәк читлеген өзмәс каккан «чүкеч» тынганчы ятып торды. Инде ул моннан ары сак булыр, сазламыкларны урап үтәр.

Фаягөл аяк астында аунаган ботакларның берсен — юанын, тазарагын сайлап алды да шуны ике куллап кысып тотып күлне әйләнеп үтәргә булды. Бераз баргач аның күзенә төрле урыннарда аунап яткан ап-ак сөякләр, чәчелеп, өелеп яткан каз, тавык йоннары күренде. Шаккатып, куркып вә гаҗәпләнеп тамаша кылып торгач, аның күзләре җир астына таба төшкән чокырга, чокыр азагындагы ишеккә төште. Ишекне тышкы яктан күсәкләр белән ике җирдән терәткәннәр иде.

Фаягөл күсәкләрне алып ташлады, көч белән каерып ишекне ачты. Борынына тынчу ис, дым исе килеп бөркелде.

Фаягөл үзе дә белмәстән Бүре Рәхмәтулладан калган, озак вакытлар яшереп торган Миша Сорокинның күп санлы өннәренең берсенә юлыккан иде.

## 27

Инде госпитальгә аннан соң эләккәннәр әллә кайчан ташлап чыктылар, берәүләрне аннан-моннан ямаштырып яңадан фронтка «яраклы» дип таптылар. Икенчеләр сөенә-сөенә туган илләренә кайтып китте. Кергәннәрнең яртысы әнә шунда, еракта да түгел, агач хачлар, кызыл йолдыз сурәте кагылган такталар сибелгән тауЧыкта ятып калдылар. Мөхәммәт Уразаев һич котыла алмады шушы К. шәһәре читенә урнашкан эвакгоспитальдән. Ул күргән-белгәннәрне бүтәннәр алыштырды. Ул агымнан да берәү дә калмады кебек, ә ул ята да ята. Госпитальнең тере тарихына әйләнде Уразаев, врачлар, шәфкать туташлары гына түгел, аны ат караучылар, пешекчеләр, госпитальгә терәлеп диярлек торган урамда яшәүчеләр дә белеп бетерделәр. Фронтка да ярамый Мөхәммәт Уразаев әлегә, иленә дә кайтарып җибәрә алмыйлар, инде генә «төзәлде» дип нәтиҗә чыгарырга җыеналар да нәни генә салкын җил исеп китә дә үпкәсе тагын шешә, чәчрәп температурасы күтәрелә. Юлга җыенган, юл капчыгын төйнәп маташкан кешене тагын палатага кертеп яткыралар. Атна-ун көндә тагын аруланган кебек була Уразаев.

Үз аралай гына әйткәндә, госпиталь башлыгының да, баш врачның да Уразаев белән тиз генә хушлашасы да, аерыласы да килми иде. Чөнки аның кебек намуслы, карышусыз, эш сөяр адәм баласы дөньяда сирәк очрый һәм моны госпиталь хадимнәре белеп бетергәннәр иде инде.

Була, нәзберек, холыксыз яралылар була, алар ду килеп врачларны сүгеп ташлыйлар, шәфкать туташларын очыртып кына йөртәләр, янрындагы яралыларның да каннарына тоз сибәләр. Шундый чакларда Мөхәммәт Уразаевка ак халат кигертеп, дулап котырган шаулы яралы янына дәшеп кертәләр. Каян җаен китерәдер, нинди сүзләр белән сихерлидер, тәртә арасына керергә теләмәгән чыгымчы ирләрне дә Уразаев ипкә китерә. Әз генә терәлеп, яткан урыныннан кубып йөри башлауга, госпитальнең тагын үз кешесенә әйләнә Уразаев. Кухняга су ташый, утын яра, коридорларны юарга, ишегалларын аруландырырга булыша, эшләгән өчен хак сорамый, мактау көтеп тормый. Сукыр-бокырга хатларны ул яза, тәмәкечеләргә тартырга авыл кибетеннән ул ташый, аның мул, юмарт күңелендә һәркемгә җитәрлек юату сүзләре дә, җылы теләктәшлек тә бар.

һәр яраланган ир, гайрәтлеме, көчсезме ул, сабый балага әйләнә. Әнә шул, яра алганнан соң, гариплекне кичерүче сакаллы сабыйларның нәнкәсе дә иде Мөхәммәт Уразаев.

Дөресен әйткәндә, хәле шәптән дә түгел иде аның, үпкәсенең капризланып торуын һәммәсе дә беләләр, Уразаевны терелтер өчен күп тә кирәкми икән югыйсә! «Җылы диңгез ягасында: әйтик, Кырымда, Ялтада, яңа сауган сөт эчеп, кавын-карбыз, йөзем ашап ике-өч ай дәвалансa... йөгереп кенә китәсе икән дә бит!» Кырым кайда да, Уразаев кайда... Кырым дип кәҗәләнмәс иде әле, Уразаев, үз аягы белән Иртеш буйларына кайтып, кедр урманнарының куе, тыгыз һавасын сулый алса, күз ачып йомганчы тернәкләнеп китәр иде дә... Өмет шәме кабынып, яктырып яна гына башлый, тагын суык кагылып китә аңа, тагын егыла. Тагын температура...

Сугыш Европа-Азияне тетрәтте, халыклар кан дәрьясында йөзделәр, ачлыктан кырылдылар. Адәм балаларының язмыш җепләре өзелде, балалар аталарын, аталар балаларын югалттылар. Океаннан-океанга җәелгән сугыш кырларында кем кемне таба алмыйча гаҗиз булып тинтерәп яшәде.

Шулай да адәм ышанмаслык могҗизалар була икән.

Мөхәммәт Уразаев алдыннан яралыларның бөтен төрләре үтеп китте, аралашкан, якынайган кешеләре булды. Ул алардан мең кыйсса, мең әкият, мең тапкыр булган хәлләрне тыңлап яшәде. Атаклы ялганчыларны да бирелеп тыңлады ул, дөресен сөйләүчеләр белән дә уртак тел тапты, колакка ятмаган риваятьләргә дә түзем карады...

Ни хикмәттер, татарлар соңгы вакытта сирәгрәк очрый башлаган иде, бүген кергәннәр арасында татарлардан берәү булуын аңа госпиталь санитары, мари егете Кузьма хәбәр итте. «Синең якташың, сибиряк түгелме икән әле ул»,— диде мари.

Мөхәммәт минуты белән якташын эзләп китте, тапты, ләкин ул кергәндә иягең, яңакларын яңа кара сакал баскан татар йокыда иде әле. Аның сакалының куелыгын күргәч ул шикләнде: «Ай-һай, куе сакал Себер татарларында еш булмый»,— дип уйлады. Бер кердә татар яткан палатага Мөхәммәт, ике кердә, өченчесендә генә татар уянган иде. Җилкәсенә мендәрен бастырып куеп, ярым ятып тора икән. Күрештеләр. Татарча сөйләшә башладылар. Уразаев, үзенең кемлеген ачып бирсә дә, татар якынаерга ашыкмады, иплән кенә, кеп-кечкенә сораулар биреп, шактый тикшерде, төпченде. Мөхәммәт аның ни теләгәнен дә, сораулар биреп ни тикшергәнен дә белә алмады, бер нәрсә хак иде: татар сак, күпне күргән һәм шул күп күрүләре аркасында да шактый нык кыйналган җан иде.

Уразаев дөрес чамалады, үз янына килеп эләккән Сабирҗан атлы кара сакал, тәмугның җиде коесына төшеп, җидесеннән дә исән чыккан сирәк язмышлы бәндә иде. Әйе, бу — ул, Сания белән Бухенвальдта булып, аның һәлакәтенә шаһит булган сибиряк иде. Уразаев белән әз-мәз танышуга ук ул аның кемлеген, ягъни Саниянең ире булганын белде, ләкин ачылып китәргә ашыкмады. Ир-атның вафатына шаһит булып, ир-ат якыннарын очратса, ул ике дә уйлап тормас иде, белгән хәбәрләрен җайлап кына җиткерер дә иде. Монда сүз хатын-кыз үлеменә бәйле иде. Кайгылы хәбәрне Уразаевка җиткерергәме, юкмы дип бик озак баш ватты Сабирҗан, байтак икеләнде, шуннан соң гына ачылырга мәҗбүр булды.

Сабирҗанның төп хәбәре бер булса да берәгәйле булды, моңарчы яңадан сугышка барып керергә ашыкмаган, алдын-артын уйлап куйган Уразаев, Саниянең үлемен ишеткәч, сыгылып төшмәде, җыламады, бер минутта аның кодрәтле көч иясе буласы килде. Әкияти батыр булып, давылланып сугышка барып керәсе иде дә гитлерчыларны кырып-себереп саласы иде...

Сабирҗан әсирлектән ничек котылган, ничек үзебезнекеләр ягына чыга алган — болары Мөхәммәт Уразаев өчен сер булып калды. Беләсе

килде килүен, кара сакалның кылын тартып-тартып та карады, әмма Сабирҗан тораташ каткан сүзсез кыя иде, ачылмады. «Әгәр исән-аман илгә кайта калсак,— диде ул,— дөнья давыллары тынса, берәр заман очраша калсак, минем сиңа сөйләр сүзләрем күп. Әлегә ул сүзләргә мин хуҗа. Сүзләремнең телемнән ычкынып миңа хуҗа булып яшәүләрен теләмим. Авылда мине Хәмдиям көтә, балаларым көтә. Үз телемнең кайтыр юлыма аркылы яткан елан булуын теләмим! Җитәр, әче суны күп эчтем!»

Улы Шамилнең үкенечле үлеме хакында аңа Йосыф хәбәр итте.

Бу хәбәрне алуга, Мөхәммәт Уразаев госпитальдән чыгып ычкыну турында уйланды һәм шушы ниятен тормышка ашыру хәстәренә керешге. Элегрәк юри дә салкынга эләккән мәлләре булды аның, артыгын сакланмады да! Хәзер көне-төне үзен карады, ныклы тәртип белән яшәде һәм озакламый аңа өенә кайтырга да рөхсәт ителде.

Уразаев госпиталь начальнигы янына керде. Тәбәнәк кенә, юантык кына, төн ката преферанс уйнарга яратучы яһүд иде начальник. Мөхәммәтне бик ярата иде. Уразаевның өйгә түгел, бөтенләй кире якка, көнбатыш өлкәләренең берсенә барырга җыенуын, документларын: «Шунда бара!» дип үзгәртергә дигән үтенечен тыңлагач, доктор Гершензон гаҗәпләнеп кашларын югары күтәрде. «Нигә алай, кире якка, пророк?» дип сорады.

— Хатыным бар иде, аттылар. Улым бар иде, атканнар. Анда онытым калды, улым. Шуны барып күрмичә өйгә кайтып керәсем килми. Шул хәтле кайгыны җиңәрлек бер таяныч — оныгым кирәк иң миңа! Көнбатышка бару ансат булмас, шуңа күрә сезнең катка йөз суымны түгеп кердем. Юлларда, вокзалларда ярдәм итәрлек бер кәгазь бирегез миңа. Шул ук кәгазь белән оныгымны илгә алып кайтырлык та булсын.

Гершензон ярдәм итәргә яратучы, шул сыйфаты белән мактанып та җибәрә торган киң күңелле яһүд иде. Язды кәгазен, һәр адымда кулдан килгән ярдәмнәрен кызганмауларын үтенде һәм Мөхәммәтнең аркасыннан кагып: «Яһүдләр кайда да очрар сиңа, алар өйдә ята торган халык түгел, син шуларны эзләп табарга тырыш. Полковник Гершензон дисәң, белерләр. Белмәгәннәргә кәгазьне күрсәт».

Тәвәккәллек кирәк, тәвәккәлләп чыкса сукыр да юлны таба. «Егылмасам гына! Егылмаска!» — дип барды Мөхәммәт Уразаев, этсәләр түзде, түбәсенә кундырганнарның эченә типте, көненә бер тапкыр тамак туйдырды, төннәрен йокламады, көндезләрен аягүрә басып кына, кысылып черем иткән мәлләре булды. Әмма үз дигәненә ирешге, адресы белән Зосяны эзләп тапты. Түбәсенә ничәмә мәртәбә ут кунып көйдергән, алмагачлары сынып-таланып беткән бакча түрендә посып кына утырган бер тәрәзәле алачыкка барып кергәндә, өйдә бер яшь хатын белән өлкәнрәк апа агач тагаракта бәбәй юындыралар иде.

Йортта ир-ат юк иде. Зосяның бабасы әле бер ай элек кенә вафат булган икән. Шул бабай, изге карт, бала атасының истәлеге булсын дип, бәбәйгә Шамил дигән исем кушып киткән икән.

Уразаевның күңеле нечкәрде, ул Шамиленең Шамил исемле улын — юындырганнан соң тәмле исләре килеп торган төенчекне кулына алды һәм әле җаны ерак та китмәгән картка, Зосяның сөекле бабасына оҗмах түреннән урын бирүләрен ялварды. Күңеле нечкәргән иде Мөхәммәт Уразаевның...

Утырдылар, таныштылар, сөйләшеп сүзләре бетмәде, төн йокламадылар. Аз ризык белән күңелле табын ясадылар. Уразаев торган саен Зосяны ныграк яратты. Икенче көннең таңы ярылганда гына йокларга ниятләделәр. Мөхәммәт Уразаев шунда гына сәфәрнең максатын туптуры әйтеп салды. Хуҗалар, аналы-кызлы, гаҗәпләнмәделәр, сабыр гына тыңладылар. Югыйсә, Уразаев:

— Мин сезне алырга килдем,— дип әйтеп салган иде.

Тегесен уйлап, боларын исәпләп шактый баш ваттылар. Уразаев ордым-бәрдем кыланмады, чамасын белеп кенә үз фикерен нигезләргә тырышты. Тышка чыгарып салмаса да, күңелендә бер шик бар иде аның: Яланда аны нинди хәлләр көтә? Йорт тоткасы, Мөхлисә әби, дөнья куйды. Сания чит җирнең иң каһәрләнгән төрмәсендә ятып калды. Йортка, кызчыгы Фаягөл янына бәбәй ияртеп яшь килен белән кайтып төшәрсең. Һәр гаилә чатнаган, кителгән чак, киленне нинди йортка төшерә Уразаев?... Хәзер, мондагы нигезне тузгытып, күктәге торнага ышанып, әллә ниләр вәгъдә итәргә һич ярамый иде.

Зося төпле уйлы бала икән, Мөхәммәт моны тиз аңлады.

— Бабабыз сәламәт иде әле безнең, таза иде. «Йөз яшим әле мин!»— дип, саулыгы белән горурлана иде. Әнә шушы сугыш харап итте аны. Йорт калмады, ихата бетте, алмагачларны ботап-сындырып харап иттеләр. Агачларны кисеп учак итеп якканда ниләргә белмәде бабай, бәргәләнде. Чия агачларын рәттән төпләделәр. Бакча урынына күз көеге генә шыраеп калды. Улым Шамил тугач, берара тернәкләнеп йөри башлаган иде. «Умарталарымны тергезәм, улыбызга бал ашатырбыз!»— дия иде, юк, мантымады бабай. Кайгы-хәсрәт алып китте аны,— дип сөйләп бирде Зося.

Мөхәммәт Зосяның сүзен эләктереп алды:

— Күрәм, нигезегездә ир-ат юк... Малайны ир-ат дип санап булмый әлегә. Дөнья янган, тормыш таланган. Әле таянырлык ир кеше булса, тормыш үз чиратында әкеренләп рәтләнер иде. Әйе, мин сезне алырга дип кердем. Бала анасына тәрбия кирәк, ансыз малай чирләшкә булып, боегып үсәчәк. Җыенабыз да юлга чыгабыз,— диде.

— Сез, папочка, өчебезне дә ияртергә телисез мени?— дип сорады Зося.

— Аеры-чөере йөри торган заман түгел. Бергә төйнәлсәк, юлда да җайлырак булыр.

Хуҗалар — аналы-кызлы уйга калдылар.

— Юк, папа,— диде, ниһаять, Зося.— Йорт-нигезне бөтенләй ташлап китәргә ярамас. Мондагы тамырларны өзеп бетермик. Мин сезнең белән кайтырга риза, папочка. Ошаса, тормыш җайланса күз күрер. Мин башка кияүгә чыгарга җыенмыйм. Баламны чит ата кулына бирәсем килми.

Шулай килешенделәр: Мөхәммәт Зося белән Шамилне ияртеп алып китә, алар яңа урында яшәп, мондагы нужалардан, хәерчелектән котылып торалар. Күз күрер тагын, язмыш алдын күрсәтерме, артынмы, шуңа карап алдагы көннәрне билгеләрләр.

Уразаев оныгын кулыннан төшермәде, бала да аңа ияләшкәндәй булды.

## 28

Фаягөлне ике көн эзләделәр. Күбек чикләвеге тирәсендәге тайганы кишәрлекләргә бүлгәләп, аның карта-схемасын кәгазьгә төшергән булып, өчәр-дүртәр кеше төйнәлеп, таңнан кара төнгәчә эзләделәр. Кычкыра-кычкыра тамаклары карлыкты, тирә-юньдәге тавыштан Күбек чикләвеген тиеннәр ташлап качты, аюлар да колакларын торгызып тыңладылар да, балаларын ияртеп төньякка, тагын да тирәнрәк аулакка күчеп киттеләр. Кичке караңгыда, алдан билгеләнгән урынга җыелалар да күңелне тырный торган, сугыш заманының иң еш кулланган бер сүзен әйтәләр: «Юк.» Уңнан килгәннәрнең телендә дә шул, сулдан әлсерәп кайтучылар да шуны кабатлый, бүтәннәр дә. Эзләгән арада җыйган күркәләрне Яланга кайтарып келәт идәннәренә җәеп тараттылар. Буш амбарлар да калмады. Ул арада торадан боерык килеп

төште: «Дәүләткә фәлән кадәр чикләвек тапшырырга! Фәләненче числога тиклем план үтәлергә тиеш!»

Моңарчы җыелып, киләткә кайткан чикләвекне торадан килгән вәкил алдында үлчәделәр, ишеген бикләделәр, ачкычын һәм үлчәү исәбен вәкил алып китте, хәзинәнең күпме икәнлеген халыкка белдермәделәр дә. Ул «хәрби сер» итеп игълан ителде.

Дәүләтшә әкәне ике көн, ике төн көттеләр. Кайтмады. Җибәрмәделәр колхозның тугры рәисен, ил агасын. Чикләвекне каерып алырга килгән, өстәмә салым хәлләрен җиткергән вәкил, райкомның өченче секретаре Семенов, теш арасын казып, читкә карап: «Рәис тиешлесен алды. Ул район рөхсәтеннән башка колхоз амбарында арыш уңышын яшереп калдырган һәм шуны үзенең якыннарына төнлә-төнлә тараткан. Сугыш заманы законнарыннан чыгып, ул дәүләт милкен аерата зур күләмдә урлауда һәм таратуда гаепләнә»,— диде.

— Күпме булачак инде аның җәзасы?

— Атачаклар,— диде явыз тантана белән сөенеп Семенов.

Идарәгә җыелганнар чүгеп куйдылар...

Сәрвәр, Мәүлия, Зиләләр мәктәптә чакта бертигез күренәләр. Һәммәсе дә яшь мөгаллимәләр. Сәрвәр директор булып саналса да, аның иптәшләреннән аерылганы, үзенә аерым хөрмәт таләп иткәне юк. Киресенчә, ул кызларны үзенә якында гына тотарга тырыша һәм каяндыр сүзен дә уйлап чыгарды: «У нас коллективное руководство»,— диде ул, РОНО мөдире килгәч. Бу сүзе өчен аны мөдир аулакта нык кына «пешереп» тә алды.

Фаягөл югалган, Дәүләтшә әкәне Тубыл төрмәсенә илтеп япканнар.

Хикмәт шунда ки, кызлар һәммәсе дә Дәүләтшә әкә өчен дә кайгыралар, «ничегрәк йолып алырга соң ил агасын» дип баш ваталар. Шулай да аларның күңеленең дәү өлешен Фаягөл хәсрәте биләгән. Бигрәк тә Сәрвәр борчыла! Ата ягыннан бертуган булсалар да, Мәүлия дә ул кадәрле үк өзгәләнми. Сәрвәр — бик күп, бик тирән кайгы дәрьяларын кичкән җан шул, аның күңел кыллары соң дәрәҗәдә киерелгән, ул нәни генә хәсрәтне дә, кемнеке булуына карамастан кабул итә. Кайгыларның тау кадәрлеләре дә кечте кызның яшь башыннан! Әле соңгысыннан айнып бетеп, тәмам акылына килеп бетә алганы юк. Йосыфның матәм хаты килеп җитеп, Шамилнең ничек-ничек дөнья куйганы мәгълүм булганнан соң Сәрвәр атна-ун көн ут эченнән чыга алмады: янды, көйде. Кайгысы сүзләргә сыймаса да кызны нинди уйлар биләгәнен аңлау, бәгыренең өзелеп-өзелеп киткәнен чамалау читен түгел иде. Кызны Ташкәйдән килгән хатлар гына аяп калды дисәк тә хата булмас. Егет төрмә режимыннан, өметсез кара киләчәктән котылып сугышка барып керүенә чиксез шат иде. «Монда да режим! Штрафбат — майлы бутка ашау урыны түгел! Әмма бусы — миңа бәхет китерә торган режим, яманнардан яхшыны ясаучы режим,— дип язды Ташкәй куанып. Аның куанычы Сәрвәрнең авыр кайгысын җиңеләйтте, рух бирде, көчен-дәртен саклады. Кыз белән егет арасында хатлар еш-еш йөри башлады, каян вакытын, кәгазь-каләмен табадыр бу Ташкәй! Аның авызыннан шундый йомшак, шундый җылы вә кадерле сүзләр чыга аладыр дип беркемнең дә моңарчы уйлаганы булмагандыр! Хәзер Ташкәйдән озаграк хәбәр килми торса, Сәрвәр чыдамый, иртәме, кичме, Йомабикә абыстай катына барып җитә...

Кызлар мәктәптә тигез, мәктәптән тышкы тормыш дулкыннарында да тигез диярлек чайкалалар иде. Фаягөл югалып, рәисне алып киткәннән соң язмышлар ачыклык сорады һәм кызлар Миңнурыйның үзләреннән өстенлеген, җитлегүен күрделәр. Иленнән сөрелгән, бик яшьли үлемҗитемнәрне күргән, елга булып аккан күз яшьләрендә чак кына батып югалмаган, ачлыкны татыган, нужаны җилкәсенә асып интеккән Миңнурыйны моңарчы иптәш кызлары белеп тә, бәяләп тә бетермәгәннәр икән! Кыз күзгә нык күренеп торырлык дәрәҗәдә җитдиләнде, уй-ният-

ләре ачыкланды, сүзләре катыланды. Хәтта ки, усалланды дияргә була. «Сарыклар инде без, шунда урманда ук теге бәндәләрне бөтереп алырга иде! Әрәм итәчәкләр ил агасын. Зонада анда эш бар, карт, сырхау дип тормаслар, урман кисәргә җибәрерләр. Бер уч арыш тараткан, имеш. Үткән кышны халыкның ничек үткәргәнен күргән ул, уйланган. Быелгысының тагын да күбрәк нужа китерәчәген чамалаган. Ул әз-мәз арыш таратып авылдашларын алдагы нужаларга әзерләгән... Дәүләтшә әкә, зирәклек күрсәткән, колхозчыны саклап калуның чарасына керешкән. Ә без аны күрәләтә палачларга тоттырып җибәрдек».

Кызлар бүген кич, инде дөм караңгыда эш бүлешеп куйдылар. Миңнурый Тубылга бара, Дәүләтшә әкә белән күрешеп-сөйләшеп нишләргә кирәклеген киңәшеп кайта. Ә мондагы кызлар, үсмерләрне, олырак сыйныфта укучы малайларны җыеп эзләүне дәвам итәчәкләр. Сүз азагында кызлар Чырык Абдрахманы янына да кагылып чыктылар. Чырык кызларны сәерсенеп вә шигәеп каршылады...

Тәмле телле Мәүлия турыдан-туры йомышын әйтеп биргәч, җыерчыклар шакмаклаган нәзек муенын ышкып торды:

— Югалган кызның кайдалыгын әйтә алам, балалар,— диде.

— Урманны синнән дә шәп белүче юк дип сөйлиләр,— дигәч, Чырыкның кәефе бозылды.

— Кем сөйли? Гайбәт! Дөрес, яшьрәк чакта тайганы аркылыгабуйга гизә идек тә, хәзер ни... Мылтык юк, мылтыкны алып киттеләр...

— Син, Абдрахман әкә, сүзне мылтыкка борма, син Фаягөлне эзләшергә чык! Балаларны ияртеп шунда йөр,— диделәр кызлар бер авыздан.

— Бик барыр идем, бик! Изгелек кылып яман эшләремнең җәзасын җиңеләйтер идем. Юк шул, баралмыйм, сөяк-санакларым үтереп сызлый. Ходай сезләргә булышсын, ә мин өйдән торып сезгә дога кылырмын,— дип ыңгырашты хәйләкәр карт.

Миңнурый куе эңгер-меңгерне ертып юлга чыгып китте, туп-туры НКВДга кагылды, эш сәгатен иртә бетереп, начальниклары кайтып киткән булып чыкты. Миңнурыйга таныш апаларына барып кунарга туры килде. Танышларына баргач, өйгә керә алмыйча, капка төбендәге эскәмиягә утырып бер җылады. Ул өйгә кергәч тә күз яшен тыя алмады. Бар иде ич аның шушы йортта Ишморза Муллин белән очынып-очынып йөргән чаклары! Әгәр Ишморза исән булса, Миңнурыйны бу көннәргә төшермәс иде, шунда ук ярдәм кулын сузып килеп җитәр иде!..

Ул НКВД капкасы төбенә барып җиткәндә көн яктыра гына башлаган иде. Ул шул тирәдә, якында гына әрле-бирле йөреп торды. Калын, юнылмаган кытыршы такталар белән томаланган подвал тәрәзәләре яныннан терәлеп диярлек ничә мәртәбә үтеп китте. Эх, шунда, подвал почмагы тирәсендәге суык идәндә юка пинҗәгенә төренергә тырышып, бөкшәеп һәм моңаеп Дәүләтшә әкәнең утырганын белсә! Тәрәзә ярыгыннан черки булып үтеп керер иде.

«Начальник командировкада»,— диде аңа НКВД ишегеннән кергәч тә уңда, өстәл саклап утырган сары, сипкелле марҗа. «Кайчан кайта?» — дип сорады өметсезләнеп Миңнурый. Сары марҗа аңа гаҗәпләнеп һәм кимсетеп карады, аның бер күзеннән: «Син нәрсә, шаштыңмы әллә? Начальникның кайда булуын, кайчан кайтасын урамнан кергән һәр эткә әйтеп торам ди мин!» дигән мәгънә аңлашылса, икенчесеннән: «Шушы күлмәге таушалып, туфлясенең үкчәләре ашалып беткән татарканы да берәрсе яратып йөридер әле»,— дигән ишарәләр ага иде.

Кайсы ишеккә барып кагылырга белмичә коридорда ары-бире сугылып йөргәндә начальникның үзе — Лапиков килеп керде.

Кыз кыюланып аның каршысына килеп басуга, Лапиковның куе кашлары җыерылды, йөзе бозылды.

— Ә сезгә ни кирәк тагын? — дип сорады.

— Мине Ялан авылы колхозчылары җибәрде,— диде Миңнурый, сүзен башлаганчы ук өметен өзеп.

— Йә, ни йомыш?

— Мин рәисебез Дәүләтшә әкәне алып кайтырга да дип килдем. Лапиков көлемсерәде.

— Син үзеңне шундый кодрәт иясе дип беләсеңме?.. Председатель сугыш заманы законнарын бозып монда эләгә. Аны суд хөкем итәчәк! Трибунал!— Лапиков шулай диде дә үтеп китте.

Ул ишек артына кереп югалуга, сипкелле марҗа Миңнурыйны куа башлады:

— Гражданка! Җавап алдыгыз, монда озак буталмагыз! Барыгыз, бар.

Миңнурый йокысызлыктан авырткан башын кая куярга белмичә, буш йодырыкларын һавада селки-селки, әллә кемнәргә нәләт юллап, коры барып Ялан авылына буш кайтты. Кайтышлый ук Булат абыйсы янына кагылды. Бәлки ул бер-бер акыл бирер? Коткаруның бер-бер юлы калгандыр ич әле?! Бәлки, Төмәнгә үк барырга кирәктер? Әгәр Булат абыйсы, фронтовик: «Бар, Миңнурый!» — дия икән, ул иртәгә үк юлга чыгачак.

Ул өметсезлеккә уралып кайтты, Ялашда да аны күңелсезлек каршылады: Фаягөл табылмаган. Эзе юк әлегә бичара баланың...

Миңнурый күргән-ишеткәннәрен Булатка сөйләп кенә бетергән иде, почмактан, чаршау артыннан бер тавыш ишетелде. Шәүкәт тавышы иде бу.

— Мине тыңлагыз сез,— дип, Шәүкәт сүзгә катнашты.— Миннән башка эшегез барып чыкмас сезнең...

— Син ни әйтәсең инде? — дип сорады Булат, Шәүкәтне яшергән юка пәрдәне тартып.

— Иртәгә Тубылга мине алып барыгыз. НКВДга рәт тапмасак, райкомга керербез. Яхшымы-яманмы — коммунист ич әле мин! Җылы урын даулап, тәлинкә ялап кермәгән партиягә, каты сугыш башланыр алдыннан бирделәр миңа кызыл билетны. Дөрес, кайтуымны райкомда ишеткәннәрдер, учет карточкасы да әллә кайчан кайтып җиткәндер... Тик менә аптырап ятам: фронтта мин бик кирәк идем дә... хәзер яратып бетермиләр, шиңгән кишерләр! Бер очтан анысын да әйтеп кайтырмын. Миңа ни? Курыкмыйм!

Фронтовик, гарип, инвалидның чып-чыны Шәүкәтнең сүзендә бер акыл барлыгын Булат та, Миңнурый да тиз аңладылар. Тик менә ничек аны алып барып җиткерергә? Ат сорар идең, каян килсен ат!? Дәүләтшә әкә югында рәис булып калган Сәлимәне телефон аша көненә биш мәртәбә пешерәләр, ун тапкыр куыралар. Чыдасаң чыда! Чикләвек салымының күләмен әллә ничә кат арттырдылар. Ат хакында авыз ачарга да ярамый, эт итәрләр, виноват ясарлар.

Булат төне буе йокламады, ике тәгәрмәчле кул арбасын Шәүкәт ятырлык итеп көйләде, җайлады. Азык, су алдылар. Чирегә белән сөт күтәреп Миңнурый килеп җитте. «Бисмилла» әйтеп өйдән чыктылар, «Аллага тапшырып» кузгалдылар.

Алдан Булат белән Миңнурый бара, күчәре майланган арба җинел генә тәгәри, арба төбенә җәелгән коры печәнгә чалкан ятып, башын йомшак мендәргә салып Шәүкәт бара. Аның мондый хозурга күптән чыкканы юк. Булат әллә кайчаннан вәгъдә биреп килсә дә вакыт теткөзә алмады: Шәүкәтне Иртеш буйларына, Кыз Убасы тирәләренә алып бара алганы юк. Хәзер ул мендәрне текәрәк утыртуларын сорап утырып иярлек бара, булдыра алганча як-ягына карана, яшьли йөргән юл ормаларын, төбенә утырып ял иткән ялгыз агачларны күреп соклануын шыгып-ашыгып белдерә дә күз яшьләре килеп бөялгәч: «Эх-х!» — дип ер ярсып эндәшә.

Байтак юл киттеләр, Шәүкәт күз яшьләре сеңгән тавыш белән:

— Дускайлар, сез арбаның алдыннан түгел, артыннан, мине этеп барыгыз,— дип эндәште.

— Нигә, Шәүкәт абый?

— Минем сезне күреп барасым килә.

Тәртәләрне артка бордылар, хәзер Шәүкәт аларга карап, һәммәсен күреп, моңсулыгын белдермәскә тырышып, елмайгандай итеп бара. Тәгәрмәч кигиләре тузанга баткан, юл коры, арба артыннан нәни генә тузан болыты да сузылып кала.

— Кеше кыймылдарга тиеш шул, туганнар,— дип башлады Шәүкәт сүзен,— әгәр аның кул-аягы юк икән, теле булса да хәрәкәтләнсен. Мин бит, туганнар, хәзер төшемдә генә яшим. Төшләремдә мин үземне төзек, сәламәт итеп күрәм. Йөрим, йөгерәм, сикерәм, чумам... Төннәр буе төш күрәм, еш кына мәтәлчек атам, салам эскертеннән шуып төшәм. Малай чакта атыбыз бар иде, Йолдыз кашка, атнага бер Иртешкә шуны алып төшәм. Төшәм дә юам, коендырам, иркәлим... Көндезләрен дә йоклыйм йоклавын, бүтән эшем юк, иллә мәгәр көндезләрен төш керми миңа, ни гаҗәп! Хатын-кызлар да керә төшләремә...

Һәм Шәүкәт, заманында Ялан авылының иң сылу егете, иреннәрен кыса төшеп, әйтер сүзләрен интектереп кенә чыгара-чыгара бер җыр җырлады:

Иртән томан, кичен томан
Күпсенмәгез, күп тормам.
Җәйләр үтеп, көзләр житәр,
Сагынырсыз — мин булмам.

Юл үр менә башлады, монда арба авырайды. Миңнурый белән Булат бер-берсенә иңнәре тия-тия тарталар, тирләделәр.

— Эх, арбадан төшеп шушы үрне йөгереп менәсе иде лә! — дип куйды Шәүкәт.

Йә, әйтегез: мондый сүзләр ишеткәндә таза кеше ни әйтеп бахырны юатсын да, нинди фикерләр белән аның яшәү өметен ныгытсын?..

Барып җиттеләр, төн кундылар, иртәнчәк кул арбасын НКВД ишеге төбенә тартып китерделәр.

— Сез мине начальник катына кертегез дә үзегез чыгып торыгыз. Мин аның белән ялгыз очрашырга телим,— диде Шәүкәт. Аның көчле тартышка әзерләнгәнен Булат та, Миңнурый да аңлап алдылар.

Шәүкәт абыйсының фикерен Миңнурый да хуплады. Ул:

— Кыеп, инде сезгә каршы чыга башлыйлар икән, без ярдәмгә килеп житәрбез, ахыр чиктә дау күтәрербез,— диде. Булат көлемсерәп аңа карады:

— Алай да чаманы онытып җибәрмәбез! — дип куйды. Аның ни өчен шулай дип әйтүе аңлашылып та бетмәде.

Шәүкәтне җаймәгә салып, ике башыннан, дүрт почмагыннан тотып Лапиков бүлмәсенә керттеләр. Шакымыйча-нитмичә килеп кергән төркемне күреп Лапиков: «Кая? Кая керәсез сез?» — дип әтәчләнә башлаган иде. Шәүкәтне өстәлгә китереп салып, җаймәне чишеп җибәргәч, начальникның күзе акайды, тавышы сынып тоныкланды.

— Ашыкма, начальник, кабаланма,— диде Шәүкәт. Тавышына караганда ул да шактый каушаган иде. Әллә юл килгәнгә генә тамагы йомшадымы? Булат белән Миңнурый Шәүкәтне калдырып аллы-артлы чыгып киткәч, Лапиков ни әйтергә, ни кылырга белмичә шашынып калды. Аның мондый бичаралар хакында моңарчы ишеткәне дә юк иде сыман. Ә монда... мә сиңа! Эш өстәлендә кешенең чирек гәүдәсе ята. Бүген сәгать уңда ул участковыйларны җыеп киңәшмә уздырып алырга тиеш.

— Ни йомышыгыз бар миндә? — дип сорады ул, телен көч-хәл белән йомшартып.

Аларның ни сөйләшкәнен, Лапиковның каршы килгәнен, Шәүкәтнең шуннан соң котырып китүен сипкелле секретарь кыздан башка берәү дә ишетмәгәндер. Шәүкәт шул тиклем кычкырып начальникны өтә башлады, сипкелле кыз да чыдамады, итәген җыештырып ишегеннән читкә атылды. Аның артыннан ук диярлек ишегалдына Лапиков чыкты һәм Миннурыйның каршысына басып:

— Син котыртып алып килдеңме бу инвалидны? Нигә минем янга керттең аны? Яралы кешене шифаханәгә алып барырга иде. Мин больницага шалтыраттым, килеп хәзер үк алып китәрләр!..

Лапиков һәм секретарен шунда калдырып, Булат белән Миннурый атылып Шәүкәт янына керделәр.

— Мине бер минут та монда тотмагыз, райкомга алып китегез! — диде Шәүкәт әллә кай җирләрдән чыккан каты тавыш белән.

Бу юлы Шәүкәтне чабып диярлек, дөбердәтеп алып бардылар. Ул бәләкәй арбага җигелгән «чаптар»ларын:

— Тизрәк, җәһәтрәк! Кызган чакта чүкеп калыйк! Тизрәк, тизрәк! — дип каулады. Булатның аркасы манма су булды, күкрәге гыжлады. Райком капкасы төбендә байтак кына җигүле атлар тора иде, бүген бюро көне икән. Җаймәне дүрт почмагыннан тотып йөртергә өйрәнеп киләләр иде Булат белән Миннурый, Шәүкәтне эләктереп алдылар да бер тында икенче катның кара елтыр клеенка белән тышланган ишеге катына идәнгә китереп тә яткырдылар. Беренче секретарьның кабул итү бүлмәсендә яшьрәк кенә милиционер утыра икән, ул идәнгә яткан Шәүкәтнең гәүдәсен күреп әйтер сүзен дә әйтә алмады:

— Иптәшләр, иптәшләр, — дип ватык телефон сыман мыдыртап торды.

Шәүкәт:

— Беренче секретарь мондамы? — дип сорады.

Чирек гәүдәдән мондый таләпчән сорауны көтмәгән милиционер ыкы-мыкы килде. Әзрәк торгач, хәлләнеп:

— Иптәшләр, иптәшләр! Бүген бюро! Бүген бик җитди мәсьәләләр карала. Зинһар, бүтән көнне килегез. Менә иртәгә, юк берсекөнгә! Юк, юк, атна азагында шалтыратыгыз. Мин беренчедән белешеп куярмын, — дип бытылдады.

Булатның мондый зур урыннарга кергәч каушый торган гадәте бар, ул коелды да инде. Әле ярый Миннурый монда иде. Ул Шәүкәтне төргән җаймәне тарткалап:

— Бүгенге көндә иң олы мәсьәлә бер: секретарь аны кабул итәргә тиеш. Шулай диде дә Миннурый җаймәнең бер башына барып ябышты:

— Күтәр, Булат абый!

Әйтүләре булды, милиционер беренче секретарьның клеенка ишеген аркасы белән каплады. Миннурый аны очырып кына җибәрде, ишеккә аягы белән типте, ишек бу якка ачыла икән, Миннурый җаймәне теше белән кысып күтәреп, бушаган кулы белән ишекне үзенә тартты. Кемдер нидер кызып сөйли иде, бүлмә тәмәке төтене белән тыгызланган, алар да керде, телефон чылтырады. Кыска муенына өч-дүрт ияк элгән базык, юантык кеше, гимнастеркасын кысып буган киң каешын тарткалап трубкага үрелде һәм «Әйе», «Тыңлыйм», «Алаймы?» дигән сорауларны шактый койгач, телефонын куеп, керүчеләргә карады. Бюрога җыелганнар утырган урыннарыннан калкынып идәндәге җаймәдә яткан Шәүкәтне карадылар...

— Миңа, — диде беренче секретарь, — әле генә НКВДдан шалтыраттылар. Бу иптәшләр анда хулиганлык кылып, тарткалашып чыгып киткәннәр икән... Бюроны өзмибез. Фролов!

Ул кычкыруга, җыелганнар алдында милиционер пәйдә булды.

— Иптәшләрне моннан чыгарып тор. Карышсалар, конвой чакыр! Хәтта сугыш инвалидларына да бюроны өзәргә дигән сүз юк. Барыгыз!

Ул, сүзне беткәнгә санап, аркасын керүчеләргә куеп тәрәзәгә борылды. Шәүкәт, иреннәрен чәйнәп, авылдашларына эндәште:

— Сез... чыннан да, чыгыгыз! Сездән гаепләне ясый күрмәсеннәр. Ә мин... мин алар белән үзем сөйләшермен!

Булат белән Миңнурый карышып тормадылар, башта кабул итү бүлмәсенә чыкканнар иде, бүлмәдәге тавышларның монда да чыгып җитүен чамалап аска ук төшеп киттеләр һәм ишегалдына чыгып бастылар. Икенче катта күк күкри һәм аның дөбердәүләре монда да ишетелеп төшә иде. Ачу килүнең төрле-төрле формалары бар һәм һәр очракта да адәм баласының ачуын белдерергә байтак әгъзалары ярдәмгә килә. Дошманының танавы төбендә гайрәтле яшен яшьнәтергә йодырыгы бар аның, ачу уты чәчәргә күзләре бар! Ачу соңгы дәрәҗәгә җиткәндә вулканга әйләнә. Җиргә тибеп дошманының котын чыгарырга нык аяклар биргән Ходай бәндәләргә... Гомумән, сикереп куеп, иңнәрен уйнатып, үкчәләре белән тибәргә әзер булып адәм баласы гайрәтен төрледән-төрле ысуллар белән чәчә ала...

Бичара Шәүкәт НКВД бусагасы аша үтеп чыкканда ук дөрләп ут кабынган салам эскертенә әйләнгән иде. Эскерткә ут төшсәме? Аны сүндерер әмәл юк, андый эш бер Ходаның кулыннан килсә килер. НКВДдан райкомга кадәр араны «аргамаклар» юртып кына үтсә дә, салкынча җил Шәүкәткә кабынган утны сүндермәде, киресенчә аның дөрләвен генә көчәйтте.

«Бюро» дигәнне ул ишетмәде, мәгәр районның, тирә-юньнең баш кешесе катына барып кергәч, шактый кеше җыелганын һәм аларның инвалидны бик аптырап каршылауларын чамалады. Инде муенсыз секретарь аңа җилкәсен боргач, Шәүкәт күкрәгендә дөрләгән ут әллә нәрсәгә әверелде. Өч башлы дию пәриенең киң борын тишекләреннән атылган ут көлтәсе иде ул...

Шәүкәтнең ачуын белдерергә авызы белән теле генә калган иде. Ул бар нәфрәтен, ачуын, кимсенүләрен, гарьләнүләрен тавышына йөкләп кычкыра башлауга тәрәзә пыялалары зеңгелдәде, түшәмнән балчык коелды, идән такталары сыгылып-сыгылып алды...

Әгәр арадан бер кеше — К. авылыннан килеп бюрода катнашкан председатель Кәраметдин булмаса, белмим, бу ачыктан-ачык дошманлык, ызгыш-талаш, янау-куркытулар ни белән бетәр иде икән. Чөй өстенә тукмак, сүз сөйләшүдән талашка әйләнгән бу әңгәмә дөрләгәндә секретарьга ярдәмгә Лапиков та килеп җитте. Ул, Миңнурыйны урамда күрүгә бармагы белән янап:

— Синең белән сүз бетмәде! Нокта куелмады! Сагай! — дип кычкырып узды.

— Нигә сиңа бәйләнә бу эт? — дип сорады Булат.

— Курка ул миннән, күп белә дип курка! Шуңа бәйләнә,— диде җене чыгып Миңнурый.

Шәүкәт тиз генә бирешмәгән, кадакка чүкеч белән бәреп торып, тәки кадак кереп беткәнче гайрәтен күрсәткән: «Әгәр авылыбызның күрке, толларның, ятимнәрнең өмете булган ил агасы Дәүләтшә әкәне хәзердән азат итеп, бер гаебе дә юк дип Яланга кайтармасагыз, минем менә шушы яткан урынымнан кубачагым юк. Теләсә нишләтегез!» — дигән.

Уйламагыз! Райком секретаре, шушы гадел сүзләрдән соң, үз хатасын танып үзгәргәндер дип өметләнмәгез! Алар — ике башлык, ике үҗәт кәҗә тәкәләре — өстәл төеп парлап сайрадылар, хуҗаларына тәлинкә тотарга әзерләр бүлмәдә байтак иде. Куш кына, гарипне җәймәсенә төреп тә тормыйча баскычтан чыгарып атачаклар.

Ходай алдан ук һәммәсен күреп торган һәм шушы мәхшәр кубачак урынга Кәраметдинне ирештергән.

— Туктагыз әле,— диде ул, маңгаеның сул ягындагы зәңгәрсу җәрәхәт эзләрен кулъяулыгы белән сөртеп.— Ашыкмыйк. Ипкә килик. Глеб

Иванович, сез дә тынычланыгыз! Архип Федорович! Сез дәүләт эшлеклесе, депутат! Алай ярсып китү сезгә дә килешеп бетмәс.

— Тәкъдимең ни? Тәкъдимең? — дип парлап кычкырдылар НКВД башлыгы белән район хуҗасы.

— Дәүләтшә әкәне беләбез. Тырыш, итагатьле рәис. Инде бүтән юлы калмаган икән, әз-мәз игенне авыл арасына тараткандыр. Хәзерге көндә һәр колхозчы фронтовик ул! Ким дә түгел, аз да түгел — фронтовик. Дәүләтшә әкәнең гамәлен шулай аңлыйм мин, шулай гына кабул итәм дә. Тәкъдимем: хәзер үк рәисне азат итәргә, авылына кайтарырга, авылдашларын, бигрәк тә сугыш батырын тинтерәтеп йөртмәскә! — дип әйтеп салган Кәраметдин. Һәм иелеп Шәүкәтнең тирләгән маңгаен сөртеп алган... Берәү Кәрамны сак кына хуплаган, икенче берәү нык ук кушылган, тора-бара бюрога җыелганнар күмәк тавыш белән Дәүләтшә әкәгә «амнистия» сораганнар. Лапиков белән Архип Федорович та җүләрләр түгел, эш болай көтелмәгән якка киткәч, «Азат итәргә», дигән карарга килгәннәр. Кәраметдиннең яхшылыгы моның белән генә бетмәгән, Булаттан сорашып, Шәүкәтне бәләкәй арбага яткырып алып килүләрен белгәч:

— Дәүләтшә әкә белән икесен дә ат белән озаттырам,— дигән. И-и, ниләр генә әйтсәләр дә, татарда бар инде юмарт күңелле тәвәккәл егетләр!

Дәүләтшә әкәне НКВДга барып алдылар. Үзенең котылып чыгуына да ул кадәр гаҗәпләнмәде рәис, Шәүкәтне күргәч исе китте, җылап җибәрде.

— Ничекләр киләсе иттең син, бахыр?! Каян акылыңа килде бу? — дип йөз тапкыр кабатлады. Сакалы житкән, өс-башы таушалган, күңеле китек рәис, авылдашлары белән очрашкач, кайгыларыннан арынып, яшәреп, аруланып китте. Шәүкәтнең аягы булырга тиешле урынга, кабык арба төбенә җәелгән печәнгә дә менеп кунаклагач, аның шатлыгының чиге юк иде.

— Каян башыгызга килде бу, туганнар? Ничек Шәүкәтне алып киләсе иттегез? — дип әче күз яшьләрен түкте Дәүләтшә әкә.

Тубыл-Ялан юлына, җәяүлеләрнең тузанлы эзләре өстендә озын сызык сузып арба тәгәри. Арбада җәйрәп Шәүкәт ята. Аның хәлен сорашып борчымыйлар, ул юлдашларының ни уйлауларын болай да белә, һәм:

— Арганнар онытылды, Дәүләтшә әкә! Нәни генә җиңү дә җанга ял өсти, көч бирә икән, икмәктер! — дип әйтеп куя. Аның башы очына олаучы, курач кына үсмер утырган, артка йодырык булып йомарланган Дәүләтшә әкә сеңгән. Булат белән Миңнурый аруларын онытып, талуларын саннамыйча, гүләп сызлаган аякларының авырлыгын сизмәмешкә салышып арба үрәчәсенә ябышып кайталар.

— Ничек җиңә алдыгыз сез ул явыз секретарьны? Лапиковны ничек җиңә алдыгыз? — дип инде ничәнче кат сорагандыр Дәүләтшә әкә. Сорый да җавап көтеп тә тормастан соравын тагын бер кабатлый.

— Күрәм, дары кебек кабынырга әзер секретарь! Хәзер шартлап ярылачак! Шунда мин аңа балачакта ишеткән бер кыйссаны сөйләдем,— диде Шәүкәт.

— Кая, райком секретаре кадәр райком секретарен ипкә китерә алган кодрәтле кыйссаны без дә ишетик,— диде Миңнурый, чынлап ук кызыксынып.

— Болай булган... Урманда гамьсез генә кура җиләге ашап йөргәндә, дәү бер аюның түшенә һич көтмәгәндә әрлән сикереп кунган. Очлы, әрсез тешләрен аюның калын тиресенә батыра алмыйча яман ырылдый, талкына икән тегe! Аю карап-карап торган да селкеп җиргә төшергән моны һәм әйткән: «Аллаһе Тәгалә сине белеп гәүдәңне йодырык тиклем генә яраткан икән. Әгәр хаталанып минем гәүдә эләккән булса, син урмандагы бөтен җәнлекләрне буып, пыран-заран китереп чыккан булыр

иден»,— дигән. Менә син, секретарь, әле шушы бәләкәй генә төбәктә баш булып утырасың. Зыян-зарар салырга хәлеңнән килә килүен. Әгәр сине Төмәнгә яки Мәскәүгә үк күтәрсәләр, ай-һай-һай! Син әрсез әрлән кебек кыланып илне харап итәр идең!» — дидем. Һай, җене котырды секретарьның! Яраннары алдында әйттем бит!

Юлаучылар рәхәтләнеп шаркылдадылар, ат та күңеллерәк атлады, үзен әйдәп баручыларның күңел көрлеген ат та ярата, бахбайлар ул җәһәттән искиткеч сизгер җаннар.

«Дәүләтшә әкәне алып кайттылар! Дәүләтшә әкә кайтты!» — дип кычкырган Ялан малайлары янына тиз үк өлкәннәр дә чыгып җитте. Ат туктады, колакларын кайчыландырып, җыелган халыкка карады. Арбадан көч-хәл белән төшеп, оеган аякларын язарга теләп чүгәләгән рәисне апа-җиңгиләр кочаклап ук алдылар. Шуннан соң гына күзләр арбада тын гына яткан Шәүкәткә төште. Күпчелек аны беренче тапкыр күрә иде, сискәнделәр дә, сокландылар да. Каяндыр йөгерешеп мөгаллимә кызлар килеп җитте, алар сөенешеп Миңнурыйны зыр-зыр әйләнделәр.

— Сөенче! — дип сикергәләделәр.

— Сөенче, сөенче! — дип сикергәләде малайлар.

Шулчак Дәүләтшә әкә дә, Миңнурый белән Булат та, чак егылып китмәделәр: арба янына, классташ кызлары белән җитәкләшеп, Фаягөл якынлаша иде.

## 29

Тубыл тирәсе авыллары гөж килде! Әле аның гөже күчә-күчә яңарып, яңа елларга кадәр адәмнәр теленнән төшмәде. Имеш, Ялан авылыннан бер кыз бала тайгада адашып чак кына үлми калган икән. Инде бетте, югалды, урман ашады, сазлык йотты дигәндә авылның бер әүлия карты төш күрә. Төшендә аның янына Җәбраил фәрештә иңә. Һәм ул әүлия картны җитәкләп карурманга алып китә. Баралар болар, баралар, әллә нинди адәм үтмәслек чытырманлыкны аралыйлар, күлләрне кичәләр, бүтән чакта кош та кунарга базмаган сазлыклар да фәрештәнең аягы астында тирбәлеп-тирбәлеп кенә кала икән! Шуннан соң боларның каршысына бер иске йорт пәйда була. Ишегенә тай камыты хәтле алагаем зур йозак эленгән ди. Шунда фәрештә ак җөббәсенең кесәсеннән алтын ачкыч чыгара. Ул ачкыч каршысында ачылмый торган йозак юк икән, йозак шап итеп төшеп китә, ишек тә ачыла. Керсәләр... түрдәге ап-ак җәймәдә ап-ак күлмәк кигән әкияти бер кыз бала йоклап ята икән. Әйтә икән фәрештә әүлия картка: «Менә, күреп бак, исән-сау, алып кайтып тапшыр ияләренә!»

Яланның үзендә бу хакта бүтәнчәрәк сөйлиләр иде, хәбәр авылдан чыгып киткәч аның рәвеше шактый үзгәрде һәм көннәрдән бер көнне шушы вакыйганы яланлыларга әнә югарыда язылганчарак кайтарып җиткерделәр.

Асылда бу имеш-мимешләрнең нигезе хак, дөрес тә иде.

Көн эзләделәр Фаягөлне, иртә-кичләрен дә тик кенә ятмадылар, башта үзен, соңра ак сөякләрен күрә алсак та ярар иде дип тайгадан чыкмадылар. Тубылдан: «Чикләвек җыюны фәлән кадәргә арттырырга, фәләненче числога тапшырып бетерергә!» дигән күрсәтмә-янаулар тоташтан агылып торды. Алгарак китеп булса да әйтеп узыйк, шунсыз безнең язмаларда чишелмәгән бер мәсьәлә калыр: Дәүләтшә әкәне азат итеп, атка утыртып җибәргәч, райком секретаренең атна буе эче борды, ә НКВД начальнигы Глеб Ивановичның теше сызлады. Алар ике имза белән: «Халыкка законсыз таратылган икмәкне бөртегенә хәтле җыеп алып дәүләткә тапшырырга һәм сезгә элегрәк җиткерелгән чикләвек салымы планын өчләтә арттырырга боерыла. Сез әнә шул өчләтә арт-

тыруны күтәреп аласыз һәм, социалистик ярышка чакырып, район хезмәт ияләренә мөрәҗәгать кабул итәсез!» дигән катгый язуны җибәргәч кенә тынычландылар.

Бу боерык соңгы көннәрдәге Ялан авылын ураган тантаналы вакыйгалар арасында әллә ни колакны да ярмады шикелле: тапшырырга дигәч тапшырырга! Мөрәҗәгать белән чыгарга икән, әйдә, анысына да риза! Чукынып китсен!

Моңарчы Чырык Абдрахманның күрәзә икәнен белмәгән икән яланлылар!

Чыны шул: хикмәтле төш керде Чырыкка! Кабыклы яшь бәрәңге пешергән иде, аны бер табак чамасы төелә-төелә ашады да, рәттән биш чынаяк чәй эчте. Төнлә уянды, курка-курка гына ишегалдына чыгып нәни йомышын үтәде. Күтәрелеп күккә карады, башы очыннан үтеп барган өзек-өзек болытлар кош өере булып күренде. Аннан соң ашыгып-ашыгып өенә кердә дә иске юрганын башыннан ук бөркәнеп ятты. Башын мендәргә салуга йоклап та китте. Биек-биек бер йортта кемнедер эзли икән... Әйбәтләбрәк караса, чека йортында икән бит! Әнә, астан маңгай йолдызларын ялтыратып, бил кылычларын чыңлатып өч-дүрт кеше менеп киләләр. Ары тартыла Чырык, бире йолкына, һич качар, котылыр әмәл таба алмый. Текәлебрәк караса, бер тәрәзә шар ачык икән, шунда ташланды Чырык һәм тәрәзә янында гына үскән кәкере-бөкере каенны абайлады. Кәкере булса да буйга үскән, озын, бик озын! Йортка терәлгән каенга Чырык үрелгән иде — очын тотып та алды. Һәм каен кәүсәсенә күчеп аска карады... Һәм иплэп кенә шуып та төшә башлады. Бер бормага төшеп җитә, туктап асны тикшерә. Бормаларның саны-исәбе юк, алай да Чырык туктап тормады, кәүсәне кулыннан ычкындырмады. Тәки хафасыз-нисез шуып төште, җиргә басты һәм шунда үзен Рәхмәтулла алачыгында дип белде. Озын каен алачык янында үскән икән, имеш. Хәл җыярга дип алачыкка керсә... түр сәндерәдә бер кызчык йоклап ята... Яхшылабрак караса... бу кыз дигәннәре мөгаллим Мөхәммәт Уразаевның адашып югалган кызы Фаягөл, имеш... Таң йокысы сак була картларның, төше шушы урынга җиткәч, ул чәчрәп уянды һәм торып утырды, аркасын мендәргә терәп калкынды һәм озак кына уйлады. Күргән төше гаҗәпләндерде аны һәм ул төшен яхшыга юрады. Чекадан качып каен башына очып дигәндәй кунды... Һәм очы болытларга тигән биек-биек каеннан егылмыйча, имгәнмичә шуышып каты җиргә төшеп җитте!.. Котылды! Рәхмәтулла карунның алачыгы да юкка гына кермәгәндер! Җитмәсә, адашып югалган кызны шунда дип күрде...

Төше рас килер дип өзеп әйтә алмады Чырык, әмма ләкин мәзкүр төшнең асылы бик кызыктыргыч, бик тә серле иде!

Соңгы вакытларда Чырыкның абруе какшап, нужа баскан авыл арасында барлыгы да онытылып торган чак иде. Ир-атлар әз, карт-коры йөгәнгән, намаз-нияз кылып, сәхәбәләр тормышыннан бер-ике риваять сөйләп мажикларның исен китерә торган чак-заман түгел. Туйлар юк, үлем-китем булганда да исәп-хисап бик кечкенәдән бара, гүр сәдакасына бирелгән бер дистә күкәй белән сакал сыпырып куясың.

Ә Чырык авыл арасында бәләкәй генә таш кыя булып яшәргә күнеккән. Начар сөйлиләрме аның хакында, яхшы гамәлләрен искә алаларммы, аның өчен барыбер диярлек. «Мин Фаягөлнең кайдалыгын беләм, төшемдә фәрештә белән очраштым. Башымнан сөеп, сыйпап торды Җәбраил вә әйтте: «И-и, Алла колы Абдрахман! Син гомер-гомергә иманлы булдың, шуңа күрә Алла кушуы буенча бер изге хәбәр җиткерәм. Авылыгызның адашкан баласы Фаягөл исемле кызның кайдалыгын әйтәм. Тыңла: «Ул Бүре Рәхмәтулладан калган алачыкта, карурман эчендә!» Әгәр шушы хәбәрне чыгарсам? Кыз анда булырмы, юкмы, ахыр чиктә моның кыйммәте дә шулкадәр генә. Ә авыл арасында сүз таралачак! Очратканнар Абдрахман әкәләре алдында бөгелә-сыгыла сәлам бирәчәкләр... Әгәр шушы хәбәргә кушып тагын бер гайбәт өстәп җибәрсәм?»..

Абдрахманның юка башы уйлардан авырайды, зурайды...

Ятагында тик кенә ята алмыйча сикереп торды, иске кәвешен уңын сулга, сулын уңга киеп интекте. Юка күлмәге өстеннән сидерәгән төссез иске чапанын салып урамга чыгып китте. Бәхете, мөгаллимәләр үсмер балаларны ияртеп сәфәргә. Фаягөлне эзләргә китеп баралар икән... Каршыларына Чырык килеп чыгып, тып итеп алларына баскач, тегеләр туктальп калдылар. Тузган сирәк чәчләре өстенә майлы коймак кәләпүшен бастырып куйган, күлмәк изүе ачылган, чапаны төймәләнмәгән Чырык иртәнге сүрән яктылыкта әллә кайдан, тәмуггтан качып чыккан албастыны хәтерләтә иде.

— Эзләргә китеп барасызмы? — дип сорады ул баллы-майлы тавыш белән.

— Эзләргә калды инде,— диештеләр кызлар.

— Ә мин, Фаягөл исемле кызның исәнлеген дә, кайда булуын да беләм!

Кызларның Чырыкны күргәч үк шикләнүләре бермә-бер артты, алар: «Тешләргә, чәйнәкләшергә тотынмасын тагын бу карачкы»,— дип, Чырыкны урап үтеп бер урынгарак җыйналдылар.

Кызларның өркеп читкә кагылулары Чырыкның кәефен генә күтәрде, ул, кыяфәтенә серлелек өстәргә тырышып, сары тешләрен ыржайтып, авызын ерды, колакларын селкетте.

— Әйе, беләм, юлын да күрсәтә алам.

Эзли-эзли гаҗиз булган, инде өметләре суына башлаган кызлар картның соңгы сүзләрен элдереп алдылар:

— Соң алайса, алып бар безне, Абдрахман әкә!

— Үзең барып йөрмәсәң, юлын күрсәт! — диештеләр.

Чырыкның бик күп әкәмәтләрен, этлекләрен белгән Сәрвәр ышанмады, башын гына чайкады:

— Юри үрти ул безне! — дип кулын селкеде.

Бүген Чырыкны сүз белән ега торган көн түгел икән, ул җиңнәрен җилфердәтеп, кәвеше белән җиргә тибә-тибә:

— Аппарам дигәч, аппарам! — дип каурашты.— Менә хәзер өемә кереп, аны-моны хәстәрлим дә чыгам. Матри, мине көтегез!

Карт җилкенеп кереп китте, эзләргә баручылар төркеме икегә бүленде, сабыр гына барган кызлар ярсып бәхәсләшә башладылар... Берәүләр ышана, икенчеләр «юк сүз!» дип кул гына селти. Чырык өеннән нәни генә капчык асып, нидер күши-күши килеп чыкты.

— Еракмы без барасы җир? — дип сорады Сәрвәр.

— Шактый ара булыр. Бала-чаганы ияртмибез. Ат җигәсе иде дә, каян аласың аны? Әйдә, күңелем һәрвакыттагыча бары тик яхшылык кына тели, Алла ярдәме белән барып та җитәрбез, алып та кайтырбыз, боерган булса.

Карт ышанып, ышандырып сөйләде ки, икеләнгәннәр дә барыр юлга төштеләр, авылны чыгып, кабалана-кабалана урманга барып керделәр. Абдрахман әкәнең үзе салган сукмаклардан йөргән кебек ышанып, һич икеләнмичә терек-терек атлавы, бераз барган саен итәген кайтарып танавын сеңгереп куюлары, җилкә капчыгына китап салып чыгуы, сәер дә, гаҗәп тә иде. Иң мөһиме, аңа ышанасы килә сәфәрчеләрнең, эзләүчеләрнең күңелендә өмет уятты карт, шул өмет аларга туктап хәл алырга да рөхсәт бирмәде, бардылар да бардылар.

Абдрахманга таныш сукмаклар, таныш бормалар, таныш чокырлар иде бу тирәдә. Менә монда бер оя каз урлап алып кайтып суйганнар иде. Каурый-мамыкларын җил әле дә таратып бетермәгән! Симез каз ашап эче авырткан иде Чырыкның. Ел буена симез иткә карый алмыйча йөдәде карт. Хәзер менә салкын каз ите ашап бүксәне кашып утырасы иде. Әйдә, менә Чырыкка ирешкән төнге фараз гына раска чыксын! Ярты авылның казлары аңа ризык булыр! Күрәзәчеләр, багучылар заманы... Солдаткалар, толлар һәммәсе савылып аның катына йөри башлаячак! Барып

чыкмаса да ошбу спектакль аның данын күтәрәчәк. Шөһрәтен таратачак! Иншалла, алачыкны эзләп табарлар. Әнә теге каен чаукалыгында агарып поши башы ятып калды. Монда Березовка ягыннан урлап алып кайткан ике тайны кх иткәннәр иде.

Бу билгеләрне бары ул гына күрә, ул гына!

Кыз анда булмаса да, читенсенмәс Абдрахман. «Кыз монда булган!» — дип, үз сүзен сүз итәрлек дәлилләр табачак.

Юлдашларыннан берсе дә: «Абдрахман әкә, юлсыз урманнарда ничек шулай ышанып йөри аласың да, адәм күзенә чалынмаслык сукмакларны ничек күрәсең?» дип сорамады. Чырыкның моңа да җавабы әзер иде: «Фәрештәләр юл күрсәтә, балалар, барасы юлларымны да алар билгели!» — дип әйтәчәк иде.

Хикмәт-тамаша юл үткәндә булмаган икән әле, хикмәт җәйрап яткан күл кырын үтеп киткәч булды. Кызлар тиз-тиз генә бит-кулларын юып алдылар, «инде озак калмады, Аллага шөкер!» дип әйткәч, Абдрахман әкәләренең изгелегенә, әүлиялегенә ышанып бетә язып Бүре Рахматулладан калган алачык каршысына барып бастылар. Абдрахман Чырык ишекне ачты һәм кызлар берьюлы куркынып кычкырдылар. Алачык түрендә Фаягөл кызчык йоклап ята иде. Аны башта капшап карадылар: җылы! Тынын тыңладылар: сулый! Шуннан соң гына уяттылар. Кыз торып утырды, күзләрен уды һәм килүчеләрне күреп бер дә исе китмәде, әле йокысыннан айнып җитмәгән иде бала! Бераздан башланды ах-ухлар, тантаналы күрешүләр, кочаклашулар... Алачыкка тап булганчы ниләр булганын... Алачыкка тап булгач, Фаягөл үзенең күпме йоклаганын белми дә диярлек.

Ул:

— Кердем. Өй булгач куандым. Хуҗалары кайтыр дип уйладым. Күпме торсам да торам, хуҗаларны көтеп алам дип күнелемә ныгыттым. Төнлә аю килде. Якында гына йөрде, ишеккә якын килмәде, — дип әллә ничә кат сөйләп алды. Ятып сөйләгәндә Фаягөл җанлы гына кыланган иде, торып аягына баскач ул чайкалып китте, Сәрвәр апасына тотынды. Аны бу хәлендә үз аягы белән алып кайту турында уйларга да ярамый иде. Чырык та алҗыган иде, әмма тоташ мактаулар, хуплаулар, аның тапкырлыгына соклanулар аның күпне күргән башына баллы яңгыр булып яуды. Үз гомерендә шушы кадәр мактауны ишеткәне юк иде картның, ул сөенеченнән күз яше чыгармыйча гына җылап та алды.

Абдрахман Чырык әллә кай җирдән күгәргән балта табып чыгарды, беләк юанлыгы ике колга кисеп, иске бер җәймәне шулар арасына тарттырып бәйләделәр, Фаягөлгә носилка шул булды. Кызны алмаштилмәш күтәрергә булдылар.

Үзен тирә-якның әүлиясе дип игълан итәр өчен Фаягөлне эзләп табу гына җитмәячәген чамалый иде Абдрахман карт! Тагын бер гамәл кылып, изгелеген күрсәтеп өлгерәсе иде! Менә шуннан соң аның эшләре худка китәр иде. Таягы белән киң тайганы үлчи-үлчи кайтканда аның башына кыю гына бер фикер килде... Һәм ул, беренче форсат чыгуга ук, шуны сынап карарга булды.

Фаягөлнең никадәр вакыт югалып торып, янәдән исән-аман кайтуы авыл өчен тарихта күрелмәгән вакыйга булды.

Фаягөлне төн ката карап чыктылар. Уянып су сорагач, кайнар сөт бирделәр, таң алдыннан мунча өлгертеп, Мәүлия белән Сәрвәр алмаштилмәш чаптылар. Йомшак себерке Фаягөлнең тәнен рәхәт иркәләде. Зилә кызның аркасын йомшак мунчала белән сабынлап ышкыды, юды.

Кичкырын, үзегез белгәнчә, Дәүләтшә әкәне алып кайтып җиткерделәр. Бер-беренә ялганып киткән сөенечле хәлләр Ялан авылында күптән күренмәгән бәйрәм ясады. Һәм Чырык бу күңелле ыгы-зыгылардан, адәм балаларының уяулыгы кимегәннән файдаланып калырга, соңгы көннәрдәге вакыйгаларны үз файдасына борып җибәрергә уйлады. «Җә-

браил фәрештәне юлдашың итеп игълан иткәнсең икән, син аның исеме белән әллә ниләр кыла аласың, Абдрахман!» — диде ул үз-үзенә.

Дәүләтшә әкәне каршылау вакыйгасыннан да файдаланып калырга кирәк иде аңа!

Ул бер читтәрәк йөргән Мәүлиха янына барып басты. Каушаган хатынның күзләренә карады. Туры карады, туры карап Мәүлиханы каушатты. Чырыкка әнә шул гына кирәк иде дә!

Омскига барып ирен лазаретта калдырып кайткач та авыл нык ук гөжләгән иде. Атна-ун көн Мәүлиха урамга чыгарга, кеше күзенә күренергә кыймыйчарак та йөрде. Авыл — авыл инде, кая барасың да авылдашларыңнан башка башыңны кая бора аласың?.. Урамына да чыкты Мәүлиха, элеккечә артын уйнатып, түшен киереп йөри дә башлады. Авыл Шәүкәт белән булган хәлне онытмаса да телләрдән төшерде. Инде кайтып, Шәгъбикә белән еш-еш очрашып, колагы ишетә башлаган Булатның теле дә ачылганын белгәч, Мәүлиха ирен Омскида калдырып кайтуына сөенде. Кая ул, авыл арасында сасысы чыккан Шәгъбикә белән торамы соң аның яшьлек дусты Булат! Көннәрдән беркөнне барыбер Мәүлиха янына кайтачак әле ул. Шулай дип юатты күңелен Мәүлиха, шуңа ышанды, яман гамәлләрдән сагайды, күрше-тирәгә гел яхшылык, өзмәс эшләр кылырга ашкынды.

Каян, ничек Булатның башына ул тиле теләк килгәндер! «Булат Шәүкәтне барып алырга җыена икән»,— дигән хәбәрләр таралгач, ул бот чабып көлде дә кинәт башын кысып тотып тирән уйга калды. Әгәр дә бу хәбәр чын булып чыкса? Булат барып җитеп аның ирен алып кайтса?.. Мәүлиха йортына төшерерме ул аны, әллә башка берәр уе бармы?..

Булатның сәфәр чыгып китүен Мәүлихага көне-сәгате белән китереп җиткергәннәр иде. Иң читене Шәүкәтне авылга алып кайтып, Булатлар йортына кертеп салгач булды. Җитмәсә, бәла өстенә каза дигәндәй, аның аяксыз-кулсыз Шәүкәтен сылу бер татар кызы озата кайткан иде. Әнә шул кыз җан көеге булды да инде Мәүлиха өчен! Әле гарип-горәбә булса бер хәл, «аптыраганнан кодагый, иргә чыгасы юк, тагылып кайткан шунда бичарага!» дип юаныр идең, юк шул, кыз нәзек билле, сылу вә зифа иде. Урамнан үтеп барганда ир-ат кына түгел, хатын-кызлар да борылып карап калалар, «ай-һай!» дип тел шартлаталар... Шул бала, мәрхәмәтле вә шәфкатьле кыз, тегендә дә караган аның ирен, үз иткән, җитмәсә ияреп тә кайткан. Авыл арасында: «кыз Булат абыйсына гашыйк булган икән»,— дигән гайбәтләр дә йөрде. Бу хәбәр дә Мәүлиха файдасына түгел иде. Көннәрдән беркөнне дөньялар үзгәрер дә Булат аңа борылып кайтмый калмас, дип уйлый иде Мәүлиханың әрсез күңеле...

Фаягөлнең табылуы, Дәүләтшә әкәнең котылып кайтуы, алда әйткәнебезчә, зур бер бәйрәмгә әйләнде. Бәйрәмнең үзәгендә Чырык Абдрахман да, Фаягөл кызыкай да, ахыр чиктә Дәүләтшә әкә дә түгел иде. Көннең батыры булып аның Шәүкәте калды. Аяксыз-кулсыз гарип ерак юлга чыгып китеп, бик күпләр ишегенә кагарга да кыймаган НКВД, райкомнарга бәреп кереп, олы-олы начальникларны тез чүктереп, баш идереп, әллә нинди гамәлләр кыйратып кайткан лабаса! Хәзер, моннан соң, шушы кичтән соң бик озак вакытларга кадәр халык телендә аның Шәүкәте булачак. Сабан туе батырларын бер җәйдән икенче җәйгә кадәр телләрдән төшермиләр, мактап сөйлиләр, аларга атап җырлар чыгаралар. Ә аның ташлап калдырган ире Шәүкәт турында бәет чыкмас дисеңме? Шәүкәтне мактарлар, ә Мәүлиханы эттән алып эткә салырлар...

Ничекләр яшәрсең шул чагында?

Улы үсә һәм көн аралаш:

— Әйдә, әни, әтине алып кайтабыз,— дип җылый.— Малайлар мине үртиләр, әтиегезне урамга чыгарып ыргыткансыз сез, диләр.

Бүтәннәр дәшкәндә, башкалар тешләгәндә ырлашып җиңә алган Мәүлиха малае алдында көчсез, чөнки малай ни әйтсә дә дөресен әйтә...

Ул Чырык Абдрахманның күзләрен челт-челт йомып халык арасыннан кемнедер эзләвен тойды. Сизү әгъзалары соң дәрәҗәдә сагайган иде Мәүлиханың. Картның үзе янына килеп басканын да аңлады. Әйтер сүзе барлыгын да абайлады. Соңгы вакытта беркемнән дә ягымлы сүз ишетмәгән, колагы катылыктан саңгырауланган Мәүлиха йөгереп китәргә, качарга дип аягын атларга җыенган иде дә, урыныннан купмады... Соңыннан ул бу хәлне болайрак аңлатты: «Аяк табаннарымны ябыштырды да куйды Абдрахман әкә. Сүз дә әйтә алмыйм — телем аңкауга ябышты, авыз эчем эссе көндәге күлләвек кебек кипте, корыды. Кулым да селкенми, башымны да бора алмыйм, валлаһи! Илаһым дим, җанымны ал шушы минутта, коткар минек тәмуг җәзаларыннан дип ялварам. Юк, Чырык янымнан китми, караган да каткан. Ә күзләрендә әллә нинди утлар яна, чәчләре кыймылдый явызның. Иелде дә колагыма пышылдарга тотынды. Тыны — ут, сүзләре — таш, «Тыңла мине, и Алла колы Мәүлиха!» — диде. Тыңлыйм. Тыңламыйча кая барыйм. «Син, ди, бик зур языклысың! Сугыш корбаны тәрбияләүдән баш тартты синең гөнаһлы җаның!.. Сугыш корбаннары алар Ходайның күз уңында торган якыннары, ди. Бу языгыңны юар өчен бер генә юлы бар, ди. Ишетсен колагың: бер генә!» ди. Нинди юл ул дип тә сорамыйм, телем әйләнми, дер-дер калтырыйм. «Ирең Шәүкәтне үз йортына алып кайтып аның гомере азагына чаклы тәрбия кыласың, ди. Бу минем әмерем түгел, мин сиңа үземә тапшырылган Җәбраил фәрештәнең әмерен генә житкерәм», — ди...

Хикмәти Хода, Дәүләтшә әкә өенә кайтып китте, Фаягөлне Миңнурый житәкләде. Әнә Дәүләтшә әкәләрне кайтарган олау китеп тә бара, атның койрыгы гына җилдә җилферди. Тирә-юньдәге базар таралды, Мәүлиха белән Чырык урам уртасында икәүдән-икәү генә басып калдылар. Иң гаҗәбе шул булды ки, аларны беркем дә күрмәде, берәү дә атап эндәшмәде.

Бәләкәй арбага салып Шәүкәтне дә алып кайтып киттеләр. Булат белән Мәрзия елмаешып аңа ниләрдер әйттеләр. Ә Мәүлиханы күрмәделәр бугай, югыйсә кул арбасының бер тәгәрмәче аның башмагының башын таптап узды. Берзаман Мәүлиха исенә килеп Чырыкка караса, Абдрахманның эзе дә юк, Ялан авылы йортларының өстеннән, түбәннән генә бер койрыклы йолдыз очып үтеп бара.

Мәүлиха белгән догаларын кабатлый-кабатлый җан-фәрманга өенә чапты.

Төне буе йокламады бичара хатын, төн шактый салкын булса да манма тиргә батып яткан урынында боргаланды, чүмече-чүмече белән салкын су чөмерде. Күкрәгендә әллә нинди сызлау ялпалды, ул дымлы куллары белән имиләрен уып карады, чалкан ятты, әйләнде, тәненнән өзмәс тир акты. Тагын торып рәттән ике чүмеч су эчте. Башын бер уй тукыды: «Иртәгәдән сиңа тыныч яшәмәк юк, бел, моннан ары син авыл арасында тәмуг кисәве! Халыкның каргышы башыңа төшкәнче, иреңне алып кайт, тәрбиялә!»

Караңгылы-яктылыда ишек шакыганны өй эчендәгеләр берьюлы ишеттеләр. Иң әүвәл Шәүкәт бахыр ишетте. Булатны йә Мәрзияне уятырга дип җыенганда, Мәрзия үзе: «Ишектә кемдер бар!» — дип, Булатка эндәште. Булат барып оялды ишеген ачып җибәрсә, ишек борысына сөялеп тын гына Мәүлиха басып тора. «Юк, Булат, сине эзәрлекләп йөрмим, каушама, зинһар. Мин Шәүкәтне алып кайтырга дип килдем. Бар, сораш, белеш: кайтырга ризамы ул, юкмы?.. Риза икән, халык кузгалганчы озатыш. Теге кыз да барсын! Ничек, ничек багарга кирәклеген өйрәтсен. Кыз бераз бездә торып торса да ярый», — диде. Киенеп өлгергән Мәрзия дә ишеккә килеп житкән иде, ул Мәүлиханың соңгы сүзләрен ишетеп кычкырып ук җибәрде: «Барам, бармыйлармы соң? Шундый изге теләге булган кешегә булышмыйлармы соң?» — дип такмаклап диярлек жылап алды.

Ни өчен бар булган ир-атларның Мәрзиягә тартылуларын, аңа талпынуларын шунда гына аңлады Мәүлиха: тавышы матур икән кызның, һәр сүзе йөрәккә үтеп керерлек ягымлы икән!

Шәүкәт, чиста урында, тәрбиядә яшәсә дә, гомеренең азагы турында да уйлый иде, үткәннәренә түгел, алдагы тормышына барып-барып кайта иде. Бүгенгә ярый, Мәрзия дә янда, Булат та түзем, әмма ләкин гел-гел болай булып тормас ич! Шәүкәтнең чирләп авырып китүе дә ихтимал. Картлык килер, көч китәр, ул чакларда кемгә таяныр ул бичара?..

Борын очын тешләп өзүгә үкенгән вакытлары булса да, ул киләчәк тормышын Мәүлихага китереп җиткерә ала иде. Уртак балалары бар ич аларның, уллары! Менә кемдә Шәүкәт бичараның соңгы өмете! Соңгы куанычы әнә шул бала аның! Тик аның өчен бала ата янында, аның белән бергә үсәргә, атаны яратып өлгерергә тиеш. Ә баланың мәхәббәтен яулап алу җиңел түгел. Гарип ата белән бала арасы үзе бер табышмак ул!..

Шулай итеп, Мәүлиха да Булатның биек бусагасын атлап керде. Һәм менә өйдәгеләрнең өчесе дә көтеп торган сүзне әйтә алды...

Булатның куанычы бөтен түгел иде. Шәүкәт хатыны янына кайтып киткәч, Мәрзия нишләр? Шул сорау аны сагайтып, борчып тора иде.

Сораулар сорау белән, әмма ләкин тормышның һәркемгә кулай кануннары бар. Аларның берсе, беренчесе — шәфкатьлелек. Бүген Булат нигезендә шул гамәл берләштерә иде аларны.

Шәүкәтнең озын-озак җыенасы юк, инде сыналган кул арбасына мендәр юрганы артыннан үзе дә чыгып яткач, бер генә сүз әйтте ул:

— Азагы хәерле булсын, азагы!..

Мәрзия Мәүлихаларда атна чамасы яшәде. Шәүкәтне ничек юындырырга, ничек йомыш-юлларын үтәргә кирәклеген өйрәтте, ризыкның төрлесен ашатып күрсәтте. Мәүлиха аның хәрәкәтләрен кабатларга теләсә дә әллә ни бурттерә алмады, кашыгыннан шулпасы урынга түгелде, юынырга дип чишенгәч, иренең җәрәхәт эзләрен күреп, ирексездән күзләрен йомды.

— Мин шуның өчен ашыгып китеп бармадым, Мәүлиха апа,— диде Мәрзия, икәү генә ишегалдына чыккач,— аның җәрәхәтләренә күнегү кыен. Мин байтактан яралылар арасында! Җәллим мин аларны, җәллләгәнемне белдермәскә дә көчем җитә. Син дә белдермә!

Мәүлихалардан ул тагын да чибәрләнеп кайтып керде. Булат кызны дүрт күз белән көтә иде, кайткач өрмәгән җиргә дә утыртмады. Менә, Булат өендә, икәүдән икәү генә калдылар. Кара-каршы утырыштылар. Сүзләре тиз генә ялганмады, кыз да, Булат та бер-берсен түгел, үзүзләрен сыныйлар кебек иде.

— Булат абый! — дип башлады сүзен Мәрзия.— Син мине әйбәтләп кенә озат инде. Озак кунак булдым. Болай ук торырмын дип уйламаган идем, торылды. Мәшәкатьләр чиксез булса да зарланмыйм, мин шушы бәхетле мизгелне — Шәүкәт абый белән Мәүлиха апаның кавышуларын көттем. Беләсеңме, Булат абый, кичә аларның уллары нәрсә диде?..

— Нәрсә диде, Мәрзия җан?

— «Әти, башта мин синнән бик курка идем. Ә хәзер мин сине бик яратам! Әтиле булдым ич. Теге очта бер малай бар, бездән олырак инде, усал малай. Әтисе дә бар аның. Аны сугышка алмаганнар. Ә безнең беребезнең дә әтиебез юк иде. Тукмый малай безне! Бакчаларына алып керә, бездән бәрәңгеләрен утата!.. Хәзер менә тиеп кенә карасын! Син, әти, аның арт сабагын укытырсың бит?» Улы авызыннан шушы сүзләрне ишеткәч, Шәүкәт абыйның ничек куанганын белсәң син! Мин дә сөендем. Хәзер Шәүкәт абыйның гаиләсе бар: хатыны, улы үз янында. Инде миңа кайтып китсәм дә була...

Булат акылсыз ир түгел, Мәрзиянең тел төбендә әйтеп бетерелмәгән, үзе өчен бик кадерле ымнар барын сизә. Эх, хәзер аның күңеленә ачкыч яратып, юл салып, дөньядагы иң кадерле сүзләрне ишеттереп, уйларын

шушы Ялан ягына гына юнәлтәсе иде!... Булат сизә: хәзер иң кирәкле вакыт җитте, шушы кадерле мизгелдән файдаланып калса кала Булат, юк икән, Мәрзия китеп барачак. Булатның җибәрәсе килми Мәрзияне, шушы кыен вакытларда Шәүкәтне багып кыз үзенең күңел дәрьясының киңлеген, бөеклеген күрсәтеп өлгерде. Кемгә тәти тагын мондый хатын? Мәрзия белән булганда киләчәктә әллә ниләр көтсә дә куркыныч түгел. Яхшы хатын уртача ирне дә кеше итә, яхшы хатын иң ышанычлы терәк. Мәрзия шикелле кызлар йөз елга берәү генә туадыр...

— Йә, Булат абый. Мин синең сүзеңне көтәм. Ни уйлыйсың?

— Мәрзия кадерлем... Уем бер генә: ничек итеп сине куркытмыйча, өркетмичә төп сүземне әйтим икән, дип баш ватам.

— Әйт. Боргаланма, сыргалама, әйт тә бир, Булат абыем!

— Мәрзия! — дип эндәште дә Булат, тотлыкты. Әйтерсең бер сүз ярамас, ике сүз ычкындырырсың — бөтен эшне бозып куярсың.

— Әйтеп бетер, Булат абый.

— Китмә, кал минем янда. Гомерлек ярым бул.

Күтәрелеп бәрелмәде Мәрзия, җавап бирергә дә ашыкмады, аның йөзен тагын да матурлап, баетып нур йөгерде, күзеннән дөньяны яктыртып очкыннар чәчелде, ул җавабын әзерләп тирән генә көрсенеп тә алды.

— Ир-атларны беләм дип әйтмим, минем аралашкан ирләремнe үзең күрдең. Мәҗрүхләр, моңлылар иде алар. Миңа алардан «яратам» дип әйткән ир-ат булмады. Әтине дә ай күрде кояш алды. Без йортта, әни канаты астында ятим үстек. Якыннан белгән, төрле гамәлләр башкарганда күргән бердәнбер ир-ат моңарчы син булдың, Булат абый. Мин сиңа ышанам! Ни әйтсәң дә, әллә нинди тузга язмаган әкиятләр уйлап чыгарсаң да синең сүзең миңа акыл, гыйбрәт. Синең белән яшәгән хатын бик бәхетле булырга тиеш. Син ялгыз кеше булсаң, ике дә уйлап тормас идем, Булат абыем, хәзер үк муеныңа асылыныр идем. Әйе, әйе, син мине аңларсың, әле дә кулларым янып-кычытып тора...

— Соң, эш нидә? Әгәр син риза булсаң?..

— Юк, Булат абыем. Начармы-яхшымы, Шәгъбикә апа синең хатының. Син аның хаталыкларын гафу ит, түреңә алып кайт. Бергә-бергә яшәгез... Әгәр яши алмасагыз, соңгы чигенә җитсәң, хәбәр сал: шунда ук килеп җитәрмен.

Һәм Мәрзия беренче вә соңгы мәртәбә Булатны кочаклап алды, егет куенында эреде, әмма онытылмады. Иреннәр иреннәрне яндырып мәхәббәт очкыннары чыгаргач, ул житезләнеп аның кочагыннан чыкты...

Шул көнне үк Булат Мәрзияне юлга озатып калды.

Яхшылык бакчасында һәрвакыт шәфкать агачлары җимеш бирә. Яман чирләр генә түгел шәфкать-мәрхәмәт хисләре дә йогышлы була, тирә-якларда, күршеләрендә яхшылык күреп яшәгәндә яманнарның җаны да агара, арулана. Мәрзиянең кайтып китүе дә, Булатның аны калырга үгетләве дә, кызның китәр алдыннан Шәгъбикәгә күрсәткән изгелеге дә авыл арасына чыкмады түгел, бу хәбәрләр, гадәттәгечә, бераз үзгәртелеп, чак кына арттырып япа-ялгыз яшәп яткан Йомабикә абыстайның мүк үсә башлаган колагына барып ирештеләр. Бер яктан Чырык кылган изге гамәлләр, Мәүлиханың ирен үз йортына алып кайтып тәрбия итәргә тотынулары, Миңнурыйның, Булатның чаялыклары Йомабикә абыстайның йөрәген ярсытты, йокысын качырды.

Уйлады, төрлечә үлчәп, кисеп азапланды, уйлаган саен башы ыграк буталды, ахыр чиктә, бисмилласын әйтеп Гобәйбә буйдакларга китте. Барып керсә, йорт хуҗасы өйдә юк, тәрәзә пәрдәләре төшерелгән, Шәгъбикә бер башы, кырыйлары каткан агач бадьяннан төслә-төслә ботка ашап утыра. Күрештеләр, ары-бире сөйләштеләр, авыл хәбәрләре тирәсеннән йөгереп кенә уздылар. Йомабикә чәйдән баш тартты һәм Шәгъбикәгә якынрак күчеп утырып, ике-өч көн әзерләгән нотыгын башлады.

— Нинди чибәр пар идегез бит сез, Шәгъбикә! Булат белән урамнан узып китсәгез бөтен кешенең күзе кызыгып яна иде. Унган бит син, Шәгъбикә! Дөнья көтә ала торган булдыклы хатын. Авылда гына түгел, тирә-юньдә син бер генә. Гыйззәтбану түтине бәладән йолып алуыңны авыл бүген дә сөйли. И, мин кылган яхшылыкларны саный башласаң... Менә шул, буласы булган — буявы уңган. Интектермә Булатыңны, кайт янына. Гомерләр бик кыска, үтә дә китә. Булат ир итмәслек ир түгел, бергә яшәгез, син аның хаталарын оныт, ул да синнән гелән яхшылык күрә башласа, гөнаһларыңны ярлыкар. Бел — ирләрнең кадере арткан замана! Булатның базары төшкәне юк. Кайт өеңә.

Шәгъбикәнең әллә шушы сүзләрне ишетергә зарыккан идеме күңеле, аны әйтү кыен, аның Гобәйбә буйдак белән эч серләрен ачып сөйләшкәне булмады. Йомабикә абыстай авызыннан чыккан сүзләрне шешә кочаклап кына йокларга күнеккән Гобәйбә белми дә иде шикелле. Йомабикәне Шәгъбикә бүлдермәде, тыңлап бетерде дә җыена да башлады.

Шәгъбикәне Йомабикә өенә кадәр озата барды, үз кулы белән хатынын Булатка тапшырды. Хатынының бер әйләнеп кайтасын белә иде Булат, аны-моны әйтмәде. Ак димәде, кара димәде, алар ипләп кенә яши башлагандай иттеләр. Күрше-тирә бер нәрсәгә игътибар итте: Булат хатыны белән мунчага бергә барып йөрмәде...

Йомабикә Булатлардан туры гына өенә кайтмады, уйлаган эшләренең һәммәсен дә җиренә җиткереп бетермәгән иде әле.

Ул барып кергәндә Мәүлия мәктәптән кайтып җитмәгән иде, кызын сабырсызланып көтеп алды Йомабикә. Көтеп алды да аның ай-ваена карамыйча алып та кайтып китте.

— Сугышлар бетәр, аеры-чөере килеп йөри торган дәверләр артта калыр. Кавышу-күрешү заманы килер. Адашкан казлар сыман икебез дә ике читтә йөрмик әле. Фаягөл белән булам дисәң, үз йортыбызга ал, мин каршы түгел. Карармын, багармын. Мин синең анаң булудан туктадыммы әллә? Әнә, Ташкәй дә шуны яза: «Бергә торыгыз, мине бергә каршылагыз. Югыйсә, кешедән оят», — ди.

Мәүлия яшьле күзләрен сөртеп, әнкәсенең кочагына кереп киткәнен абайламый да калды.

Йосыф та нәкъ шушы сүзләрне язган иде аңа.

## 30

Иртеш дулкыннарын ярып килүче пароходны күргән Ялан халкы яр буена агылды. Сугыш чыкканнан бирле пароходлар бик сирәк сәлам бирә иде Ялан авылына. Бердән, бүген пароход килергә тиеш һәм шуңа утырып Ялан фронтовикларыннан берничә кешенең кайтуы көтелә!

Ир хатыны булган көннәреннән чордаш кызларыннан бераз читкә тартылган, ал белән ялны оныткан, нужа камытын киеп көне-төне эшләп, йөзен сары баскан, ияк асларына күгелҗем сырлар йөгергән Сәлимә дә бүген җанланган. Ул яшьлек дуслары янына еоактан ук кулларын болгаштырып килде, ябыклыгын, муен сырларын күрсәтмәс өчен кояшка арты белән басты. Әнкәсе янында күбәләктәй уйнаклаган кызы Гөлчәчәкнең күзе — карлыгачларда. Ярны чуарлап оя тишкән бу кошлар кешеләрдән куркып та тормыйлар, яр буена җыелганнарның колак төпләреннән выжлап очып узалар, канат очларының сызгырганы да ишетелеп кала. Кошлар хәрәкәттә! Кояштан күзләре чагылмый торгандыр шул, кояшка карап кинәт текә күтәрелеп китәләр дә, аска томырылып төшәләр, ярны эре шадралы бит кебек чуарлаган тишекләрнең берсенә кереп югалалар.

Сәлимә кызлар белән сүз дә алыша, ә күзе яр кырында ялгыз торып калган өянкене беренче тапкыр күргәндәй озаклап карап та тора. Язгы

ташкын сулар аның тамырын юып-юып шәрәләгәннәр, шуңамы аның оч ботаклары корый да башлаган. Түбәндәрәк куыш яралганга яр ыржаеп ярылып та киткән. Шатлыктан кәжә бәтиедәй сикергәләгән кызыен Сәлимә кулыннан тартып туктатты.

— Гөлчәчәк, ярның ярыгын күрмәденме? Якын йөрмә, җимерелеп төшмәсен. Барма анда!

Якынаеп ук килүче пароход палубасында яшел гимнастеркалар күренүгә, яр буена сибелгән каршылаучылар яулыкларын чишеп болгый башладылар. Төрле төстәге яулыклар җилфердәп болын чәчкәләренең җилдә бөгелеп-сыгылып тирбәлүләрен искә төшерде. Кемдер гармун сыздырып җибәрде, берәү ау мылтыгыннан атты. Бүгенгәчә мылтыгын кем саклады икән? Мылтыкларны НКВДга җыеп алдылар, урманнарда бандитлар күренә башлауга. Тубыл тирәсендә мылтык тотарга рөхсәт юк иде.

Пароходның борыны ярга терәлүгә, олысы-кечесе этешә-төртешә шунда ябырылды. Тар траптан чайкала-чайкала төшүчеләрне кочаклап алып китә тордылар. Һәркем үбә, коча, җылый, сораша.

— Исән-сау кайттыңмы?

— Безнекеләрне күрмәденме?

— Балам очрамадымы?

Туктасын әкә җавап бирү урынына җиргә егылды, йөзтүбән капланды, җир туфрагын үбәргә тотынды.

— Туган туфракка кайтып егылыр көннәр дә бар икән.

Аннан соң гына халыкны ерып үтеп сыңар кулы белән хатыны Өннәне кочагына алды, аның кар яуган, кар төсенә кергән чәчләрен үпте. Гөлчәчәк йөгереп килеп бабасының муенына сарылды. Сәлимәнең күз яшьләре дә елга булып акты, ул: «Әткәем, әткәем!» — дип кабатлады.

Туктасын күз яшьләрен ерак яшерергә өйрәнгән иде инде, кызының аркасыннан кагып, юатып:

— Бетеренмә, кызым. Кайтыр, насыйп булса, Маннур кияү дә кайтыр, — дип кабатлады.

Алинең хатыны тәбәнәк буйлы ирен култык астына кыстырды да, читләр каптырып китә күрмәсен дигәндәй, тизрәк кайтырга ашыктыра башлады. Әтиләре исән-сау пароходтан төшкән бала-чаганың түбәләре күккә тиде, әткәләренә ятсынып карауччылар да, бөтенләй танымаучылар да бар иде. Гөлчәчәк белән Фаягөлгә әлегә бәхет тәтемәде. Алар көткән кешеләр бу пароходта юк иделәр.

Туктасын әкә артыннан, култык таягына авырлыгын салып, уң аягы тездән өзелгән Сәмукъ чыга иде, абынды да егылып ук китте... Аны күргән Гөлсем әби әйтә куйды:

— Ә-ә-ә! Сәмукъ икән! Утызынчы елда безне раскулачивать итеп, сыерыбызны талап чыгып барганда мине тибеп еккан аягыны калдырып кайтып киләсең икән, гуй. Каргышым белеп төшкән икән. Балаларымны сөтсез калдырдың, икәвесе ачтан үлде, җаннары оҗмахта булсын бәбекәйләремнең. Күз яшьләремне Аллам күргән, сине җәзасыз калдырмаган!

Күкрәгендәге Ленин орденын ялтыратып, ике рәт итеп тезелгән медальләрен чыңлатып пароходтан иң соңгы кеше булып Айсетдин төште. Гимнастеркасы таза гәүдәсенә ятып-сыланып тора, хром итегенең куныычлары кояшта елык-ялык килә, маңгаена кызыл тасма беркетеп баш очына бөдрә бәрән бүрек чәпәгән, киеме, тотышы тирә-юньгә ямь биреп тора иде. Башта аны танымадылар, кулын каш өстенә куеп төшүчеләрне берәмтекләп күздән үткәреп торган Гыйззәтбану түти беренче булып төсмерләде.

— Бәрәкәт, укытучы Айсетдин түгелме соң бу? Кара син аны, кияү егете булып кайтып килә. Өч елдан артык хәбәрең булмый торды, кайларда сугышып йөрдең шулай озак? Ник хат язмадың?

Айсетдин рәхәтләнеп елмайды:

— Үлеп тérелдем диярлек. Партизаннарда булдым,— диде егет, каушавын белдермәскә тырышып.— Партизаннарда идем.

Теле тотлыкмады, әмма йөзе куырылып китте, куллары тирләде. Аның дымлы учын кысып күрешкән Гыйззәтбану түти дә аптырабрак калды. Бәлки әле кешенең бөтәеп бетмәгән яралары сызлыйдыр, ә мин җүләр юк-барны сорашып торам, дип эчтән үзен тиргәде. Шуннан соң гына Айсетдиннең күкрәгендәге тәрене төртеп күрсәтеп сорап бакты:

— Монысы нәмәстәкәй була инде, балам?

— Польша партизаннарының бүләге.

— Алай икән! Син фашистларны нык кырган, ахрысы, мондый бүләкне күргән юк иде.

Кызлар Айсетдинне урап алдылар, Айсетдиннең орден-медальләрен саный-саный телләрен шартлаттылар.

— Айсетдин абый, нинди герой булгансың син! Күз тимәсен! — диде үзенең кыюлыгыннан кызарынган Мәүлия.

— Тырыштык, сеңлем, тырыштык! — дип кабатлады кызлар боҗрасына эләккән Айсетдин. Ул Гыйззәтбану түтидән ятрәк ычкынырга маташты, ләкин түтәйнең суы саекмаган иде әле, ул Айсетдин барган шәпкә адымнарын ешайтты.

— Ашыкма әле, Айсетдин улым. Йосыфым турында сорашырга өлгермәдем. Аның да быел хәбәрләре аксап-туксап кына йөри... Сәгъдетдин әкәңне дә алдылар, карт дип, сырхау дип тормадылар. Трудармиядә генә булса да, бәлки, күзеңә чалынгандыр? Менә сине дә үлде дип язганнар иде, томтап торган егет булып кайткансың, сөбханалла.

Айсетдин юлына туры килгән таш кисәген алып Иртешкә ыргытты.

— Әнә шуның кебек югала инде адәм баласы. Кеше — тузан бөртеге ул. Әйттем ич, мин дошман тылында, партизаннар арасында сугыштым. Ялан кешеләрен түгел, якташлардан да берәүне дә очратмадым.

Гыйззәтбану түтинең төпченүеннән туйган Айсетдин кызлар арасына кереп шылырга ашыкты. Ачуы кабарган түти мөгаллимнең дорфалыгын, үзен саннамавын бер дә кичермәде, әйтәсе сүзен Айсетдиннең артыннан кычкырып калды:

— Юк, минекеләр тузан бөртеге дә, суга төшеп югала торган таш та түгел. Аллаһы боерса, һәммәсе дә кайтырлар. Мөхәммәт тә кайтып керер, менә күрерсең.— Гыйззәтбану түти Фаягөлне үзенә табарак тартты да баш түбәсеннән үбеп алды.— Кайтырлар, кызым, әниең дә кайтыр!

Өч-дүрт кенә бөртек ир-ат кайтса да, авылның рәвеше үзгәрде, аңа төс кунды. Эшкә сусап кайткан солдатлар, сыңар куллысы да, аксагы да ясканып эшкә тотындылар. Сука башына, чабагач сабына ябыштылар. Сәлимәнең генә сәламәтлеге начарая барды. «Яраландым. Госпитальдә, Ковров каласында ятам»,— дип язгач, ул Маннурын шушы араларда нык көтә иде. Ире кайтып җитмәгәч, аны көтелмәгән кара кайгы басты. Сәлимә мае беткән шәмдәй көннән көнгә күзгә күренеп сүнә бара иде. Врачлардан юнәткән даруның да файдасы тимәде, багучылар, им-томчылар да яшь хатынга булыша алмадылар. Кан төкерүен ул әнисенә дә сиздермәде. Әтисе белән әнисенең очрашу шатлыгына күләгә төшерәсе килмәде. Сорасалар: «Хәлем әйбәт, бик әйбәт!» — дип кенә җавап бирде. Әмма ана йөрәге сизми каламы соң? Сәлимәнең тамагын аерып куйдылар, аны сөт-майдан өзмәскә тырыштылар. Үзләренең авызларыннан өзеп булса да бар булган ару ризыкны аңа гына тоттылар. Белгән им-томнар — берсе дә калмады, ырымын ырымга туры китерделәр, хәттә кәҗә сөтен дә юнәтеп эчерттеләр. Сәлимәнең чире турында йортта сөйләшмәсәләр дә, бөтен борчылулары, мәшәкатьләре ул булды. Беркөн аргы йортларның берсеннән кәҗә сөтен алып кайтканда Өннә әбинең күзе томаланып, башы чатнап китте, ул аны яманга юрады. Чыннан да, Сәлимә аны яңа сүз белән каршылады:

— Әни, Гөлчәчәк минем янга кереп йөрмәсен, яме. Чирем йогар!

Шул төнне Сәлимәнең ютәле кызып китте, әнкәсе төн ката аның янында утырып чыкты. Иртәгесен ул түшәктән күтәрелә алмады. Сәрвәр белән Мәүлия аны шәһәр хастаханәсенә кереп ятарга димләделәр.

Мәүлия белән Сәрвәрнең карт-карчыкларның вафатына шаһитлар булганнары бар, анда, ичмасам, юатырга да, әз-мәз ялган катнаштырырга да ярый. Ә монда, күз алдында яшь-яшь, әле яши генә башлаган ана кеше ята. Нинди сүзләр табып аңа көч өрергә соң?

— Кымызга җибәрикме әллә сине, Сәлимә?

— Соң инде, Сәрвәр бәгърем. Җан эреп бетеп бара. Иң соңгы зур теләгем берәү генә: Маннурымны бер генә күреп китсәм дә мең риза! Кайтсын иде тизрәк!

— Чакырып телеграмма сугыйкмы әллә?

— Савыкса үзе дә кайтыр иде лә!.. Юк, юк, чирем хакында язмагыз. Үзенең сәламәтлеге кире китәр,— Сәлимә бераз үйлагач өстәп әйтте:

— Сез мондагысын кайгыртыгыз! Мең газап белән үстергән игеннәрне җыеп алыр көн җитә. Дәүләтшә әкә бик йөгәнгән, дөньяга чыгып йөрер хәле дә юк. Аның Тубылдан рухы сынып кайтты. Идарә җыегыз да яңа рәис сайлагыз! Миннән булмый инде. Болай да беркемне дә рәхәтләндерә алмадым.

Рәис итеп Айсетдинне сайлап куйгач, адәмнәр бер-берсенә караштылар. Ничек алай булды әле? Җыелыш алдыннан Айсетдин хакында бер дә сүз булмады лабаса! Ялт-йолт итеп торган медальләр җыелыштагыларны сукырайттымы? Сугыш каһарманы бит, Ленин ордены таккан кеше... Айсетдинне персидәтел итәргә нык тырышкан кешеләрнең берсе — Булат бичәсе Шәгъбикә иде. Орден түгел, күгәргән калай такса да, Шәгъбикә өчен кеше беренче сортлыга әйләнә иде. «Сайлыйбыз, сайлыйбыз! Безгә дә бер юньле рәискә тиенергә вакыт!» дип ул кычкырды.

Айсетдиннең һич карышып тормыйча, икеләнмичә, колхоз хәле белән юньләп танышмыйча тирән кесәсенә печәт шудырып куюына гаҗәпләнгән кешеләрнең берсе Дәүләтшә әкә иде. Ул каршы сүз әйтергә җыенып аягына басты, залга җыелганнарны күзе белән барлап чыккач, кулын селтәде дә урынына утырды.

Айсетдин рәис булгач, икенче көнне үк керфекләрен каралтып, иреннәрен мөлдерәп пешкән гөлҗимеш төсенә кертеп, герман җиреннән килгән матур крепдишин күлмәген, аның өстеннән нәзек билле бәрхет камзулын киеп, көмеш чулпыларын чылтыратып идарәгә Шәгъбикә кереп утырды. Аның таңнан торып печтәнләвен, бизәнүен, көзге каршысында канчыклавын астан гына күзәтеп йөргән Булат: «Нәрсә, табан астыңа тагын ут каптымы?» дип сорамыйча булдыра алмады.

— Яңа рәистән кулайрак берәр эш белешергә барам! — диде Шәгъбикә.

Бармагы саен алтын балдак елтыраган нәфис кулын өстәл өстенә сузып куйды. Күлмәк җиңеннән кояш нурларында җемелдәп киң алтын беләзеге елкылдап тора иде. Ул ары-бире каранды да, аулак булуын күреп, сүзне кыю башлады.

— Йә, нәрсә диярсең: чибәрләгән җуймаганмы Шәгъбикә апаң?

Айсетдин аның бәби табып интекмәгән гәүдәсенә, алсу йөзенә күзен майландырып карап торды, авызы җырылды:

— Ничего не скажешь! Баба в соку! — дип урысчалатып җавап бирде. Әле хатынның тел төбен аңлап бетермәгән рәис житди төс алды.

— Ярый, шутканы кырыйга алып ташлыйк. Ни йомыш?

Шәгъбикә киң ачык изүле күлмәген юри киеп килгән иде. Айсетдиннең хатын-кызга ач күзе хатынның шоп-шома муенына, камзулын төртеп торган күкрәгенә төште. Әйдә, карап рәхәте килсен дигәндәй, Шәгъбикә кыйшаебрак утырды. Айсетдингә аның кайбер татлы мажаралары турында әйтеп өлгергәннәр иде инде.

— Йомыш дип, Айсетдин энем, үзең беләсең. Хатын-кыз арасында көнләшү бетәме? Башта юк-бар сәбәп табып, Сәлимә гел миңа кадалып

килде... Инде Гыйззәтбану дигән әрсез кортканың күзенә чүп булып утырдым. Гел минем белән булыштылар! Яклаучым юк, иремне ишеткәнсеңдер, акылы җиңеләеп кайтты сугыштан. Янвалид. Хатыннар үзләре кешечә яши алмыйлар, кулларыннан килми! Ябыгып, чабактан корышкан Сәлимәгә кем күз салсын? Бөтенесенең күзе миндә, менә көнләшә Сәлимә! Көнләшеп кенә калса бер хәл иде — үчегә! Хәерче көненә калсам әй сөенерләр иде дә, тутаң андыйлардан түгел! Үз башыма көн күрергә өйрәндем, биргәненә шөкер.— Ул тагын күкрәкләрен тирбәтеп алды, керфеген сирпеп елмаеп куйды. Айсетдиннең әлеге тук күкрәкләргә үрелеп карыйсы килде, кеше-кара күреп сүз итмәсеннәр, дип тартынды. Эшли башлаганда ук гайбәткә дучар булудан сакланырга кирәклеген уйлап куйган иде егет. Хәзерге авылда хатын-кызның чуты-кырые юк. Шуларны уйлап, ул сүзнең җебен үз кулына алды.

— Төшенеп җитмим, йомышың ни-нәрсәдә соң синең?

— Гел авыр эштә изеләм бит. Гел авыр эштә йөреп билләрем сызлый. Янвалид Булат әкәңне каравым үзе ни тора! Мине берәр җиңел эшкә куйсаң, яхшылыгыңны мәңге онытмас идем.— Аннан өстәп куйды.— Буш итмәм.

— Түләве дә булыр дисең алайса? Акчалатамы, натура беләнме? — Айсетдиннең итләч битләре елмаюдан җәелде, ямьсезләнде.

— Шаяртмасана! — дигән булды чая хатын битен каплап. Үзе бармак аралары аша яңа рәискә ашардай булып карап торды. Аннан чем кара күзләрен майландырып бик матур итеп бер көлеп җибәрде.

Айсетдиннең тәне котырды, ул байтак кына вакыт икеләнеп утырды. Шәгъбикәнең ирләрнеаздыра алучы иблис икәнлеген ул тиз үк аңлады, әмма ләкин үзенең дә шайтан коткысына бирелгән азгынлыгын тыя алмады, торып, тәрәзәләргә карый-карый Шәгъбикәнең тирәсендә юргаланды, әле имиләренә кагылып китте, әле артын кытыклады.

— Ярый, Шәгъбикә апа димәсәм, үпкәләмәссеңме?

— Ниткән үпкәләү тагын? Үзем дә саный-саный килдем әле, нибарысы биш яшь кенә икән аермабыз!

Айсетдиннең кыяфәте җитдиләнде:

— Иң әүвәле әйт,— диде ул,— синең тешләрең сирәк түгелме?

Башта Шәгъбикә кинәяне аңлап җиткермәде, тешләрен елтыратып авызын ачты, бармагы белән сыдырып күрсәтте. Шунда гына Айсетдин әйткән сүзнең асылына төшенде.

— Кирәк икән, валлаһи дип әйтәм, авызыма капкан суны озак тотам мин! Беркемгә берни чыгармам, валлаһи шулай.

— Алайса, бик игътибар белән тыңла. Мин сине теге сугыштан кайткан Аляитдин урынына хат ташучы итеп куям. Аның аягының авыртуына сылтарбыз. Ул ат сораган иде, мин «юк» дидем. Сиңа соңырак, тел-теш басылгач, ат та бирермен. Син шуңа ризамы?

— Булдырам мин ул эшне, Айсетдин туган,— диде Шәгъбикә эш турында түгел, ат турында уйлап.— Лисапедым да бар, шуңа атланып йөрермен.

— Инде икенче шарты шул: Уразаевлардан һәм Сакин Йосыфтан килгән хатларны миңа гына тапшырасың. Моннан аларга китәчәкләре дә минем аша узар. Аңладыңмы?

— Ник аңламаска? Барысы да көндәй ачык. Син авылның башы икәнсең, бөтен хатларны да әүвәл башлап сиңа китереп бирсәң дә «эһ» диюче дә булмас.

— Бигрәк тә хөкүмәт оешмаларына: НКВД, райком, прокуратура ишеләргә адресланган хатларны онытып җибәрә күрмә! Ярый, уңышлар телим,— диде рәис, идарәгә якынаеп килгән адәмнәрне шәйләп.

Шәгъбикә әрсез чыгып сызарга ашыкмады, рәиснең каршысына ук басып, күзенә керердәй булып сөзеп карады:

— Кая медальләреңне җентекләп күрим әле. Тьфу, тьфу, күзем тимәсен! Хәрби кием сиңа шундый килешә, баш-аягың белән бер кашык суга салып йотасы килә.

Аларның танышлыгы шул көннән башланып китте. Сак Айсетдин Шәгъбикә янына барырга бик ашыкмады әле. Халык теленә керүдән тартынды, икенчедән, ни дисәң дә инде ул таушалган товар, ә рәис кешегә ул гына җитми, андыйлар әнә буа буарлык.

Кирәкле документларны юнәтеп, түшне орден-медальләр белән бизәгәч, Айсетдин мөнәсәбәтләрнең һәр тармагын, эчен-тышын исәпләгәч «Кая кайтырга?» дип баш ватты. Ялан халкының гадилеген, хәтта ки сәяси мәсьәләдә беркатлылыгын да уйлап, шунда кайтам дигән карарга килде. Ул, кайтып укытканда яшәгән фатирына төшеп урнашкач та, эчтән генә бик куркып һәм кылт-шылтка колак салып яшәде. Ямьсез төшләр кереп интектерде. Бер уйласаң, аның җинаятен әзме-күпме белгән кеше Сания Уразаева гына иде. Айсетдин аны Бухенвальдка дөмектерде. Ай-һай, аннан котылып иленә кайта алган кеше бар микән? Шулай да ул әллә нәрсәдән курка. Ахыр чик, җинаятьләренең тамчысы гына ачылып китсә дә — үлем аңа... Әгәр шуны алданрак сизенеп калса, Айсетдин анда да югалып калачак түгел, очсыз-кырыйсыз тайга аны йотып кына алачак. Эх, теге Колгасар исән-сау булса! Кызганыч, аны да харап итеп ташлаганнар. Чырык Абдрахман да бик үзгәргән, ике сүзенең бере «Ходаем» ди. «Аллаһе Тәгалә ни язгандыр», дип күккә бага. Бер күрде, шикләнде Айсетдин. Югыйсә ул картның да кирәге чыгар чаклар булыр иде.

Гел дер-дер килеп яшәгәнче, өйләнү җиңеллек бирмәс микән, дип уйлады ул, ниһаять. Хатын белән тигез тормыш итә башлагач кеше күзе дә төшеп йөдәтмәс иде. Өйләнеп авыл арасына сеңгәч, яңа тормыш башланып киткәч, үткәндәге гөнаһлы гамәлләрне дә онытттырып торыр иде. Хәерле булсын, Сания аңа бик ошаган иде ошавын, кулга төшерерлек мал гына булмады. Һәм Айсетдин Сәрвәрнең кылын тартып карарга ниятләде. Тиз арада авылның дилбегәсен үз кулына алып кысып тоткан Айсетдин киенеп-ясанып медальләрен чыңлатып Сәрвәрләр йортына аяк басты.

— Исәнме, Сәрвәркәй!

«Сәрвәркәй» дип барып керү үзе үк кызга нидер аңлатырга тиеш!

— Исәнме! — Кызның сәламне кабул итүе бик салкын тоелды.

Сәрвәр Айсетдиннең яхшы ният белән йөрмәвен абайлады, ишек янындагы сәке астында яткан балтага күз ташлап алды. Узып утыр диюче булмады, Сәрвәр баскан җирендә басып тора бирде. Айсетдин якындагы урындыкка җәелде, елмайгандай итте:

— Туган җир сагындырды, бигрәк тә сине сагындым, — дип, куштанланып сүз башлап китте Айсетдин. — Бер-бер ярдәмгә мохтаҗлыгың юкмы дип сугылуым әле. Кирәк нәрсәләрең юкмы?

— Игътибарыңа рәхмәт! Күрәбез, ил өчен кан койгансың. Юкса...

— Юкса нәрсә? — дип сагайды рәис.

— Мәктәптә эшне бутап киттең.

— Да-а! — дип сузды җиңеләеп, ияге дерелди башлаган Айсетдин. — Син һаман шул тигәнәкле кызыкай булып калгансың икән. Һаман борын чөеп, кадап сөйләшү. Итәк асты юеш булса да, һаман сер бирмәскә ниятме?

Рәиснең алай тиз генә тәртәгә тибәргә нияте юк иде, Сәрвәрнең һич буйсынмыйча күзгә карап торуына гарьләнгән Айсетдин авызыннан бу сүзләр уйламыйчарак ычкынды, бераздан кинәт ычкынган сүзләре өчен Айсетдин кабат-кабат үкенде, әмма эш узган, кулга керергә тиешле торна чамадан тыш сагайган иде.

— Оятсыз! — Сәрвәрнең тавышы көр һәм усал иде. — Шуны әйтергә кердеңме? Бар, югал күземнән! — Сәрвәр үзен-үзе белештермәслек дәрәҗәдә кызып китте. Ялан авылында аның йөрәк ярасын кузгаткан кеше юк иде әле. — Чыгып кит диләр бит сиңа!

— Кызма, Сәрвәр! Әйдә ипләп кенә сөйләшик, киңәшик! Тиешле уртак фикергә дә килербез. Мин ышанам.

Сәрвәр үзен тынычланырга мәҗбүр итте:

— Ни йомыш?— дип сорады.

— Мин, Сәрвәркәй, синең кулыңны сорарга кердем.

Сәрвәр лып итеп урынына утырды, әллә ниләр уйлап бетерсә дә, үтерсәләр дә, мондый сүзне көтмәгән иде. Башка сыймаслык тәкъдим!

— Сиңа дигән кул юк миндә, Айсетдин. Белмәсәң, бел. Минем сөйгән егетем бар. Ул — Таштимер. Ташкәй. Син аны хәтерлисеңдер?

— Кыланмасана! Син хәзерге хәлеңдә кемгә кирәк? Кемгә ярыйсың? Мин сине хурлыгыңнан коткарырга дип кердем. Шул гына. Кем син?

Бу сүзләр Сәрвәрнең сизгер җанына туры барып тиде. Аның күзләрендә нәфрәт чаткылары уйнады. Ул куркыныч кыяфәттә:

— Йә, әйт. Кем мин?— дип, Айсетдиннең авызын ертырга үрелде.

— Синме? Син вәхши Үлмәстән калган хатын. Әйттерден!

Айсетдин канәгать иде, кире беткән Сәрвәр үзенең кирәген алды. Күп карышып маташса, Айсетдин күп сорамас, аны әллә кайларга, Боз диңгезе тирәләренә дөмектерер! Канлы күз яшьләреңне коясың алда әле, кызый!

Сәрвәр үзен-үзе көчкә тыеп, бая күзе белән әзерләп куйган балтага карады, Айсетдин аның карашының кайда тукталганлыгын аңлады, кызның кулын читкә кагып җибәрде.

— Ярар. Беренчесе-соңгысы шушы булсын. Черт побери! Чыннан да, сылу син! Ачуланганда бигрәк тә матурланасың икән! Бел: мин синең янга начар ният белән килмәгән идем. Үзең котырткангa гына ямьсез сүзләр ычкындырдым. Миңа тормышка чыксаң — отасың.

Сәрвәр соң дәрәҗәдә гарьләнде. Айсетдиннең кызны бу хәлендә ташлап чыгасы килмәде, ул юмаларга керешге:

— Сәрвәр, котыл син бу кире җүләрлегеңнән. Барыбер миннән артыкны тапмассың. Теләсәң, хәзер үк өйгә алып кайтып китәм үзеңне. Болай ачлы-туклы яшәмәссең. Председатель буларак, мәктәбеңне рәтләргә дә ярдәм итәрмен. Уйла әле, уйла! Дөрт итеп кабынма! Чыннан да нинди шәп булачак. Син — олы бер авылга баш булган түрәнең сылу хатыны! Көне килер, дип көтеп ятмабыз, үз җаебызны үзебез карарбыз! Колхозның аргамакларын симертербез, елкылдап торган чаптарларда буран уйнатып туйдан-туйда гына йөрербез. Тагын бер кат, ашыкмыйча гына уйлачы, Сәрвәркәй!

— Күрегезче моны, ниндәен купец! Аргамак, тезелеп киткән туйлар... Сүз өчен генә «мәктәп» тә бар! Менә Мөхәммәт абый кайтып җитсен, чаптар атларда ничек-ничек йөрергә кирәклеген ул сиңа өйрәтер...

Мөхәммәтнең исеме Айсетдиннең йөзен куырып алды, авызы чалшаеп китте. Әллә Сәрвәргә генә шулай күрендеме?

— Көт, көт Уразаеңны! Бетле шинелен, тезе ямаулы галифиен киеп кайтып керер. Үпкәсе череп беткән ди аның! Кислород мендәрен имеп кенә ята, ди. Кашыклап ашаталар икән ул батырны!.. Нигә моңарчы кайтмаган? И кайтмый да ул!

— Мөхәммәт абыйны кайтмый дисәләр, Иртеш кирегә ага башлар. Боерган булса, кайтып та керер һәм...— Сәрвәр бүлмәне тутырып көлеп тә җибәрде.— Сине тәхетеңнән тотып та атыр!

Сәрвәр, үзе да сизмәстән, Айсетдиннең иң тирән ярасын тырнап канатты... Тегенең иң курыккан кешесе Мөхәммәд Уразаев иде... Бәлки нинди дә булса әмәлен, юлын табып Сания аңа бер-бер хәбәр җиткергәндер? «Шикле шикләнер, чикмәнен бөркәнер»,— дигәннәр. Айсетдин авыл, колхоз белән генә чикләнеп калмады, ул капшагычларын районга да сузды. Йомыш тапкан булып райкомга да барып керде, «Үтешли генә кагылдым»,— дип, НКВД ишеген дә юри киереп ачты... Ленин ордены аңа теләсә кая юл салды. Аны һәр урында ачык чырай белән каршы

алдылар, зурлап озаттылар. НКВД начальнигы Глеб Иванович Лапиков аны аерата үз итте. Бер баруында икәү генә ашханәнең арт ишегеннән кереп, югары дәрәҗәдәге затлар өчен махсус тәгаенләнгән аулак бүлмәдә сыйланып та утырдылар. Җәл, затлы аракылары юк икән, начар гына җирле аракыны берәр стаканнан бөкләп куйгач, Айсетдиннең теленнән чак кына үз-үзенә хөкем карары ычкынмады. Теленә юк сүз килде аның, мактанасы килде һәм чүт кенә: «Менә немецларда ул аракы! Эчкән саен эчәсене генә китерә!»— дип ычкындырмады...

Утыруның файдасы шул булды: Айсетдин Лапиковны кунакка дәшеп кайтты. «Ул бездәге күлләр!.. Ул безнең күлләрдәге үрдәкләр!..» «Барам, барам»,— диде Лапиков калайланган күзләре белән яшь, өметле рәисне ашап.

Бөтен җирдә Айсетдингә ишекләр ачык, бөтенесе аның белән дус булырга, якынаерга тырышалар... Ә бу... Үлмәс исемле егетнең калдыгы!.. Үлмәс аны иптәшләренең күзе алдында алган, «шаһитлар ясап» энже сандыгын ваткан, диләр.

Авыл урамы куе караңгылыкка күмелгән иде. Ирлеге котырган Айсетдин Сәрвәрләрдән чыккач туп-туры Шәгъбикәләргә таба атлады. Колхоз белән мәктәп арасына шул кичтән башлап авыр кара таш кереп ятты.

## 31

Фаягөлне эзләп табып алып кайтканда, арада Миңнурый юк иде. Аннан соң да Миңнурыйның кызлар белән арасы әз генә суынгандай булды. Юк, суынды дип әйтсәң дә дөрес үк булмас, шулай ук күп вакытларда алар үзгә юллардан, тарайган үзләренең сукмакларыннан йөри башладылар. Мәүлия Йосыфына көн саен диярлек җавап яза, хатлары торган саен серлерәк була бара, кызлар элекке кебек язганнарын бер-берсенә тулаем укып, күрсәтеп тормыйлар. Мәсәлән: «Йосыф бәгырем! Бүген таңдагы татлы йокым вакытында төшемә кердең... Кайнар кочагыңа суырып алгансың икән дә...» Боларны иптәш кызларга ничек укыйсың? Сәрвәр белән Ташкәйнең арасы да җылынганнан җылына бара, алар да мәхәббәттә аңлашып, инде вәгъдәләшеп тә өлгерделәр. Ташкәй күкнең җиденче катында оча, яшьли сөеп, ничә кат читләшкән, бер-берсен бөтенләй югалткан өметсез мәлләрдә кайгы-хәсрәт дәрьясында чак батып югалмаган егет, үзенең моңарчы бер тарафта да исраф ителмәгән сөю ялкыннарын Сәрвәргә белдереп, хатларына ут-ялкыннар тутырып җибәрә иде.

Миңнурыйның мәхәббәте монда, якында гына ята. Ул атна-аралаш аның каберенә барып йөри, сирәк кенә булса да Коръән укыта, кабер өстенә кыр чәчәкләреннән бәйләмнәр куеп Ишморзасы белән озаклап-озаклап сөйләшә. Ул шыпырт кына сораштырып, якыннарыннан белешеп һаман-һаман Ишморзаның югалган әткәсен дә эзли. Сәрвәр Мәүлияләр янында хәзер үзгәрәк, өлкәнрәк, уйчанрак. Беркөнне көзгедән карап утырганда, маңгаена сүтеп тараткан чәчләр арасыннан ике бөртек көмеш тә табып алды. Өзмәде.

Мәүлия белән Сәрвәр исә аны читләмәскә, аннан ерагаймаска тырышалар, кулларыннан килгәнчә мәктәпне әз-мәз караштырып, мич-морҗаларын төзәткәләп, ярыкларын сылап агарттылар. Кирәк әйберләрнең чиге юк: дәреслекләр юк, әсбаплар юк, китапханәгә өч ел рәттән бер генә яңа китап та кайтмады. Бигрәк тә татарча дәреслекләрнең юклыгы изә...

Ялан халкы булып узган могҗизаның асылын кайчанрак аңлап бетерер икән? Әлегә һәммәсе дә сер, чишә алмаслык авыр табышмак иде. Җәбраил фәрештә нигә Чырык Абдрахманны йөзләрчә кеше арасыннан сайлап алып, аның төшенә ингән? Яланда фәрештәләр белән арадашлык итәрлек бүтән кешеләр юк иде мени? Әйтик, Гыйззәтбану түтинең төше-

нә керсен, ди. Яки сердәш итеп бахыр Шәүкәтне сайлап алсын, ди. Ә Чырык... Гөнаһлары авыр Чырыкның, языклары күтәрә алмаслык, ә төшенә Җәбраил фәрештә кереп, югалган кызның адресын дөп-дөрес итеп әйтеп бирә!..

Фаягөл кайтып кереп, Чырыкның төшендә күргәннәрен раславы гаҗәеп хәл булса да, кызның табылу шатлыгыннан әле берәү дә төпченеп, чын җавапны табарга тырышып баш ватып тормаган икән. Югалдымы — югалды, табылдымы — табылды... Әмма ләкин тормыш үзенең гадәти эзенә төшеп утыргач, мөгаллимә кызлар берсе өстенә икенчесе юшкын булып утырган гаҗәп хәлләргә җавап эзләргә керештеләр. Тапмадылар. Динне белмәгән, Җәбраил фәрештәнең миссиясен дә юньләп аңламаган комсомолкаларга бу яңалыклар үтә гаҗәп булып тоелды. Аларның уйларына үзгәреш, иманнарына икеләнү кертте.

Белгәнегезчә, Миңнурыйның ерактан ук ияреп килгән сөтләч сыерыннан кызлар бергәләп файдаландылар. Савып сөтен дә эчтеләр, катыгын да оеттылар, сөзмә-каймаклардан да баш тартмадылар. «Бары бергә — югы уртак», дигән канунның тарафдарлары булган кызлар кышлык курмы ягын да бергәләшеп кайгырттылар. Көннәрдән беркөнне Кызлар убасыннан ерак та түгел түгәрәк күл тирәсендә печән чабып, киптереп, бәләкәй арбаларны тартып кайтырга җыенганда, күл өстенә бер оя кыр үрдәкләре төшеп кунды. Ары-бире йөзеп чупырдаштылар да үрдәкләр очып та киттеләр. Бөтен ягы куаксыз шәрә күлне өнәмәделәр шикелле. Шунда, Фаягөлнең серле сәяхәте турында әңгәмә куерткан кызлар Чырык Абдрахманга ияреп тыр-тыр барганда күзләренә чалынган күлне хәтерләренә төшерделәр.

— Менә ичмасам, күл дисәң дә күл! Үрдәкләр анда мыжлап тора! — диештеләр Мәүлия белән Сәрвәр.

— Нигә үрдәк атарга бармыйбыз соң без? — дип сорауны турыдан-туры куйгач, Сәрвәр белән Мәүлия Миңнурыйга җавап та бирә алмадылар.

— Әләй! Ничек йөрәгең җитеп кош атмак кирәк? — диде Сәрвәр.

— Хатын-кыз мылтык күтәреп ауга йөриме? — дип, аңа кушылды Мәүлия.

— Сәлимәгә үрдәк ите бик ярап торыр иде! — диде Миңнурый.

Сәлимәнең көннән көн сыза барып, чирләп ятуын хәтерләренә төшергәч, Мәүлия белән Сәрвәр җиңелделәр. Печәнне сыртлап төяделәр. Алдан Миңнурый белән Мәүлия тартты, арттан арбаны Сәрвәр этеп барды. Юлда кайтканда сүз гел үрдәкләр, үрдәк бәлешләре тирәсендә йөрде.

Мөхәммәт Уразаевның ау мылтыгы исән иде әле. Миңнурый вакыт-вакыт аны чолан почмагында сөялеп торган җиреннән алып кирә, шыбын башына чүпрәк урап көпшәләрен чистарта, патроннарын барлый. Менә хәзер мылтыктан файда күрер көн дә җитте.

— Үрдәк атканым да бар, кышын куянга чыгып кыска койрыкларның берничәсен билгә тагып кайтып әнкәйләрне шаккатыргалаганым да булгалады, — диде Миңнурый, печәнне лапас астындагы бушлыкка тутырып бетергәч.

Иртә таңнан юлга кузгалдылар. Моңсу һәм тын урман аларны кочак җәеп каршылады, юлда килгәндә авызлары тик тормаган кызлар, урман тынлыгы тәэсире астында юашланып, югалып калгандай булдылар. Уңда да, сулда да кеше тавышлары ишетелде, агачларда күркәләр нык кимесә дә, соңарып җитешкәннәрдән кышка запас әзерлиләр иде әле кешеләр.

Сунарга йөреп ауның мәшәкатен дә, рәхәтен дә татыган Миңнурый күл өстенә килеп чыгып, тип-тигез су өстендә өер-өер йөзеп йөрүче үрдәкләрне күргәч сөенеченнән сызгырып ук җибәрде. Күл артык киң түгел, озынлыкка шактый озын, сулъяк чите күренми дә диярлек иде.

— Болай итәбез!— диде Миннурый кызларының кулына озын чыбыклар тоттырып.— Сез икәүләшеп теге як ярга чыгасыз һәм үрдәкләрне бу якка таба куа торасыз. Ә мин аларны каршылый белермен!

Үрдәкләр өер-өер чуар утраулар булып теге як ярга якынлаштылар һәм шул чакта, Мәүлия белән Сәрвәр, агач-куакларга ышыкланып алар янына кузгалабыз дигәндә, аръякта мылтык шартлаттылар. Миннурыйның исәпләвенчә теге ярда мылтыклар берәү генә булмаска тиеш иде. Алар бирге ярда чикләвек куакларына ышыкланып торалар иде, баш очыннан пыр-пыр килеп үрдәк өере үтә башлагач, Миннурый тик карап тормады, мылтыгын күкрәгенә терәде дә ике көпшәдән дә ут гөрселдәтте.

Очып барган төркемнән икесеме, өчесеме аларның аяк очына гына лыпылдап төшteләр дә, яраланган кошлар тыпыпылдап ята башладылар. Җәрәхәтләнгән кошкайларның жирдә тәгәрәшеп ятканын күреп, Сәрвәр җылап җибәрде, Мәүлия аңа караганда кыюрак икән, тыпылдаган ике үрдәкне Миннурыйның алдына китереп салды. Кыз кесәсеннән пәке чыгарды...

Ау әкәмәт шәп башланды, үрдәкләрне күзәтер өчен чатыр корып та маташмадылар, салның да хаҗәте булмады. Миннурый белгән сунарчылар бер-ике үрдәк өчен әллә никадәр җәфа чигә торганнар иде.

Кызлар аръяк ярны җентекләп күзәтергә тотындылар һәм су кырыена терәп салынган камыш шалашны абайладылар. Баягы мылтык тавышлары шуннан яңгыраган икән. Шалаштан атылып эт чабып чыкты һәм күл өстенә егылган үрдәкләрне берәм-берәм ташырга да кереште.

— Кузгалмыйбыз, шушында гына сагалыйбыз. Теге як сунарчылары аткан саен үрдәкләр бу якка очарга тиеш, аларның бүтән барыр җире юк,— диде кызлар тарафыннан «мәшһүр сунарчы» исемен алып өлгергән Миннурый.

Үрдәкләрнең байтагысы күл өстеннән пыр итеп очтылар да түгәрәк ясап әйләнделәр, канатлары белән суны кисеп төштеләр дә куанышып бакылдадылар, югалган кардәшләре турында уйлап та карамадылар. Ваемсыз кошкайлар!

Муен тирәсендәге шәмәхә каурыйларда җемелдәгән кан тамчыларына күз төшкәндә генә кызлар үзләре кылган гамәлдән чирканып киттәләр, бер-берсенә карашырга өлгерделәр. Иреннәрдән ирексез: «Сәлимәгә...» дигән сүз кысылып чыга. «Шәүкәт абыйны да үрдәк ите белән сыйлыйсы иде бер!»— дип пышылдый Сәрвәр.

Һич көтмәгәндә аргы яктан тагын аткан тавышлар яңгырады, үрдәкләр бер-берсен куәтләп бакылдаштылар, ләкин һавага күтәрелмәделәр, җанлы чуар ташкын булып күлнең озын ягына таба йөзеп киттеләр. Миннурый түзә алмады, үрдәкләргә һич тиярлек булмаса да атып җибәрде. «Тисә тиенгә, тимәсә ботакка»,— дип ычкындырды Сәрвәр. Миннурый ачуланырга да өлгермәде, теге яктан, камыш шалаштан ике кеше атылып чыктылар да каядыр йөгерделәр. Ул да булмады, куаклар ешлыгы эченнән әкрен генә гөрләп ачык өсле «Виллис» машинасы килеп чыкты да күл әйләнә болай таба килә башлады. Курыкмадылар кызлар, алар өчәү, кулларында мылтык, ышанычлырак булсын өчен Миннурый корулы патроннарны ояларына этеп кертте, күзләр машина килгән якка борылды, ишелеп йөзеп йөргән кыр үрдәкләре онытылды...

Машина якынлашты, кызлар утырган җирләреннән тордылар, посканешлыктан чыктылар. Машинада өчәү утыралар иде, кызлар шоферга карап тормадылар, чөнки арткы урынга сеңгән, күзләре белән кызларны ашардай булып текәлгән ике кеше кызларга яхшы ук таныш иде. Айсетдин белән НКВД начальнигы Глеб Иванович утырган иде машинаның арткы утыргычына. Ике як ишек тә берьюлы ачылды, Айсетдин белән Лапиков берьюлы җиргә сикереп төштеләр.

— Әһә, эләктегезме!— дип кычкырды Айсетдин нигәдер нәзек, ямьсез тавыш белән. Лапиков дәшеп тормады, эре-эре атлап Миннурыйның янына барып житте һәм кулыннан мылтыкны тартып та алды.

— Кем рөхсәте белән кайда яшеренеп яткан бу мылтык? Сугыш чорында рөхсәтсез корал саклаган өчен беләсезме ни була?

Айсетдин Миңнурыйны урап, алдын-артын карап чыкты.

— Кем бу? Әй син, кем син?

Лапиков мылтыкның корулымы-түгелме икәнен тикшергәч кенә Айсетдинга аңлатып бирде:

— Әгәр алдан ук чарасын күреп, бу кызыйның мөгезләрен сындырмасаң, алдагы көнеңдә сиңа рәхим-шәфкать күрсәтмәс бу бәндә! Сукыр черки булып кадалачак, кермәгән тишеге, сыймаган ярыгы юк аның!..

— Шулай да, кем?

— Ялан мәктәбендә укытам мин,— диде Миңнурый ушын җыеп.— Исемем Миңнурый.

— Как так, моңарчы сине күрмәгәнмен мин?— дип кабатлады Айсетдин иреннәрен ялап. Аннан аракы исе бөркелде, танавының канатларында тир бөртекләре елтырады.

— Ауга чыгарга рөхсәтегез бармы?— дип, соравын дәвам иттерде Лапиков.

Кызлар каушап бер-берсенә карадылар һәм күңелләреннән генә кара-каршы баскан төркемдәге кешеләрне санадылар. Ир-атлар өчәү һәм кызлар да өч бөртек. Ни телиләр алар? Куркытырга гына җыеналармы? Лапиковны табигать кочагында бер тапкыр да очратмаган Миңнурый аның күзләренең явызлыгын, кулларының озын, нык икәнен күрде. Миңнурый мылтыгын кулында әйләндергәләп куйганда, ул нәкъ аңа карап тора икән. Шунда ук чамалады, Айсетдин рәис тә аннан күзен алмый, кулын суза, әллә тотып капшап та карыйсы килә инде?

— Нинди рөхсәт кирәк соң аңа?— диде бераз аңга килгәч Сәрвәр. Ул ике ирнең әрсез күзе Миңнурыйны чишендергәнлеген абайлады, кызны ничек тә коткарып калырга, мылтыклы ирләрне ничек булса да «коралсызландырырга» кирәк иде.

— Нигә мин сине моңарчы күрмәдем соң? Качып йөрдеңме?— дип сорады Айсетдин.

— Нигә качыйм? Минем гөнаһ кылганым, закон бозганым юк ич!

— Ә бу?— дип кычкырды Лапиков.— Рөхсәтсез корал белән рөхсәтсез ауга чыккансың!

— Глеб Иванович,— диде Айсетдин аңа борылып карамыйча гына.— Кыз минем колхоздан. Мылтыгын син ал, ә кызны миңа калдыр. Без үзебез тиешле чарасын күрербез. Кирәк санасак, җәзасын да бирербез.

Әлерәк кенә Айсетдин алып килгән аракыны чөмереп, ул алып килгән иттән пешерелгән куырдык ашап кәефләнгән Лапиков артыгын бәхәсләшеп маташмады.

— Мәйлең, Айсетдин! Бүгеннән мин синең аркаңа, күлмәк эченә керпе салам. Чыдарсыңмы, юкмы, карарбыз. Бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый. Бу кызыйның тешләренең аклыгына карама, очлы аның тешләре һәм тыгыз да! Бик күптәннән җыелып килә зур гөнаһлар аның артыннан!

Мәүлия белән Сәрвәр алгарак чыгып, янәшә басып ахирәтләрен ирләр күзеннән капларга тырышсалар да, Миңнурый үзе дә, иптәш кызлары да яхшы ук нык эләккәннәрен, бәлагә тарыганнарын аңлыйлар иде.

Лапиков хәлне ярты сүздән аңлап алды, үзенең дә шулай юк кына гаеп өстендә тотып, законны белмәгән кешеләрне ансат кына өркетеп, күпме кызларны тозсыз-борычсыз кабып йотканы бар. Айсетдингә карап, эченнән генә: «Ава кайбер кешеләрнең башына әкәләле имәннәр!»— дип куйды һәм үрдәкләрне дә алырга дип җиргә иелде. Инде Миңнурыйга чират җитте, ул:

— Тимәгез! Кагылмагыз үрдәкләргә! Аларның берсе Сәлимәгә, икенчесе Шәүкәт абыйга!— дип кычкырды. Кызлар аның белән бер булып

үрә баскач һәм шактый усал кыяфәт белән кулларын бутап-бутап кычкыргалагач, Лапиков үрдәкләрне кире куйды. Айсетдин исә ныклы карарга килгән тәвәккәл кеше кыяфәтенә кереп, машина янына тиз-тиз барды да аннан тагын ике үрдәк күтәреп килде.

— Берсе Сәлимәгә, икенчесе Шәүкәткә булыр,— диде ул күкрәген киереп.— Ә хәзер... Бар, таегыз моннан.

— Шулай ансат кына ычкындырасыңмы?— диде Лапиков, кашларын җимереп.

— Глеб Иванович! Үз кадрларыма үзем хуҗа булып карыйм әле,— диде Айсетдин кыланыбрак.

— Ярар әйдә! Түзә алсаң, ал керпене! Күлмәк астыңнан чыгарып кара.

Миңнурыйның Мөхәммәт абыйсының мылтыгын урманда ят кулларда калдырып кайтасы килмәсә дә, ул, әгәр карышып, ныкышып маташса, эшнең зурга китү мөмкинлеге барын уйлап, тыелып калды.

Алар күл буеннан артларына карый-карый, ашыгып, кабаланып, тигезсез урыннарда абынып-сөртенеп кайтырга чыктылар.

Үрдәкләрне йолкып, пешекләп алгач, бер түшкәне Сәлимәләргә илттеләр. Ул җылый-җылый кызларга рәхмәт укыды. Үрдәкне күргәч Мәүлиха да чиксез сөенде, йортның түрендә, Булат иплән биргән агач караватта, ак җәймәләр, ак мендәрләр эчендә яткан Шәүкәт исә торып утыргандай булды. Кызлар:

— Бик арып кайттык, алҗыдык,— дисәләр дә, Мәүлиха белән Шәүкәт бер авыздан кыстадылар, кызларны чәй эчертмичә җибәрмәделәр.

Бер үрдәкне сугыштан кайтканнан бирле рәтләнә алмаган Туктасын әкәгә илттеләр. Ул да дога кылып, күп рәхмәтләр әйтеп, шаккатып, гаҗәпләнеп калды.

Дүртенче үрдәкне Гыйззәтбану түти, Фаягөл, Миңнурый, Мәүлия, Сәрвәр җыелып ашадылар. Бәйрәм сые җылганнарга бәйрәм төсе кертте. Үрдәкнең иң тәмле җире — күтиге, әлбәттә, Казанның иркә кызы Зиләгә эләкте. Гыйззәтбану түти үрдәкнең канат очларын сындырып алды да берәм-берәм Мәүлия белән Сәрвәргә тоттырды:

— Дәүләтшә әкә «Чикләвек уңган елны кызлар кияүгә китә торган була»,— ди. Менә сезгә канатлар, очыгыз рәхәтләнеп!— дип хәер-фатихасын бирде.

Зилә һич иренмичә кабатлап-кабатлап борынгы татар җырларын җырлады. Аны яратып, үз итеп тыңладылар.

## 32

Шәгъбиканәнең башы күктә: авыл арасында нинди кара гайбәтләр генә йөрмәсен, армас телләр, әйдә, аны язгы пычракка, җәйге туфракка салып таптасыннар, әмма ул бүген бәхетле. Айсетдин рәис аңа моңарчы татымаган бәхетне китерде. Кем дигәндә — рәис! Ленин орденлы егет!

— Менәкәчәйләрем,— дип тәкереген чәчә-чәчә мактанды ул Гобәйбә буйдакка.— Җаныңны чыгарып сал дисә — салам. Башыңны кисәргә бир дисә — бирәм. Айсетдин өчен җаным фида. Ул, җаныкаччаем, безнең ирләрнең төшенә дә кермәгәннәрне белә! Ә минем күңел төрлелек эзләгән икән.

Гобәйбә буйдак беренче тапкыр ахирәтеннән көнләште. Соң, уйлап кара, йортында менә дигән ире, Булаты бар, аның сәламәтлеге торымнан торымга гел арулана. Шәгъбикә берәр яманлык эшләп, сул аягы белән йокыдан торып ачуын чыгармаса, гел таза кеше дип әйтерлеккә әйләнә.

Бүген Гобәйбә буйдак иртәдән диярлек кәефсез диярлек иде. Сул ягыннан да тормады югыйсә, көтелмәгән хәбәрләр житкереп аптыраткан кеше дә булмады, ә кәефе юк, үзен-үзе сөйми бүген Гобәйбә буйдак. Чәче

киезләнгән, күз төпләренә сары эрен касмакланып каткан, яңарак кына Өннә карчык бәйләп биргән оегы тишелгән. Бердәнбер соңгы тавыгы лапас артына, бәрәңге ызанына чыгып үлгән. Бүтән көн булса да Гобәйбә буйдак тавыкны йолкып, пешекләп берәрсенә тондырыр иде, ә бүген юк, кулы бармый, гарьләнә. Берәүләргә ике ир язган, ә Гобәйбәгә берсе дә юк. Әйе, чәчәк зәхмәтеннән шадра калды Гобәйбә, сул аягы да уңыннан кыскарак, уң колагы, сулыннан аермалы буларак, җилпуч булып тырпаеп тора. Ә бүтән яклары кемнән ким? Биле юкмы аның, артка такканнары кыймыл-кыймыл килеп, ирләрне аздырып йөрмиме?.. Түше дә буш түгел, сөбханалла! Ә яратам дигән кеше юк, булмады, инде хәзер булмас та! Хатын-кыз күзе төшәрлек ирләрне герман муры кырды... Кешесенә карап инде, бәхеткәйләрең бер дә юк икән, ник асты-өскә килми шунда дөньясының...

Шәгъбикә исә бәхетне үзенчә аңлый иде һәм, чыннан да, бәхетле булуы белән куана иде. Рәис кадәр рәис, орденлы егет аның артыннан йөрсен әле!

Юк, җанын чыгарып салырга да, башын бирергә дә туры килмәде Шәгъбикәгә, бүтән бер яхшылыгы белән Айсетдиннең күңелен яулады ул.

Ат ярата иде Айсетдин, начар булса да, яманлыклары чутсыз булса да татар баласы иде ул, затлы бер малга хуҗа булу аның иң зур хыялларының берсе иде. Күрше авыл урысларыннан берәү чаптар ат сата дигәнне ишеткәч, ул шул сәгатьтә үк күрше авылга торып чапты. Озын торыклы, киң күкрәкле, нәзек муенлы айгыр, чыннан да, күзне кыздырырлык сылу иде. Бәясе дә майлы иде каһәрнең! Урыс күпмегә сатарга уйлавын әйткәч үк, Айсетдиннең сөмсере коелды. Андый акча үзендә дә, колхоз кассасында да юк иде. Кайтып кергән көннән бирле эшләр гел уңайга барып, борын чөяргә дә гадәтләнгән Айсетдин авылга пошаманга төшеп, тешен кысып кайтып керде. Авылга кергәндә генә почтадан менеп килүче Шәгъбикәне куып җитте. Алар авыл урамын, идарәгә кадәр бер арбада утырып үттеләр. Айсетдин үзенең ни йомыш артыннан йөрүен сөйләп бирде. Шәгъбикәгә шул гына кирәк тә, ул дөньясын онытып:

— Мин бирәм сиңа ул акчаны!— дип кычкырып ук җибәрде.

— Мин аны сиңа кайчан һәм ничек түләрмен?— диде Айсетдин, сүз өчен генә.

— Түләмәссең!— диде Шәгъбикә,— дуслар арасында андый гына хәлләр була ул!

Тимерне кызуында сук, акча кулга керүгә Айсетдин шул кичтә үк урыс авылына кире чапты һәм бөтен тирә-якның күзен кыздырган чаптар айгырның иясе дә булды. Һәм атны колхозныкы санап, «фәлән-фәлән сумга, фәлән авыл урысыннан сатып алынды», дип документлаштырып та куйды. Сатып алуның суммасын өчләтә арттырып күрсәтте.

Әвендә очрашты Айсетдин Абдрахман әкә белән. Бабай колхоз орлыгын киптереп, җилгәреп, тиешле рәвешенә җиткереп дәүләткә озатып тора икән. Чырык белән якынаерга бик вакыт иде, ни әйтсәң дә, иске таныш! Серләре килешә иде элек! Картның да үзенә тартылмавын, алай гынамы сиңа, читтәрәк йөрергә тырышканын зирәк рәис абайлаган иде инде. Хәзер очрашсалар да була: рәис кара айгыр җигелгән тарантаска утырып килде бүген. Җиргә казып кертелгән зур мич авызына яртылаш кереп, чи утыннарга ут йөгертә алмыйча өреп маташкан картның чалбар төбендәге чәчәкле ямавыннан көлеп тә җибәрде рәис, кычкырып сәламен дә бирде:

— Исәнлекме, Абдрахман әкә!

Бабайның тавышы ишетелде, сүзләре аңлашылмады.

Нидер мыгырдый Чырык, яртылаш мич авызына кергән картның сүзләре генә аңлашылмый.

— Исән-аман гына яшисеңме дим!

Мич авызы нидер улый, ә карт һаман мич авызында.

— Нәрсә, башың кысылдымы әллә анда?— Айсетдиннең тавышы шактый коры вә кырыс яңгырады, ул ботинка башы белән Чырыкның тез астына кагылды, аңлап алды: Чырык аның чаптар атта җилдерүен күргәч кенә мич авышына кереп киткән, аның яңа рәискә нинди дер үпкәсе бар, хәзер дә аннан качып маташа, имеш...

Айсетдин Чырыкның аякларыннан әләктереп сөйрәп чыгарды. Абдрахманның көлгә, корымга буялган иреннәре нык кысылган иде, ул күзләрен челт-челт йомган булып, тез башларын какты, йөри-йөри табаннары ялтырап беткән кәвешләрен киде. Шуннан соң гына, кулларын бер-берсенә бәргәләп кагып рәискә карап бакты.

— Ә-ә, бу син йөрисең икән, Айсетдин туган. Китергәннәр утын, лычма чи! Урманда коры агач таба алмаганнар мени?.. Үзен йөрмәсәң, берәвесенең дә кулы җитми, миннән киткәнче — иясенә җиткәнче дип кенә эшлиләр. Замана үзгәрде, замана кешене дә үзгәртте.

— Әллә игеннәрнең бөтенесен сушилка аша үткәрәсез инде?

— Урман ягасындагы дымлы җирләрдән урганны киптермичә кабул итмәделәр. Өченче көнге яңгыр көлтәләрне суга салгандай иткән,— дип аңлатты Чырык. Аның үзен җаваплы, җитди кеше итеп тотарга тырышуын чамалап алган Айсетдин картның салпы ягына салам кыстырды:

— Хәтәр кеше булган син!— диде.

Чырык, чыннан да, Фаягөлне эзләп алып кайтып, фәрештәләр боерыгы белән сугыш гарибен хәләл хатынына тапшыргач, якын-тирәдә даны таралгач, үзен бөтенләй бүтән кеше итеп сизә һәм бүтәннәрдән дә шундый мөнәсәбәт көтә иде.

Айсетдин урнашып ныгыгач, үзен кәнсәләргә махсус чакырып алыр да бер-бер бүләк бирер, һич югында исемен «кызыл тактада» балкытып куяр дип йөргән иде. Баксаң, үз данын гына гел өскә күтәреп йөри икән рәис! Тирә-якта дан тоткан чаптарны иярлекләп алган әнә, ә Чырыкка һаман шымытыр!

Айсетдин бабайга папирос сузды, алар бер читкәрәк барып утырдылар, тәмләп-тәмләп төтен суыра башладылар. Бабай Айсетдиннең сүз башлавын көтеп тынып калды. Үзенә калса, рәис нәрсәдер әйтергә теләп килгән иде кебек. Ул Айсетдиннең тап-таза, соңгы көннәрдә тагын да тулышып киткән гәүдәсенә карады да көрсенде. «Булса да булыр икән! Сугыш кырында бер Ялан авылыннан күпме кеше ятып калды, күпмесе гомерлеккә гарипләнде. Бүгенгә кырык өч кеше үлде! Бала-чагалары ятим, бичәләре тол калды, гомергә нужа күрәчәкләр! Толга һәм ятимгә бер чакта да кояш яктырып чыкмаган! Ә менә елан да сыгырмаган! Пәри калтырчасы булып кайтып та кергән!»— дип уйлады.

Айсетдин дә аңа карап уйларның төрлесен күңеле аша үткәрде. «Җәнҗалчы, астыртын, әләкче, шымчы бер адәм иде. Үзгәргән бу чепи күз! Теге чакта мин аңа байтак сүзләр ычкындыргаладым бугай. Һәммәсен хәтерендә бикләп торадыр әле! Җаен сагалыйдыр! Бу бәндә минe төчкермичә дә сатып җибәрәчәк! Әгәр минем өскә сыек кына күләгә төшсә дә... Ярамый! Һич ярамый! Төтен тарала башласа, аның уты да бәреп чыгачак!.. Авылдан качып китүемне моңарчы искә алган бер генә кеше булды! Сәрвәр генә. Сәрвәр — явыз түгел, әйтер дә — бетерер дә! Әмма ләкин, бу үзен әүлия санаган иблискә кучәр башы кагылып китсә... Эх, шушы мичкә тыгып яндырасы иде үзен!»

Утыралар ике кеше тәмәке пыскытып, читтән караганда: «Менә дуслар ичмасам болар! Ничек матур итеп гәп сугалар!»— дип уйларга мөмкин.

Уйларның карасын уйладылар, телләр генә бүтәнчә сөйләде.

— Әле колхозга да булышып йөрисең икән, Абдрахман әкә. Ярый, ярый.

— Син дә, Айсетдин туган, ару гына хезмәт иткәнсең икән! Рәхмәт, рәхмәт!

Айсетдин сугышта булганнарны, күргән-белгәннәрне сөйләргә һич яратмый иде, ике-өч сүз белән генә сүзне кыскартты.

— Тырыштык, Абдрахман әкә, сынатмадык.

Ә Чырыкның гел шул хакта сорашасы килә, тотты да:

— Бу Уразайны әйтәм, ранный булганына кайчан, һаман кайтармыйлар үзен.

— Сугышка бармас өчен госпитальдә качып ята ич ул! Йә бер-бер әгъзасын бозгандыр. Уразай җүләр түгел!

— Булмас, энем.

— Ник булмасын?

— Уразаев кебекләр алай итсә, шулкадәр көчле фашистны кем куар дисең! Куалар бит, выжгытып куалар! Син, энем, хәзер олы кеше. Кеше сөйләсә дә тузга язмаганнарны телеңнән ычкындырып, алдагы тормышыңда көлкегә кала күрмә!

Айсетдин башын күтәреп үзен көтеп торган кара айгырына карады: бу карт тәре акылыннан шашканмы әллә?.. Рәис белән дошманлашырга телиме? Кем рөхсәт иткән аңа рәискә акыл өйрәтергә! Тубыл кадәр Тубылда аңа «ләббәйкә» дип тәлинкә тоталар, янында юргалыйлар, ә бу нидер кыландыргандай итә. Берәрсе котыртамы? Айсетдингә каршы чыгарга оешып маташалармы?.. Бүген аның килүенең максаты бик гади һәм ап-ачык иде. Беркөн Шәгъбикәне ире янынннан өерләп алып чыгып киткәч, Булат хатынны нык кына ярган икән. Сыртын ачып күрсәтте, камчы эзләре бөгәрләнеп-бөгәрләнеп яткан хатынның ап-ак, йомшак тәненә! Айсетдиннең чибәр Миңнурый артыннан кыдырып йөргән көннәре. Ачуың да килерлек шул, валлаһи, шашарсың да: биш көн мөгаллимә кызның артыннан чаба, ә тегенең качуы качу! Һич койрыгын тоттырмый. Юньләп сөйләшми дә... Менә шушы тинтәк Чырык ишеләр сүз тараталар, кызга гайбәт ирештерәләр булыр!.. Ирлеге кызган Айсетдин Миңнурый тирәсендә ялманып, күңеле басылмаслыгын аңлагач, Шәгъбикә белән тагын очрашырга теләгән иде. Авыл арасында, адәмнәр күзе алдында очрашырга ризалашмады Шәгъбикә: «Тап бер җайлы урын!»—диде. Айсетдин Шәгъбикәне шушы тирәгә алып килеп гыйшыкгыйшык уйнарга ниятләгән иде, бу килүе аның нәни генә разведка кебегрәк иде! Бакса, монда бер карачкыны аның юлына чыгарып басырып куйганнар.

Бу әңгәмәнең уңай ягы да булды, «разведка»сының максатын Чырыкка ычкындырып ташламады Айсетдин. Яшерен гамәлләр ярдәмчеләрсез барып чыкмый, гомер-гомергә шулай килгән. Айсетдиннең һәр тармакта үз кешеләре, «уң куллары» булырга тиеш. Чырыкның соңгы вакытларда нык үзгәргәненә тәмам төшенде Айсетдин. Юк, бу кеше ул белгән Абдрахман түгел, авызыңны ачмасаң, телеңнән каптырып алыр бу әрлән! Күр инде, гомергә дошманы санаган Уразайны яклап маташа! Уразай кайтсын гына! Каты көрәш заманасы икәнен Айсетдин аңлый... Уразайның Колчак белән сугышып йөргәндә бик шикле рәвештә исән калганын хәтерли Айсетдин! Шул бер гамәлен казып чыгарып кәҗә җиктерәчәк ул Уразайга! Кайтып кына карасын!..

— Ярый, Абдрахман әкә, эшләрең уң булсын! Район кыса, һәр эшне тизләтергә кирәк.

Һәм рәис капылт кына китеп тә барды. Трантас артыннан күтәрелгән әче тузан Чырыкның борын тишекләрен эзләп тапты, озак кына төчкертте картны! Айсетдиннең кытыр-мытыр гына сөйләшүе, саубуллашмыйча да китеп баруы аны нык кына рәнҗетте. Ләкин рәнҗерлек сәбәпләр алда булган икән...

Өч көннән соң, өенә кайтып йокларга ятыр алдыннан гына Абдрахман әкәнең мич кырыйларына кыздыргычка чыра таратып кибәргә куймавы исенә төште. Ул эшне мич җылы чакта башкарырга кирәк иде. Кипкән чыраң юк икән, көне буе мичкә утын үрләтә алмыйча җыгың чыга. Ул кырык ямаулы кыштыр тунын киеп, аягына кәвешен элдереп

кыбырсып чыгып китте. Әвен ишегеннән кереп, һичбер шөбһәсез-нисез сукыр лампасын кабызып җибәрде. Кыштырдаган ят тавышка борылып караса, ни күзе белән күрсен: ләүкәдә Айсетдин белән Шәгъбикә сөешеп яталар икән. Башта карт югалып калды, тез буыннары бушады, аннары тамагын кырып куйды. Соныннан бер-ике сүз әйтергә дә кыюлыгы җитте.

— Икмәк ята торган урында! Ходай орыр үзегезне. Җир йотар!

Айсетдин чалбар балагына аякларын тыга алмыйча сикергәләп:

— Артык күпне күрәсең! Онытма: теленне тыймасаң, җаныңны җәһәннәмгә олактырырмын! Киптерер иген юк, кайсы шайтан кушып монда тилереп йөрисең? Минем арттан шпионлык итәсеңме, карт пәри?!

Айсетдиннең соңгы сүзе аерата нык рәнҗетте Абдрахман Чырыкны. Әлерәк кенә аны әүлия санадылар, көлчә пешереп, баллап чәй эчерттеләр. Ә монда гөнаһлы гамәл кылып, ир хатынын монда сөйрәп китереп аздырган албасты ни ди бит!

— Кем кемнең җанын җәһәннәмгә олактырыр бит! Синең дә кем икәнлегеңне беләбез!

Айсетдин бер сикереп карт янына килеп җитте, таза, көчле бармаклары белән Чырыкның гел сеңердән генә торган нәзек муенын буа башлады. Шәгъбикә килеп җитеп ике арага кермәсә, белмим, бу очрашу ничегрәк тәмамланыр иде икән?!

Абдрахман әкә Айсетдиннең кыланышларыннан таң калды, бу хәлләрне акылына сыйдыра алмады. Аның уенча, язык кылганда тотылган адәм, җирдә аунап аннан гафу сорарга, кат-кат тәүбәгә килергә тиеш иде!..

Айсетдин бөтенләй бүтәнчә уй йөртте: «Колхозга, авылга, кешеләрнең һәрбарчасына ул хуҗа! Кешеләрнең кылган гамәлләренә дә ул хуҗа! Бу тиле-миле карт рәисне күрүгә, ук булып атылып чыгып чабарга һәм теленә катлы-катлы бик салырга тиеш иде! Ә ул, әче әрем, әрепләшеп маташа бит әле!»

Абдрахман әкә, чыннан да, чыгып чапты, бу языклы урыннан тизрәк ераклашырга тырышып йөгерде. Эсселәп, кыптыр тунын чишеп, җилбәгәй бара башлады, бер кәвеше төшеп калды, иелеп аны алмады. Тыны бетеп, күкрәге кысылып тыкрык башына туктап калды. Кабырга араларын дәү келәшчә белән кемдер кыса кебек тоелды. Атларга тырышып карый, нидер җибәрми. Авызын зур-зур ачып күкрәгенә һава тутырырга тырышып азаплана — ачык авызга һава керми!

Ә күңеле һаман рәис Айсетдин белән тарткалаша! «Зинахур!» дип атый ул аны. «Анау елны да Уразай хатыны артыннан ятсызларча сөйрәлгән идең гуй!.. Булатын әйтер идем, шул ачкүз хатынына хуҗа була алмады!.. Боерган булса, мин моны болай гына калдырмам. Иген өстендә, җир-суларны мәсхәрәләп... Иртәгә үк Тубылга барам! Рәиснең чаптар айгырын җиктереп. Нибуч җигәрсең! Күчер итеп кузлага утыртам әле мин ул йолкышны!»

Уйлары чәбәләнгән карт аңына килә, күкрәген, җилкәдә калак сөяге асларын чолгаган авыртуга чыдый алмыйча ыңгырашып та ала...

Гыйззәтбану түти шул көнне генә Сәгъдетдиннән сөенечле хат алган иде. «Сүзләр йөри, безнең эше карт-корыларны илгә озаталар, дип сөйләшәләр. Бирсен ходай! Исән-аман илгә кайтып күрешергә насыйп итсен!» — дип язган. Мондый хат алган кичтә Гыйззәтбану түти өйдә утыра алмады, җыенды да кызлар янына китте...

Тыкрык башында караеп торган багананы күреп ул әсәреп тукталды. Ничәмә вакытлар көн-төн үтеп йөри, бер дә багана шәйләгәне юк ич анын... Чекерәеп, карангылыкны тишеп-тишеп карый Гыйззәтбану түти, кара багана дигәне кымшанган да кебек, тавышы да бар сыман. Үз авылында кемнән курыксын Гыйззәтбану, җил-җил атлап килеп җитеп караса... багана түгел, Чырык Абдрахман атынып тора, имеш.

— Нишләп монда торасың, Абдрахман әкә?— диде ул картны танығач.

Абдрахман җавап бирергә, хәлен аңлатырга итенә, бугазыннан ата каз ысылдавына охшаш бер тавыш кына чыга. Кайда култыклап, кай араларда биленнән тотып Гыйззәтбану түти Абдрахман әкәне үз өенә алып керде, сәкегә яткырды, баш астына мендәр салды.

Шунда, баш астына йомшак мендәр таралып яткач, картның сызлаулары сүрелгәндәй булды, калак сөякләре тирәсе сулыгып-сулыгып авыртудан туктады. Һәм Абдрахман карт үзенең әҗәле килеп җиткәнлеген аңлады. Гомеренең азагына кереп баруын төшенде. Уразай мөгаллимне нык көтә иде карт! Элек кылган хаталары өчен аннан гафу үтенергә тиеш иде. Фаягөлне эзләп табуы белән дә озаклап, тәмләп сөйли-сөйли мактанасы килә иде аның. «Мин дә төшеп калганнардан түгел, мөгаллим, халыкка, авылыма байтак яхшылык эшләдем!»— дип үз-үзен аклыйсы килә иде. Уразай мөгаллим аны аңларга тиеш! Аңлар да! Инде Җәбраил фәрештә белән дуслашып кына килгәндә, каян шулай ашыгып килеп җитте соң бу Газраил дигәннәре...» Карт бер минутка гына онытылды һәм Газраил дигәннәре, рәис Айсетдин кыяфәтенә кереп, аны тотып алды, бугазын буа, типкәләп эчен изә башлады.

Гыйззәтбану түтинең үзе кебек үк өлгер самавыры кайнап чыкты, капкач тишекләреннән сызгырып пар ургылды һәм шул тавышка Абдрахман әкә аңына килде. «Минем гомер дә шулай сызгырып бушана бара»,— дип уйлады ул һәм тагын бер мәл иссез ятты. Гыйззәтбану түти аңа бал каптырды, кайнар чәй йоттырды, карт чалкан ятып күзләрен йомгач җәһәт кенә чыгып китте. Гыйззәтбану түти күршеләргә дәшеп, аларның олы кызларын мөгаллимәләрне алырга җибәрде. «Булган даруларын да калдырмасыннар, Абдрахман әкәнең хәле бик яман!»— дип әйтеп калды.

Абдрахман әкәнең авыртулары кимеп, җиңеләеп калгандай булса да, һушы таралган, зиһене томаланган иде. Ул Гыйззәтбану түтинең аяк очларына гына басып чыгып киткәнен дә, мышкылдап кайтып кергәнен дә ишетте. Әйтер сүзләре тел очына килде, әмма көче-куәте җитмәде. Күзе ачык булса да, йомылса да каршысыннан Газраил-Айсетдин китмәде. «Айсетдин белән Шәгъбикә»,— дип кычкырырга теләде ул, тавышы чыкмады, шөкер, Гыйззәтбану түти аңа иелә төшеп карап тора иде, картның «Айсетдин... Шәгъбикә...» дигән сүзләрен аермачык ишетте.

— Айсетдин белән Шәгъбикәгә әйтеп калдырыр сүзләрең бармы әллә, Абдрахман әкә?— дип сорады ул һәм күңеленнән рәнжеде: «Үләр алдыннан шул кара йөзләрнең исемен яд итеп ятмасаң!»— дип уйлады.

— Айсетдин белән Шәгъбикә...— дияргә тырышты тагын Абдрахман.

— Нигә шул ике исемне бергә кушып кабатлыйсың?— дип сорады Гыйззәтбану түти. Ләкин картның теле юк иде инде.

Аннан-моннан гына киенгән мөгаллимәләр ашык-пошык кереп җиткәндә Ялан авылында шактый еллар яшәгән, кайгысын да, хәсрәтен дә мул кичергән Абдрахман Чырык өзелгән иде инде.

«Котылган инде, әйдә, авыр туфрагы җиңел булсын»,— диде күпчелек халык. Айсетдин бу әҗәлгә астан гына чиксез сөенде. Ләкин мәрхүмнең соңгы сүзен Гыйззәтбану түти, төрле юраулар катнаштырып, укытучыларга чишкән иде. Әллә үзенең авызыннан чыгып ычкынды, әллә бүтәннәр бик теләп бу хәбәрне тараттылар: картның әҗәле рәис белән аның мәгъшукасы исеменә барып ялганды. Хәбәр коры саламга барып ябышкан ач ут кебек кайта-кайта, арта-арта авыл арасына таралды һәм Айсетдин белән Шәгъбикәнең арасын ябыштырды.

Яланлылар Айсетдин дисәләр, Шәгъбикә исемен кушып җибәрделәр. Шәгъбикә дигәндә, рәис исеме аңа үзеннән-үзе кушыла торган булды. Айсетдин мондый халәткә — «агылый-тагылый» кушаматына чик куярга

булды. Миңнурыйның бер генә минутка да үзе янында ялгыз калырга теләмәвен дә ул Шәгъбикәдән күрә иде.

Шәгъбикәнең кыланмышына читтән генә карап түзеп торган кеше Яланда бары тик ире Булат кына калды. Гайбәтләрне җылы килеш аңа да китереп җиткерделәр, ул аларны исе китмәгән кыяфәт белән тыңлады. Ләкин Булат та тик ятмаган икән. Омск каласына, Мәрзияне чакырып телеграмма суккан. Почта алырга баргач, җавап телеграммасын беренче булып Шәгъбикә укыды. «Фәлән числода юлга чыгам. Сагындым. Үбәм» дигән иде Мәрзия.

Шәгъбикә иренең сүзсезлегенең серен аңлады. Телеграмманы тапшырыргамы, юкмы дип шактый баш ватты, ахыр чиктә, Булатка кайтарып тоттырды. Булат эндәшмәде, аңлатмады, укып телеграмманы кесәсенә салып куйды да Шәгъбикәгә тирән мәгънәле, кискен, үтә кискен карашын ташлады...

## 33

Мең бәлаләр белән төсен үзгәртеп, ялган, әмма ышанычлы документлар юнәтеп Ялан авылына кайтып тукталырга карар кылган Айсетдин үз тормышы болай башланып китәр дип күз алдына китермәгән иде, әлбәттә. Юлдашлары, үзе шикелле үк гитлерчылар ягына үз ирекләре белән авышкан сатлык җаннар, сугышның немец файдасына борылмаганын күргәч, җайлап-җайлап төрле илләргә сыпырта башладылар. Айсетдин чит илгә китеп олагырга теләмәде, үтә куркак иде ул, үз илендә җиңеллек көтмәгәнен белгән хәлдә, очраклы гына бик ышанычлы кәгазьләр юнәтеп Себергә кайткан иде. Себер татарлары арасына. «Үз татарың үз татарың булыр әле, бер тукмаса — бер сыйпар!» — дип юатты ул күңелен. Кайтты, менә дигән итеп каршыладылар. Бусы ул көткәннән дә артыграк булды, яши, ләкин тормышы бер дә ул уйлаганча түгел. Документлар, үткәндәге гамәлләр тулысынча алышынып бетсә дә, Айсетдин бер нәрсәне искә алмаган иде: чир китсә дә, гадәт китми икән!

Үзенең гөнаһсызлыгына бүтәннәрне ышандыра-ышандыра Айсетдин үзе дә шуңа күнегеп килә иде, инде күпме авыр юллар үткән, үзе авыр юлларга ничаклы адәмнәрне дучар итеп, упкынга этеп төшергән кеше яши-яши тагын хаталар кылып ташлады. Шәгъбикә белән нигә тагын кети-кети уйнап маташырга иде? Беткән идеме аңа Яланда иseme-чабы чыкмаган мыймылдык хатыннар?!

Чырык Абдрахманны җиренә җиткереп күмделәр, җеназа чыгымнарын Шәгъбикә янчыгыннан алып Айсетдин түләде. Карт гүрдә, ә тавышы көннән-көн ныграк арттырып кайтаваз булып яңгырый.

Айсетдиннең тынычлыгы тәмам югалды. Өй ишеге ачылган саен аның бите тартыша башлый, йөрәген нидер чеметеп ала. Төннәрен мич арасында таракан кыштырдаса да, мендәр астыннан парабеллумын тартып чыгарып, караңгылыкның күзенә текәлеп ниндидер хәвеф, әшәкелек көтеп тора... Ничәмә-ничә кешенең башына җиткән коралның тимер суыгы, кулы аша йөрәк бәгыренә күчә. Аны калтыравык ала. Караклардай ары-бире ялт-йолт карана, ишегалдына чыгып китә, капка бикләрен кат-кат тикшереп, ишек келәләрен тартып-тартып күздән үткәреп чыга. Озак йокыга китә алмаса, эчне җылытырлык итеп әз-мәз салгалап куя.

Гади шул кешеләр, аны-моны уйламыйча орден-медальләрнең тарихын белергә теләп сораулар биреп куялар! Айсетдин һәр бүләккә үз легендасын әзерләде, ялганын ялганга кушып, тора-бара үзенең сөйләгәннәренә үзе дә ышана бара. Аңа хәтәр хатирәләрдән арынырга, яңа легендалар яктылыгында яшәргә кирәк иде.

Башыңны бәлагә тыгып, кулыңны иблискә тоттырсаң, муеннан пычракка батасың икән! Волхов фронтында беренче бәрелештә үк ул үзе

теләп немецлар ягына чыкты. Фашист көчле иде, ул бөтен фронтларда җиңеп Мәскәү янына ук житеп куйды. Кырды немецлар Рәсәй халкын, сугышта да кырды, өйдәгеләрне дә жәлләп тормады. Айсетдин яшь иде, аның яшисе килде, әле дөньяның нинди рәхәтен күргәне бар аның?

Фашистларның ыжгырып, урыс гаскәрен өзгәләп, теткәләп килгән чагында Германиянең җиңеп чыгачагы аңарда һичбер шик тудырмады.

Чолганышта калган иптәшләре барлы-юклы патроннарының соңгысына хәтле сугышып, кан койганда, Айсетдин немец шпигы мул сыланган ак күмәчне мүкелдәтеп утыра иде. Куеныннан Геббельс листовкасын чыгарып салгач, немецлар «гут-гут!» дип аның аркасын как-тылар...

Күпмедер вакыт ул немецларның тугры ялчысы булды...

Ниләр күрмәде сугыш елларында ир-атлар! Хәзер ни тырышсаң да, никадәр сак вә акыллы булсаң да җилкәнә Гитлер ябыштырган бөкерене селкеп кенә төшереп, аннан котылып булмый икән... Дөрес, әлегә Айсетдинне куркуга салырлык тикшерү дә, шикләнү дә юк. Инде каһәр суккан Шәгъбикәгә бәйләнмәгән булсачы... Миңнурыйны дөбердәтеп куенына ала торган көннәр иде ләбаса!...

Кара айгырның башын баганадагы тимер божрага тарттырыбрак бәйләп калдырган, ахрысы, чаптар башын чайкап авызлык тимерләрен чылтырата, тоягы белән каткак җирне казый. Айсетдиннең чыгып тезгенне бушатасы килми, авыр уйлар бөтен барлыгын ялмап алган егетнең кузгаласы да килми. Бәхетсезгә вакытсыз, дигәндәй, бүлмәгә Сәрвәр килеп керде, ипле генә итеп сәлам бирде, утырыр урынын бармагы белән сөртеп карагач кына утырды, рәискә карады.

— Айсетдин иптәш,— диде ул шактый нык тавыш белән.— РОНОдан телефонограмма килде. Безнең мәктәпкә дә китаплар, әсбаплар бүлеп биргәннәр. Кичекмәстән килеп алыгыз, дигәннәр.

— Шуннан?— диде төксе Айсетдин.

— Шуннан шул, ат кирәк.

— Ат? Каян алыйм ди мин аны? Сез, хөрмәтле иптәш, колхозда ничә ат барлыгын, аларның хәзерге сәгатьтә нинди эшләр башкаруын беләсез булыр. Атлар дәүләткә ашлык илтә киттеләр.

Хисапчы Шәехов, кара җеп белән колак артына тарттырып куйган, бер пыяласы чатнаган күзлеген рәтли-рәтли чут салуыннан туктады да рәискә таба борылды. Ертык авызлы кесәсеннән каңсасын алып, аны бармагы белән баса-баса эре йомычкалы самосад белән тутырды, кабызырга дип Айсетдин янына килеп басты. Шырпы рәистә генә бар иде. Рәис хисапчыга карамыйча гына янган папиросын аңа сузды. «Беломор» очындагы утны каңсасына терәп хисапчы шактый вакыт пыс-пыс итеп торды. Тәмәке зәһәре Шәеховның арган миен ачып җибәргәч, хисапчы тыңкыш авазлар белән сүзен кыстырды:

— Җирән кашка өйдә бит, Айсетдин. Аты юаш, ипле, адымы да нык. Бир шуны.

— Ул атның почта йөртергә билгеләнгәнен үзең беләсең.

— Моңарчы почтаны җәяү генә барып алалар иде түгелме?

Нибарысы ике чакрым юл үтәсе. Почтасын әйтер идем гуй, ике гәҗит, ярты хат!— Шәехов курка-курка гына үзенең әйткәнен яклады.

— Шәехов!— диде Айсетдин тавыш күтәреп.— Карыйм мин сиңа һәм гаҗәпләнәм. Председатель юк ди икән, араныңда ник утыз ат тик тормый, син аның сүзен куәтләргә тиеш ич!

Шәеховның юаш кына теләктәшлеге дә Сәрвәргә көч бирде.

— Айсетдин, диде ул, директор кеше тавышы чыгарырга тырышып,— Шәехов абый дөрес сөйли, әлегә кадәр бер генә рәис тә почтага ат кумады. Шәгъбикә эшкә алынгач кына почтаны җәелеп утырып бары ул ала. Ни өчен аңа шундый өстенлек бирелә әле?

— Анысында синең эшең булмасын.

— Мин атны үзем өчен сорамыйм. Болай да китап-дәфтәрләр әз кайта. Көнендә барып алмасаң, андагы башлыкларның да Шәгъбикәләре бар! Шундук йомдырып куялар. Йөр соңыннан эзләп китапларны!

— Җирән кашка бик иплe ат! — дип өстәде Шәехов кансасын суыра-суыра. — Адымы да җитез!

— Юк кына нәрсәдән проблема ясарга яратасың син, Сәрвәр.

— Айсетдин! Заманында син мөгаллим идең. Шул чакларны истә тотып әйтәм: авыл арасында яманатың таралып ята. Кайберләренә ышанмый да идем, хәзер күрәм: дөрес сөйли халык. Һәм син аларның авызын тегеп куя алмассың. Абдрахман әкә сезнең исемнәрне бергә тегеп җан биргән. Аның ни әйтергә теләгәнен халык төрлечә фараз итә! Мин бәләкәй арба тартып Тубылга китәм. РОНО белән райком янәшә, шуны онытма. Мин әләк-чәләк белән йөри торган җан түгел, әмма ләкин мәктәп, укучылар дигәндә мин синең белән дә тартышырга әзер!

Сәрвәр ишекне шапылдатып ябып чыгып киткәч, Айсетдин ачуыннан буылып Шәеховны камап алды.

— Син нәрсә, ишек колагы! Кычытмаган җирне кашып, ат дагалаганда танавыңны сузып кыстырып утырасың! Күрәсең ич, Сәрвәр мөгаллимә бер дә аттан ким түгел! Подумаешь, барыня! Утынын китер аңа, ремонт ясат, атын бир!.. Шәехов, бар, ай-ваена карама, Шәгъбикәне идарәгә алып килеп җиткер!

— Шәгъбикәне? — Шәеховның бу соравында күпме ачу барлыгын Айсетдин дөп-дөрес аңлады һәм икеләнергә урын калдырмастай итеп:

— Әйе, почтальон хатынны алып кил.

Шәгъбикә атын җигәргә ниятләп, киенеп-ясанып почта алырга барырга җыенып йөри иде, «рәис чакыра», дигәч, бераз аптырап калды. Рәиснең аның белән бүген очрашырга теләге юклыгын хәйләкәр хатын чамалый иде. Айсетдин тәрәзә каршысына басып, туктаусыз папирос пыскытып каршылады аны. Шәгъбикә артыннан ук килеп кергән авыр аяк Шәеховка чыгып торырга кушты. Алар идарәдә икәү генә калдылар.

— Шәгъбикә! — Айсетдин җайлы сүз эзләп кесәсенә керде, аннан таушалган «Беломор» кабы тартып чыгарды, калтыранган бармаклары кесәсеннән сүз эзләп таба алмады.

Хәзерге мизгелдә икесенең дә язмышы хәл ителергә тиеш. Шул сүзне эзләп табарга, аңа тиешле юнәлеш биреп, язмышын җиңеләйтергә тиеш Айсетдин. Шәгъбикәгә дә хәсрәт төшкән бүген! Булатның бер кызып китсә, иңе белән таулар күчерәсен белә ул хәзер, әгәр Мәрзиясе килеп төшсә, йортта аңа урын калмас! Калса да, ул хезмәтче хәлендә яшәргә мәҗбүр булыр! Моңарчы үз тормышының тоткасын үзе кысып тоткан үзсүзле, текә хатын Булат белән Мәрзия хезмәтчесе булып яшәргә риза түгел! Һич! Күзен чокып алыр Мәрзиянең, Булатның тамагына балык кылчыгы булып кадалыр! Тик Айсетдин генә аны ташламасын! Ник кырык чөйләре кырылып бетми яланлыларның, ник Шәгъбикә исемен тәсбих итеп тартып көне-төне телләрендә әвәләмиләр — Айсетдин генә аны ташламасын! Ялан гына димәгән ич, тарсынсалар, торага күчәрләр. Түмән-Ишим якларына китеп барырлар. Тик бергә генә булсыннар!.. Байлыгы да җитәрлек Шәгъбикәнең! Кайда да югалмаслар.

Рәиснең ут-сөрем томалаган чыраен күрүгә, Шәгъбикәнең балтасы суга төшеп китте: тагын нидер булган. Шәгъбикә Айсетдиннең куркак, котан батыр икәнлеген аңыша башлаган иде инде. Тагын өркеткәннәр рәисне. Аның мондый пошаман кыяфәткә кергәне юк иде моңарчы.

— Безгә сөйләшергә кирәк, — диде Айсетдин. Гәрчә аның кыяфәте бер дә сөйләшергә, аңлашырга әзер кебек түгел иде.

— Ни булды? — диде Шәгъбикә тавышын чак-чак ишеттереп.

— Эшләр харап! Чырыкның үлеменнән гаеп табарга тырышалар һәм гаепләнә эзлиләр.

— Бәй, эзләсеннәр! Тапсыннар әйдә. Җитмешне үткән картның үлеме кемгә тигән икән?

— Аның үлеме бер сәбәп кенә. Асылда сине-мине яратмыйлар. Сине күрә алмыйлар!

— Мине? — Шәгъбикәнең чырае ямьсезләнде, муенын сарган җыерчыклары чәчрәп беленә башлады. «Шушы әбигә бәйләнмәгән булсамчы!» — дип уйлады Айсетдин әрнеп.

— Үзең дә беләсең, авыл хатын-кызлары арасында тормышын алып бара, авырлыгын җиңгән бердән-бер хатын син булып чыккансың. Ирең дә бар. — Айсетдин елмаерга теләде, елмаюы барып чыкмады. — Сөяркә дә тотасың. Әнә шул хәлләр адәмнәрнең тамагыннан үтмәде. Хәзер Чырыкның теленнән ычкынган сүздән гаеп тапмакчылар. Миңа әлеррәк кенә прокурор шалтыратты. Без иртәгә торага, аның катына барырга, җавап тотарга тиеш.

— Барырбыз соң, — диде исе китмичә генә Шәгъбикә.

— Күрерсең күркәңне алар кулы арасына барып керсәң!

— Син ни кушасың соң?

— Безнең беребезгә авылдан югалып торырга туры килер.

Шәгъбикә танавын тартып куйды.

— Миңа югалырга кушасыңдыр инде? Үзең югалам дисәң, мине чакыртып тормас идең.

— Сиңа, Шәгъбикә, сиңа! Хәзер болай ит: Сәрвәр мөгаллимә кул арбасын тартып РОНОга китте. Атыңны җик, аны куып җит. «Минем дә Тубылга барасым бар», — диген. Торада атны Сәрвәргә калдыр да, күзгә күренмичә генә берәр яры тай. Югалып тор, зинһар. Үз вакытым белән мин сине эзләп табармын.

Шәгъбикә көлеп куйды.

— Ни кызык табып көлә аласың?

— Юк инде, Айсетдин рәис. Картның бугазыннан мин алмаган, буарга ябышмаган. Аның муенында синең бармак эзләрең! Эзләп ала, имеш. Юк, минем кирәгем калмады сиңа. Синең Миңнурый гүзәл артыннан сөйрәлүеңне ишетмәдем дисеңме? Барысын да беләм. Мин сине тыңладым, мине тыңлап бак: китсәк, икебез дә авылдан китәбез! Бергә! Минем синнән аерылыр мәлем юк. Шул менә сиңа.

Айсетдин тагын бер мәртәбә: «Ник бәйләндем мин шушы убырлы карчыкка!» — дип сызанып уйлады. Һәм Шәгъбикәне үгетләргә керешге. «Яратам» диде, «Миңнурый сине алыштыра торган хатынмы соң?» дип тасма телләнде. Җыламсырады, ялган антлар эчте.

Шәгъбикә аның сыңар сүзенә дә ышанмады. Тик бер нәрсәне ачыклады: үҗәт кеше икән Айсетдин, бер кискәнне кире ябыштырачак адәм түгел! Муенына бау салсаң да моннан ары ул Шәгъбикәгә борылып карамас!

Булат яшь кәләш алып кайтса... Айсетдин өйләнәме-юкмы, моннан ары ул Шәгъбикәгә юл биреп, якын итеп торачак түгел. Утыртып куярга да күп сорамас бу кансыз зобани... Китәр Шәгъбикә, тик үзенең көче барлыгын, көчен сиздереп китәр!

— Бел! Үз сүземнән кайтырга яратмыйм. Әйе, тавыш-гауга тынганчы китеп торам. Сәгате суккач хәбәр итәрмен: килеп алырсың мине!

— Кайда булырсың соң син?

Шәгъбикә сөенгәндәй көлеп җибәрде:

— Анысы инде, бөркетем, әлегә сер! — диде.

Айсетдиннең хатынны эттән алып эткә саласы килде, дәшмәде, кай ара телне тешләп торуның иң уңай гамәл икәнен әллә кайчаннан үзләштергән иде ул. Әмма иске холкы үзенекен итте, хаталарны тагын ясап ташлады.

Гобәйбәнең күзен кыздырган ундүрт чемодан, чыннан да, Булатларның чоланында тезелеп тора иде. Базга күмелгән алтын-көмешләре дә бар иде Шәгъбикәнең. Иренең йортта юклыгыннан ул тулаем файдаланды, яшерелгән хәзинәсен казып алды, атын җикте, чумаданнарны әйбәтләп, баулар белән ныгытып бәйләп арбага төяде һәм сәфәр чыкты.

Булат Мәрзияне алып кайтып өйгә кергәндә чолан ишеге шар ачык, өй ишеге дә ябылмаган, өй эчендә дә әйберләр күзгә күренерлек кимегән, ә чолан бөтенләй буп-буш иде.

Йортта Шәгъбикәнең бердәнбер теләге булып пианино гына калган. Җиһазлар тыгыз чакта ул әллә ни күзгә бәрелми торган иде, хәзер кап-кара булып ялтырап, хатынының кара язмышы булып кәперәеп утырган кара тартма Булатның күзен кисте. Ул тешен кысып урамга чыгып китте, хәллерәк абыстайларны җыештырып кайтты, алар пианинонны кул арбасына чыгарып утырттылар һәм сәгате-минуты белән мәктәпкә илтеп бирделәр. Казан кызы — иркә Зилә, пианинонны күргәч, кулларын чәбәкләде.

— Балаларга бездән бүләк. Мәрзия белән икебездән! — диде Булат.

Зилә ак-кара клавишларга баскалап пианинонны көйләргә керешге. Аның бәхетенең чиге юк иде.

Шәгъбикә исә бөтенләй бүтән якка, Тубылга артын куеп юлга чыкты һәм күңеленнән генә: «Биргәннәр иде ди сиңа ат. Кара айгыр сиңа миннән бүләк иде, җирән ат синнән миңа бүләк булсын!» — дип кабатлады.

## 34

«Юл газабы — гүр газабы!» — дигән безнең борынгы бабаларыбыз. Бу хикмәтле сүзләрне алар бик белеп, күп сынамышлар кичергәннән соң гына әйткәннәр! Татарларның ташкын булып илләр гизгән чаклары булган, тарих битләрен актарсаң, анда татарның бик күп юл-сукмакларын күрербез. Татарны данга күмгән юллар да байтак булган, милләтне оятка калдырганнары да очраган. Дөнья ул!

Килен-бала төшеп өлгерә алмаган, ул Шамиле белән язылышмаса да аннан ир бәбәй тапкан, тәвәккәл, сөйкемле, теле җырлап, күзе көлеп кенә торган Зосяны ияртеп ерак-еракларлан, Белоруссиядән Көнбатыш Себер якларына, Иртеш үзәнлегенә ерак сәфәргә чыгып киткәндә Мөхәммәт Уразаев үзенең хәтәр юлга төшәсен чамалый иде, әлбәттә. Уй — бер нәрсә, уйны да тиз-тиз артка калдырасың, тормышның чынлыгына батсаң... башны еш кына кашырга, аптыраудан телсез калырга да туры килә.

Ни әйтсәң дә сугыш чоры көзе! Немецларны Рәсәй киңлекләреннән пыр туздырып куа башладылар, инде җиңүнең кайсы якка булачагы ачыкланган диярлек. Әмма Берлин — фашистларның мәркәзе әле еракеракта, аңа кадәр солдат гәүдәләреннән бик озын күпер саласы бар. Тимер юл — армиянең төп таянычы, ул гаскәрләрне, коралларны әллә кайлардан төяп чыгып һәркөн, һәр сәгать фронтка җан, мылтык-туплар-ны биреп торырга тиеш. Тимер юл — гүр газабы гына түгел, сугыш чоры тимер юллары җәһәннәм астының үзе, станцалар тирәсендәге буталышларны бәян итәр өчен сүзләр бер телдә дә яралмаган.

Поездлар, поездлар... Тәүлекнең кайсы вакытында карама поездлар үкереп, ашыгып, шаулап әрле-бирле, бирле-әрле чабышалар. Һәммәсе фронт өчен, ил өчен!..

Аерым кеше ул көннәрдә чүп! Аны исәпкә тыккан, санаган кеше дә юк, бер генә кагыйдә, бер генә канун да аны якламый. Ул тарих тәгәрмәче астында калып изелгән ком бөртеге, очып барган чыпчыктан төшеп калган каурый кисәге. Ызгыш-талаш, минут саен тарткалашып, чәкәләшеп алулар, вагон өсләренә, баскычларга төялешеп, андагы һәр карыш җир өчен сугышып китүләр, урлашулар, көчләүләр, вокзал хәдимнәренең оятсызлыгы, адәм улларының бәхетсезлегеннән файдаланып калырга омтылучы тыл күселәре — гаскәриләр, хәрби комендатура ишеген катлы-катлы камаган гарип-гораба солдатлар, сукырлар, чукраклар... Сират күперен ул елларда Рәсәй киңлегенең һәр тарафында очратырга була, оҗмахы да, җәһәннәме дә монда иде.

Юл — газап кына түгел икән, озын юл — сыналу күпере да икән әле ул! Моны Мөхәммәт Уразаев белән Зося кайта-кайта, Рәсәйнең очыннан-очына кадәр үтеп кырык тапкыр сынадылар.

Нәни Шамилне күтәреп юлга чыкканның беренче тәүлегендә үк Мөхәммәт Зосяны татарча өйрәтә башлады.

— Өйрән, безнең телне ятрак бел дип әйтмим, мәгәр миңа «әти» дип эндәш. Минем өчен дөньяда иң-иң якын сүз ул «әти!»

Зосяның телгә дә маһирлыгы бар икән, шул сәгатьтән ул Уразаевка тутырып ачык итеп «әти» дип эндәшә башлады. Бик борчылган, гасабиланган мәлләрдә генә «папа, папочка!» дип ычкындыра иде. Андый мизгелләр юлда әз булмады, мәгәр Мөхәммәт килененә рәнжемәде, аның үзенең бүре булып улардай чаклары әз булмады шул. Уразаев бер чакта да сер бирмәде, элек тә үтә сабыр, чыдам кеше иде ул, хәзер ят якларга баручы Зосяны һәм томырылып карап яткан нәбәрәсе алдында бигрәк тә сынатасы килмәде. Аның югары дәрәҗәдә тәрбияле, киң күнелле, тәмле телле булуына Зосяның исе китте. Себер татары моңарчы Зося укыган китапларда, телләрдә йөргән зәһәр анекдотларда кысык күзле, кәкре аяклы, чыгынкы яңаклы, саргылт чырайлы, төтенле чумнарда яшәп ятучы ярым кыргый бер халык иде. Зося укыган дәреслекләрдә дә алар кәрлә, капкорсаклы, кәкре кылычларын болгап тәбәнәк арык алашаларга менгән, очлы бүрек кигән вәхшиләр иде. «Ермакның Себерне буйсындыруы» дигән рәсем ул укыган дәреслекләрдә дә бар иде... Нинди мескен, ярдәмчесез, куркак итеп сурәтләнгән иде андагы татарлар!

Озын буйлы, мәһабәт гәүдәле, киң җилкәле, ирләрчә калын тавышлы Мөхәммәт Уразаевны белгән саен аның зиһене ачыла барды. Юк, юк, бу татар урыс китапларында тасвирланган адәмнәргә бөтенләй охшамаган иде. Теләсә нинди һөнәр иясе белән сүзен таба, чатырдатып урысча сөйләшә, немецчә дә аңлый икән, солтанатлы олпат ир иде аның кайнатасы. Көймәләре комга терәлгәндә, ашарларына ризык тәмам беткәндә, ул кыю рәвештә ишекләрен ачып вокзал комендантлары янына барып керде, интендантларны эзләп тапты, адым саен очрап документ сорап, тикшереп борча эзләгән патрульләр белән дә елмаеп кына гәпләште, вокзал начальниклары белән йомшак кына бәхәсләште, сүзнең кадерен белеп, иң кирәклесен әйтә алды. Кырыс ачулы, ярсыган начальниклар көчле, нык тавышын ишетүгә аның һәр үтенеченә дикъкать иттеләр. Инде бетте, инде өзелдек дигәндә складлар ачылды, балага кирәкле ризыклар табылды, юл документлары рәтләнде. Ата-анасы, әби-бабасы эшлекле кешеләр иде Зосяның. Ул эш арасында, адәмнәрне эштә-хезмәттә танып үсте. Мөхәммәт Уразаевны да ул нужа диңгезен кичкәндә мең кат сынады. Шулай белеп бетергәч кенә, якынайгач, яратып бетергәч Зося аңа эч серен әйтеп салды.

— Әти,— диде ул тавышына яңа аһәң өстәп.— Безнең ерак бабаларыбыз да татарлар булган ич. Без кайчандыр белорус татарлары идек. Бик күптән, бик еракта... Сез бабамны күрә алмадыгыз. Ул нәсел тарихыбызны Шамилгә дә сөйләп өлгермәде... Миңа ул сезгә бик күп гыйбрәтләрне ачып бирер иде!..

Сөенде Мөхәммәт, Зосяның ачылып бетәргә теләп эч серләрен ачуына да сөенде, нәбәрәсенең тамырларында татар каны катнашуына да шатланды.

Юлда бик киеренке мизгелләр дә булды, билетләр алгач, инде кереп утырабыз дигәндә аларның борын төбеннән генә поездлары узып китте. Нәни Шамилнең «йомышы» килеп җитеп, тәпи тотып соңгарак калдылар. Кайсыдыр станцада, кайнаган казанда сикерешкән ярма бөртекләре кебек чәбәләнгән чегән хатыннары Шамилнең чүпрәкләре салынган төенчекне сугып киттеләр. Төннәрнең берсендә ике хулиган корал, акча сорап Мөхәммәт Уразаевның касыгына пычак терәделәр. Ике якта — ике бандит — алар вокзал янындагы куаклыкта төн кунарга җыенганнар иде — караңгы, Уразаевның ике касыгына очлы пычаклар кадалырга

тора. Шунда да каушап калмады ул, пычак арасыннан ничек шуып чыккандыр, бандитларның икесен ике якка сугып очыргач кына, Зося аңына килде. Бала кычкырып җылап җибәрде. Зося ачыргаланып:

— Папочка, сез ничек түзәсез?! — дип сорады.

Мөхәммәт баланы үз кулына алып, вокзал ишегенә якынрак урынга, сыек кына яктылык төшкән мәйданга алып чыкты. Теге явызларның кабат бәйләнүләре ихтимал иде. Нык төшергән иде аларга Мөхәммәт Уразаев, Себер татары.

Баланы кулында тирбәтә-тирбәтә, күзен тирә-яктан аера алмыйча Мөхәммәт Зосяга болай диде.

— Һөнәрем буенча мин укытучы бит, кызым. Ходай мине дөньяга укытучы итеп китергән, бабам да мине укытучы итеп тәрбия кылган. Әбием миңа акыл биргән, Коръән сүрәләрен ятлаткан. Әти-әниләрем дә минем тәрбиячеләрем булганнар икән! Бөтен авылга аларга киңәшкә килә, өметләнгән ярдәмнәрне ала торганнар иде. Кем ул укытучы? Мин шушы сорауга җавапны бер генә эзләмәдем һәм мондыйрак фикергә килдем. Укытучы — шәфкать иясе ул, мәрхәмәт сакчысы. Укытучы җирдә яшәүче адәмнәрне — сез барыгыз да тигез, әнә шул гадел билгеләмәне сакларга тырышыгыз, дип халыкларга акыл биреп кенә утырмый, үз яшәеше, тормыш-әхлак нормалары белән бүтәннәргә мисал була алучы!.. Буш вәгъдәләр бирмәскә, кеше хакында фикер йөрткәндә һәрчак сак булырга, ялгышканда хатаңны таный алырга... Менә аның, ягъни минем тормыш кагыйдәләрем шулар. Гайсә пәйгамбәр, Мөхәммәт пәйгамбәр, Будда, Гандилар үз халыкларының мөгаллимнәре, остазлары булмаган мыни?.. Һәр укытучы — ниндидер бер дәрәҗәдә пәйгамбәр дә ул...

Юлның зур кыенлыкларына, авыр мәшәкатьләренә, вак-төяк ыгы-зыгыларына баш бирмәгән Мөхәммәт Уразаев белән Зосяның исемнәрен якты сүзләр белән яд итик тә, мөхтәрәм укучым, вакланмыйк. Алар кичергәннәрне өр-яңадан кабатлап, нечкәлекләренә кереп тормыйк. Чөнки... Зосяның да: «Нигә чыктым инде бу юлларга?» — дип офтанган мәлләре булгандыр. Мөхәммәтнең дә: «Бу баланы сәфәргә өндәп хата кылмадыммы?» — дип уйлап икеләнгән мизгелләре дә очрагандыр. Кеше тигез юлдан да шома гына, тигез генә атлап бара алмый! Була, гәүдәсен нык тотарга бик теләсә дә, юлдаш итеп Хәзер Ильясны сайласа да чайкалган чаклары була! Аларын бүген телгә алмыйк. Бәби тотып сугыш еллары юлын исән-аман үтә алган Ана язмышы — ул үзе бер маҗаралы китап булыр иде. Алдагы көннәрдә, ходай насыйп итсә, бәлки андый китап та язылыр...

Мөхәммәт белән Зосяның сөйләшеп сүзләре бетмәде. Вакыт-вакыт бу ике изге җан юлны — гүр газабын шатлыклы аңлашу минутларына әйләндерделәр. Башта күбрәк Зося сөйләде. Хәтере шәп кызның, шуның өстенә тәрбияле бала, үткәннәрнең кадерен белергә өйрәнгән. Чират Мөхәммәт Уразаевка җитте, хәзер ул да нәсел җепләре, ата-бабалары, гаиләсе белән яшь киленен таныштырырга тиеш... Каян башларга? Бөтенесен сөйли башласаң... Белоруссия белән Себер арасын үтү генә җитмәс, җир шарын биш-алты тапкыр урап чыгарга кирәк булыр.

Гомеренең кайсы мизгелләре аерата кадерле аңа? Тарихның кай төшләре акылын аерата нык тәрбияләгән?

Зося Уразаевның җавап бирмичә шактый озак баруын үзенчә аңлады һәм:

— Сез, әти, мине без барасы ил белән бераз таныштырыгыз! Һич бер нәрсә белмим икән ич мин себер татарлары турында.

Мөхәммәтнең йөзе ачылды:

— Беләсең киләме, кызым? — дип сорады ул, канатланып.

— Белсәм шәбрәк булыр иде. Югыйсә, сезнең авылдашлар белән очрашкач, чукрак-сукыр булып утырырга туры киләчәк бит! Мәктәпне әйтер идем, бер дә, бер дә дөреслеккә укытмаганнар инде!

Туган җир хакында Мөхәммәткә сөйләргә куш инде! Госпитальдә чакта ул үзе янында яткан яралыларга тулы мәгълүматләр биреп еш кына аларны гаҗәпкә калдыра иде. «Ничек? Шулай булган мыни? Белми идек!» — дип шаккатып тыңлыйлар иде аны...

— Себер халкы, себер татарлары тарихы әз өйрәнелгән, өйрәнелгән кадәресен дә әдәбиятта сирәк кулланганнар. Алтай, Казакъстан археологлары, тел галимнәренең язмаларына караганда, Көнбатыш Себергә, Казакъстан далаларына күчмә тормыш белән яшәп яткан төркиләр VI—VII гасырларда күчеп килгәннәр. Иртеш буйларына килеп төпләнгән шул төркиләр безнең төп бабаларыбыз була инде. Беренче елларда алар шактый таркау төркемнәр булып яшиләр дә, унберенче гасырда акыллы кабиләләр берләшеп, беренче дәүләтләрен төзиләр. Кызганыч, аның нинди исем йөртүен чагылдырган мәгълүматләр калмаган. Үзәгенең Кызыл Тора дип аталуы гына билгеле.

— Кызык, дәүләт булган, иселе сакланмаган! — диде Зося.

— Нишлисең, тарих кайвакытта аяусызлык күрсәтә. Дәүләт Ишим елгасы буенда булган, ул хакта Абрамов фамилияле тарихчы язып калдырган. Беренче ханының исемен дә тарих йоткан! Ә икенче хан аның улы Кызыл Төн була. Дәүләт үсә, ныгый, көчәя. Он Сон дигән хан заманында аның дәүләт чикләре Тура елгасы буена кадәр сузыла. XIII гасырда Көнчыгыштан калкып чыккан татар-монгол яулары Иртеш тирәләренә килеп җитә. Чыңгыз хан гаскәрләре белән орышта Он Сон ханы үтерелә, аны җир-сулары Алтын Урда империясенә кертелә.

XIII гасыр азакларында XVI гасыр башында Алтын Урда таркала һәм аның йомшаруыннан файдаланып, себер татарлары үзләренең Төмән ханлыгы, дигән дәүләтләрен игълан итәләр. Ирекле чакларын сагынып яшәгән татарлар беренче мөмкинлекләрдән үк файдаланалар! Ханлыкның үзәге хәзерге Төмән утырган җирдә була. Уналтынчы гасыр азакларында Махмет хан дәүләтнең үзәген Иртеш елгасы буена күчерә. Аны Искер дип атыйлар. «Искер» — «Иске җир» — «Элеккеге җир» мәгънәсендә була.

Шулай итеп, Себер ханлыгы дөньяга ярала. Авыллар ныгый, калалар төзелә, ханлык бик күп дәүләтләр белән бәйләнешкә керә. Урта Азия, Ерак Көнчыгыш купецлары кәрван-кәрван маллар белән Искергә килеп, мәһабәт кәрван-сарайларда яшиләр. Әмма Себер ханлыгы озак яши алмый, тарихи лаеклы урынын дөньяга танытырга өлгерә алмый. 1852 елның 26 октябрендә Ермак отряды яу булып килеп Күчем ханны җиңә, Искергә урыслар керә. Шул вакыттан башлап Себер ханлыгы тар-мар ителә, аның булуын, яшәешен урыс тарихчылары онытырга, исемен сызып ташларга тырышалар. Татар җире урыс дәүләтенә кушыла һәм бәйсезлеген югалта.

Җәгърафия ягына килгәндә, Себер татарларының иң зур күпчелеге Иртеш, Тобол, Тура, Вагай, Исәт елгалары һәм аларның кушылдыклары тирәләренә урнашканнар. Хәзер дә шунда яшәп яталар. Мөэмин мөселманнарны урыслар тарих буенча кысканнар, асканнар-кискәннәр, җирләрен тартып алганнар. Нәтиҗәдә Себер якларына Татарстаннан, Башкортстан мәмләкәтләреннән бик күп татарлар күчеп килгәннәр. Дин кардәшләр гомер-гомергә тату, дус яшәгәннәр...

Уразаев вагон тәрәзәсенең каралып-калҗаеп беткән пыяласы аша авып-авып калган агачларга, баганаларга карап бара иде, сүзеннән туктап Зосяга күз салды...

— Ә Искер? Ул борынгы башкаладан ни дә булса калганмы? — дип сорады бала имезеп утырган яшь килен.

— Искер, Искер!.. Барып җиткәч күрерсең, Иртеш ярларны яз саен ишә-күчерә торган көчле агымлы елга!.. Ярлар ишелә, ишелгән җир катламнары арасыннан сансыз-исәпсез мамонт сөякләре юылып чыга. Елга ярлары буйдан-буйга сөякләр белән тулган... Мамонт калдыклары чыга, ә менә Себер ханлыгының мәркәзе Искер тарихта югалган. Кай-

сыдыр бер чорда Кашлык дип атаганнар аны, иллә мәгәр башкалабызның төзелү елы да, бетүе вакыты дә билгесез. Бер нәрсә ачык мәгълүм: 1587 елда Данил Чулков җитәкләгән урыс гаскәрләре Иртеш тирәләрен яулап алалар, әмма Искер урынында шәһәр торгызмыйлар. Себер татарларының башкаласы урнашкан калкулыклар читтә кала, анда яшәп, соңгы гомерләрен үткәрүче татарлар шәһәр хәрәбәләрен ташлап урыслардан еракка, төрле төбәкләргә таралалар. Шәһәр үле шәһәргә, караңгы хатирәләр сакчысына әйләнә һәм җимерелеп бетә, югала.

— Нинди кызганыч хатирәләр,— диде Зося офтанып.

Мөхәммәт юри күтәренке күңел белән:

— Зося, халык калган! Татарлар әле бетмәгән! Иртеш агып ята, барыннан да бигрәк тайга бар. Ә тайгада биеклеге кырып метра җитә торган мәгърур кыя агачлар — кедрлар үсә. Сигез йөз ел яши таза кедрлар. Ел саен күпме чикләвек кенә бирәләр алар! Чикләвекнең файдасы,— Мөхәммәт ак чүпрәкне кайтарып нәни Шамилнең йөзенә карады,— сөйләп бетергесез. Себернең атаклы мех хуҗалары — кеш җанварлар чикләвек уңган елларда гына бала китерәләр һәм балалары тазасәламәт була.

Барыннан да бигрәк Иртеш таңнары матур була, кызым! Менә җыйнаулашып Иртеш ярына чыгып басарбыз. Мине өйдә көтеп, зарыгып торган Фаягөлем юл күрсәтүче булыр. Таңны каршылар өчен ул безне иң гүзәл урынга алып барыр... Эх, Иртеш таңнары! Гомерләрне озайта ул, гашыйкларга җан азыгы, өлкәннәргә сихәтлек, моңлыларга сөенеч китерә ул таңнар!..

## 35

Ел ярым чамасы госпиталь койкаларында аунаганнан соң Маннур терелде. Мина ярчыгы тубык сөяген чәрдәкләп бетергән иде. Башта «аякны саклап алып калабыз, ярасы төзәлер!» дигән ышаныч белән тотынганнар иде, тора-бара эшләр кәкәйләнде: яра йомылмады, ая кара көеп чыкты. Маннурны җылатып, куркуга салып кистеләр аякны. «Хәзер куркыныч бетте!» — диделәр аңа врачлар. Тик аяк төзәлмәде, өркетеп, бәгырьне көйдереп тагын карала башлады. Үлекләде. Аякның ун сантиметрын тагын кисеп ыргыттылар... Тагын операция, тагын наркоз, операция соңындагы авыртулар, йокысыз төннәр, газаплы көннәр. Тәки төзәлмәде аяк! Ел эчендә Маннурга җиде операция ясадылар, сул аяк нык ук кыскарды, соңгы операция тездән шактый югарыда үткән иде. Өметсезләнгән, чарасыз калган мәлләре дә булды Маннурның. Шул өйдән, сөекле Сәлимәсеннән өзмәс килеп торган хатлар, аның йөрәккә ятышлы кадерле сүзләре иң бәрәкәтле дәва булды. Маннурның кәефе төшенке икәнен Сәлимәсе әллә ничә чакрымнар аша да тоеп торды. Аның хатлары иң авыр сызланган, үзен өметсезлек упкынында хис итә башлаган минутларда гына килеп керде. Чалкан яткан килеш укый-укый йокыга китте Маннур, палатада беренче булып уянып тагын шул хатларны укырга тотынды. «Сәлимәм булды минем иң яхшы табибым!» — дип кабатлады Маннур, хатирәләрне сүтеп-сүтеп сөйләшкән әңгәмәләрдә. Күпләр аңа көнләшеп карыйлар: «Повезло тебе, браток!» — диде аңа Пермь урысы,— крупно повезло! Не у всякого такая добрая жена! Урыс хатларны өч айга берне ала иде.

Ни гаҗәп: соңгы вакытларда Сәлимәнең хатлары сирәгәйде, килгәннәреннән дә әллә нинди ят битарафлык сизелеп-сизелеп китә иде. Хат азагына төшенке күңелләрне кысып җылата торган җырлар өсти Сәлимәсе. Солдатка җылак хатлар түгел, аңа сөенеч тәялгән, бәхет-шатлык тутырылган хатлар кирәк шул!

Әмма Маннурның теләге кабул булмады, хатлар җылынмады, алар торган саен хәвефлерәк, серле-сөремлерәк була бардылар. Маннур Сәли-

мәсенә ниндидер бәла-каза килгәнен аңлады. Сәлимәнең соңгы хатларында «гомернең азагы», «үлем-җитем», «зират-каберләр» дигән ят сүзләр кушылгач кына егет чынлап торып борчыла башлады. Врачлар да: «Сиңа ни булды, солдат? Ару гына төзәлеп килгән яраларың шикләндерә»,— дип төпчендeләр. Ни әйтсен Маннур? Ни әйтә ала да, ни белә? Сәлимәсенә хәвеф яный, шуннан бүтәнне аңлатырлык дәлилләр аңарда юк иде.

Маннур Хода хәзрәтләренә ялварып карады, үзенә тизрәк савыгу сорады. Ахрысы, догасы кабул булды, егеткә: «Өйгә!» дигән язуны тоттырдылар. Госпитальдән котылып чыккач өенә ашыкмаган солдат була димени? Маннур да ашыкты, аның хәлен сизеп поездлар да ашыктылар, сәгатьләр дә ашыкты, календарьлар да кабаланды, ниһаять, егет туган төягенә кайтып элгәште. «Сәлимәгә сөенеч булсын әле бер!» — дип, хәбәр биреп тә тормады, телеграмма да сукмады. Сәлимәсен, Гөлчәчәген, әткә-әнкәсен, Яланын, Иртешын, Ялан сазлыгындагы түгәрәк түмгәкләрне, түмгәкләргә оя типкән озын торыклы торналарны да өзелеп сагынды ул.

Сыңар аяк белән дә яшәп була ич! дип юанырга тырышты ул. Хәленә кереп колхозда эш бирерләр, йә каравылга куярлар, йә ничек. Сәлимәсе ел саен бәби алып кайта торыр! Малай! Сугыштан соңгы елларда күбрәк ир балалар туа диләр ич. Малай кирәк Маннурга! Бер өер малай! Күрегезче, сыңар аяк белән дә ул ничек җитез йөри: тук та тук! Җилкәгә элгән капчык та булмаса... Ашыгып атлап кайтып та килә иде Маннур, абынып егылды, тәгәрәп китте. Күр инде, үзен сынар өчен ул чакрымнарны җәяү үткән иде, авыл урамына кергәч тәкмәрләде. Ул тук-тук басып өйгә кергәндә Өннән түти уяу иде.

— Аллага мең шөкер, кияү кайтты! — диде ул һәм шунда ук балавыз сыга башлады. Аның белән исәнлек алышкач, Маннур эчке бүлмәгә үтәргә ашыкты. Анда җәелеп-таралып дүрт яшьлек кызы Гөлчәчәк йоклый иде. Маннур аның караваты янында озак кына елмаеп, онытылып торды. Кашлары, чәчләре, маңгае нәкъ әнисенеке, ирене, борыны, битләре аныкы, Маннурныкы. Нарасый иреннәрен кыймылдата, елмая, тәмле төш күрә, ахрысы. Маннур шинелен салуга, Өммә апа килеп җитте, кияве кулыннан шинелен алып чөйгә элергә ашыкмады, тукталды, көтеп калды. Маннур Сәлимәсе белән йоклый торган карават куелган бүлмәгә — кече якка таба атлады. Тук-тук дип сәлам бирде култык таяклары. «Тук, тук! Уян, Сәлимә!»

Керде, як-ягына каранды, карават буш, ятак сап-салкын иде. Маннурның йөрәге жу итеп китте, стенадан Сәлимәнең кара кайма белән чолганган сурәте карап тора иде. Маннур өйдәге салкын тынлыкны бозып тук-тук йөренә башлады. Сәлимәсенең сурәте каршысына килде дә тораташтай катып калды. Әнә мавылга Сәлимәнең күлмәкләрен тезеп элеп куйганнар. Ишегалдындагы колгага мендәр-ястыкларны, юрганнарны җилләтергә чыгарганнар икән! Аларны да керешли күреп үткән иде Маннур, игътибары гына җитеп бетмәгән икән. Ни гаҗәп, Маннур боларның һәммәсен дә үзе аңлады. «Син мине мәңгегә ташлап киттеңмени?» — дигән кара уй йомгагы аның муенына уралды. Аның гомердә булмаганча үкереп-үкереп, башын ташка ора-ора җылыйсы килде, ләкин тыелды. Маннур Сәлимәнең өйләнешкәндә, кубәләктәй очына-очына кунакка йөрешкәндә, сугышка озатканда кигән күлмәкләрен берәм-берәм кулына алып, иреннәре яныннан үткәрде.

Кесәсеннән хатынының соңгы хатын табып алгач, аны өр-яңадан әллә ничә кат укып чыкты. Хатка сыйган ымнар, ишарәләр менә хәзер генә тулысынча аңлашылды. Сәлимәнең әҗәл чире белән шактый вакытлар тартышып ятуы мәгълүм булды. Ак кәгазь кисәге өстенә тамган яшь аның үзен дә сискәндерде, яшь тамчысы башта җәелеп китте, аннан хатны эретеп, тишеп үтте. Шулкадәр ачы иде солдатның күз яше!

Аның кайтканын күреп күршеләр килеп керде, ерак өйләрдән ишетеп өлгергәннәр җыелды, өйдәге кырыс ыгы-зыгыга Гөлчәчәк чәчрәп уянды.

Нәни йодырыклары белән ике күзен уды. Башта бик ятсынып карап торды да, әбисе:

— Әтиең кайтты, балам, тор! — дигәч, ике кулын сузып:

— Әттәү, миңа курчак алып кайттыңмы? Әннәм «алып кайта!» дигән иде,— дип әтисенең муенына сарылды.

— Алып кайттым, кызым, алып кайттым!

Минуты житте, кызының тургай булып сайрап, янында уралганын күргәч Маннур түзмәде, күз яшьләре тау елгасы булып агарга тотынды.

Йә, сабыең «Әннәм дә синең белән кайтмадымы?» дигәндә, ничек түзәсең ди инде? Гөлчәчәк бүлмәдәге кешеләр арасыннан әнисен эзләде. Сәер иде бүген солдатны каршылау!

Маннур калтыранган куллары белән бәләкәй генә юл капчыгын актарырга тотынды. Аннан күзләрен бер ачып, бер йомып торучы курчак чыккач, Гөлчәчәкнең йөзе яктырып китте, курчагын кочаклап әтисенең алдына менеп утырды, шунда гына әткәсенең аягы юклыгын абайлады.

— Әттәм, син аягыңны кайда калдырдың? — дип сорады.

— Сугышта, кызым, сугышта,— диде Маннур калтыранган иреннәрен көч-хәл белән җыеп.— Әле шөкер, үзем исән калдым. Бер аякны алып калдылар да, икене биреп җибәрделәр.

Гөлчәчәк йомылып әттәсенең алдынан шуып төште дә култык таякларын берәм-берәм тотып карады.

Гөлчәчәкнең бабасы эштә иде, менә ул да тыны бетеп, ахылдап кайтып керде. Аңа авыл картларыннан ике-өч кеше ияргәннәр. Өй эче Сәлимәне озаткандагы кебек тулып, тыгызланып калды. Кызчык курчагын сөенә-сөенә күрсәтеп аларга да мактанып алды:

— Әттәм алып кайтты,— диде ул кат-кат.

— Әнкәсе, чәй куеп җибәр,—диде, бүтән сүз тапмаган, кияве белән юньләп сәлам дә алыша алмаган Туктасын әкә. Кичә генә Сәлимәнең өчесен укытып, бүген беренче мәртәбә эшкә чыгуы иде аның.

Маннурның тамагыннан аш үтмәде, ул кергән кешеләр белән бер-ике сүз алышып, юлда кайтканда кичергәннәрен сөйләп утырды. Хәзер аңлады: юлда кичергәннәре хәсрәт булмаган икән әле, сугыштагы авырлыклар да алай ук кыйнамаган икән аны, менә монда, бабай йортында көтеп торган икән хәсрәтнең олысы, мәңгелеге!

Кешеләр керә торды, күрешеп, хәл белешеп чыга торды. Маннур моңарчы таныш булмаган халәт кичерде: хәл белешергә кергәннәр белән күрешә, кул алыша, хәл-әхвәл сораштыра, алар нидер сөйли, Маннур да кушылып киткәндәй итә, ә күңеленә бер генә уй хуҗа: Сәлимәсе! Ни әйтсәләр дә, сүз кай тыкырыкка гына борылып кермәсен, анда да, монда да Сәлимә каршылый аны!..

Кич житте, иренеп кенә караңгы төште, сәхари кисәген тәмләптәмләп авызында эретеп яткан Гөлчәчәк сабый да эреп йокыга китте, әбисе Маннурга урын җәйде.

— Сәлимә бәгырькәем, гел сине көтеп ятты, кияү. Дүрт көн элек кайткан булсаң, күз тересенә килә идең,— дип кабатлады Өннә апа.

Маннурны йокы алмады, торып утырып карады, күзләрен кысып йомып урында аунады, күз алдында тере Сәлимә гәүдәләнде. Ул каядыр эш белән киткән дә менә әле генә кайтып керер кебек иде...

Менә иртәнне тукылдатып Маннур түр як бүлмәгә чыкты, Туктасын әкә дә, Өннә апа да әле йокламаганнар, берсе ияген учлап өстәлгә таянып нидер уйлый, икенчесе мич тирәсендә кыштыр-мыштыр нидер эшләп йөри.

— Ничекләр бу хәлгә төштегез? Чухут алырлык ни булды Сәлимәгә?

Маннурның әрнеп соравы аларны сискәндереп җибәргәндәй булды, бер-берсен бүлә-бүлә, бер-берсен куәтли-куәтли алар байтак нәрсәләр сөйләделәр кияүгә. Бу сүзләрне хатларда язмадылар шул, бу хәлләрне

Маннур күз алдына да китерә алмаган иде. Туктасын әкә сак, сүзне сатып кына бирә, аның каравы Өннә апаның теле язылды.

— Шул, Алланың каһәре төшкере калхуз гаепле инде. Шул җитте Сәлимәбезнең башына! Ничә айлар балам йокы күрмәде, инде генә кайтып ятты дисең, выжлатып алып чыгып киттеләр. Әле җыелыш, әле утырыш! Рәис чирләп китте исә, бар эшне аңа йөкләделәр. Салымнарны ул җыйды, заем кәгазьләренә өй борынча йөреп ул кул куйдырды... Йөрсә дә вай, йөрмәсә дә вай, гуй. Көзге яңгырлар, язгы пычраклар... Чиләк судан, ишәк эштән бушамас, диләр. Ишәк итте калхуз кызыбызны! Бүтәннәр галуш башына тутырып булса да бөртек алып кайткалады-лар, ә аңа ярамый, актив янәсе! Ал-ял белмәде, үзен карарга, кайгыртырга җае калмады. Шул каһәр суккан калхуз ашады баламның башын!

Туктасын әкә карчыгын тыярга маташмаган булса, ай-һай, авыл тормышының бөтен күзәнәкләрен күреп бәгыре көйгән Өннә апа ниләр сөйләмәс иде икән?

— Әкерен, әкерен, әнкәсе! Телеңне тыя төш. Тыелу белмәгән телнең кая барып кысылганын беләсең гуй! — дип, әйткәләп утырды Туктасын.

Маннур авыл хәлләрен сораштыра башлады, Айсетдиннең рәис булып йөрүен ишеткәч:

— Тоттырганнар икән кәҗәгә кәбестә бакчасын! — дип куйды. Нигә шулай диде, ник яратмаган ул рәисне, Туктасын әкә белән Өннә апа сорашырга базмадылар.

Маннур үз ягына чыгып киткәч Туктасын да теленә бөялгән сүз ташкынына арык ачмыйча түзә алмады.

— Телгә бик остаргансың әле, карчык. Дөньядан сагай, аның төрле чаклары була. Утыз җиденче елларда нишләткәннәрен беләсеңме? Авылдан уннан артык кешене алып киткәннәр иде, әлегәчә эзләренең табылганы юк. Сугышта бер авылны алгач, «ур-ра, ур-ра!» дип тамак яручыларга арабыздан бер солдат: «Бер авыл өчен ярты сәгать акырабыз, ярты илебезне дошманга биргәндә авыз да ачылмады! — дигән иде, чирек сәгать эчендә трибунал җыеп, чыгарып аттылар бахырны... Сагырак бул,— дип үгет-нәсихәт кылып ятты.

Иртәнге чәйне эчеп, Өннә апа пешергән төче коймак белән кинәнгәч, Маннур Гөлчәчәкне алдына утыртып озак кына сөйде дә, туп-туры Шәүкәт янына китте. Шәүкәт тә аның кайтканын ишетеп, ах-ух килеп, Маннур янына барырга җыенып ята икән. Озаклап, сугыш җәрәхәтләрен телгә кертмичә генә, дустанә сөйләшеп утырдылар. Мәүлиха аш өлгертте, батырларны һәйбәтләп сыйлады. Шәүкәтнең эчемлектән авыз иткәне юк диярлек иде, бу юлы Маннур кайткан хөрмәткә нәни генә чеметеп тә куйды. Гобәйбә буйдакның самогоны сасы, әмма куәтле иде.

Озак кына утырып, бик күп сүзләр сөйләшеп, телләре аргач кына Маннур кайтырга чыкты.

## 36

Мөхтәрәм укучым, син Миңнурыйга ияреп йөргән сыер турында онытып та бетергәнсеңдер әле! Сыер исән-сау, таза диярлек, сәламәт, ел саен бер бозау алып кайтып бирә. Бозауны гына түгел, сыерны да җыйнаулашып багалар. Сыер да, үзенә нинди «җаваплы бурычлар» йөкләнгәнен аңлаган сыман, елның-елны шактый мул сөт бирә! Кемнәр генә эчмәде инде аның сөтен дә, авылның карт-корыларыннан кемнәр генә аның куе катыгын ашап кинәнмәде. Күрше-тирәләргә таратты сөтен Миңнурый, чирлеләрнең өенә илтеп биреп йөрде, балчык чүлмәкләргә тутырып мәктәпкә алып килде, сөтне кашыклап диярлек балаларга өләште. Печән өстендә балалар үзләре дә бурычлы булып калмаска тырыштылар, кем бауга бәйләп, җилкәсенә йөкләп, кем рәистән качырып култык астына кыстырып сөтлебикәгә кышкы ризык

ташыдылар. Сыер мәшһүр хайванга әйләнде, үткән-сүткән атлылар да, күт асларына салып кайткан колхоз саламыннан да аңа өлеш чыгардылар, соңгы кәҗә-сарыкларын суеп ашарга мәҗбүр булган ярлыхәлсезләр дә агач табакларга салып сыерга бәрәңге кабыгы ташыдылар, яши-яши сыер да Миңнурыйның гына түгел, ярты авылның сөйгәненә әйләнде.

Мәшһүр сыерны адәм улларыннан берәвесе генә яратмады. Бу кеше колхоз рәисе Айсетдин иде. Ул, Шәгъбикәне авылдан куып чыгаргандай озатканнан соң, төрле фронтларда алып барган «мәхәббәт көрәшләрен» бермә-бер киметте, тол хатыннарның капкаларын кагудан туктады, житеп килгән кызчыкларның түшләрен керле кулы белән пычратмады, капшамады. Ул Миңнурыйны кулга төшерергә һәм эше уңай барып чыкса аңа өйләнергә ныклы рәвештә карар кылган иде. Сүзләре әзер, тәкъдимен дә теле ятлаган, вакытында ул боларны Сәрвәргә әйтеп караган иде инде.

— Мин сине ефәккә төрермен... Балда-майда йөздерермен! Кара эш эшләтмәм, абруйлы рәиснең хатыны булып аштан-ашка, кунактан-кунакка гына йөрерсең. Сугышлар бетәр, дөнья тынычланыр. Ә син Ленин орденлы батыр сугышчының бичәсе булып, Кара диңгез курортларында гына ятырсың!

Бер тыңлады Миңнурый шушы татлы әкиятләрне, ике тыңлады, өченчесендә тыңлап бетермәде: «Сыер савасым бар»,— дип ашыгып кайтып китте.

Айсетдиннең җене котырды дисәк, бу бәя бик аз булыр. Миңнурый ташлап киткән көнне җене котырган иде Айсетдиннең, кызның ачыктан-ачык качып йөри башлавын белгәч, аның күкрәгенә сигез убыр, унике шайтан кереп оялады. Ике сүзнең берсенә урысның дөньяга бик киң таралган, милләтара аралашу чарасына әйләнгән оятсыз сүзләрен кыстыргалый башлады. Хатын-кыз дип тормый, өлкәннәрне санламый. Сүгепме сүгә! Кемне сүксә дә сүзләре Миңнурыйга адресланган!

Ниһаять, Айсетдин Миңнурыйны сындыру әмәлен тапты, әлеге дә баягы торадагы якыны Глеб Иванович Лапиков ярдәмгә килде. Көннәрдән бер көнне ресторан дип йөртелгән ашханәнең арткы, яшерен бүлмәсендә (бу бүлмәдә райком секретарьлары, райбашкарма хуҗалары һәм прокурор гына иркенләп утыра ала, Лапиков белән аралашканнан бирле орденлы Айсетдин өчен дә аның ишекләре һәрчак ачык иде) шешәләрнең икесен бушаткач, кәефе килгән Лапиков Айсетдинне үзе белән ияртеп алып кайтты һәм ике катлы ишекле тимер сейфтан бер «Дело» тартып чыгарды.

— Утыр. Укы. Таныш. Тик тавыш-тын чыгарма! — диде.

«Дело»ның тышын караугa Айсетдин айныды, ул йотлыгып киләчәктә үзенә ярдәм итәчәк «данныйлар» белән танышып чыкты. Аллакайгынам, менә кем икән бу буй бирмәс тәкәббер Миңнурый дигәннәре. Сөргендә яшәп ята икән ич! Мәэзин бабасы белән куылып килгән икән! Еш кына советка каршы шикле сүзләр ычкындыручы бәндә икән ул! Аны мәктәптән куарга да күптән вакыт икән ләбаса!

Үзәге черек агачны аудару берни түгел, төртәсең дә егасың! Ләкин... Лапиковтан шүрли Айсетдин, «тавыш-тын чыгармаска» кушылган аңа! Миңнурыйның якасыннан алырга иртәрәк... Сак эш итәргә кирәк...

Һәм ул Миңнурыйның үзенә түгел... сыерына бәйләнә башлады. Миңнурый колхозчы түгел, колхозда эшләми, ә малын колхоз басуында йөртә, кышлык курманы да колхоз җиреннән әзерли... Идарә утырышын җыйды Айсетдин һәм ике-өч куштан сүзенә таянып, «укытучы Миңнурыйның сыерын колхоз кырларында йөрттермәскә, кышка азык әзерләтмәскә», дигән карар чыгартты. Шул кичне, капка төпләрендә саклап торып, Миңнурыйга үтеп китәргә юл бирмәде. Кызны куркытты, әркетте, дулады.

— Мин сиңа оҗмах вәгъдә итеп, мәңгелек яр булырга чакырдым,— диде ул тамак төбе белән сөйләшеп.— Тыңламадың. Ир-атларга кытлык заманы. Минме сиңа тиң түгел? Менә сайла: йә миңа кияүгә чыгасың, йә мин сине дөньяда яшәтмим! Кем икәнеңне белмиләр дисеңме? Артыңнан кара койрыгың сөйрәлә синең, мәэзин токымы!

Шушы бер сүз җитте Миңнурыйга, ул барысын да аңлады: Айсетдин аның үткәннәре белән танышкан, анда теләгән кешегә бәйләнер урыннар күп, моннан ары рәис ялынып, ялварып торачак түгел, ул аны чека гармунына, райком кубызына биетәчәк...

Һәм Миңнурый Яланнан чыгып качарга булды. Тик Айсетдиннең һәм аңа булышырга әзер торган көчләрнең күзе төшмәслек итеп кая качарга?

Шул чакта кыз өзелеп-өзелеп Ишморза Муллинны хәтеренә төшерде. Ишморза табигать тарафыннан аңа билгеләнгән егет булган икән шул! Ул исән булса, алар әллә кайчан өйләнешерләр иде, Миңнурый мондый бәла-казаларны күрмәс тә, ишетмәс тә иде.

Хәзер котылу юлы бер генә: моннан китеп, Айсетдиннең күзеннән дә, үзеннән дә югалырга кирәк!

Төмәндә бабасының бертуганы Хаҗи бабай яши иде. Хәзер ул вафат, әмма аның нәсел-нәсәпләре шунда берегеп калдылар, кузгалмадылар. Алар һөнәр ияләре. Миңнурый, якыннарын җирләп япа-ялгызы калгач алардан бер-бер артлы хатлар килеп торды. Алар ятимә кыз баланы үз яннарына чакырдылар. «Монда татарлар бик күп, эш тә җитәрлек. Шәһәрдә халык ишле, теләсәң, югалырга да була. Яшәү кыенлашса, ике дә уйлап торма, тот та үзебезгә кил!»

Миңнурый шушы җепнең очына тотынды һәм Төмәнгә барып югалырга карар кылды. Мәүлия, Сәрвәрләр аяк терәп каршы төштеләр:

— Уку елы башлана дигәндә ничек безне ташлап китәсең? Кемнән шулкадәр куркасың! Без бергә булганда әллә нинди куркынычларны да җиңә алабыз! Тиздән Мөхәммәт абый кайтып җибәр. Аңа ни диярбез? Китмисең дә, бу хакта уйламыйсың да!

Дөресен әйткәндә, үҗәтлек дигәндә Миңнурый да төшеп калганнардан түгел иде, кызлар ни үгетләсәләр дә ул үз сүзен сүз итте, китәргә тәвәккәлләде. Тик сәфәренең көнен дә, кая барырга җыенганын да чишәргә, авыл арасында да сиздерергә ярамый иде...

— Сез, дускайларым, китеп атна узып, эшләрем суынгач кына бу хакта Шәүкәт, Булат абыйларга белдерерсез. Мәрзиягә, Гыйззәтбану түтиләргә сөйләрсез... Шулай кирәк. Яхшы чакта мин моннан котылыйм инде.

Шулай сөйләшенделәр, төрле юлларын уйлап бактылар да, иртәләрнең берсендә, инде уку елы башлана дигәндә Миңнурый кыз сыерын җитәкләп Тубылга чыгып китте. Ул кызларның берсенә дә үзен озатырга рөхсәт итмәде. «Болай сыерын ашатырга чыккан кеше рәвешендә генә булыйм әле мин. Айсетдин шайтаннан куркам!» — диде.

Юк — сер ул, табышмак ул, алда сине ниләр көтәчәген һич бер чакта тулысынча белеп булмый икән! Миңнурый да кунакчыл Ялан авылыннан чыгып күп тә бармады, үзен көтеп, сагалап торган маҗараларга юлыкты.

Күрше авылның көтүен олы юлга якын гына җиргә чыгарганнар икән. Миңнурый аны-моны уйламыйчарак бара иде, көтүдән ике-өч сыер аерылып, ят сыерны күрүгә, сөзәргә килә башладылар. Мөгезләрен турылап куйганнар, мин сиңа әйтим, Миңнурыйның сөтбикәсе дә усал икән, ул да мөгезләрен тегеләргә төбәп куйды. Миңнурыйның коты чыкты, әле ярый пеше генә талчыбык алган иде, шуны селтәп һөҗүмгә омтылган малларны куа башлады. Бәхете, көтүче уяу икән, чыбыркысын шартлатып ул килеп җитте һәм үз сыерларын куалып читкәрәк алып китте.

Миңнурый сыерының каны кызганын күреп, беренче очраган күл янында туктап малга су эчерде, аны сыпырып-сыпырып үлән ашаганын

көтеп торды. Кичкә таба, чираттагы авылда кунарга тукталганда, урамда адашып мөгрәп йөрүче үгез аның сыерына гыйшык төшереп, алар тирәсендә юргалый, әйләнгәли башлады. Миңнурыйның коты калмады, үгез шәп, симез, тиресе елкылдап тора, иснәнә-иснәнә яратты Ялан сыерын! Сыер да аңа мәхәббәтле күзләре белән карый... Сыерны тизрәк яшерим дип, бер капкадан кереп, җәһәт кенә келәне төшергән иде, мәхәббәттән исергән «үгез-егет» очлы чөй мөгезләре белән капканы тишә, җимерә башлады. Ярый әле хуҗалар чыгып өлгерде, алар «кунак егетен» таяклый-таяклый куалап җибәрделәр...

Тубылдан Төмәнгә кадәр сыерны алып китәргә пассажир пароходының капитаны, чәчрәп торган җирән чәчле калынча марҗа, ришвәт сузгач кына риза булды. Миңнурыйның өр-яңа, күз явын алырлык ырынбур шәле бар иде, тоттырды Миңнурый марҗага.

— Коерыкта барырсың. Сыерыңның астын сәгате-минуты белән чистартырсың. Мөгрәмәсен, шауламасын! Пассажирлардан бер шикаять булса да сыерың белән үзеңне дә куармын!

Шаркылдап, бот чабып көлгән кешеләргә игътибар итмәскә тырышып, алдан әзерләгән ике капчык коры печәнен йөкләп, сыерын җитәкләп өченче класс коридорын үтте һәм коерыкка чыкты.

Көз булса да көннәр эссе иде. Сыерына еш-еш су эчертте Миңнурый, астын карады, өстенә су сибеп коендырды. Ресторан кухнясыннан калдык-постык аш-сулар алып чыгып ашатты, авызыннан өзмәде малкаен. Тамагы тук сыер иртә-кич чиләкләп сөт бирә башлады. Балалы хатыннарга сөтен бушлай өләште. Алар, рәхмәт йөзеннән, пароход туктап торган пристаньнарда ярдан үлән йолкып керттеләр. Пароход командасы кешеләре һәм хәллерәк пассажирлар җылы сөт сатып ала башладылар, шулай итеп юллык акчаны чак юнәтеп, сәфәргә чыккан Миңнурыйның байтак сәрмиясе тупланды.

Ул үзен бай, акчалы кеше итеп хис итте һәм үз тамагын теләгәнчә туйдырырга булды. Сугыш башланганнан бирле мондый кәтлитләрне, мондый суганлы-борычлы шулпаларны ашаганы юк иде шикелле кызның...

Кызның сыер җитәкләп килеп керүен күргәч, Төмәндәге туганнары да аны ачык чырай белән каршыладылар...

## 37

Мөхәммәт Уразаев кайтып төшкәч, Ялан авылы кешеләренең олысы-кечесе җиңелрәк сулап куйды дисәк тә һич хата булмас! Моңарчы кайтканнарны багарга, тәрбияләргә, үз авызыннан соңгы ризыгын бүлеп бирергә тырышкан адәмнәр Уразаевны яклаучысы, булышчысы, киңәшчесе итеп кабул итте. Төрле яктан авылның астын-өстен талаган вәкилләрнең исемен атап әби-бабайлар: «Тукта, менә Уразай кайтты! Ул сиңа күккә сикереп азынырга ирек бирмәс!» — дип тешсез авызларын киңрәк ачып, көр тавышлар чыгарып, үзара сөйләшергә тотындылар. Шыпырт кына булса да рәис Айсетдинне дә теш арасына да кыстырдылар. Кибәк чәйнәп май чыкмаганын белсәләр дә, шулай сөйләшеп күңелләренә тынычлык табалар иде. Кызлы йорт хуҗалары йодрыкларын бушлыкта болгап: «Уразай кайтты, шәт-иншалла, ул сиңа да чарасын табар!» — дип әйтеп юандылар. Үксезләрнең, толларның, чирле-чирләшкәләрнең авызында Уразай гына булды һәм һәркем диярлек алдагы тормышын Уразайга бәйләде. Ни хакында сөйләшсәләр дә, нинди мисаллар китереп каһәрле тормышларыннан зарлансалар да хәзер уй вә сүзнең азагы итеп Уразайның исемен тәкърарлап, җиңел сулап куялар иде.

Авыл арасында Мөхәммәтнең абруе шулкадәр зур иде, моңарчы аннан көнләшебрәк йөрүче калдык-постык ир-атлар да, салым түли-түли

кара җәяүгә калган гаиләләр дә ул кайтып төшкәч өсләреннән йөк төшерделәр. Агай-энене, күрше-күләнне әйткән дә юк инде, алары ул сәгатьләрдә бәхет дәрьясында йөзде! Әйтерсең лә Уразай оҗмах ачкычын тотып кайтып кергән дә моңарчы җиде кат бик астында торган капканы киереп ачып җибәргән.

Мөгаллимә кызлар Фаягөлне җитәкләп яныл-пешеп килеп керделәр. Табигать сихри көчләр тапшырган, җыланның җир астыннан җиде кат тирәнлектә йөргәнен дә сизә торган Гыйззәтбану түти ах-ух мышкылдап килеп житте. Тәүге кунакларны Зося һәм аның сабые Шамил белән ныклап таныштырырга да өлгермәде, шактый хәлсезләнгән, бит очлары тартылып эчкә суырылган, күз кабаклары агарып шешенгән Дәүләтшә әкә килеп керде. Таянган таягын кайсы почмакка куярга белмичә аптырап каударланды, ул арада таяк җитезләнеп кулдан ычкынды, шапылдап идәнгә барып төште. Иелеп алыйм дигәндә Дәүләтшә әкә чайкалып китте, Сәрвар тотып калмаса, бөтенләй егылып ук китәчәк икән. Аягында олтан салынган, кунычларын көя ашаган киез итек, башында колакчын бүрек.

— Җылыга туймыйм, Мөхәммәт,— диде ул, ашъяулык чаклы кульяулыгына кылыч булып калган борынын сеңгереп.

Чыр-чу килсәләр дә шактый җанланган, күзләренә якты ут эленгән мөгаллимәләр олы кеше, ил агасы килеп кергәч, тавышларын нык кына сүндерделәр, кече якка, агач караватта улын чишендереп салган Зося янына чыктылар. Сәрвәр Зосяга кызыксынып һәм үтә җәлләп карады. Зося татарча бик әз белсә дә кергән һәр адәмнең аның «папочкасы» кайтуына ихлас сөенгәнен белеп, аңлап торды, юл газаплары, юл җәфалары бердән югалды, ул куанычларның уртак икәненә төшенеп, улына иркәләү сүзләрен яудырды.

— Менә, улым, син әткәң йортына кайтып җиттең. Монда сине зарыгып көтеп торганнар. Күрәсеңме, улым, бабаңны ничек сөенеп каршылыйлар... Сау яшә, үс, ныгы,— дип кабатлады.

Яше ягыннан мөгаллимәләрнең тиңе булса да, күргән-кичергәннәре җәһәтеннән ул алардан күпкә өлкән, күпкә өстен иде.

Фаягөлнең әткәсе яныннан һич чыгасы килмәде, ул аның тез араларына кереп кысылды да, әтисенең чыршы ботагына охшаган кытыршы, чәнечкеле ияген кулы белән сыпырды, бил каешын тартыптартып карады, ниһаять, түзмәде, теге якта бәбәй сөйгән җылы тавышлардан исереп, кече якка чыгып басты. Урысчасы бик чамалы иде Фаягөлнең, ул Зося апасы белән мөгаллимәләр арасында кызып барган сүзгә катнаша алмады, томырылып карап яткан бәләкәч Шамил өстенә иелде һәм теттереп сабый белән татарча сөйләшергә-гөрләргә тотынды.

Башкалар югалып калса да, үз гомерендә күпме кешене озатып, күпмесен каршылап, тәҗрибә туплаган Гыйззәтбану түти җәһәт кенә төп хуҗа булып алды, йөгерә-чаба өенә кайтып килде, күрше Чeләкә әкәне дөбердәтеп чакырып алып, күкәй салмый торган чуар тавыкны «кых» иттеләр. Кай арада тавыкны йолкып, юып эшен бетерделәр. Кар өстендә казан кайнатырга сәләтле уңган куллар Мөхәммәтнең моңарчы ятимялпы өе эченә җылылык өстәп, тавык ите исен тараттылар.

Кем су җылытты, кем сабыйның кайта-кайта шактый керләнгән чүпрәкләрен юарга кереште. Сәрвәр белән Мәүлия мунча ягарга йөгерделәр, мичләрдә ут кабынды, күңелләр җылынды, эш кызды.

Мөхәммәт белән Дәүләтшә әкә тереләрне вә үлгәннәрне искә алаала Ялан авылын иңләп-буйлап өй борынча йөреп чыктылар. Дәүләтшә әкә төсне нык ташласа да, хәтере ачык икән әле, әллә кайчан үткәннәрне искә төшереп утырды, сөйли башлагач яшәреп, көрәеп киткәндәй булды. Инде бөтен йортларга кагылып үткәч, Дәүләтшә әкә күкәй салырга йөргән тавык сыман каударлана башлады. Нидер әйтәсе дә бар кебек, сүзне башлый да, кулын селкеп читкә борылып та куя.

— Айсетдин ни хәлләрдә? Рәис итеп сайладылар, дигән хәбәрне хат аша белдерделәр, берәү дә чынлап торып, аңларлык итеп язмады дисәң дә ярый.

Дәүләтшә әкә калкынып, күтәрелеп үк китте.

— Менә, менә! — диде ул. — Үзем дә баядан бирле шул хакта сүз башлый алмый утырам, ярый әле үзең ызанга керттең. Башыбызга бәла булды, әй, ул бәндә! Башка сыймаслык эшләр кыдырып ташлады. Монарчы без күргән мөгаллимнәр бер дә андый сыйфатларны белмиләр иде. Бу... ничек дип әйтергә? Адәм балалары хакында бер дә яман сүз әйтәсем килмәсә дә әйтәм, Уразай!

Дәүләтшә әкәнең аскы ирене калтырады, аңа көч-куәт биреп Уразай сүз катты:

— Йә, йә, Дәүләтшә әкә! Мәктәпне ташлап качкан адәмнән мин болай да әллә ни көтмәдем көтүен. Сөйлә, тайчынма!

— Хатыннар белән ямьсез чуалды, мөртәт. Рәис булып алганнан бирле танымаслык булып үзгәрде эт... Алай текәлеп карама миңа, Мөхәммәт!.. Халыкның күңелен каралта ул мәлгунь! Колхозчыны кол итеп йөртә! Сөйләгәненең эт җыймас ул кара йөзнең!

Мөхәммәт Дәүләтшә әкәне бүлдермичә, сабыр гына тыңлап утырды. Дәүләтшә әкә кулларын җәеп, нигәдер бик аптырап аңа карады.

— Менә! Әллә ниләр сөйләмәкче булып тотынган идем, сүзем бетеп тә куйды гуй. Бер караганда гаепләрлек сәбәпләр дә юк кебек, төптәнрәк уйласаң, кеше җанын каралта аның кыйлган галәмәтләре! Изә ул безнең кешеләрне. Болай да боек күңелләрне аяк астына салып таптый...

— Ә районда моны беләләрме? Алар ни карый?

— Эх, Уразай! — дигәч, Дәүләтшә әкә тагын кульяулыгына тотынды. — Түшендә Ленин ордены елтырый шул. Күзләрне шул сукырайта. Валлаһи газыйм дип әйтәм, әгәр аның шундый буласын белсәм, үлгәнче рәислектән китми идем. Район башында да аның ишеләр утыра. Бар белгәннәре аракы эчү дә, катыннарны кармау. Тотанаклы кешеләр сугышка китеп гаип булды. Калды монда сөзелеп җыен әтрәк-әләм. Быел чикләвек уңды. Инде генә тамаклар тук була дигәндә... өй борынча йөреп булган запасларыбызны «фронтка кирәк!» дип сыпырып алып чыктылар...

Ике арада сүз шактый озак дәвам итте, ул арада мунча да өлгерде, тавык шулпасы да пешеп табын уртасына чыгып утырды. Дәүләтшә әкә күчтәнәчкә бер бәләкәй «акбаш»ны да иярткән икән. Йолага туры китереп аны да йоткалап куйдылар. Мөгаллимәләр Мөхәммәт абыйларын тизрәк мәктәпне үз кулына алуны үтенеп, тагын килергә вәгъдә биреп кайтып киттеләр. Дәүләтшә әкә дә артыгын юанмады. Уразаевка сәламәтлек теләп, сабый Шамилнең ияк астын кытыршы бармагы белән кытыклап кайтып китте. Мөгаллимәләр капканы ябарга җыенганда гына болдыр башыннан Мөхәммәтнең тавышы килде:

— Кызлар, кызлар! — диде ул. — Мин сантый, сүзгә мавыгып оныттып җибәргәнмен! Миңнурый кайда соң? Нигә күренмәде? Чирләп ятмыйдыр ич?!

Туры куелган сорауга анык җавап кайтарасы урынга, кызларның аптырашта калулары, кемнәндер курыккан кебек бер-берсенә карашып ык-мык торулары Уразаевны соң дәрәҗәдә гаҗәпләндерде. Алай гына да түгел: «Әллә вафатмы?» дигән уй солдатның йөрәген телеп үтте. Ул арада булмады, урам уртасыннан шәп ат җигелгән кара трантас үтеп китте, трантаска җәелеп утырган ир бу якка карап башын бормады, сәлам ташнырмады, атлыны күргән кызлар шыбырдашып кирелән ишегалдына керделәр һәм абыйларына ияреп өйгә үк үттеләр.

Шунда гына Мөхәммәт Миңнурыйның Айсетдин комсызның әзәрлекләүләренә түзә алмыйча, РОНОдан расчет та алмыйча, авыл-көн белән саубуллашмыйча карак рәвешендә авылдан качып китү хәбәрен ишетте. «Минем кайдалыгымны, зинһар, беркемгә дә әйтмәгез!» — дигән икән Миңнурый...

Кызлар китте, тирә-як тынып калды, шул аулак чакны көтеп кыбырсыган Гыйззәтбану түти Уразаев янына якынрак килеп, ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдады:

— Рәислекне үз кулыңа ал, Мөхәммәт, югыйсә, эшләрлек кешеләр авылдан качып бетә. Боз диңгезе ярларына — Салихардка, бүтән шәһәрләргә күченә кеше. Айсетдиннең сүгенүләрен, янауларын, кызларны изүләрен кем тыңлап яшәсен. Тормышыбызны тагын да ямьсезләде шул өстерәлчек. Каян башыбызга бәла булып кайтып төшкәндер. Авылыбыз белән ләгънәт укыйбыз шул явызга! Миңнурый сабыр, түзем җан, ул да чыдамагач инде... Булатның Шәгъбикәсен аздырды, бичара хатын качып китәргә мәҗбүр булды. Ямьсез булса да арага сыя иде әле. Әллә читтә әзерләп куйганнармы? Көтеп торалармы?

Гыйззәтбану түти Шәүкәт, Мәүлихаларны, Булатның күргәннәрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Булат янына ерак Омскидан бик чибәр кыз бала кайтуын хәбәр итте. Теге кара шайтан хәзер шул Мәрзия артыннан өстерәлә башлаган икән. Хәл белешергә дип кич керә дә ярты төнгә кадәр Булатларда утыра икән... Азгын шайтан!

Кунаклар таралып, мунча кереп, юл пычракларыннан тәмам арынгач Фаягөл, Зося, нәбәрәсе Шамил белән дүртәү генә калгач, килен, йортка хуҗа булып, табак-савытларны юып, табын урынын җыештыргач, мендәр-ястыкларны барлады һәм: «Иртәгә өйне арулап, идәннәрне юып чыгарырга кирәк булыр»,— дип уйлый-уйлый кайнатасына карады.

— Әти,— диде ул татар колагына иң ягымлы сүзне әйтеп.— Сезне монда бик яраталар, үз итәләр икән.

— Сугышка кадәрге елларда да, аннан элек тә татарлар укытучы мөгаллимне бик югары күтәреп йөртәләр иде. Аның һәр гамәлен үрнәк итеп санаганнар, әйткән сүзен тоталар иде. Татарлар бик борынгыдан укый-яза белгән аңлы, укымышлы халык булганнар! Аларның күңелләренә кара таш бастырып торучылар гына тулы хокуклы булып яшәргә ирек бирмәгәннәр...

Сүз өзелмәде, әңгәмә шактый озынга сузылды.

Мөхәммәт, гадәтенчә, бүген күргән-белгәннәренә йомгак ясап озак кына йокысыз ятты. Хәбәрләрнең, ишеткәннәрнең сөенерлекләре дә байтак иде! Никадәр авыр, буталчык булса да, тормыш дәвам итә, теләсәңтеләмәсәң дә алга бара. Ташкәй маҗараларын ишеткәч, Мөхәммәт таң калды, Сәрвәрнең егет белән язышa башлавын белгәч, шатлыгын кая куярга белмәде. Ул эченнән генә: «Үлмәснең һәлакәтендә, ахыр чиктә, Ташкәйнең гаебен йомшарта торган сәбәпләр шактый күп ич. Сәрвәрне үлемгә китереп җиткезә язган явыздан егет кеше бүтәнчә ничек үч алсын?» — дип уйлаштыра иде. Хәзер дөреслек урнашкан диярлек, Сәрвәр дә Ташкәйдән баш тартмаган, аның котылуына сәбәпче булган диярлек... Ишморза Муллин хакында кайбер сүзләрне ишеткәч, аның Миңнурыйны күрәсе килүе бермә-бер артты.

Юлда чирләмәгән, чирләмәскә тырышкан, үпкәсеннән ничәмә-ничә тапкыр җыелган суларны суыртып, шактый йончыган Мөхәммәт, кайтканның икенче көнендә урыныннан тора алмады. Арганлык, берсе өстенә икенче өелгән мәшәкатьләр аны тагын урынга яткырды. Авырткан җире дә юк сыман, торып йөреп китәргә теләге дә зур, ә гәүдәне нидер бәйләп тота. Фаягөл гел ятып торган әтисе янына килеп, гел әнисе турында сорашты.

— Кайтмыймы инде безнең әниебез? — дип зурларча җылап та алгалады. Башта Зося «тетясына» ятсыныбрак карап торган кызчык берике көн эчендә аңа күнегеп өлгерде. Бәләкәч Шамилнең кул, аяк бармакларын кат-кат санады, аннары:

— Ул мине Фаягөл апа дип йөрерме? — дип әтисенә иркәләнде.

Шәүкәт янына барасы килде Мөхәммәтнең, кузгалып китә алмавына уфтанды. Ике кич кунгач, аның хәлләнә алмыйча, караватта ятуын ишетеп, Шәүкәт үзе кыбырсый башлады, аны төрле сәяхәтләргә алып

чыккан кул арбасына чыгарып салуларын үтенгәч, Мәүлиха Булат янына китте, Мәрзиясен иярте́п Булат килде, алар Шәүкәтне арбага салып Мөхәммәт янына алып бардылар. Алар ишегалдына кереп барганда, култык таякларын канат иткән Маннур да күрешергә килеп житте. Яралы ике солдатның килеп житкәнен ишетеп, Мөхәммәт урынында ята алмады, табаннарын ышкып атлап болдырга чыкты. Алар шунда, лапас ышыгында, бер түгәрәк жыйналып, сагынышкан күңелләрен бушатып озак кына сөйләшеп утырдылар. Сөйләшеп сүзләре бетмәде. Зося самавыр куеп, Гыйззәтбану китереп киткән оннан коймак пешереп кунакларга чыгарды. Шәүкәтнең хәлен, бүрәнә башы буйлап арбада жәйрәп ятканын күргәч, өйгә кереп сиздермичә генә яшь коеп та алды. Кунаклар таралышырга торганда гына, капкадан Йомабикә килеп керде. Баксаң, ул тавык суеп, шулпасын да, тавыгын да Мөхәммәткә кучтәнәчкә алып килгән икән. Табынның ярлылыгын күреп, эчтән генә көеп утырган Мөхәммәт, кучтәнәчләрне күреп, Йомабикә абыстайга кат-кат рәхмәт укыды. Мәрзиянең бер бөртеген коймыйча, бер тамчысын читкә түкмичә Шәүкәткә ашатканын карап торгач:

— Һай, кызым, син үзең бер хәзинә икәнсең! — димичә булдыра алмады. Мәүлиха көнләшмәде, мөгаллимнең сүзен куәтләде:

— Хәзинә генәме соңа, алтын ул безнең Мәрзия! — дип куйды.

Татулык белән, бер-берсен кадерләп шулпаны да ашадылар, тавыктан да берәр кисәк чеметеп алдылар.

— Болары киленгә, Фаягөлгә һәм үзеңә булсын! — дип, якты чырай күрүгә бәхете арткан Йомабикә абыстай калган ризыкларны өйгә кертеп үк куйды.

Бүтәннәр таралышты, тагын кемнәрдер кереп, Мөхәммәт белән күрешеп чыктылар. Инде килер кешеләр калмагач, көн кичкә тартылгач, Фаягөлне иярте́п кече якка чыгып китеп Зося сабыен имезә башлагач, баскычтан менәргә иңен куеп торып булышкан Йомабикә абыстай, Мөхәммәт яткан киң караватт кырына урындыгын тартып китереп, эш арасында бүселеп чыккан, көмеш йөгергән чәчләрен яулыгы астына жыеп тутырды да хужаның күзләренә карады. Сорап куйды:

— Мөхәммәт... Жәмәгатеңнең үлем хәбәре дөрескә чыктымы? — диде.

— Кызганычка каршы, дөрескә чыга шикелле. Хәбәр-мазар алмасам да, аның үлемен үз күзләре белән күргән кешене очраттым.

— Алай, алай, — дип утырды, үзенчә нидер уйлап Йомабикә.

— Үзең ни хәлләрдә яшисең?

Йомабикә Мөхәммәтнең соравын ишетмәде дә бугай, ул йомшак, назлы тавыш белән:

— Фаягөл сабый әле. Аңа әнкә кирәк булыр. Безнең уртак балабыз бар, Мөхәммәт. Әллә мин әйтәм, ике түбәне берләштерәбезме? Мәүлияң дә үз янында булыр иде, «кызым» дип аны законлаштырыр идең. Мәүлиягә Йосыфтан хатлар килеп тора. Читтән генә булса да мин барысын да күзәтәм, Мөхәммәт. Өлкәнәйсәм дә әле минем егәрем бар. Һәммәсенә дә ярармын, үкенмәссең! Төп теләгем: Мәүлияне ата йортыннан тапшырасым килә.

Йомабикә абыстайның шулай ачылып, уен нигезле итеп, яшермичә тормыш иткән, ачыны-төчене татыган хатын булып сөйләшкәне бар идеме икән?

Әллә моңарчы Мөхәммәт аны бары тик Ырсыйдиннең бичәсе санап, өстәнрәк карап йөрдеме?..

Әйе, тормыш фронтта гына түгел, монда да адәмнәрне чарлаган, ахрысы, менә шушы кыска гына арада ничаклы авылдашлары белән очрашты: алар элекке кебек тә, түгел дә, барысы да акыл ягыннан олыгайганнар, аларга уй тәгәллеге иңгән. Авылдашлары арасына кереп китү Мөхәммәтнең үзенә дә ансат булмас. Чөнки авыл халкы аннан кодрәт көтә, жиңеллек китерер, дип уйлый. Сугыш бер заман бетәр,

тормыш сукмаклары үзгәрер, киңәер. Шул яңалыкларга әзерме Мөхәммәт?

Тагын ике көн үтте. Зося да, нәни Шамил дә яңа урынга, яңа шартларга күнегеп киләләр. Фаягөл кич житте исә, әткәсе янына үрмәли, йокыга киткәнче нәзек беләге белән әтисен кочаклап ята. Мөхәммәт аның сулышы тигезләнгәнен көтеп, татлы уйларга чумып, көндәлек мәшәкатьләрдән арынып ял итә. Шәфкатьле табиб Гершензон бирепп җибәргән, хәзерге заманда сирәк очрый торган дарулардан бигрәк, Уразаевны әнә шул сабыеның тылсымлы, татлы тыны дәвалады бугай.

Иртәләрнең берсендә Фаягөлне җитәкләп, бәбәй күтәргән Зосяны ияртеп Иртеш буена төшеп китте Мөхәммәт. Көннең шундый чагы туры килде, урамда кешеләр әз иде, юлда тоткарланмыйча гына яр буена барып бастылар. Уймакланып аккан житез елга, яр буе таллары, аръяктагы күз күнеккән кадерле манзаралар Мөхәммәтне йотып алды, ул ни әйтергә дә белмичә күзләрен рәхәтләндереп туган төбәге күренешләренә текәлеп карап торды.

— Матур сезнең яклар, әти,— диде Зося, ап-ак тигез тешләрен елтыратып.— Безнең яклар да ямьсез түгел иде, сугыш имгәтте җирләребезне, сугыш яралады...

Мөхәммәт «Үтәр, тормыш аруланыр!» дип ансат кына сүз кыстырып Зосяны юатырга теләгән иде, сүзләренең купшы вә кирәксез буласын чамалап телен тешләде, нәни Шамилнең башын сөеп, битеннән үбеп алды. Озак басып тордылармы, әзме, берзаман яр буеның борма юлыннан атлы килеп чыкты. Уразаевлар төркеменә җитәрәк, камыт бавы чишелдеме, аркалыгы бушадымы, трантастан төште, текәлеп карап атның уң-сул якларына чыкты, текә атлап, житез кыланып трантасына сикереп менде, кулындагы камчы очын атның сыртына тигезде. Ат ыргылды, һәм трантас Уразаевлар яныннан дөбердәп узып китте.

Мөхәммәт нигәдер Зосяга карады һәм куркып китте: киленене чырае бозылган, күзләре зур булып куркынып ачылганнар, бәбәй тоткан куллары дер-дер калтырый иде.

— Папа, папочка!— диде ул ят тавыш белән. «Папочкасы» киленнең соң дәрәҗәдә каушавын, алай гына да түгел, әҗәл белән очрашкандагы кебек чиксез куркуын сөйли иде.

— Ни булды, кызым?— диде, Зосяга йоккан каушау, нигәдер Мөхәммәтнең үзенә дә ябышып, ул Зосяга татарча эндәшеп бакты, аннан соң гына урысчага күчте.

— Әти! Бу немец офицеры сезнең авылда нишләп йөри?

— Нинди немец булсын ди ул? Үзебезнең як кешесе. Шушы колхозның рәисе.

— Юк, юк, папочка,— диде Зося ашыгып.— Мин беләм. Мин күрдем аны. Безнең хутор читендә, чүнниктән ерак та түгел балчык базлары бар. Шунда бер көнне өч партизанны аттылар. Икесе ир, берсе хатын-кыз иде. Атучылар арасында әнә теге ир кеше дә бар иде. Мәетләрне күмеп тә тормадылар, өсләренә ярны ишеп кенә төшерделәр. Мин куе агачлар арасыннан карап тордым. Качып китә дә алмадым!.. Немецлар көлешә-көлешә машинага төялделәр. Кат-кат карадым, үләрдәй булып курыксам да немецларны хәтерләп каласым килде... Сез рәис дип әйткән кеше мин яшеренгән куакка таба килеп чәптерде... Оят булса да әйтәм! Сул колагы янындагы миңенә хәтле күреп калдым...

Мөхәммәт Зосяны тынычландырырга теләде, сүзен, әмәлен тапмады, ачыкларга җыенып сорау арты сораулар гына яудырды.

— Кызым, гаепнең зурысын әйттең. Уйлап бак, чыннан да шул кеше идеме?

— Чыны шул, әти.

— Ялгышмыйсыңмы?

— Андый сүзне әйтер өчен күзнең жете, хәтернең нык булуы кирәк. Бөтенесен дә үз күзләрем белән күрдем, карап тордым. Буе да шул, сыны да шул.

Тынычлыгын җуйган Мөхәммәт, Зосяны Айсетдин белән күзгә-күз очраштырмаса да, тагын бер тапкыр читтәнрәк булса да күрсәтеп кайтты.

— Шул, үзе,— диде Зося ышаныч белән.

Мөхәммәт Уразаев, ике ут арасына кысылып, кечерәеп калды. Айсетдиннең юньсез бәндә икәнен белә иде ул, авылдашлары да беравыздан шуны раслап торалар. Авылда кылган галәмәтләре дә, иш янына куш булып, рәиснең явызлыгын ачыклыйлар иде. Тик бер нәрсә борчыды Мөхәммәтне: арты таза булмаган хәлдә, нинди дер оста хәйләләр аша, орденнар тагып, ялган кәгазьләр юнәтеп авылга кайтып оялаган бәндә, урысча әйткәндә, «тише воды, ниже травы» булырга тиеш иде, өненнән томшыгын чыгармыйча гомер сөрергә тиеш иде дә... Ә ул монда адым саен абынган, үзе абынмаган очракларда бүтәннәрне абындырган, ямьсезлекләрен яшереп тормаган, киресенчә Шәгъбикә белән көпә-көндез буталган, бик сәер рәвештә Чырык Абдрахманның вафатына да кагылып узган... Сәрвәр белән талашкан, Миңнурыйны авылдан китәргә мәҗбүр иткән?.. Нәрсә бу? Чамадан тыш ахмаклыкмы? Тик тома ахмак кеше арыслан авызыннан, тәмугның җиденче базыннан исән-аман котылып чыга алыр идеме? Йөзен Ленин ордены белән каплап илгә кайтып төшә алыр идеме?.. Чит илләрнең берәвесенә ялланып, астыртын заданиеләр төяп кайткан дияр идең... Андый йөкле адәм Яланга ник кайтсын? Ни хезмәт күрсәтсен ул моннан торып?

Шунысы да бар, Айсетдиннең авылга кайтып төшкәннән бирле кылган гамәлләрендә нинди дер яшертен бер система да шәйләнә иде...

Тагын бер авыр сорау Мөхәммәтнең аңына хуҗа булып өлгерде: гомере буе бер кеше өстеннән әләк-чәләк йөртмәгән, зарланыр чакларында да авырлыкны бүтәннәргә йөкләмәгән, адашканда юлны һәрчак үзе эзләп таба алган Уразаев, бүгенге шартларда, Зося сөйләгәннәрне кая да булса җиткерергә тиешме?.. Әгәр барып чыкса, белдерсә, Зося сөйләгәннәр расланмаса?.. Расланса?.. «Уразай мөгаллим кайтып кына Айсетдиннең башына җитте!» — дигән хәбәрләр кара койрык булып Уразай артыннан сөйрәлеп йөри башласа?.. Айсетдин хыянәтче булган тәкъдирдә дә Мөхәммәтнең НКВД ишеген шакып, әләк өстерәп килеп керәсе килми иде...

Җайсыз иде аңа ул кара вә шакшы ишекне кагып керү.

Юлда кайтышлый ул быел язын, май аенда, Кырым татарларының илдән сөрелүе хакында ишетеп калган иде. Башта курка-курка гына, пышылдап кына, ышаныр-ышанмас сөйләнгән сүзләр, бер Казан татарын очраткач чын, дәһшәтле хәбәр булып оештылар. Казан татары әнә шул, Кырым татарларын куу операциясенә катнашкан, сугышка кадәр ветеринария институтында эшләгән аңлы егет булып чыкты.

— Пычрак эш дигәндә урыс татарны җигә! Арыслан читлегенә әвәл башта татарларны өерләп кертә... Урта Азияне кемнәр буйсындырды? Татарлар. Ил хуҗалары татарларны да Кырымнан казанлылардан кудырды диярлек.

Егетнең әрнеп, үкенеп, Рәсәйдәге язмышын каһәрләп сөйләгәннәре Мөхәммәтнең кайнар йөрәгенә боз булып төшеп утырды...

Айсетдиннең татар, Себер татары булуы да аның рухын рәнҗетә иде. Бөтен фронтларда чамасыз батырлык кылган меңнәрчә татарларны пычрата иде Айсетдин. Татарларның батырлыгын күрмәскәрәк маташкан урыслар Айсетдин-хыянәтчене каптырып алгач, моннан усал рәвештә файдалана башларлар... «Әһә, Кырым татарларын дуылдатып куган идек, хаклы булганбыз! Хыянәтче алар татарлар!» — дип дөнья сасытмасларммы? Әллә Айсетдиннең үзен генә очратып: «Егет, тай моннан! Күземнән югал!» — дип серне ачып салыргамы?

Уразай кичкырын Дәүләтшә әкә янына китте һәм Зосядан ишеткәннәрен түкми-чәчми аңа сөйләп бирде. Икәүләшеп, уйларны бер ноктага юнәтеп, шактый вакыт баш ватып утырдылар. «Әйтергәме, хәбәр итәргәме?» — дип, Уразай Дәүләтшә әкәдән, ил агасыннан киңәш сорады.

Дәүләтшә әкә озак мәшәләнергә ирек бирмәде:

— Әйдә әле! — дип, Мөхәммәтне җәһәт кенә ияртеп чыгып китте. Алар туп-туры җаны көеп яткан бичара Шәүкәт йортына барып керделәр.

— Менә! — дип күрсәтте Дәүләтшә әкә Шәүкәтне. — Аны кем шушы хәлгә җиткергән?..

Юл уңаеннан гына аяксыз Маннурларга да кагылып үттеләр.

— Чибәр, уңган, сылу егетнең аякларын кем тураклаган? Кем аның ярты саулыгын алып калган? — диде Дәүләтшә әкә тыела алмыйча ярсып.

Мәсьәлә үзеннән-үзе хәл ителде: иртәгесен Мөхәммәт Уразаевны РОНОга чакырып телефонограмма килеп төште. Коммунист Уразаевның райкомга да керәсе бар иде. РОНОдан да чакырып торалар, ул кыска гына арада Айсетдин рәис янына кереп чыкты, сүз тиз хәл ителде, икенче көнне кара айгырны җигеп, трантас кузласына утырып бер үсмер Мөхәммәтләр капкасы төбенә килеп туктады.

Әтисенең торага барасын белгәч, Зося кистереп әйтеп куйды:

— Әти, син мине ачуланма. Әмма ләкин син югында мин теге бәндә белән авылда кала алмыйм. Куркам...

Улын күкрәгенә кысып кочкан ананың шушы шомлы сүзләре Мөхәммәтнең күңеленә дә ачыклык кертте. Ул Тубылга барып кергәч райкомга ашыкмады, РОНОда да көтәрләр, дип уйлады һәм иң әүвәл туп-туры НКВДга барып керде...

* * *

Айсетдин бәдбәхетне ай күрде кояш алды. Үзе бик яратып җигеп йөргән кара айгырына утыртып, дөбердәтеп алып киттеләр коры куыкны. Кулларына тимер беләзек кигерттеләр, ике ягына ике милиционер утырды. Авылда гайре табигый хәлләргә юлыкканда, бөтен халык урамга чыгып, йә күз белән, йә куллар болгап китүчене озатып кала торганнар иде. Гөнаһ шомлыгы, сәгате шундый булдымы, кара айгыр урам буйлап юртып барды, «Айсетдинне камарга килгәннәр!» — дигән сүз яшен тизлеге белән йорттан-йортка таралып өлгергән булса да, мәртәтне озатырга беркем дә чыкмады.

Китте, югалды, авыр эзе генә калды. Айсетдин ясаган яралар кеше күңелләрендә әле бик озакка чаклы сыкрап тордылар. Иң авыры Зосяга төште, аны атна буе торага чакырып җәфаладылар, сорау алдылар. Сүзендә нык торды немецлар кылган явызлыкларны үз күзе белән күргән чая кыз.

Мөхәммәт Уразаевның абруе көнләп түгел, сәгатьләп үсә торды. Яланлылар беравыздан:

— Кайтып та төште, авыл өстенә албасты булып сузылып яткан Айсетдинне чөеп тә ыргытты! — дип куаныштылар.

РОНОда Ялан мәктәбенең директоры итеп билгеләнүе турында боерык кәгазен алып кайткан Мөхәммәткә ял итү насыйп булмаган икән. Дәүләтшә әкә, Булат, Мәүлихалар авыл бетереп, өй борынча йөреп чыкканнар, аякта басып тора алганнар мәктәп залына җыелганнар. Мөхәммәт килеп кергәндә, аны колхоз рәисе итеп сайлау турында сүз куерган иде инде. Мөхәммәт, бүген генә РОНОдан алган боерык кәгазен әләм итеп селкеп, карышырга тырышып маташса да, аңа йомгакларга мөмкинлек бирмәделәр.

— Әнә Дәүләтшә әкә булышыр. Булат та терелеп, савыгып килә. Аның да кулыннан килмәгән эше юк. Беләбез, тәненнең телгәләнгән, яраң газапларының үтеп китмәгәнен дә беләбез. Иллә мәгәр без синең сүздән чыкмабыз, һәр кушканыңны үтәргә тырышырбыз. Зинһар, Ялан авылы таралып, җиргә сеңеп бетмәсен дисәң, мәктәбен дә, колхозын да үз кулыңа ал! — дип тоташтан җылый-җылый ялынгач, Мөхәммәт икенче камытны да кияргә ризалашты. Күпне күргән, кай араларда җинаятьләрне дә раслаган, йөри-йөри таушала башлаган түгәрәк пичәтне ике куллап Уразаевка китереп тоттырдылар.

Мөхәммәт авыл язмышын хәл итә торгән ике пичәтне өстәл тартмасына салып куйгач, сорау тулы күзләрен үзенә текәп торган Зосяга кыска-кыска сүзләр белән җыелышта булганнарны бәян итеп бирде. Яшь киленнең Мөхәммәт язмышына ныграк катнашасы, һәммәсен белеп, бәя биреп яшисе килә иде. Аның яшь җанының терелегән күреп Мөхәммәтнең килененә булган аталарча мәхәббәте көннән-көн арта, ул нәбәрәсе Шамил өчен чиксез сөенә, куана иде. Яхшы ана кулындагы бала — балавыз ул, аннан оҗмах җимеше дә, тәмуг кисәве дә ясап була.

Инде дөнья тынычлана төшкәч, менә җимереләм, менә авам дип торган мәктәп бинасында яңа уку елын башлап җибәргәч, мөгаллимнәрне барабан кагып, быргы кычкыртып каршылагач, юлбашчыбыз Сталинга багышланган шигырьләрне бик кычкырып, Мәскәүдә дә ишетелерлек итеп укыгач, Мөхәммәтнең исенә Миңнурый килеп төште. Айсетдинне алып киткән көнне үк Сәрвәр, Мәүлия, Зиләләр Мөхәммәт абыйлары янына килеп Миңнурыйның кайдалыгын белдереп, адресын биргәннәр иде. Уразаев кызга телеграмма сукты. Кыз озак көттермәде, пароходларның берсенә утырып, мәшһүр сыерын җитәкләп, Ялан авылына кайтып та төште! Аны шау-гөр килеп, сөенешеп, кадер-хөрмәт белән каршыладылар. Сыер чиләк-чиләк имиләрен селкетеп урам буйлап барды-барды да элек яшәгән Сәрвәрләр йортына борылды. Шулчак аның мөгезеннән Миңнурый тотып алды.

— Чү, — диде ул, — мине Мөхәммәт абый чакырып кайтарды. Мөгаен, әгәр ул каршы килмәсә, мин аларда яшәрмен.

Кызлар, һәрберсе күз карашына үзенчә мәгънә кушып, бер-берсенә карашып алдылар.

Миңнурыйның үз түренә кайтып төшүенә Мөхәммәт чиксез шат иде. Бердән, аның йортына уңган, аш-суга оста, сабыр канатларын сындырмаган сылу кыз төште. Икенчедән, тернәкләнергә, тезләнгән җиреннән калкынырга тырышкан мәктәп менә дигән укытучылы булды!

Менә кич җитте. Иртеш дулкыннарын каралтып-кабартып йөгергән җилләр тәрәзә капкачларын кагалар, кагалар да ыңдырларга, бәрәңге сабаклары таралып яткан ызаннарга кереп сүнәләр. Җил кермәс җылы абзарда сыер күшәп ята. Күк читенә поскан ай урагын мөгезенә эләктереп югарырак чөясе килә аның. Җил тавышын ул да ишетә... Сәяхәтче сыер! Алда озын, дәртсез, салкын кыш киләсен белеп ята ул.

Өй эчендә, авыр аяклы дәү өстәл тирәсенә һәммәсе җыелганнар. Мөхәммәт булачак мәктәпнең сызымнарын караштырып утыра... Миңнурый белән Фаягөл дәрес әзерлиләр. Лампа калфагының күләгәсе төшкән ярым караңгы почмакта Зося улын, татар малае Шамилне имезеп утыра.

Мөхәммәтнең күзе Миңнурыйның иелгән башына, чәчләренә төшкәч, ул сискәнеп китте. Миңнурыйның күпереп торган чәчен бизәп (ие, бизәп!) киек каз юлы кебек ак тасма яткан иде.

Сугыш бетәр, яралар йомылыр. Мөгаен гена, сугыш елларында яшәгән адәм балаларының бер елын ике, өч, хәтта биш елга исәпләргә кирәк булыр. Миңнурыйга ничә яшь икәнен бүген кем әйтә алыр? Мөхәммәт эшен куеп кызның сөйкемле сызыкларын, ак юл салынган кара чәчләрен күзәтеп утырганда, Миңнурый да башын күтәреп карады. Аларның күзләре очраштылар, очраштылар да җылындылар. Күзләре бер-

берсеннән аерылырга теләмәделәр, алар берсе эченә икенчесе чумып озак кына серләштеләр, аңлаштылар. «Мөхәммәт абый, мин сине яратам бит!» — диде Миңнурыйның күзләре. Мөхәммәт олпат ир, сабыр ир, уен сүзгә чыгармады, әмма аның күпне күрсә дә сүрелмәгән якты күзләре, кыз җаны гына аңлый торган телдә әллә нәрсәләр сөйли иде...

## 38

Кырлач. Аяусыз декабрь суыклары. Төкерек җиргә төшеп җитми, боз кисәгенә әверелә. Җилсез, аяусыз коры суык. Агач ботаклары бәсәргән, күгәрчен тәпие юанлыгы ботаклар да арканга әйләнгән. Дөнья, мөхит, тирә-як шул кадәр тоташ салкынга, бозга әверелгән ки, география дәресләре алып барып, кайдадыр канны куыра торган эссе чүлләр, җылы сулы дәрьялар барлыгына ышандыру кыен. Сыйныф бүлмәләренә ягу әз эләккәнгә, укучылар дер калтырап, кәгазь-каләмгә үрелердән элек тыннары белән кул-бармакларын җылытырга тырышалар. Җылылык энергиясе бирүче ашказаны буш булгач каян килсен ул тәнгә җылы?.. Тәнәфескә чыккач балалар ач-ялангач икәнлекләрен онытып дөбердәтеп әүмәкләшәләр, юк, күңел ачмыйлар, шул рәвешле аз-мәз җылынырга телиләр.

Түбән сыйныфларның арыклыгы, кием-салымнарының теткәләнеп бетүе ул кадәр гаҗәпләндерми, күзне иң нык кискәне, күңелне кычкыртып талаганы үсмер кызлар. Алар егет-җиләнне тәрбияләргә, каннарын арлыбирле куып йөртергә тиешле зифа буйлар, сызылып киткән җәя кашлар, дөньяның бар моңнары сыйган кап-кара күзләр... Алар өтәләнгән киемнәр арасында югалып калалар. Үсмерләрнең исе китми, ә житкән, тупырдап торган кызларның тәннәре ояла. Алар көзгегә багарга да, берберсенә үтәли карарга да читенсенәләр...

Мөхәммәт күбрәк вакытын колхоз эшләренә бүлеп куйды. Мәктәпкә кереп дәресләрен укыта да туп-туры идарәгә чаба. Миңнурыйны кайтаруның бәрәкәтен хәзер татый директор, ул югында мәктәпнең хуҗасы булып Миңнурый кала. Мөхәммәт кайткач, балалар арасында онытылып торган түгәрәкләр эшли башлады. Аерата җыр түгәрәгенә бик теләп йөри кызлар. Шәгъбикә пианиносы эшкә ярады, Зилә генә түгел, үсмер кызлардан Гөлбикә белән Нурлыкыз да шактый йөгерек уйныйлар хәзер. Зилә дигәндә, ашарына бирмә, чәй эчертмә, аңа җыр-моң гына булсын. Шопенын да уйнап җибәрә. Рахманинов көйләренең ноталарын каяндыр табып Казаннан салдылар үзенә. Салкын, котсыз мәктәпкә ямь өстәп, уйнап җибәрсә, дөньяны онытып тыңлыйсың.

Хәзер бөтен мәктәп Яңа елны каршылау концерты белән мәшгуль.

Ә дөнья ага! Сугышның соңгы пәрдәсен алып баралар, азагы да шәйләнә аның! Тормыш нужалары гына бугазны буа, адәмнәр чынлап торып шатлана да алмыйлар. Җыелыш азакларында «ур-ра, ур-раларны, яшәсеннәрне» көчләп кычкыртсалар да күңелләр боек, борыннар салынган...

Декабрь урталарында буралар бушады, фермаларда курма калмады диярлек. Хәллерәк апаларны урак-чалгы тоттырып якындагы күл өстенә чыгардылар, камыш урып, коры кура чабып үрәчәле тәртәләр белән ташыдылар. Яланлылар хәзер вакытны көннәр-атналар белән түгел, сәгатьләп кенә саный башладылар. Шушы сәгатьтә егылып үлмәдеңме, димәк, өмет бар әле дигән сүз! Бүген кичкә кадәр яшәп, төндә җан бирмәгәнсез икән, Ходага шөкерана ит. Әнә, Таифә карчык таңда җан биргән, Миңнулла бабай телдән калган. Атна буе тамагына ризык капмаган икән бичара.

Ләхет алып тормыйлар, каберләрнең ике көрәк тирәнлеге генә булуы да тормышның хәерчелек ярының читенә килеп басканнан соң килеп чыккан бер чарасы иде. Таңнар кара, көннәр караңгы, кичләр шомлы.

Шундый иртәләрнең берсендә Зося сорап куйды:

— Әти... Сез һәрвакыт «Безнең Иртеш якларының таңнары бик матур», дип сокланып, сагынып әйтә идегез. Кайчан ата инде ул таңнар? Кайчан килер ул кояшлы көннәр? — диде.

— Исемем Мөхәммәт булса да, мин кодрәт иясе Мөхәммәт пәйгамбәребез түгел шул, кызым. Кулымнан килсә, бар халыкларга рәхәт тормыш китертеп Иртешнең гүзәл таңнарын бүген үк аттырыр идем — диде.

Ач кешенең ачуы яман, ач кешенең ачулы чагына юлыкма икән! Моңарчы күрше-каршы, ахирәт-бавыр, сердәш-өйдәш булып сабыр гына яшәгән хатыннар үзара чәкәләшә, ызгыша, тарткалаша башладылар. Толлар ирлеләрдән көнләште, ирлеләр тол хатыннарны күрә алмас булдылар. Халык арасына көннән-көн ныграк кереп барган яман бу чирне дәваларга Мөхәммәттә дә көч-куәт юк иде. Юк кына нәрсәдән тавыш чыга да, тавыш гаугага, гауга давылга әйләнә. Икенче көнне кочаклашып тәүбәгә килер хатыннар. Әмма бүген кулларындагы ураклары белән бер-берсен кадап үтерергә әзерләр. Дөнья кешеләрне алыштыра, дөньяның барыр юлын Иблис мәлгуньгә бирә.

Мөхәммәтнең түрендә әлегә татулык. Зося Миңнурыйны үз итеп кабул итте, Миңнурый исә Зося дигәндә чәчрәп китәргә әзер. Шамил сабыйны иркәләп кулдан-кулга гына йөртәләр...

Әнә шундый хәтәр көннәрдә яшәп-интегеп маташканда алдан хәбәр итеп тә тормыйча Ялан авылына егерме гаилә калмыкларны китереп ташладылар. Себер якларындагы салкын көннәрнең дә салкыны иде. Әллә нинди желекне суыра торган сыкылы, томанлы суык. Адәмнәр ишекләрен кул яссылыгы киңлегендә генә ачып өйдән атылып чыгалар да лапас-кура арасына кереп йомышларын үтиләр, тагын өйгә, җылыракка томылалар. Очкан җирдән чыпчыклар таш булып мәтәләп җиргә егылалар. Сабыйлар өйдә, югары сыйныф балаларын гына берән-сәрән мәктәптә күрергә була...

Идарә каршысына атлылар килеп туктаганын ишетеп, Уразаев шунда ашыкты. Җылы толыплар, өр-яңа киез итекләр кигән, билләрен киң каешлар белән кысып буган солдатлар шактый көр, коры тавышлар белән чаналарга төялгән ят адәмнәрне идарә баскычы тирәсенә җыйнарга тырышалар иде. Чанадагы ярым ялангач, бүрек урынына чүпрәкчапрак бәйләгән мыексыз ир-атларны, бозланган күлмәк итәкләре тирәсенә өчәр, дүртәр баланы җыйган, арык, күзләре эчкә баткан каракучкыл хатыннарны күргәч, Мөхәммәтнең йөрәге жу итеп китте.

— Калмыклар! — диде җылы бияләе белән төркемне күрсәтеп, кыпкызыл чырайлы тәбәнәк майор.— Ил хыянәтчеләре! Сатлык җаннар! Хөкүмәт карары белән үз илләреннән куылып, Себергә, мәңгелек сөргенгә җибәрелделәр. Кабул итеп алыгыз.

— Идарәгә керик,— диде Мөхәммәт.— Мин колхоз рәисе Уразаев булам.— Майор бияләен салмыйча гына Уразаевка кулын сузды.

— Бик шәп,— диде ул,— керәбез, бик керәбез. Ялан авылының булачак коменданты да монда. Лейтенант!

Аргы башта, соңгы чана янында солдатлар белән нидер сөйләшеп торган озынча буйлы, какча лейтенант ул арада йөгереп килеп тә җитте.

— Ни бар анда? — дип сорады кырыс майор.— Ни мыштырдыйсыз?

— Мәетләр, иптәш майор. Тагын өчәү үлде.

— Читкә ташлап торыгыз. Үлгән икән — синең бәхеткә, мәшәкатьләрең кимрәк булыр. Менә рәис. Фамилиягезне ничек дидегез әле? Кстати, сез Кырым татары түгелме?

— Уразаев мин. Себер татарымын.

— Бик яхшы.

Өчәүләп идарәгә керделәр, моңарчы карлы тәрәзәдә имән чикләвеге зурлыгында тишек-күз ясап калтырап басып торган хисапчы, тегеләр ачкан ишектән чыгып та сызды.

Майор кулшы планшетыннан шактый ишле кәгазьләр чыгарып салды һәм исемлеккә тук бармагы белән төртеп күрсәтә-күрсәтә сөйләргә тотынды.

— Иң элек комендантны урнаштырасыз. Аны азык-төлек белән тәэмин итәсез. Менә исемлек. Син, рәис, боларак, калмыкларны җан башыннан санап кабул итәсең. Алар шушы авыл территориясеннән читкә чыкмаска тиеш. Радиус — биш чакрым. Кем шул сызыкны үтеп чыга — атарга. Судсыз-нисез. Һәркем йоклар алдыннан комендантка явит булып тамгасын сала. Кем дә кем кача икән, син җавап бирәсең! Комендант Зозуля белән кулга-кул тотынып эшлисез. Сораулар бармы?

Мөхәммәтнең уйлары бер-берсен кисеп башын бутадылар.

— Ә ризык? Кем ашата аларны?

— Син нәрсә, председатель, хыянәтчеләрне, Ватанны саткан калмыкларны ризык белән дә тәэмин итмәкчеме әллә? Үзләре эшләсеннәр. Эшләсеннәр, файда китерсеннәр, ризыгын да тапсыннар.

— Ничек алай? — Мөхәммәт «Без, җирле авыл халкы да көч-хәл белән җан саклыйбыз», — дип әйтергә теләде, телен ачмады, курыкты. Майор артык тупас, лейтенант аңгыра кебек тоелды аңа.

Майорны өйгә алып кайтып кайнар чәй белән сыйлап озатырга туры килде. Аңынчы калмыклар туплауга җыелган сарык көтүе кебек булып бергә укмашып көтеп тордылар. Майор кул биреп саубуллашты, Зозуля белән Уразаевка карап:

— Бу бандитларны саклау, эшләтү сезнең өскә төшә. Тикшереп, белешеп торырмын! — дип кисәтте дә чанага кереп чумды. Озын толыбының итәге әле байтак вакытларга кадәр юлда сөйрәлеп барды.

Моңа кадәр Ялан өстенә төшкән нужалар, бәла-казалар, кимлекләр чут та булмаган икән әле! Әле башланды нужаларның уникe башлысы, тармаклысы. Майор күздән югалуга, лейтенант Зозуляның тавышы үзгәрде, биле турайды.

— Кая куярга бу бичараларны? — дип сорады тәмам башы буталган Уразаев.

— Ишеттең ич, майор сиңа йөкләде: әмәлен тап!

— Бүгенгә мәктәпкә кертеп торыйк. Төн эчендә уйлашырбыз тагын, диде Уразаев. Зозуля һәр адымында үз сүзен өстен чыгарасы килеп кыҗрап торса да бүген ул Уразаевтан читкә китә алмады. Катыпкалҗаеп беткән калмыкларны мәктәпкә алып керделәр. Ул арада аннанмоннан суыкка баш бирмәгән чаярак хатыннар җыелган иде, алар йөгерә-чаба өйләренә кайтып, пешкән нинди ризык бар, шуларны мәктәпкә китерә башладылар. Алар килүчеләрнең кем булуларын аерып та тормадылар. Балаларның ач бүреләрдәй ризыкка ташлануларын, ипи кыерчыгы өчен талашуларын күргәч, яланлылар исәңгерәп калдылар.

«Фашистлар алар, хыянәтчеләр! Илне дошманга сатучылар!» — дип атады аларны бая авызы чәй белән җылынган майор.

Сөрелгәннәр арасында балаларның күпчелек булуы беренче күргәндә үк Мөхәммәтне гаҗәпләндергән иде, хәзер коты чыгып уйлады: әниләренең итәгеннән әлерәк кенә төшкән бала-чагалар нинди хыянәтче булсыннар да, бөлтерәп беткән тешсез карчык-корчыклар илне кемгә, ничек итеп сата алсыннар икән?...

Гомере буе балалар тәрбияләп яшәү тәме тапкан педагогның бөтен күзәнәкләре дерт итеп уянса да, ул шушы газаплы сорауга җавап таба алмады. Бер яктан аның мәктәпкә керәсе, калмыклар белән әйбәтләп сөйләшәсе, сорашасы, аңлашасы килә, ә комендант Зозуля аның итәгенә ябышкан, бер адым читкә китәргә ирек бирми. Дөнья күргән Уразаевның беренче көннән үк комендант белән талашасы, әчелешле буласы, ямьсезләнәсе дә килми иде. Комендантларның нинди зур хокуклар белән эш йөрткәнен ул моңарчы бик күп мисалларда күргән иде инде. Белорус ягыннан Иртешкә кайтып җиткәнче байтак эчте андыйлар Мөхәммәтнең канын.

Ул беренче тапкыр укытучы һәм рәис булуның үзе өчен күпме кыен китерәсен аңлады. Мөхәммәт мәктәпкә борылып кына карый, артыннан: «Кая, кая? Идарәңдә утыр. Тәртип билгелик, хыянәтчеләрнең исемлеген тагын бер кат күздән үткәрик!» — дигән закон тавышы яңгырый.

Комендант белән янәшә баскан рәис-директорның бер дә, бер дә хокукы калмый микәнни?!

Мәктәптә мәхшәр...

Берәү бәхетсезлеккә очраганда аны юатып була, әгәр бәла-каза аерым гаиләгә килсә, аларны коткару җае табыла... Әгәр бәла, бәхетсезлек тоташкан халыкка килә икән — бу тиңсез зур афәт, һәлакәт, бетү.

Калмыклар ике көн мәктәптә яшәп калдылар, өченче көнне таң алдыннан ут чыгып, коп-коры бүрәнәләре чери башлаган иске бина сәгать эчендә янып бетте. Әле ярый мич арты бүрәнәләре төти башлаута олылардан берәү уянган да сыйныф ишекләрен ачып ташлап, бар көченә разбой салган. Калдык-постык киемнәрен, корымлы кәтилүкләрен, чиләкләрен элдереп калмыклар ишегалдына чабып чыга алганнар. Мәктәп соңгы җылысын зыкы салкын Себер төбенә биреп бетереп җиргә инде, утырып янды. Мөхәммәт Уразаев янына хәллерәк кешеләр җыйналды, арада Булат белән Мәрзия, Гыйззәтбану түти, Мәүлихалар, мөгаллимә кызлар, өшәнгән ике-өч ир-ат бар иде. Чайкала-чайкала атлап, бүрек колакчыннарын күтәрергә дә онытып Маннур да килеп җитте. Нишләргә? Калмыкларны кая куярга? Җитмәсә эч пошырып, әтәчләнеп, муенын куян шарф белән ураган Зозуля буталып йөри.

— Иптәш Уразаев,— дип такылдый ул,— хәзер калмыклар теләсә кая таралган. Юлларга сак куярга кирәк. Качып китүләре ихтимал.

Уразаев түзә алмады, авызыннан ачулы сүзе ычкынды:

— Куып җибәрсәң дә качмыйлар алар! Адәм склетларының качканны кайчан күргәнең бар?!!

Зозуляның камыл мыеклары тырпайды, ул вакыттан файдаланып рәисне пешереп алырга авызын ачканда, идарәдәгеләр, бер авыздан рәисләрен якларга тотындылар. Нәтиҗәдә, Зозуля да телен тыйды.

— Биш-алты җанны өебезгә без алабыз! — диделәр Булат белән Мәрзия бер авыздан. Мәрзия шактый калынайган корсагын иске бишмәте белән капларга тырышып:

— Күп балалы берәр гаиләне безгә кертсәгез, бергәләп яшәрбез,— диде иренә кушылып.

Бүтәннәр дә: кем күбрәк, кем әзрәк балалы калмык гаиләләрен үзләренә ияртеп алып кайтып киттеләр. Бу эш шактый озакка сузылды: вакчыл комендант Зозуля һәр каюсының исемнәрен сорашып, кемнең кемгә фатирга керәсен җентекләп дәфтәргә теркәп утырды.

Эш-мәшәкатьләр дәвам иткән арада калмык карчыкларыннан тагын берәвесе җан тәслим кылган иде, аны да элеккеге мәетләр янына, мәктәп утыны саклана торган тәбәнәк сарайга, әрдәнәләр янына кертеп салдылар.

Әзрәк баш-күз алгандай булдылар.

Хуҗалары кайсы-кая таралып, инде өч-дүрт ел буш торган ватыккакшак йортларны аннан-моннан ямаштырып калмыкларны шунда дыңгычлап тыктылар. Бер гаилә башлыгын ат караучы итеп билгеләделәр, аларны ишле гаиләләре белән ат абзары янындагы камыт-бөят ямаштыра торган алачыкка урнаштырдылар. Бала-чага өзмәс кереп-чыгып йөргәнлектән, алачык эче бу-томаннан тыгызланып торды, әче пар арасыннан кәкере аяклы, ыштансыз малайларны аермачык күреп тә булмый иде. Дыңгычлап тутырылган йортлардагы кайбер гаиләләр үзләренә карлы тау итәгендә землянкалар казып, шунда көчәнделәр. Йөткерек кизүе, кан төкереп түшәктә ятучылар саны көннән-көн арта торды.

Болай да такы-токы яшәгән, бетешкән Ялан халкы өстенә кара яу булып килеп төшкән калмыкларга һәммә кеше дә сөенде дисәк, хата йомгак ясаган булыр идек. Беренче атнада чак-чак яңгыраган зар-моң

тавышлары, сукранулар тора-бара тоташ карганууларга әйләнде, авыл халкы белән килүчеләр арасында ызгыш-гаугалар ешайды. Калмык бала-чагалары ачлыкка түзә алмыйча кулларын озайттылар. Дымлы землянкалар тирәсендә тавык йоннары очып-бөтерелеп йөрде.

Җирле халыкның калмыкларны төрле тойгылар белән каршылавы нигезсез дә түгел иде. Тормыш итү ысуллары, гореф-гадәтләренең аерымлыгы торган саен үзен ныграк сиздерде. Ул халыкның яраткан сыйлары күсәбәсе белән пешкән ит тә, тозлы чәйгә май салып ашау икән. Ялан халкы тозны кайдан алсын да, җыбыр булып килгән әрсез бала-чагага майны каян юнәтсен? Мөхәммәт Уразаев «Әгәр хөкүмәттән әз-мәз паек булмаса, калмыкларның берсе дә язга чыга алмас!»— дип дау күтәреп Тубылга барып, бик күп ишекләрне кагып карады. Тук ачны аңлый мени, Мөхәммәттән көлделәр генә. Кайберләре авызларын аның колагына якын китереп: «Кычытмаган җирне кашып йөрмә, Уразай! Хыянәтчеләрне оҗмахка җибәргәннәр дисеңме әллә? Әйдә үлеп бетсеннәр, дәгъвәсе кимрәк булыр!»— дип пышылдадылар.

Хыянәт тә хыянәт дип дөньяны сасытсалар да, бу гаепнең төбенә төшенә язды сизгер Уразай. Калмыкларның атлы сугышчыларын немец танкларына каршы җибәргәннәр икән... Бу тигезсез һәм хаксыз бәрелештә кем кемне җиңгәнен, сугышның ничек тәмамлануын күз алдына китерү өчен әллә ни зур акыл вә сугыш тәҗрибәсе кирәкми!...

Чырык Абдрахманның йорт-җире таза һәм бөтен диярлек иде әле. «Шул йортны иң ишле балалы гаиләгә бирик!»— дип, Зозуляга тәкъдим ясаган иде Мөхәммәт рәис, лейтенант йортны барып карады да... үзе кереп утырды. Чырыкның капка башына «Комендатура» дип язылган такта очып менде.

Болын кадәрле йортта ята Зозуля киерелеп...

Һәр көн, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән могҗизалар китереп чыгара иде. Сигез-ун градустан артык салкыннарны күрмәгән, Азов буе далаларында гомер сөргән кешеләр, чатнаган, аяусыз гыйнвар суыкларын күтәрә алмадылар. Ачлык аларны аяткан екты, күтәрәмгә калдырды. Көн саен диярлек үлем-китем булмый калмады. Тоташтан дәвам иткән каты салкыннарда туңып тимергә әйләнгән җирне казырлык хәлле адәмнәр Яланда калмаган иде инде. Мәетләрне зират итәгендәге кар көртләренә илтеп күмделәр. Ачлыктан тилмергән, акыллары җиңеләя башлаган калмыклар нәрсә эләкте, шуны ашады. Авылда булган эт, мәчеләргә көн бетте. Фермада сыерлар еш кына бозау ташлыйлар иде. Кешеләр әнә шул үләксәләрне, хәтта сыерларның чүбен-соңгылыкларын көтеп торалар, кайчакта шул «мөлкәт»не эләктерер өчен якага-яка килеп сугышып китәләр иде.

Мөхәммәт Уразаевны соңгы ишетелгән хәбәрләрдән берсе аерата сагайтты һәм ул үзенең шикләрен Зосяга һәм борынгы дусты Дәүләтшә әкәгә генә сөйләде.

— Безнең төбәккә сөрелгән калмыкларны бары тик татар авылларына гына тараткannар!

Зося, мәсьәләнең асылына төшенеп житмәсә дә, монданиндидер хаксызлык барлыгын аңлады, Дәүләтшә әкә авызын ныграк йомды...

Һәр нәрсәдән гыйбрәт алырга, нәтиҗә ясарга остарган Уразаев, Айсетдиннән мирас булып калган кара айгырны җигеп күрше-тирәдәге урыс авылларына юнәлде, анда рәисләрне эзләп табып, идарә әгъзаларын җыйнап-ялварып, кемнән ни, әз-мәз фураж оны, кедр чикләвеге, өшегән бәрәңге алып кайтты, яланлылар һәм калмыклар арасында тигезләп таратты. Электән таныш, тавык күзе булганга сугышка алынмаган Ефим Александровчи Малов атлы рәис, зур колхозның житәкчесе, атлан май белән ярты түшкә сарык ите дә биреп җибәрде. Сарык маен чәйдә йөздереп кинәнде калмыклар!

Соңырак, авылның яшүсмерләре белән бергә, кайбер калмыкларны да леспромхозга агач эшенә җибәрделәр. Моңа рөхсәт алу ифрат катла-

улы, четерекле булып чыкты. Леспромхоз авылдан унике чакрымда иде. Калмыклар исә биш чакрымнан ары китә алмыйлар, рөхсәт юк! Гобәйбә буйдакның базында теге бишьеллыктан бирле качып утырган ике-өч шешә сасы самогон булмаса, комендант Зозуля һәрбер хохол шикелле утлы «первач»ны яратмаса, калмыкларга балта-пычкы эләгәсе түгел иде. Урыс илендә самогон көчле корал ул, капкалардан үтеп керә ул, йозакларны ача, дошманнарны дуслаштыра...

Районга агач кисү планын квартал саен арттырып торганга, калмыкларга да леспромхозда эшләргә рөхсәт ителде. Анда эшләүчеләргә әз-мәз ипи бирәләр иде. Далаларда үскән, гомерләрендә бер агач та егып карамаган кешеләр, очына карасаң башыңнан бүрегең очып төшәрлек биек, юан кедр-наратлар янына барып баскач, тәмам аптыраштa калдылар. Агач егар өчен дә әмәлен белү кирәк ләбаса! Агачның кайсы якка авышып үсүен дә еккач кая барып төшәсен дә, җилгә юнәлешен дә исәпкә алырга кирәк. Агачның кайсы якка егыласын төгәл билгеләмәсәң, ул әле төбеннән өзелгәч тә «бии»башлый. Син һич уйламаган якка авып китә! Ун-унбиш метрлы юан кәүсә барын җимереп-аударып сызгырып төшә башлагач... калмыкларың укынып кайсы-кая чаба башлаганнар... Ике кыз шулай һәлак булганнан соң Мөхәммәт тагын уйга батты һәм «урман кисү белгече» итеп әлеге дә баягы Дәүләтшә әкәне билгеләде.

— Үләргә дә вакыт юк инде! — дип, Дәүләтшә әкә зарланмыйча гына чир-чорларын, картлыгын онытып урман кисәргә чыгып китте.

Әлегә мең бәла кичереп тә исән калган калмыкларны ничек яшәтергә? Авыл халкын ни әмәлләр аша туздерергә? Фронтка ничекләр ярдәм итәргә? Заемга ничек яздырырга да салымнарны ничек итеп җыеп алырга? Гуҗ Зозуляның тамагын ничек капларга? Тамагын капламасаң, аның күзе дә йомылмый. Ә аның күрмәве әйбәт. Кирәкмәгән җиргә барып тыгылуы бер дә кирәкми! Леспромхоз егетләре калмыкларны җәлләп трактор чанасына төяп коры-сары, ботак-сатак китереп киткәннәр иде, Зозуляның сырт йоны кабарды. Ничек? Нигә? Кем рөхсәт биргән?...

Адәмнәр арасыннан иң кирәген сайлап алырга остарган Мөхәммәт бу мәсьәләне дә тиз үк җайга салды. Ул Гобәйбә буйдакка Зозуляны тәрбияләү эшен кушты. Гобәйбә буйдакның аксаклыгын, шадралыгын, чагыр күзен онытып, Зозуля аны кочагына да ала башлады. Ахыр чиктә Гобәйбә буйдак Чырык өендә куна-төнә ятып лейтенантны бакты... Гобәйбә буйдакның иңе-буе шактый зур булган йортын сыйныф бүлмәсе иттеләр.

Мәктәп булган урын яныннан үткәндә Мөхәммәтнең тешләре сыкрый... Директор өстенә төшәргә тиешле бик күп мәшәкатьләрне Миңнурый сылу үз кулына алса да, уку-укыту эшләренә төп җаваплы кеше булып Уразай калып килә. Янган кисәүләрне, бүрәнә башларын кыюрак бәндәләр әллә кайчан ташып якты лар. Вак-төяк чокырларны беленмәслек итеп калын кар каплады... Уразаев үзенең йортын да мәктәп итте: иртә-кичен алмаш-тилмәш укыйлар хәзер, өйнең бер башында. Бу хәлләргә Фагыйлнең куанганын күрсәң!.. Кулларын чәбәкләп сикергәләде кызчык.

— Миңнурый апа, мин беренче класста да, икенче дә дә, өченчедә дә укыйм хәзер! — дип куанды.

Булат белән Мәрзия дә үз йортларын мәктәп иттеләр...

Мөхәммәт леспромхоз җитәкчеләре белән киңәшеп-сөйләшеп йөри башлады, алар карлар китеп, юллар төшкәч тә мәктәплек бүрәнә әзерләп бирергә вәгъдә иттеләр...

Мәктәп салырлык, укырлык, тормышны алга алып барырлык көчләр генә исән-аман язга барып җитәрме?..

Берзаман Мөхәммәт Уразаевка, Кундан күлендә боз астыннан табан балыгын күпләп тоталар икән, дигән хәбәрне ишеттерделәр. Мондый җылы хәбәр колагына эленгәч, һәр эшне печеп эшләргә өйрәнгән Мөхәммәт, атна дигәндә әртил оештырып, үзләре белән калмыкларны да ияртеп, чаналарга елымнарын, сөймәннәрен, нурәтәләрен төяп юлга

чыктылар. Ашыгычрак та китәселәр иде, әлеге дә баягы, Зозуляның кирелегә тоткарлады. «Калмыкларны җибәрергә рөхсәт юк!» — дип карышып катты. Өч көн үгетләде явызны Уразаев. «Балыкның симезләрен, иң зурларын сезгә ташып торырбыз», — дигәч кенә, башын кашып рөхсәт бирде.

Шул күл янына юл тоттылар яланлылар, балык салып кайтырга чыпта капчыкларын да алдылар.

Алар килеп төшкәндә өч әртил Кундан күлендә балык тотып ята иде. Уразаев әртиле дә канатланып эшкә ябышты. Боз кантарлары кисеп җилдән ышыкланырлык эскимос өе — иглу ясадылар. Бик калын бозны кисеп зур гына кое казыдылар. Аннары ярым божра ясап вак-вак бәкеләр тиштеләр һәм елымның бер башын нуриләргә беркетеп коега чумдылар. Нуриле дигәне озын, шома колга була инде аның. Ул боз астыннан йөзеп күрше бәкегә килеп җиткән саен, аны махсус агач ыргаклар ярдәмендә алдагы бәкегә шудыра тордылар. Иң соңыннан йөзеп күрше бәкегә килеп җиткән саен, аны махсус агач ыргаклар ярдәмендә алдагы бәкегә шудыра тордылар. Иң соңыннан дәү коеның почмагында нуриләнең башы күренде. Аңа тотынып елымга бәйләнгән бауны тартып чыгара тордылар. Шулай итеп, елым байтак арадагы суны өереп сөзеп, сары алтындай елтыраган симез табаннарны капчыгына — мәтичәгә җыя барды, ниһаять, елымның ике як канатыннан өскә күтәреп алдылар...

Сөйләгәндә җиңел сыман тоелган бу гамәлләр, чынлыкта бик күп вакыт, көч сорадылар. Бер бәкедән икенчесен эзләп тапканчы өс-баш юешләнеп күл өсте җилендә шыкранлап катты, куллар күшекте. Елым савылып коедан чыгып бетеп, табаннар боз өстендә тупырдашып ята башлагач, нәзек муенлы яланлылар кыл калынлыгы тавышлары белән «ур-ра!» кычкырдылар... «Әртил» белән бергә Сәрвәр һәм Миңнурый да барганнар иде. Алар балыкны күреп күз яшьләрен тыя да алмадылар, кочаклашып җылап та алдылар... Әртил күл өстендә кала торды. Миңнурый белән Сәрвәр бер чана балык төяп кайтып киттеләр. Кайтышлый, Мөхәммәт абыйлары өйрәткәнчә, балыкны иң әүвәл Зозуляга күрсәттеләр. Ул иң эре, иң симез табаннарны чиләк ярым үзенә алып калгач, калган хәзинәне исемлек төзеп авыл арасында бүлделәр. Татарларга да, калмыкларга да өлеш бер тигез иде. Икенче таңда Сәрвәр кайткан атка бер үсмерне утыртып күл ягына озаттылар.

Авыл белән күлнең арасына сукмак салынды... Ходайның рәхмәте белән көннәр җилсез, бурансыз торды. Бер яктан леспромхозда эшләүчеләрдән акмаса да тама, коры утын кайтып тора. Бүген бер өйгә, иртәгәсен күршесенә җылы чыганагын кайтарып аударалар.

Эшләр көйләнгәч, әртилдә ныклы тәртип урнашкач, Булатны баш итеп калдырып Мөхәммәт Уразаев Яланга кайтты. Кайтып, ашап-эчеп тамак ялгагач, Зозуля янына кагылды.

— Тәртипме? — дип сорады ул.

— Тәртип, тәртип... Атна инде үлүчеләр юк, качмыйлар да, — дип мыгырданды махмырдан башы авыртып интеккән комендант. Ул арада авызы ерылган, чамасыз сөенгән Гобәйбә буйдак лейтенантның тар маңгаена юеш сөлге китереп салды.

Мәктәп сыйныфларында эшләр ару гына бара икән, дәрес калдырулар кимегән, татарча белмәсәләр дә, калмык балалары да дәресләргә кереп утыра башлаганнар, аерата зирәкләре телне дә үзләштереп киләләр икән...

* * *

Кырлач. Җиргә тиярлек булып янган йолдызларны туңдырып-калтыратып, Иртеш өстеннән куе салкын ага. Мөхәммәт белән Миңнурый Шәүкәт янына барганнар иде, шуннан кайтып килешли, капка төбендә тукталып калдылар.

— Вакыт исәбен оныта язган идем инде, Мөхәммәт абый,— диде Миңнурый һәм үзенең өлкән дустына сыенды.— Шәүкәт безнең Ялан авылының күзе дә, колагы да, хәтере дә булып яши икән. Ә без көн-төн нужа куып яз якынлашканын да онытып җибәргәнбез. Бүген ул: «Яз килер юлга чыкты, төньяк бозларның шатыр-шотыр уянуын ишетеп ятам мин»,— дип әйтеп, шаккатырды мине.

— Әйе, яз якынлаша...

— Бүтән язларга бер дә ошамас инде ул, иеме, Мөхәммәт абый.

— Шулай булыр төсле, Миңнурый...

— Яз үзгәрмәсә дә, без аны үзгәреп, бөтенләй бүтән кешеләр булып каршылыйбыз түгелме?..

Миңнурый мамык шәлгә төренгән башын Мөхәммәт Уразаевның күкрәгенә куеп, күзләрен күтәреп абыйсының күзләренә бакты. Өлкән иптәшенең кыюсызлыгын күреп, аның нык муенын кочып алды да суырып үпте. Мөхәммәтнең тәне буйлап ут йөгерде, ул Миңнурыйның чакыруын кабул итеп, кызның сизгер, елгыр гәүдәсен кочагына сеңдереп бетерде.

Өйгә керделәр. Зося улын йоклатып, чүпрәк-чапракларын юыштырып, чәй кайнатып аларны көтеп тора иде. Бүген генә җиргә иңгән тантаналы тынлыкны сүз белән бозарга теләмичә чәй эчтеләр.

— Бүген кичен ишегалдына чыккан идем, кош сайравын ишеттем, песнәк булды бугай,— диде Зося. Әллә яз якынлаша инде?

Мөхәммәт белән Миңнурый берьюлы көлеп җибәрделәр.

Зосяның сүзе тәмамланмаган икән әле, ул әтисенә елмаеп карап:

— Әти... Син миңа Иртеш елгасының сихри таңнарын күрсәтергә булган идең. Кайчан атар инде ул җиргә сөенеч китерер таңнар?— дип сорады.

Хәзерге заманның һәр соравына сак карарга гадәтләнгән, җаваплары җиде кат үлчәп кенә бирә торган Мөхәммәт Уразаев кызының бу соравына өзеп кенә сүз әйтмәде, әйтә дә алмады. Йокларга яткач та ул бу хакта озак итеп, уйларын бик тирәннән казып чыгарып газапланып ятты.

Иртештә таңнар атар анысы, шәфкатьле Аллаһе тәгалә татар ягын бөтенләй ятим итеп өметсезлек дәрьясына агызып җибәрмәс. Тик ул таңнарда хәзер газапланып яткан калмык халкы бәхетле булырмы? Әгәр алар бәхетсез, йортсыз-җирсез байгыш язмышлы икән, Иртеш таңнарының яме җитәрлек булырмы? Ташкәй, Йосыфлар исә Мәүлия, Сәрвәр туташларның куанычына исән-аман кайта алырлармы? «Сәгъдетдинем кайтты, ашка килегез!»— дип, Гыйззәтбану түти өйдән-өйгә өндәп йөрерме?.. Булат-Мәрзияләрнең уллары туармы, кызлары? Шәүкәтне бага-бага Мәүлиха артыгын алҗып калмасмы?.. Фаягөл Миңнурый апасына кем дип дәшәр?..

Тагын бик күп, бик авыр сораулар Мөхәммәтнең киң маңгаена яңа сырлар сызган төн авыр гына үтеп бара иде. Юк, Мөхәммәт элеккечә ансат уйламый иде инде. Ул таңнарга хуҗа булып үзен алда көтеп торган мәшәкатьләр, нужалар, хәсрәтләр хакында да уйлый хәзер. Шамил үсә төшкәч Зося кая таба борылыр? Мөхәммәтне борчыган сораулар арасында бусы да бар иде. Бәлки иң мөһиме шул булгандыр да әле?

*1980—1990 еллар.*
*Хуҗайлан-Тубыл.*

---

Искәрмә: роман язучы Аяз Гыйләҗевнең әдәби эшкәртүендә басыла.

ШИГЪРИЯТ



**Халисә Мөдәррисова**

## Кырык яшьтә

Пәйгамбәр яры яшендә —
Минем иң пешкән чагым,
Үзем теләп учларыңа
Өзелеп төшкән чагым.

Минем әле шундый чагым:
Ут булып янам кебек,
Кыраудан соң көз башында
Балланган балан кебек.

Минем әле шундый чагым —
Дөньяга алкышым бу,
Үкенечкә калган язның
Күзендә балкышым бу.

Пәйгамбәр яры яшендә —
Хисләрне тыймас чагым,
Кадереңне белеп сөяр,
Сөелеп туймас чагым.

## Ташлар җыям

Ташлар җыям, төсле ташлар,
Дөнья гүзәл, дөнья — садә,
Тормыш кебек чал дулкыннар
Бер тына, бер ярга бәрә.

Дулкын чигә, юеш ташлар,
Берсе якут, берсе — алмаз,
Йә зөбәрҗәт кебек яна,
Кем иелеп аны алмас.

Мин әкият дөньясында —
«Асылташ» дим, аяк аста,
Тик тамчылар кибәләр дә
Әйләнә ул чуерташка.

Үлә нурлар, сүнә төсләр,
Таш — таш булып кала бирә,
Ә битараф бу дулкыннар
Яңа ташлар кага бирә.

Асылташ, дип, чуерташка
Алданулар булды инде.
Бер балкысам, мен сүрелдем,
Күңел әрнеп тынды инде.

Кесәм тулы, учым тулы,
Җанда ята күпме ташлар.
Җыйдым үзем, бәрде кеше
Яраланды җаннар, башлар.

Ташлар ява, ташлар авыр,
Күңелемне китеп килә,
Гомер үтә, шул ташларны
Санар вакыт җитеп килә.

Ташлар җыям, тик дөньяга
Мин таш түгел, аш атырмын,
Ә ташларны...
Күңелемә атканнарын,
Йөрәгемдә ятканнарын
Җырларымда балкытырмын.

* * *

Үз илендә пәйгамбәрләр булмый,
Булалмадым мин дә пәйгамбәр.
Булды алар, булды, тик мин түгел —
Өлешенә көмеш тигәннәр.

Мин яраттым сине әрнү белән,
Бит газапка булды бер рәхәт,
Булдың миңа ятлар яры кебек,
Бер җавапсыз гүя мәхәббәт.

Сөйкемле зат булалмадым синдә,
Ни кылсам да күңел кителде,
Үз өендә үги ана белән
Үсеп килгән бала шикелле.

Денем өчен дисәм, көнем өчен
«Әпипә»гә дөнья биетте,
Гөрләп торган табын түрләремдә
Җыен әрсез җырлап туй итте.

Җыр башласам, җырны гайбәт күмде,
Сүз сөйләсәм, кабер салкыны,

Йә битараф тынлык, таш коймадай,
«Син чит, син ят»,— диеп талкыды.

Ә шулай да юка иңнәремдә
Пәйгамбәрләр йөге йөретәм,
Кабатланмас фани бу дөньяның
Һәр мизгелен бакый җыр итәм.

Үз илендә пәйгамбәрләр булмый,
Булмасам да мин дә пәйгамбәр,
Минем авыр йөктән хәзинәсен
Үзе алыр,— үзенә тигәннәр.

## Очкынлана яфраклар

Офыкларда көзге кояш
Сүнде сибеп ал нурын,
Баш очында ак торналар
Калдырып үтте җырын.
Алар алып китә сине,
Торналарда — канатлар,
Ә усакта, хушлашкандай
Очкынлана яфраклар.
Хушлашма үткәннәр белән,
Син — минем күрәчәгем.
Мин синең үткәнең түгел,
Бүгенгең, киләчәгең.
Язлар алып кайтыр сине,
Мәхәббәттә — канатлар.
Тик усакта, хушлашкандай,
Очкынлана яфраклар.

## Яңа ел алдыннан

Җылы да юк күңелемдә,
Салкын да юк, каргыш та юк.
Күңел ап-ак кәгазь сыман,
Юксыну да, табыш та юк.
Үткәннәр юк, киләчәгем —
Башланмаган бәхет кебек,
Учак кына — берчә алтын,
Берчә күе кара дегет,
Очкын гына ялтлап сүнә,
Синең таныш сының кебек.
Төшме, өнме бүгенге кич,
Сагышларны утка салам,
Бөтерелеп, ялкын ялмап
Югалганын карап калам.
Сабыр гына искә алам,
Тыныч кына хатлар ягам.
Башланмаган бәхет кебек
Яңа елны каршы алам.

* * *

Кайларда йөрдек икән без,
Нинди сулар эчкәнбез
Гомер үткәч, кичләр җиткәч,
Бер учма нур микән без?
Кайларда йөрдек икән без,
Сак белән Сок микән без,
Әллә, язмышка үч итеп,
Так белән җөп микән без?
Кайларда йөрдек икән без,
Үкенечкә микән без,
Әллә — бәхетнең үземе,
Бәхетсезлек микән без?

* * *

Таң алдыннан тагын буран,
Март аеның соңгы җиле.
Карамыйча тамчыларга
Ак кар белән күмә җирне.
Өерелә, бөтерелә,
Әйтерсең лә кыш арада.
Күңелемә карлар ява
Салкыннардан кем аралар?

Яз — яз булыр, соңгы буран,
Соңгы тапкыр бөтерелер,
Күңелемә яуган карлар
Кайчан туктап, кайчан эрер?

## Кара кош

Әйтерсең тәүге югалту,
Йөрәк әрни дә тора,
Кайгы кара кош шикелле
Күңелгә оя кора.

Әйтерсең кыш уртасында
Яз кабатланган иде,
Ак күгәрчен кебек сөю
Бер канатланган иде.

Бөтерелде, талпынды да
Югалды зәңгәр күктә,
Сызланма, күңел, син белдең,
Килмәсен аның күпкә.

Хәзер күңел түрләремә
Кара кош оя кора,
Бу соңгы югалту кебек
Йөрәк әрни дә тора.

* * *

Иртә иде әле күз булырга,
Июльләрдә йөрәк тавышым,
Күңелемдә әле җәй уртасы,
Ә күзләргә кереп барышым.

Кагылалар минем яңакларга
Ут-кипарис, миләш бәйләме,
Вакыт урманымда — яфрак туе,
Ә күңелдә — гөлләр бәйрәме.

Ә күңелдә — хисләр тантанасы,
Әйтеп бетергесез хозурлык,
Син бар миндә, шуңа гомер күзем
Барлык язларыма торырлык.



# Әзһәр Габиди

## Була төрле чаклар

Сөенгән чак та була,
Көенгән чак та була,
Сөенсәм гамь,
Көенсәм кан
Йөземә килеп куна.

Җырлаган чак та була,
Елаган чак та була,
Җырласам дәрт,
Җыласам яшь
Йөземә килеп куна.

Атлыккан чак та була,
Абынган чак та була,
Атлыксам дан,
Абынсам кан
Йөземә килеп куна.

Егылсам да,
Еласам да
Түзәрмен мин барсына,
Үҗәтләнеп таш ыргытмам
Кешеләр бакчасына.

Елмаеп кына барырмын
Дусларым каршысына,
Чәчәкләр генә бирермен
Мин аларның барсына.

## Чит утлар җылы түгел

Канәгать булып яшим мин
Туган ил бирнәсенә,
Җылынырга сырышмыйм мин
Чит утлар тирәсенә.

Урман-кырым, болын-суым
Иңләп бетәрлек түгел,

Офыгыннан — офыгыма
Барып житәрлек түгел.

Чит җирләрнең мөлкәтенә
Исем китәрлек түгел,
Туган илем хәзинәсен
Әйтеп бетәрлек түгел.

Үзең кабызган утлардан
Чит утлар җылы түгел,
Үзең аттырган таңнардан
Чит таңнар нурлы түгел.

Җылынырга сырышмыйм мин
Чит утлар җылысына,
Чөнки мин яшим илләрнең
Хозуры, олысында.

## Ышаныч

Күп вакытта була күңелем
Кайгыдан мөлдерәмә,
Төннәр буе кайнар яшем
Коела мендәремә.

Кичергән шул кайгыларны
Үлчәп лә булса әгәр,
Җирдә булган бер үлчәү дә
Күтәрмәс иде мәгәр.

Авыр кайгыларны куып
Килмичә калмый шатлык,
Гамьсез генә яшәгәнче
Кайгырып яшәү артык.

Кайгыдан ник баш иягә,
Кайгысыз булмый тормыш,
Егет булсаң син кайгыны
Җиңеп чыгарга тырыш.

Күп вакытта була күңелем
Кайгыдан мөлдерәмә,
Ләкин ышанып карыйм мин
Туасы көннәремә.

## Гөлгә мансам иде

Дөнья кичәр өчен,
Юллар үтәр өчен,
Кеше килә җиргә;
Умырзая кебек,

Бик аз гына көлеп
Яши икән нигә?!

Күңел уятырлык,
Кеше елмайтырлык,
Җырлар язсаң иде;
Язган җырларым да
Теләк, уйларына
Күпер салсам иде.

Алсу яшен кебек,
Зәңгәр күкне телеп,
Балкып янсам иде,
Шушы газиз җирне,
Туып үскән илне
Гөлгә мансам иде.

## Сагындырырмын

Ялган белән мавыкмадым,
Сүз белән каратмадым,
Игелек кылдым кешегә,
Яман атны сатмадым.

Булмады түгел, булды бит
Ялага тарыганым,
Ә шулай да беркемгә дә
Шикләнеп карамадым.

Имән кебек сабыр булдым,
Усак кебек шаулադым,
Эшнең җиңеле димәдем,
Иң авырын сайладым.

Эзләнеп юлларда үтте
Иртәләрем, кичләрем,
Яктырттым гомерем буе
Нәниләрнең хисләрен.

Әйтер сүзем булган чакта
Яшереп сакламадым,
Тырыштым мин кешеләрнең
Җылытырга җаннарын.

Арган-талган чагымда да
Уфылдап суламадым,
Түземлегемне югалтып
Йөз сытып сызланмадым.

Җирдән киткән чагымда да
Көлеп кенә китәрмен,
Сабыр, тыйнаклыгым белән
Сагынырлык итәрмен.

## Күбәләк булып куна

*Үлгәч кешенең җаны*
*күбәләк булып кайта, диләр.*

Саубуллашу көне җиткәч
Хушлашмыйча да булмас,
Ләкин минем һич кайчан да
Яшәүдән җаным туймас.

Сау чакта да кайгы белән
Һич кемне борчымадым,
Соңгы сәгатьләрем сугып
Сүнгәч тә борчымамын.

Ничек итеп Сез дусларны
Ташлап китәсең инде?!.
Җаннан якын җирдәшләрне
Ятим итәсең инде?!.

Кайтырмын сезнең арага
Күбәләк булып кына,
Йөрермен сезнең тирәдә
Гөлләргә кунып кына.



## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Факил Әмәк**

# ЧЫТЫРМАНДА КОШ ОЯСЫ

ПОВЕСТЬ

Быелгы сабантуен Әхнәфтән дә ашкыныбрак көтүче булды микән? Иртәгә бәйрәм буласы көнне өйгә дә кайтмады ул. Әле кич булып беткәч тә Бәдри бабасы белән «Йолдыз» тирәсендә бөтерелде, йөгәненә каештан ясалган җыйнак, матур кара чуклар тагып куйды, җиз тәңкәләр белән бизәде. Ул кайтып киткәндә инде йолдызлар калыккан, Күперле урамнарында бәйрәм алларында гына була торган күңеллелек хакимлек итә иде. Күктә сызылып кына яңа ай туган, Коры елга буенда бакалар чурылдый, баш очыннан гына пырхылдап адашкан бер кош очып үтте.

...Бәйрәм көннәре Гөлҗиһанга куаныч китерми, бәйрәмгә каршы төндә исә төне буе күзенә йокы керми, яткан урынының җаен тапмый, түшәгендә ауный торгач, тәмам изелеп, алҗып бетә. Кемнәрдер кунаклар көтә, шау-гөр килеп күңел ачалар. Кайсылары үзләре каядыр кунакка китеп баралар, андый чакта йорт-җирләренә күз-колак булып торырга Гөлҗиһанга тапшыралар. Күрше хакы — тәңре хакы, Гөлҗиһан авырыксынмыйча гына риза була, гадәттә, бәйрәмнәр ике-өч йорт арасында йөгереп үтә дә китә. Үзе кунак төшергән кешедән ким мәшәкатьләнми ул.

Шулай, аларга кунак киләсе дә юк, үзләренең барасы җире, чакырган кешеләре юк. Шәйхаттар абыйсы да таш йөрәкле булып чыкты, кайтып күзгә күренү түгел, елына бер-ике хат салса сала, салмаса анысы да тәтеми. Эштәге уңышлары өчен берничә ел элек Зуравылга, алдынгы терлекчеләр җыелышына һәм ак он тегермәне дигән булып Әмәкәйгә барып кайтуны уйламаганда, Гөлҗиһанның Күперледән чыкканы да юк иде. Зуравылга зоотехник белеме алып кайткан яшь кенә егетне куйганнар иде. Ул инде баш күтәрми эшләүче Гөлҗиһан апасын бик тә үз итте, җай килсә, мактап, иң беренче аның исемен атый башлады. Моңарчы Сәйфинең каныгуларыннан башканы белмәгән хатын, мактау сүзләре ишеткәч, бөтенләй үсенеп китте, иңенә басып торган төшенкелек, күңел күгән каплап торган шыксыз болытлар тарала башлады.

---

Ахыры. Башы 11 санда чыкты.

Гыйльметдин килеп кергән төннән соң... Ул бөтенләй үзгәреп китте шикелле, офыклар киңәйде, йөрәгендә, еш кына, кинәт актарылып төшкән язгы ташудай хисләр өермәсе кузгала. Мондый чакларда, сизмәстән өй түренә эленгән зур көзге каршына килеп баса. Карый да исе китә — ул әле үз-үзен ышандырып йөргәнчә, җилкә сөякләре төртеп чыккан, өзлексез авыр эштән кул бармаклары бирчәеп каткан, авыр уйлардан, кайгы-хәсрәтләрдән бөкшәеп калган карчык кыяфәтендәге бетәшкән хатын түгел! Көзгедән аңа шактый яшь йөзле, төскә-биткә чибәр, мөлаем хатын карап тора. Һи-и, иреннәренә елмаю да килеп кунакласа, Шәмси түти әйтмешли, егетләрнең иң кәттәләренең дә башларын әйләндереп бетерә әле ул! Күзләреннән тамам-тамам дип торган сагышлы моңсулык та аңа килешеп кенә тора икән. Гәүдәсе чандыр булса да, сөякләре төртеп торган арык түгел, тыгыз бәдәнле, йомры гәүдәле хатын. Кул-аяклары да, сөбханалла, килешле. Җиңсез юка күлмәге аша тулы күкрәкләре төртеп тора. «Йә, Раббем,— дип сөйләнә ул үзалдына,— минем бит әле сөеп-сөелеп туймас чагым, яшәүнең чын тәмен белеп яши башлар чагым... Нигә мине ким яраттың соң Син?! Башкалар кебек минем дә бәхеткә хакым бардыр бит...»

Фермада, терлекчеләр йортында бергә җыелышып утырган чакта, ир-ат заты күренмәсә, хатын-кызларның сүзе, әлбәттә, гыйшык-мыйшык эшләренә килеп терәлә. Аяусыз сөйләшеп өйрәнгән Гөлзада, Куян Сәйфинең йодрык хәтле генә хатыны, аякларын алга сузып бер киерелеп ала да һәрнәрсәнең «исем-фамилиясе» белән атап, тел чарлый башлый:

— И-и малайкайлар, кияүгә чыккан мәлләрдә ир белән йоклауның тәмен белеп буламыни ул?!. Мин дә шулай идем инде. Сәйфинең мышнап азаплануына әлсерәп ятасың да, бетте-китте. Чиратың үткәнгә сөенеп йокы ягын каерасың. Ни рәхәте, ни ләззәте дигәндәй... Икенче малай тугач, үземне җен алыштырдымыни, малайкайларым. Сиздем бит эшнең нәрсәдә икәнен. Хәзер, уйнап әйтү түгел, Сәйфинең кыбырсый башлаганын гына көтеп ятам. Үземнең кайда ятканымны онытыплар бетерәм инде... Әле кичә Сәйфи эштән соң печән алып кайтты, төн уртасына кадәр чиллек түбәсенә кертеп өйдек. Яткач, мин сиңа әйтим, Куяным артын куйды да, мырлап йокыга да китеп маташа. Алай боргаланам, болай боргаланам, селкенми дә теге. Эш-эш ди торгач, тәмам йончыган бу. Һи-и, ниятенә кергәч, үземнекен итмичә каламмы соң! Тәки уяттым тегене...

Куеннарында ир асраучы хатыннарны тотып тыям димә инде, шуны гына көткәннәрмени, бу темага башланган әңгәмәнең кызуын сүрелдермәскә тырышып, учакка һәркайсы үзенең өлешен өстәргә тырыша. Күзләр яна, телләр-телгә йокмый, үзләре шырык-шырык көләләр. Бу «нечкә мәсьәлә» кечкенә вaклыкларына кадәр тикшерелә башлый. Мондый күтәренкелек, мондый җанлылык башка мәсьәләләрне хәл иткәндә сирәк күзәтелә торгандыр. Бер читтә нәүмизләнеп утырган Гөлҗиһан алар өчен әллә бар, әллә юк. Берсе туктамас борын, икенчесе сөйләргә тотына, чыр-чу, көлеш...

Мондый чакларда Гөлҗиһан оялып, кимсенеп, үзалдына бикләнеп тик утыра. Ярый да нинди дер сәбәп чыгып, туктап каласы итсәләр. Башкача алар тынарга уйламыйлар да. Гөлҗиһан тәмам аптырашка төшә. Чыгып китсә, теге хатыннар үз артыннан мыскыл итеп калырлар сыман, берәрсе йөрәкне көйдереп алырлык сүз әйтергә дә тайчынмас. Калсалар-калырлар инде, бу пычрак сүзләрдән гарык... Ул түзми, ферма өенең авыр ишеген ачып, тышка атыла...

* * *

Сабантуе буласы урынга Гөлҗиһан соңлап килде. Мәйдан инде гөж килә. Соңгы көннәрдә яңгырлар яугалап торган иде, бүген исә көн — сорап алган кебек. Кояш юмартланып нурын сибә, җанга рәхәтлек биреп, ара-тирә талгын җил исеп куя. Дымга туенып,

чатнар дәрәҗәдә сусылланган үләннәр келәм кебек җәйрәп ята, аяк атлаулары рәхәт. Чиста зәңгәр күккә анда-санда каурый болытлар типчеп куйганнар. Мәйдан тирәсенә җыелган халык бар гамен онытып, сабантуй мәйданын күзли: уртада исә ихлас дәрт белән малайлар бил алыша. Йөзләгән күз алдында «яшь әтәч»ләрнең һич тә сынатасы килми, сөлгеләрен билләренә җүнләп салырга да өлгермиләр, түгәрәк буйлап зырлап бөтерелә дә башлыйлар: мең кат кәҗә майларын сыккан, азу ярган көрәшчеләр кебек җиргә кадәр сыгылып төшәләр, уңга-сулга тарткалаган булалар, аякларын саташтырып чөңкәеп тә киткәлиләр, икенче карауга инде икәүләп чирәмдә мәтәлеп яталар. Гөлҗиһанның мәйдан уртасында барган бу күңелле галәмәтне бик карыйсы килсә дә, озак тоткарланмады. Яланның аргы башында ат җитәкләп, чабышка хәзерләнеп йөрүче үсмерләр янына ашыкты. Әхнәфне башкалар арасыннан ерактан ук танып алды. Ак майка, кара чалбар кигән Әхнәф «Йолдыз»га минут та тынгылык бирми, тезгененнән җитәкләгән дә әрлебирле теркелдәп йөри, атын әкренләп кыздыру эшенә керешкән иде. Әнисен күрүгә, малай, атын җитәкләгән көйгә, аның каршысына килә башлады.

— Әнкәй, чабышка баручылар язылды инде,— диде ул бик мөһим яңалык әйткәндәй.— Мин дә язылдым.— Урынында биеп кенә торган «Йолдыз»ның маңгаеннан сыйпап алды.— Бәдри бабай әйтә, быел «Йолдыз»ны узар ат күренми, ди. Җай белән генә узышсаң, мәхәтле, беренчелек синеке, ди.— Узыш белән тәмам сихерләнгән малай үзенең шөбһәләрен дә әйтеп алды:— Сәйфи абзый камчысы белән уйнарга ярата, аннан сак булырга кирәк...

Озын торыклы, ялтырап торган тыгыз бәдәнле чабыш атын күргәч, Гөлҗиһан борчуга төште.

— Беренче киләсеңме, унынчымы — сак бул инде, улым. Ат өстеннән егылып төшә күрмә. Сезнең эше малай-шалай белән Сәйфи абыең ярышып йөрмәс инде, кана.

— Һи-и, Бәдри бабай әйтә, Куян Сәйфи шул чүпрәк-чапрак өчен үлеп китә, ди. Ел саен чабышка барып, тавыш чыгармый калганы юк ич. Хәрәмләшеп булса да беренче бүләкне алып кала. Шуның өчен ярышка да үзе бара, югыйсә малаен атландырса да була инде.

Сәйфинең эшкә жигеп йөрүче Туры биясе дә чабышкылар нәселеннән булып, «Йолдыз»дан калышкан җире юк икән. Үз дәрәҗәсен белеп, арт саннарын уйнатып баруын гына күр син аның!

Чабышка әзерләнгән атларны зоотехник Мәхмүт абый әле язылган чакта ук җентекләп тикшергән иде, Коры күперне чыккач, янә бер мәртәбә күздән кичерде, аннан ярыш тәртибен аңлатты да мотоциклга атланып, иң алдан Айтык чишмәсе буена җилдерде.

Әхнәфләр барып житкәндә, Мәхмүт ике юл читенә кечкенә әләмнәр кадап куйган, итек үкчәсе белән шактый тирән итеп аркылы эз ясалган — бусы кузгалып китү сызыгы инде. Кабат ярыш тәртибен аңлатып, атларны чабыш сызыгына тезеп, шактый вакыт үтте.

* * *

Сәйфи үкенеп бетә алмый, бик уңайлы чаклар булды, тик аяк астында шушы бүрек кадәр малайның уралып йөрүе һәрчак җентекләп төзелгән планнарны да җимерә дә куя иде шул. Их, Гөлҗиһанга кызыкты да инде ул! Авыруга сабышкан мәлләре дә аз булмады. Кысыр хыяллар белән күпме көннәр, төннәр үткәрде ул, әмма яшь хатынның кайнар кочакларында эрергә насыйп булмады шул. Аннан инде ачуына чыдаша алмый, Гөлҗиһанга өзми-куймый бәйләнә, аның эшеннән гаеп табарга тотына. Узган елгы вакыйгадан соң үзара дошманлык хисе бигрәк көчәйгән иде.

...Үткән җәй, уку тәмамлангач та, Әхнәф бозаулар көтәргә кергән иде. Башта Мәхмүт абыйсы: «Син бәләкәйрәк шул әле, көн саен иртүк торып эшкә йөрүләре авыр булыр»,— дип, аны читкәрәк кагарга омтылып караса да, малайның туктаусыз диярлек артыннан ияреп, ялварып йөрүе үзенекен итте, рөхсәт бирми булдыра алмады. Аннан, көтүне үзе генә көтми бит, янәшәсенә үзе кебек үсмерне куйсаң, эш бөтенләй үк өметсезгә әйләнмәс, дип тә уйлады ул.

Әхнәфнең исә көтү көтәргә керүенең дә сәбәпләре бар. Беренчедән, алар яшендәге барлык малайлар да колхоз эшенә катнаша башлый инде, кем үҗәт, өлгеррәк, шуңа эшнең төшемлерәге эләгә. Акча мәсьәләсе бик мөһим, малайның яшерен хыялы — җәй буе эшләгән акчасын җыеп, үзенә өр-яңа велосипед алу иде. Икенчедән, ел саен, беренче сентябрь көнне бәйрәм линейкасына тезелгәч, колхоз җитәкчеләре эштә катнашкан укучыларга бүләк тапшыралар. Тегенди-мондый эшләрдә йөреп вакыт үткәрүчеләргә көндәлек, циркуль ише «бүләкләр» тия; комбайн ярдәмчеләре, көтүче булып эшләүчеләрне зурлап телгә алалар, тәбриклиләр, бүләге дә, әлбәттә, мулдан була. Әхнәфнең бүләккә әллә ни исе китми, әмма мондый укучыларга мәктәптә караш икенче була инде, хәтта классташлары арасында да андыйларга башка мөнәсәбәт: алар белән киңәшләшәләр, хисаплашалар иде. Малайның эш күрсәтәсе, тизрәк зур булып үсәсе, егет буласы килә иде шул. Үзең эшләп тапкан акчага алынган велосипедка атланып җилдереп кенә укырга килүләре, эре-эре атлап мәктәпкә кереп китүләре ни тора! Әтисез үскән малайның башкалар алдында кимсенеп йөрисе, сынатасы килми иде.

...Мәхмүт абыйсыннан рөхсәт алган көнне малай кош тоткандай йөрде. Көтүгә чыгарга атлыгып торган икенче малай Рәфит иде, Әхнәф белән икәүләп эшкә башладылар. Икесенә дә атланып йөрү өчен атлар бирделәр. Бәдри бабай әйтмешли, көтүче атсыз буламыни!

Әхнәфнең өлешенә кыш көне силос базына төшкән чакта аягын имгәткән «Очар» кушаматлы алаша туры килде. Үзенә аксак ат бирүләренә кәефе китеп йөрсә дә, күндәм холыклы тимеркүккә Әхнәф тиз ияләште. Җаен табып, бахбайга тәмлерәк ризык җүнәтә, җәйләүдә эшләүче Өлфәт абзыйдан көн саен ялынып-ялварып бер чиләк апара алып чыга. «Очар» тәмлегә өйрәнеп киткәч, малайның артыннан энә артыннан йөргән җеп кебек тагылып кына йөри башлады. Тимеркүкнең шушы гадәте бик ошый иде. Башка малайлар белән очрашырга туры килсә, аты өстеннән сикереп кенә төшә дә, нинди дә эш табып кайсыдыр тарафка китеп барган була, «Очар»да аннан калмый, артыннан әллә кайларга барып керә иде. Яшьтәш малайларның бу хәлгә исләре китә, гаҗәпләнеп, үзләренчә сынау оештыралар: Әхнәфне әле бер якка җибәрәләр, әле икенче якка — ат тәмам сихерләнгән кебек, хуҗасы артыннан теркелдәвен белә. Малайлар инде Әхнәфнең «өйрәтелгән» атына, чын-чынлап көнләшеп карый башлыйлар.

Җәй урталарында «Очар» тазарды, матураеп китте. Җәйләүдә Әхнәфне күрсә, озын аксыл ялларын җилдә тузгытып, гәүдәсен уйнатып хуҗасының каршысына чабып килә, хәтта йөгән кигерткәндә баш бирми, кылтая, малайны ирештерергә дә чамалый башлады. Мәхмүт абыйсының: «Атның аяк сеңере зыянланган, көч китермәсәң, әкренләп рәтләнер»,— дигән сүзләре дөрескә чыкты. «Очар»ның аксап йөрүе бетте дияргә дә була иде.

Рәфит белән тыныч, тату эшләделәр, бозаулар белән дә хәвефхәтәр күрергә язмаган икән, җәй матур гына узып та китте. Сатучы Шәрифҗан абый, сорауны үтәп, Зуравылдан Әхнәфкә велосипед алып кайтып бирде. Беренче сентябрь көнне тәбрикләүләр дә булды, ул елгы хыяллар тулысынча тормышка ашкан иде. Барсы да әйбәт бара иде...

...Укулар башланып берничә көн үткәч, Әхнәф мәктәптән бик күңелсез кайтып керде. Әнисе дә яңарак кына эштән кайткан, өй җыештырып

йөри иде. Күңелсезләнеп кереп килүен аяк тавышыннан ук тоеп, әшеннән бүленеп, улына сораулы карашын текәде.

— Ник болай балтаң суга төшкәндәй кайтып кердең әле? — диде ул тизрәк мәсьәләнең асылына төшенергә теләп.— Мәктәптә бер-бер хәл булмагандыр бит?

Малай җавап кайтармады. Өйгә үтеп, букчасын чөйгә элеп куйды һәм урындыкка барып утырды. Һаман авызыннан бер сүз чыкмый. Башка вакыт булса, тизрәк өстәл тирәсенә сырышыр иде, бүген бөтенләй үзгәреп кайткан бу малай.

Әнисе хафаланып, кабат сорады:

— Йә, ни булды, сөйлә инде.

Әхнәф яшь тыгылган күзләрен читкә борып, борынын лышкылдатып алганнан соң, телгә килде.

— «Очар»ны ит нәрәтенә җибәргәннәр...

— Кем әйтте? Савыккан иде түгелме соң инде ул?

— Иртән мәктәпкә барганда күреп калдым. Куян Сәйфи белән Гариф абый куып алып киттеләр. Ташлыяр юлы буйлап. «Очар»да бар иде анда. Әллә мине күрде инде, туктады да урам якка карап кешнәп җибәрде. Мин житешә алмадым, Сәйфи камчы белән каезлый-каезлый төркемгә китереп кушты мескенкәйне... Мине күргәндер ул, күрми калмагандыр.

Малай үксеп елап җибәрүдән чак тыелып утыра иде. Гөлҗиһан улын тынычландырырга ашыкты:

— Аръяк басуга алып чыкканнардыр. Көтүгә. Трактор арбасын өстерәрлек атларны ит нәрәтенә җибәрәләрмени!

— Мин дә башта шулайдыр дип уйлаган идем. Урамда Мәхмүт абый белән Гөлзада апаның сөйләшеп торганнарын ишеттем. Гөлзада апа: «Сәйфи бүген кайтамы?» — дип, Мәхмүт абыйның каршысына чыкты.

— Мәхмүт абыең нәрсә диде соң?

— Кичкә кайтып житәрләр, диде, унжиде баш атны ит нәрәтенә илтеп тапшыра алсалар, эшләре бетә. Ташлыяр качкан жир түгел, утыз чакрым араны икешәр көн үтмәсләр инде, ди. Гөлзада апа да син әйткәнне сөйләде. «Ни йөзегез белән ул атларны ит нәрәтенә җибәрәсез?» — ди. «Ун яшен тутырган барлык атларны ит нәрәтенә җибәрергә задание килде. Райкомга карышып булмый инде»,— диде Мәхмүт абый. Гөлзада апа шәп әйтте үзенә дә...

— Нәрсә диде соң ул?

— «Тыч... райкомыгызга!» — диде.

— Кирәкмәгәнне ишетергә оста син! — Гөлҗиһан улын шелтәләп алды.— Башка кешеләргә сөйләп йөри күрмә тагын.

Әхнәф анын сүзен ишетмәгәнгә салышты. Һаман үзенекен уйлый иде булса кирәк.

— «Очарга» ун яшь туласые бит... Әләккән инде, бичара...

Шушы әңгәмәдән соң Әхнәф көне буе күңелсезләнеп йөрде. Йокларга да соң гына ятты.

...Таң алдыннан сикереп торды ул. Ашыгып әнисен уята башлады.

— Әнкәй... әнкәй, дим. Тор әле...

Гөлҗиһан таңгы йокысы бүленүгә ризасызлык белдереп, сөйләнеп алды:

— Ни булды тагын? Ник йокламыйсың?..

— Әнкәй, «Очар» кайтты!

— Саташып ятма инде. Шул атың белән хыялланасың инде.

— Саташмыйм, бакча башында ат кешнәп алды...

— Яланда атлар күп булыр ул.

Гөлҗиһан сүзен әйтеп бетермәде, ап-ачык итеп ат кешнәвен ишетте дә тукталып калды.

— «Очар» бу, әнкәй, «Очар» кайткан!..

— Ничек кайтсын ди ул? «Алып киттеләр» дисең ич...
— Ничек кайтуын белмим. Мәгәр «Очар» тавышы бу,— дип Әхнәф ашыгып киенде һәм тышка чыгып йөгерде. Яктырып килә иде. Гөлҗиһан улының шактый озак керми торуына борчылып ятты-ятты да, үзе дә киенеп ишек алдына чыкты. Чыкса, исе китте — Әхнәф арт утарда, ат тирәсендә мәш килә.
— Кайткан, качып кайткан,— дип сөйләнде ул куанычын яшермичә. Аннан әрнеп атның сыртындагы кан саркып торган буй-буй эзләргә күрсәтте.
— Куян каезлаган, мескенне...
Гөлҗиһан улының олы телләнеп, өлкән кешене кушаматы белән атауны өнәмәсә дә, ат сыртында ярылып яткан камчы эзләрен күреп, тын калды. Әхнәф бакча артындагы печәнлектән курпы чабып кайтырга да өлгергән. Ат алдына чиләк белән бераз солы да чыгарып салды.
Шуннан соң гына тынычлангандай булды малай. Өйгә кереп, ашык-пошык чәй эчте, әле вакыт бар, черем итеп алырга исәпләп, урынына барып ауды.
Әнисе аптырый төшеп, сорады:
— Атны нишләтмәкче буласың соң, улым? Болай бездә тора алмый бит инде ул.
— Мәхмүт абыйга ялынсам, яңадан җибәреп тә тормаслар...
Ул бу сүзләрне бик ышанып әйтте...
...Озак йокларга туры килмәде.
Ишек алды ягында кычкырып сөйләшкән ирләр тавышына уянып киткән уңайга тәрәзәгә капланган иде, йөрәге «жу» итеп китте. Күзләр башта әлҗе-мөлҗе килеп торды, ишек алдында Сәйфине күргәч, йокы мизгел эчендә юкка чыкты. Сәйфи «Очар»ны лапастан алып чыккан, кычкырып әнкәсенә нидер аңлата иде, ахры. Әхнәф үз-үзен белештермичә тышка атылды. Әхнәфне күреп алгач, Сәйфи тагын да кычкырыбрак сөйләргә кереште:
— Ташлыярга илтеп җиткерсәмме! — ул гайрәтләнеп атның йөзенә селтәнде,— үз кулларым белән бугазлыйм мин моны! — Аннан әнкәсенә борылды.— Бикмәч сыртыннан күтәрелгәндә кинәт ешкынлык арасына ыргылды, паразит...
Әхнәф үзен белештермичә Сәйфинең кулына урап тоткан нуктага барып ябышты.
— Кем кушты сиңа безнең ихатага керергә! — диде ул ярсып.— «Очар»ны бирмим мин сиңа, хәзер Мәхмүт абый янына барам.
Арыслан-киек кебек ыргылып ат янына килеп баскан малайга Сәйфи сәерсенеп карап торды. Кулы белән Әхнәфне читкә этәрде.
— Аяк астында уралма, малай актыгы.— Үзе нәрсәдәндер шикләнгән сыман атны капкага таба куалый башлады.Әхнәф чарасыз иде. Ул урынында бөтерелеп алды да, өй артында, кадакта эленеп торган чыбыркыга ташланды. Чыбыркыны эләктереп, урамга йөгереп чыкты, шул шапкә, атка атланып маташкан Сәйфине аягыннан жиргә сөйрәп тә төшерде.
— Җибәрмим. «Очар» безгә үзе кайтып керде! — дип үрсәләнде Әхнәф.
Сәйфи ачуыннан кызарынып-бүртенеп, малайга ташланды. Муеныннан каптырып алды һәм шартлатып капкага табан борды, күн итеге белән артына тибеп җибәрде.
— Күрсәтермен мин сиңа Сәйфи абыеңның кем икәнен! — Ул яшьләрчә җитез итеп ат өстенә сикереп менде, атның янтыгына итеге белән төртеп, чөңгереп куйды.
— На, паразит!
Әхнәфнең бирешергә исәбе юк иде әле. Үҗәтләнеп, ат артыннан торып йөгерде һәм бар көченә селтәнеп, камчысын Сәйфинең аркасында уйнатып алды. Юка пинжәк аша чыбыркы шактый саллы төште бугай,

Сәйфи чиелдап кычкырып жибәрде һәм барган хутка жиргә сикерде, тезгенен кулыннан ычкындырмаган хәлдә, ишек алдына кереп киткән Әхнәф артыннан атылды. Сәйфинең үкереп, сүгенеп капка төбенә житүе булды, «Очар» кинәт башын югары чөеп жибәрде. Сәйфинең кулындагы тезгене ычкынып китте, ат дулап урам буйлап чабарга тотынды. Сәйфи, бер капка артына посып торган Әхнәфкә, бер урам буйлап киткән ат ягына тартылып чайкалды да, әшәке сүзләр белән кычкыра-кычкыра, тилергән кеше кыяфәтендә ат артыннан элдертте.

Баштагы мәлдә югалып калган әнисе орыша-орыша Әхнәфне өйгә алып кереп китте. Куанычка, Сәйфи «Очар»ны көне буе куып та тота алмаган булып чыкты, малай Мәхмүт абыйсы янына барып, хәлне сөйләп биргән иде, белмим, әллә ит нәрәте үтәлеп торган чак булганмы, әллә Мәхмүттә хайванны кызгану тойгысы уянганмы — алашаны ул елны ит нәрәтенә жибәрмәделәр...

* * *

Шул көннән соң, бу ике кеше — үсмер Әхнәф белән ир уртасы булган Сәйфи бер-берсен күрә алмас дәрәжәдә йөри башладылар. Язмыш аларны янә очраштырды, менә хәзер ат өстендә, янәшә басып торалар. Әхнәфнең күңеле күтәренке.

Ниһаять, Мәхмүт: «Әзерләнергә!» — дип, кулын өскә күтәреп тирән тын алды, ул да булмады, һаваны ярып: «Киттек!» — дигән фәрманы яңгырады. Моңарчы кысылып, менә туктыйм-туктыйм дип типкән йөрәкләрне кайнар ут көйдергәндәй булды. Жайдаклар ай-һайлап кычкырасызгыра атларын дәртләндереп куалыйлар. Әхнәфнең бу очрак өчен өйрәтеп куйган «сихере» бар иде: Мәхмүт абыйсының кулы һаваны төшүгә, ул «Йолдыз»ның башын кинәт сулга борып, атны алга томырылудан бер генә мизгелгә тыя төште. Сәйфинең этлегеннән котылуның бердәнбер чарасы иде бу, һәм Әхнәф морадына иреште дә. Сәйфи, фәрман бирелү белән атының янтыгына китереп типте, камчысын селтәп алды, ләкин камчы очы, Сәйфи уйлаганча, «Йолдыз»га түгел, ә аның алдына атылып чыккан Сарашлы чаптарына эләкте. Моны көтмәгән чаптар гөрс итеп читкә тайпылды, жайдакның нидер кычкырып, кулындагы камчысын Сәйфи аты сыртына табан сыздыртырга маташуы күзгә чалынып китте. Әхнәфкә нәкъ шушы гына кирәк иде. «Мине нигә тыясың», — дип рәнжегән сымак булып калган «Йолдыз»ның касыгына үкчәсе белән сиздерерлек итеп чәнчеп алды да, күнегелгәнчә, ачы итеп сызгырып жибәрде. Тезгеннең бушаганын сизеп алган малкай алга укталды. «Йолдыз»ны дуамал ашыктырып, жай гына башланган эшне харап итәргә ярамый иде. Бәдри бабай өйрәткәнчә, ярты юлны Туры биядән бер гәүдә чамасы калышып барды.

Ә аннан соң тезгенне тәмам бушатып бетерде, ат үз иркендә, аңа хәзер Әхнәф бернинди комачау да ясамый иде. Ул атның муенына сеңәрдәй булып ятты, колак төбендә жил сызгыра да, алда Туры биянең жилдерүе шәйләнә.

Калган атларның иң якын дигәне дә «Йолдыз»дан биш-алты дилбегә калышып баралар, алар инде атларын яндырганчы кусалар да, житешә алмаячаклар. Сыртны үтүгә, чуар болыт сыман сабантуй барган атау күзгә чалынды. «Әйдә, Йолдыз, сынатма!» — дип пышылдады Әхнәф, әйтерсең аның өзгәләнеп эндәшүен ат аңлый...

Малкай узышның сихри көченә буйсынып алга томырыла, тирә-якка тояк астыннан күтәрелгән дымсу балчык кисәкләре генә очып кала. Узыш тәмам буласы урынга чирек юл калып килгәндә «Йолдыз» Туры биядән бер баш алга чыкты. Сәйфи каһәрле сүзләр белән акыра-бакыра Туры бияне камчылый, аның камчы очы ара-тирә янәшәдә генә дулкынланган «Йолдыз»ның кабыргасын да өтеп ала. Туры биянең көче инде

чиккә житеп килә, әмма хуҗасының каезлавыннан котылырга теләп, соңгы мәртәбә бар көчен җыеп яңа ыргым ясарга ниятләде, күрәсең, берара «Йолдыз»ны артка калдыра башлады ул.

Моңа Әхнәф әлләни борчылмады. «Йолдыз» әле бирешергә тиеш түгел, ә менә Туры биянең ахыргы көчен җыеп чабуы аның ыңгырашкан сыман тын алуыннан ук сизелеп тора. Менә шунда Әхнәф уяулыгын җуйды — ул янәшәдәге җайдакның Сәйфи икәнлеген онытып җибәргән иде. Куян Сәйфи «Йолдыз» бераз арткарак калуга үзенең пычрак алымын янә бер мәртәбә эшкә җикте. Чапкан уңайга артка борыла төшеп «Йолдыз»ның башы өстендә камчысын уйнатып алды. Бу уйсу җирдәге сулы пычрак аша сикереп үткән чакка туры килде. Сәйфи юлны алдан ук җентекләп өйрәнеп куйган иде булса кирәк. Әллә камчы «Йолдыз»ның зур булып киерелгән күзенә эләкте, ул чыдый алмаган кебек кинәт башын чайкап алды, шушы мәлдә сырт җиргә җайлап басарга өлгермәде, ал аякларына сөрлегеп китте. Бу шулкадәр тиз һәм Әхнәф өчен көтелмәгән хәл булды, искәрми дә калды — ат сыртыннан куптарып та алырга мөмкин түгел сыман күренгән малай, «Йолдыз» сөрлегеп киткән мизгелдә сикертмәдән очкан чаңгычы кебек, ат башыннан шуып чыгып, юл читенә мәтәлде. Берара зәңгәр күк белән кара җир буталып алды, ул да түгел, баш тирәләрен нәрсәдер яндырып үтте, күз алдында кызыл шәүлә биеп алды һәм малай бер тын эчендә төпсез караңгылыкка чумды...

... Гөлҗиһан чабышка киткән атлар күздән югалганчы артларыннан карап калган иде, инде алар сырт урынны үтеп, бөтенләй эреп беткәч тә, җаны тынгысызлана башлады. Көрәш кызган мәйдан янында бераз юангандай булды да, җуелган тынычлыгына дәрман табу нияте белән Коры елга күперенә табан китте.

Көткәнгә — ел дигәндәй, Гөлҗиһанның түземлеге төкәнгән иде инде. Менә берзаман урман ягыннан бер кара тап пәйда булды. Ул бик тиз зурая барып, инде аның томырылып чапкан ат икәнен дә шәйләргә була иде. Аның артыннан башка атлар да күренде. Алар чабып түгел, йөзеп килгән сыман иде. Гөлҗиһанның бер мәлгә күз аллары караңгыланып китте, ул хәле беткәнен сизеп, күпер култыксасына сөялде. Ул арада мәйдан өстеннән кемнеңдер: «Атлар килә!» — дип сөрән салуы ишетелде. Шуны гына көткән сыман, мәйданга җыелган халык аллы-гөлле елганы хәтерләтеп күпер буена, атлар үтәчәк олы юлга табан агыла башлады.

Шактый ара булуга карамастан, күпер буен сырып алган малай-шалай да дөнья шаулаталар:

— «Йолдыз» килә, «Йолдыз» беренче! Юк, Туры бия алга чыга бугай!

— «Йолдыз» бирми аңа, күрәсеңме тагын куып тота!

Гөлҗиһанның күз аллары томаланган, шәүләләрен күрә, кемнең кем икәнен һич аера алмый. Инде атлар юлга чыктылар, аларның тояк тавышларына кадәр ишетелгән сыман. Башта килгән атлар күз ачып йомган арада уйсу җирдә күмелеп алдылар да, янә җир астыннан атылып чыккан сыман, бар килешләренә күренделәр.

Кинәт җыелган халык «аһ» итеп куйды. Алдан томырылып килүче атның җайдагы юклыгы аермачык күренә иде. Гөлҗиһанның фикере чуалды, теле чатнап аңкавына ябышып калган иде. Ул ялгышмый, җан-фәрман сузылып чабучы ат — Әхнәфнең «Йолдыз»ы иде. Яннан гына атылып, «Йолдыз» үтеп китте. Аның артыннан ук колларын буташтырып җилдерүче Сәйфинең шашкан кыяфәте чагылып үтте. Халык нәрсә булганын беләсе килеп сабырсызлана, юраулар китте. Өченче булып килгән Рәфитнең чапкан шәпкә ачыргаланып кычкырганы ишетелеп калды:

— Әхнәф егылып калды!.. Әхнәф кал-ды-ы...

Гөлҗиһан да нидер сөйләнә-такмаклый шунда таба йөгерде. Үкенүле-хәсрәтле тавышын аннан башка беркем дә ишетми, чигәләре сулкылдап тибә, аяк баскан җире йомшак, шуышып торган тасма кебек.

— И-и Ходаем, кичермәслек гөнаһларым өчендер инде бу газапларың...— дип яшь аралаш сөйләнде ул. Гыйльметдин белән үткәргән төненең эзсез югалмасын бөтен барлыгы белән тоеп яшәде. Әмма ни өчен аның гөнаһсы өчен кадерле улы, йөрәк парәсе түләргә тиеш икән?

... Гыйльметдин барып җиткәндә, Әхнәф мотоцикл бишегендә ята, Мәхмүт ашыгып кузгалып китәргә маташа иде. Гыйльметдин килгән шәпкә атыннан җиргә сикерде:

— Нәрсә, әллә сынган-имгәнгәнме?

Мәхмүтнең йөзе агарып калган иде. Әхнәфкә ымлады:

— Башы белән төшкән шул... Һушы юк...

Гыйльметдин артыгын сорашып тормады. Бишектә хәрәкәтсез яткан малайны күтәрә төшеп, үзе дә шунда кереп утырды, Әхнәфне җайлап алдына яткырды. Малайның колагыннан кан саркый иде.

— Мәйданга!—дип кычкырды ул, һаман үзен кулга алырга өлгермәгән Мәхмүтне исенә китерергә тырышып. Тыны кабып Гөлҗиһан да килеп җитеште, күзенә ак-кара күренмәгән хатынга озаклап аңлатырга вакыт юклыгын басым ясарга теләгәндәй, Гыйльметдин мотоцикл үкерүен басарлык каты тавыш белән кычкырды.

— Гөлкәй, арткы утыргычка утыр, тиз!.. Тиз!.. Машина табып Наратлыга хастаханәгә алып китәргә кирәк малайны. Бичаракай, аңын югалткан гел...

Мәхмүтнең күпне күргән мотоциклы сабантуй мәйданына таба тәгәрәде. Комиссия урнашкан станга җитүгә, аларны халык әйләндереп алды. Бәйрәмнең күңелле җанлылыгы шөбһәле юраулар, Гөлҗиһанның хәленә керергә тырышу, хәсрәтне уртаклашулар алыштырды. Ул арада кизүгә билгеләнгән машина килеп тә җитте, Әхнәф тирәсендә шәфкать туташы бөтерелә башлады. Машина әрҗәсенә каяндыр табып китергән калын аслык җәйделәр, башы ак марляга биләнгән Әхнәфне шунда сузып салдылар.

Кемдер Гөлҗиһанны машина әрҗәсенә күтәреп мендерде, кемдер: «Киттек»,—дип кычкырды... Болар барсы да төштә кебек кенә тоелды Гөлҗиһанга. Ул улы янына чүгәләде, бертуктаусыз такмаклый-такмаклый Әхнәфнең күкрәкләреннән, сары төс иңгән битеннән кытыршы кулы белән сыйпады, малайның җылы кулларын үзенең учына алып битенә кыса-кыса сөяргә тотынды.

Инде кузгалып киттек дигәндә, машинага Әүхәт сикереп менде. Фәймә чыр-чыр кычкырып, иренә ташланды:

— Төш инде, Алла колы, ат дагалаганда бака боты кыстырып йөрмәсәң! Малларга печән кем алып кайта?!

Әүхәт әрҗәгә атланган килеш, күн итек кигән сыңар аягын болгап, хатынын читкәрәк китәргә мәҗбүр итте.

— Йөрмәле... карчык... Менә малайны Наратлыга илтеп кайткач нитәрмен...

Бер читтәрәк кызып алган ир-ат халкы Куян Сәйфине уратып алганнар да, астыртын гамәле өчен аннан җавап тоттыралар иде. Җыелган халык алдында Рәфит чатнатып әйтеп салган иде инде:

— Сәйфи абзый камчысы белән башына сукмаса, «Йолдыз» сөрлекми иде...

Сәйфи җан-фәрманга тарткалаша, үлсә дә моның ишe начарлыкны эшләргә сәләтле түгеллеген расларга маташып, антлар эчә иде. Бер үсмер «Йолдыз»ны җитәкләп әлеге төркем янына килде. Атның сул күзе кызарып чыккан, аннан бертуктаусыз яшь ага иде. Атны күргәч, Сәйфи шым булды, кемдер селтәнеп Сәйфинең антлар итүдә яңа гына туктаган авызына китереп тондырды. Сәйфине кызмача ирләрдән аралап хәлдән тайган, чәчләре тузгыган Гөлзада әллә кайсы төшеннән чыккан чәрелдек тавыш белән сөрән салды:

— Үтерәләр, коткарыгыз, карап торып кеше үтерәсез! Җыен..! Усырык җиле тигәнгә ат өстеннән очкан малай өчен нишләп Сәйфи җавап

тотарга тиеш! Тагын берегез сугып кына карагыз, яме, сугып кына карагыз, ник туганыгызга үкендерәм мин сезне!

Сәйфи чак кына тоныграк тавыш белән хатынына кушылды:

— Үтерәләр... Карчык, кем сукканын карап тор, судка бирәм! Бавырга типтеләр!.. Үләм, үләм... Миндә теләсә нинди әтрәкәләмгә типтерә торган бавыр юк! Үтерәләр!..

Гөлзада тирә-якны сасытып акырган Сәйфигә аптырап карап торды да, башка ирләрнең читкә, Әхнәф атланып чапкан ат янынарак китүеннән файдаланып, иренең колак төбенә ямады.

— Улама, хәсис, синең бавырыңа типкән кеше юк әле, авызыңны төйделәр, каныңны сөрт ичмасам... Ничә мәртәбә әйттем, бала-чага кебек ат чаптырып йөрмә дип, менә булгәнне алдыңмы инде?!

Бәдри бабай йөгереп диярлек килеп, «Йолдыз»ның муеныннан кочаклап алды.

— Баланы да, малкайны да харап итте, Сәйфи мәртәт...

* * *

Әүхәт белән Гөлҗиһанның юллары аерылышкач, алар бик сирәк кисештеләр. Гөлҗиһан баштарак аның турында уйламаска тырыша иде. Барысы да берьюлы өелде — фермада тынгысыз эш, улын аякка бастырырга кирәк, дөнья көтү мәшәкатьләре дисеңме... Әүхәтне уйлап, җанын корытырга чамасы да калмады. Бу хәл белән ризалашмыйча мөмкин түгел.

Әүхәткә килгәндә, гомере буе Гөлҗиһан белән очрашудан куркып яшәде ул. Сүз дә юк, яраткан иде ул Гөлҗиһанны. Фәймәнең мәҗбүриләп диярлек үзенә кияүгә чыгарга ашкынып йөрүен башта сабыр гына кабул итсә дә, күпне күргән хатыннар сыман сырышуларыннан тәмам туеп, гайрәте чикте, йөрәге аны читкә какты. Күзе Гөлҗиһанга төшкәч, Фәймәдән бөтенләй кача башлаган иде ул. Нишлисең, тормышның үз кануннары: яратып өйләнгән хатыны аны җанына якын итмәде, инде менә ялгыз гомер кичерә: ул исә Фәймәнең бертуктаусыз бәйләнүләренә, юктан да тавыш чыгаруларына түзеп яшәргә мәҗбүр.

«Үсү» теләге белән укып йөрүе дә аңа уңыш бирмәде. Әлбәттә, укуын тәмамлап кайткач, «Чапаев» колхозына партия оешмасы секретаре итеп билгеләнде билгеләнүен. Хатыны өстенә янә бер бичә алып кайтуына райкомда рәхмәт әйтмәделәр, шулай да үзебезнең кадр, хаталарын аңлар дип, хатын-кызлар белән яңадан чуалмаска вәгъдә биргәч, үзенең орденлы фронтовик булуын, каникулга кайткан җәендә алны-ялны белмичә авылдан авылга йөреп партия карарларын аңлатудагы тырышлыкларын да исәпкә алып, телдән шелтә бирү белән чикләнделәр. Әүхәт бәхетсезлегенә күрәме, әллә бәхетенәме — бу йөкне озак тарта алмады. Болай, вазифаларына үтә җитди караса да, партиянең төп коралы — тел мәсьәләсендә зур кимчелекләре барлыгы беленде яңа кадрның. Чыгыш ясый башласа, җөмләсен әнә шул «ниттем»нәренә төртелеп, халык алдында партиянең абруен төшерерлек мәгънәсезлекләр ду китереп чыгаргалавы шәйләнә иде.

Бер генә кыш эшләп калды ул секретарь булып.

...Ызандаш ике колхозның язгы чәчүгә әзерлеген тикшергән көнне «янды» Әүхәт. Йөрделәр, тикшерделәр, ахырда, йомгак ясау өчен зур җыелыш ясадылар. Һәр ике авылдан җитәкчеләр, механизаторлар җыелды, тәбрикләү өчен пионерлар килгән. Кызыл ситса ябылган өстәл артында карашына даһилыкның асыл сыйфатларын сыйдырган райком секретаре утыра.

Күрше колхозның ут борчасыдай партком секретаре трибуна артына басып, авызыннан кошлар очырды. Ялкынлы сүзләрне каян табып бетерә диген, сайрады гына инде. Һәр җөмләсен партия карарларыннан алынган

саллы өземтәләр белән нығытып куя. Бу чыгыштан соң тыңлаучыларның берсендә генә дә — тагын өч-дүрт елдан соң Америка башкисәрләренең күз чалымы җитмәслек ераклыкта калачакларына, аларның сиксәненче елларда тәгәрәшеп ачтан үлеп бетәчәкләренә шик юк иде. Бу афәт Америка коммунистларына гына кагылмаячак иде. «Коммунизм» дип аталган бөек киләчәк тә, Коры елга буенда күк чикмән киеп йөрми, ул инде ындыр башына килеп җиткән: бакча киртәсендә ике кулын куеп карап, авыл эшчәннәрен соңгы хәлиткеч һөҗүмгә рухландырып тора икән. Тракторчылар дәррәү басуга чыгу белән, ул авылга килеп керәчәк. Иптәш Хрущев исән булсын да, кукурузга кара карга төшеп, киләчәк уңышны харап итмәсен!..

Сүз «Чапаев» исемендәге колхозның партия оешмасы секретаре Әүхәт Гайсинга бирелде. Әүхәт чыгышын көйле генә башлап җибәрде. Кулында кәгазь, укуы шома. Ләкин чыгышының яртысына җиткәч, укыган фикерләрен шәрехләп тә алмакчы булып, күзен кәгазьдән аерган иде... Менә шунда башланды инде... «Нитәргә!.. Ниттермәскә!.. Нитәек, иптәшләр!.. Ниен нитәек!..» Халык тын гына көлешә башлады. Райком секретаре чыраен сытып алдындагы кәгазьгә текәлеп утыра... Бурлаттай кызарды, пеләшенә кушылып шактый киң диган фикер уятучы тар маңгаена тир бәреп чыкты. Ниһаять, Гайсин сүзенең ахырына җитеп, райком секретарена ярты гәүдәсе белән борылып, дәртле партия чакыруы ташлады:

— Иптәшләр! Партия игенчеләрдән зур эш көтә. Әмеркәләрне нитмәенчә... узып китмәенчә туктарга тиеш түгелбез. Иптәш Хрущев шулай нитә, өйрәтә. Яшәсен ни... әнә теге кызыл ни!..— дип ул райком секретаре артындагы кызыл әләмгә төртеп күрсәтте. Кызганычка күрә, әлеге рухландыргыч чакыру да, Әүхәтнең тырпаеп торган озын имән бармагы да нәкъ райком секретарена төбәлгән шикелле килеп чыкты. Әүхәт канәгать рәвештә трибунадан төште, халык гөрләтеп кул чапты һәм... бу Әүхәт Гайсинның партия оешмасын җитәкләвенең соңгы көне булды.

...Фәймә исә чая да, өлгер дә хатын булды. Һәр ике ел саен бер бәбәй алып кайтып кына тора. Шәмси түти әйтмешли, Әүхәтне дөнья түгел, бала басты. Өченче баласы тугач Фәймәгә: «Инде бусы соңгысыдыр»,— диләр икән. Тегесе күзен дә йоммаган: «Мөмкинлекләр чикләнмәгән, Әүхәтнеке чукланмаган, минеке бикләнмәгән!» — дип кенә җибәргән, ди...

Шәмси түти, зур яңалык әйткәндәй, Гөлҗиһанга пышылдап алгалый:

— Фәймәнең сер бирәсе килми, шулай да беркөн миңа зарланып торды. «Эчеп кайтса, йокы бирми,— ди.— Төн урталарында җилтерәтеп торгыза да, Гөлкәй белән Әхнәф улымны кая җибәрдең, нишләп куып чыгардың, дип җәфалый, ди. Холыксыз, ичмасам, кешегә сөйләп эчләремне дә бушата алмыйм бит»,— дигән була... Шулай инде, кеше бәхетен урлап, бәхеткә тиенеп булмый ул.

Шәмси түтинең сүзләрен колакка элмәгән кыяфәттә Гөлҗиһан чәй әзерләп йөри. Үткәннәрне кузгатып ни файда да, карчыкның әңгәмәсенә кушылудан ни мәгънә...

...Әхнәф укырга кергән ел иде бугай. Кичкырын Әүхәт аларга килеп кергән иде. Нәрсәгә юрарга да белмәде хатын. Әүхәт салмыш иде, авызыннан суган, аракы исе бөркелеп тора. Шушы кыюлык өстәүче эчемлек авызына кермәсә, билгеле, Әүхәт тә Мөлековлар өен әллә каян, читтән урап үтәр иде. Гөлҗиһан Әхнәфнең уенга киеп йөри торган чалбарын ямап утыра иде. Әүхәт ишек катыннан узасы итмәде, кемгәдер әләкләшкән сыман, аяк очларына карап сөйләнә башлады:

— Мин бик әшәке кеше бит, Гөлкәй... Сине Фәймәгә нитәргә, алыштырырга тиеш идемме соң, ә...— Ул йөрәк януына чыдаша алмагандай күкрәкләрен уып алды.— Фәймә — иблис ул... Нинди хәлгә төштем бит... Авылдашлар белән ачылып сөйләшеп тә булмый, мине чит итәләр,

хәшәрәткә чутлыйлар... Барсы да шул Фәймә аркасында... Их, Горькийга китеп бармаган булсам... Фәймәне шунда очраттым, ул юлга таш түшәп йөридерие. Юл эшендә... Эндәшми-тынмый узып китмәкче идем дә, һи... аның күземе! Очлы күз бит ул. Күрмәгән-белмәгәне юк, талаша башласа, атлы-җәяүле житешә алмый. Шулай тискәре нәмә ул. Ие-е... Ул бер карчыкта фатирда тора иде. Мине бер чакыра бу, ике чакыра... Шуннан китте инде... Ни инде... Үзең беләсең...

Гөлҗиһанның битараф, салкын карашын күтәрә алмый сүзеннән бүленде.

— Бар, кайт өенә, Әүхәт. Минем сездә бер эшем дә юк.

— Мин ни инде... Гөлкәй, синнән якты чырай өмет итеп килмәдем. Менә Әхнәфкә укырга барырга букча алган идем дә, әллә кайчан инде... Кертеп чыгарга җай табылмады, теге иблис тавыш куптара бит...

Ул пинжәге астына кыстырылган букчаны алды һәм аны мич янына куйды. Гөлҗиһан инде аптырап калган иде, Әүхәт урынында таптанып торды да көрсенеп чыгып китте.

Әхнәф ул букчага якын да килмәде, әле хәзер дә зәңгәрсу букча чоланда тузан җыеп ята.

* * *

Машина Наратлы авылындагы участок хастаханәсе каршына килеп туктады. Шәфкать туташы дилбегәне үз кулына алган иде инде, монда да эшне тиз тотты. Йөгереп кизү табибны алып чыкты. Гөлҗиһанны юатып нәрсәдер әйтеп алырга да онытмады, аны бер читкә алып китеп, сабыр булырга өндәп азапланды.

— Апа, тынычланыгыз,— диде табиб.— Инде улыгыз безнең кулда. Зуравылдан «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакырттым, сез килеп житкәнче үк Күперледән шалтыратып әйттеләр бит. Озакламый килеп тә житәр,— Зарланып та алды: — Бүген эссе көн булды әле. Күптән түгел ике егетне алып килделәр, «Урал» мотоциклы белән «очканнар», хәлләре шәптән түгел. Үзебезнең машина шуларны илтә китте. Алар барып житкәнче, Зуравылдан янә машина чакыртырга туры килде...— Әхнәф яткан карават янына килеп утырды.— Хирург кулы кирәк егеткә, болай бирешмәскә исәпли, нык күренә. Баш шуткы түгел...— Күренеп тора, аның Гөлҗиһанны бераз тынычландырасы килә иде.

Табибның сүзләре тәэсир итте, хатынга бераз җан керде. Ул елап шешенгән күзләрен кулъяулыгы белән сөртеп, ишеккә табан кузгалды. Аның артыннан озак тормый шәфкать туташы чыкты.

— Операция кирәк булачак,— диде ул белдекле рәвештә.— Баш сөягенә зыян килгән. Мие селкенгән. Ярый әле каны читкә аккан, эчкә сауса...— Яшь кыз кайтырга ашыга иде.— Мин кайтып китәм инде, Гөлҗиһан апа, сиңа Зуравылга барырга туры килер, операция ясалса, Әхнәфне карарга кирәк булачак. Берүк терелә күрсен инде,— дип шәфкать туташы машинага таба атлады.

...Зуравылга килеп житкәч, Әхнәфне туры операция бүлмәсенә алып кереп киттеләр. Гөлҗиһанның өзгәләнеп йөрүенә артык игътибар итмәделәр, бу табибларча салкын канлылык күрсәтү иде булса кирәк. «Кирәк булса чакырырбыз, шушы тирәдә генә йөреп тор»,— дип, аның борыны турында операция бүлмәсенең ишеген ябып куйдылар.

Үз гомерендә кайгылы, хәсрәтле көннәр кичергәне булды Гөлҗиһанның, ләкин шушы чактагы кебек, Әхнәфкә операция ясаган дүрт сәгатьлек вакыттагы кебек газаплы, тетрәнүле гомерне ничек үткәреп җибәрә алуын ул сөйләп тә аңлата алмас иде.

...Аттан егылган җәйне Әхнәф хастаханәдә озак ятты. Маңгай сөяге чәрдәкләнеп, сөяк кыйпылчыкларын чүпләп алганнар икән. Баш сөяге дә зарарланган, мие дә селкенгән — кыскасы, бу чабыш малайга кыйммәткә

төште. Укулар башланыр алдыннан гына хастаханәне калдырып чыкты ул, анда да әнкәсен табиб кат-кат кисәтте:

— Сак була күрегез, апа. Егеткә чын-чынлап сәламәтләнер өчен еллар кирәк булачак. Иң мөһиме — тынычлык, юк-бар нәрсә белән борчымау. Иптәшләренә, классташларына да әйтегез, укытучыларга да кисәтергә онытмагыз, чак кына көен дә көйләргә туры килер. Ул бит үлемнән калган егет! Кызып китүчән, ярсучан булып калуы да мөмкин...

Моның шулай икәненә Гөлҗиһан тиздән ышанды да. Зуравылны җәяүләп чыгып, ашкынланып-дулкынланып аккан Ык ярына аяк басу белән Әхнәф, гомердә булмаганча, үҗәтләнә башлады:

— Су керәм, җәй буе ябып яткырдыгыз,— дип биек ярдан төште дә китте.

Әнкәсенә малайны бу ниятеннән кайтарып, юмалап кире олы юлга алып менгәнче (исәбе — Ык күпере төбендә юлаучы машиналар көтеп тору иде) шактый изаланырга туры килде. Табиб сүзләрендә хаклык булган икән...

Укулар башланып, көннәр үткәч, укытучылар җай табып Әхнәфнең сәер гадәтләре хакында «тишә» башладылар.

— Дәрес вакытында Әхнәф әллә нишләде бүген. Парта өстенә сикереп менде дә, әтәч булып кычкырырга тотынды. Аптырадым да калдым инде...

— Апа, Әхнәфкә әйтеп караргыз әле, бигрәк узынды — дәрес вакытында кулымнан журналымны тартып алды да, бирмичә җәфалады. Елап беттем. Ун ел укытып, моның ишене күргән юк иде әле...

— Малаеңа әйт, Гөлҗиһан. Дәрес буе шамакайланып утырды, дәрестән куып чыгардым үзен...

Баштарак Әхнәфнең кыланмышларына гаҗәпләнеп караган классташлары, Гөлҗиһанның алдан әйтеп куюына да карамастан, малайдан көлә, мыскыллый башладылар. Еш кына «җүләрләнгән», «исәр» кебегрәк сүзләр дә ычкындыралар икән. Моны ишеткән үсмер бөтенләй шаша, котырып үзен хурлаган иптәшен куып алып китә икән...

Болай барса да ярар иде әле. Укытучылар да сабыр булырга тырыштылар. Моңарчы күзгә генә карап утыручы, акыллы, ипле малайның, имгәнүдән соң кинәт үзгәреп калуын алар үзләре дә авыр кичерә иделәр. Әмма... гафу итмәслек эшләрне дә эшләп ташлады Әхнәф.

Язга чыгып килгәндә кылган тәртипсезлеге аркасында бөтенләй мәктәпкә йөрмәс булды.

...Күперле урта мәктәбенә физкультура укытырга институт тәмамлап яшь кыз килде. Беренче дәрестә үк укучыларны «аһ» иттергән иде ул. Аның ясаган күнегүләренә карап кына да башлар әйләнеп бетте. Гәүдәсенең боргалануларына, тәгәрмәч кебек бөгәрләнеп тәгәрәп китүләрен күреп, «моның тәнендә сөяк-мазар юктыр» диеште укучылар. Укытучы кыз бер дәрестә «күпер» ясау серләрен өйрәтә башлады. Иң элек, бөтен шартын китереп күнегүне үзе ясап күрсәтмәкче булды ул. Шуны гына көтеп торган кебек, сафта басып торган Әхнәфне «шайтаннары» котырта башламасынмы — тиз генә йөгереп чыкты да укытучы кызның кендек тирәсендә чапы-чопы учларын биетеп тә алды. Китте көлеш, ыгы-зыгы... Кыз гарьләнеп, аккан яшьләрен сөртергә дә онытып, директорга йөгереп керде. Әхнәф исә куркуыннан классына да кереп тормыйча, яланөс өйләренә шылды.

Гөлҗиһан, әле Әхнәф хастаханәдә яткан чакта ук, колхоз рәисенә ялына-ялвара фермадагы эшен калдырып, клубка җыештыручы булып күчкән иде. Эштән соң өенә кайтып керсә — улының мич янында дер-дер калтырап утыруын күреп чак кычкырып җибәрмәде. Әле дәрес бетәргә шактый вакыт бар, малайның төсе киткән, авызыннан күбекләр килгән. Ә күзләре... Куркудан шашыр дәрәҗәгә җиткән мондый күзләрне гомердә дә күргәне булмады Гөлҗиһанның. Әхнәф әнкәсенең сорауларына җүнләп җавап та бирә алмады, каушый, дулкынланудан теле тотлыга...

Гөлҗиһан мәктәпкә барып хәлне аңлаткач, укытучы кыздан кат-кат гафу үтенеп кайтты кайтуын да.

Әхнәф тагын ике-өч көн укуга барган булды, әмма теге хәлнең шаукымы бетмәгән булып чыкты: укудан соң, Әхнәф чаңгы тагып, тау шуарга киткәч булды бу.

Гөлҗиһан соңгы тынычсыз көннәрдән соң бераз хәл алып, өйләр җыештырып йөри иде, «аһылдап» Әхнәфе кайтып керде. Үзе тавышсыз гына елый, ике бите буйлап яшь ага. Тагын коточкыч бәлагә таруларын тоеп Гөлҗиһанның чигә тамырлары кысып алды, ул егылып китүдән курыккандай, өстәл кырыена тотынып, улына текәлеп катып калды. Әхнәфнең авыз-борыныннан кан килә, күз төпләре дә күгәреп беткән — беренче карашка Гөлҗиһан аларын абайлап кына җиткермәгән. Кипкән телен әйләндереп сүз әйтергә өлгермәде, ишек ачылып китте: сынган чаңгыларын күтәреп Рәфит килеп керде. Гөлҗиһан улына ташланды, ашыгып өс-башын чишендерде, башындагы яулыгын тартып алып малайның авыз-борынын сөртте, тиз-тиз урын җәйгәндәй итеп, Әхнәфне яткырган арада, Рәфит нәрсә булганын түкми-чәчми сөйләп бирде:

— Без тау шуып кайта идек. Каршыга Рәкыйп абый килә...— Гөлҗиһан белә: Фәймәнең энесе Рәкыйп физкультура укыткан кыз Фәридә артыннан йөргән булып азаплана иде.— Аракы эчкәнме шунда, кызмача иде,— дип дәвам итте Рәфит.— Әхнәф белән нәрсәдер сөйләшеп кайтабыз шунда. Рәкыйп абый безне үткәреп җибәрәсе урынга, икебезнең дә сырмалардан эләктереп алды. «Кайсыгыз Фәридә апагызны мыскыл итте?» — ди. Мин әйтәм: «Без түгел». Китмәкче генә булган идек, тә... Әхнәф кычкырып елый башлады. «Башка алай итмәм! — ди.— Җибәр инде, Рәкыйп абый?» — дип ялына... Рәкыйп абыйга шул гына кирәк, «Әле синмени ул? Мин сине дөньяда яшәрлегеңне калдырмыйм!» — дип дөмбәсләде генә. Гыйльметдин абый килеп чыкмаса, Әхнәф беткән иде. Мин елап та, ялынып та карыйм, үземә дә эләкте...

...Бу кыйналудан соң Әхнәф мантымады. Төне буе ут янып, саташып чыкты. Әнкәсе малайга Шәмси түти өйрәткән үләннәрдән дарулар ясап эчертте, мендәр астына догалыклар кыстырып яткырды — әмма рәтләнеп китәр дигән өмете акланмады. Малайны тагын хастаханәгә озатырга туры килде.

Әхнәфне кыйнауның икенче көнендә, иртәнге якта шәүлә сыман тавыш-тынсыз гына Әүхәт килеп кергән иде. Башын сузып түр якка, караватта ыңгырашып яткан Әхнәфкә карап торды. Бик борчылган кыяфәттә:

— Нык ниткән... икән,— дип сузды.

Гөлҗиһан Әхнәфне хастаханәгә озатырга кием-салымнарын хәстәрләп йөри иде. Эндәшәсе килмәде.

Әүхәт юкка гына кермәгән икән.

— Син, Гөлкәй, бу эштә Рәкыйпны буяма инде, яме... Егет ни бит... характер белән. Малай бик пырдымсыз, тыйгысызга әйләнде.— Ул шикләнеп, Әхнәф ягына карап алды.— Рәкыйп әйтә: «Гөлҗиһан апага әйт, ди, мин бүген үк авылдан чыгып китәм, суд-хөкем эшләренә бәйләнмәсен»,— ди... Хөкем эше, күтем эше, анда эләксәң, үзең беләсең... Син нитмә... әләкләшеп йөрмә инде.

Гөлҗиһан Әүхәтнең килү сәбәбен төптән аңлап алган иде, күңелендә нәфрәте ташып, ярсу тавыш белән ирнең артыннан кычкырды:

— Җәллад кайнешеңне кызганып йөрисең икән, бичара! Миндә ул кабәхәт кайгысы юк. Кулы корысын балага суккан өчен. Улым гына терелсен, ул хәшәрәтне мәңге күрмәсәм дә ай-һаем юк. Моннан соң тупсамны атлап керәсе булма, җан көеге!

Чыннан да, Рәкыйп кайгысы юк иде анда. Төн буе күзгә йокы кермәде, черем итеп алырга форсат та булмады инде. Әхнәф күзен йомса саташа башлый, нидер сөйләнә, ялына, ялвара, ачыргаланып кычкыра. Малайның башында мәхшәр иде, күрәсең. Иртәнге нәрәт вакыты җитәр-

житмәс колхоз рәисенә йөгерде. Машина сорап, Әхнәфне Зуравылга илтергә кирәк иде.

Рәис хатынга мыскыллы караш ташлап, һавалы кыяфәттә, теш арасыннан кысып бер-ике җөмлә чыгарды:

— Малаең сугышкан саен минем машина белән Зуравылга чапмакчы буласың икән дә... Ялгышасың, Мөлекова! Кара әле, синең малай бит инде ул, теге укытучы кызныкын капшап карауны, ә?! Ха-ха-ха... Ну, хәзерге бала-чага! Хатын кайтып сөйләгәч, көлә-көлә үләм дип торам. Автобус тукталышына чыгып басыгыз, кул күтәрергә иренмәсәң, берәрсе алып китәр.— Рәис сасы исләр аңкытып кикерә-какыра үзен көтеп гөрләп утырган машинасы янына ашыкты.

* * *

Шушы кыйналудан соң, Әхнәфнең уң ягы начар хәрәкәтләнә, үзенә буйсынырга теләми башлады. Эш эшләргә тотынса, куллар тыңламый, иптәшләреннән калмаска тырышып, укуга тотынса, сызлауга түзә алмыйча, башын тота да караватка каплана. Укытучыларга мең рәхмәт, ничек итсәләр-иттеләр, тарта-суза Әхнәфне сигезенче классны тәмамлаттылар. Иң үзәккә үткәне — хәзерге бала-чагада кызгану, кеше хәленә керә белү хисе булмау иде. Әхнәф урамга чыкса, аяк атлар хәле юк, әллә кайдан малай-шалай килеп чыга, тотыналар үсмер егетне мыскылларга, үртәргә. Бу ирештерүләргә Әхнәф ярсып кыза, бала-чага артыннан йөгереп хәлдән тая, аннан өйгә кереп урынга ава, елый, холыксызлана иде.

Чәчләренә вакытсыз чал кергән ана улы өчен борчыла, көннәр буе кулыннан эш китеп йөри, инде Әхнәфнең сигезне бетергәненә дә өч ел. Ана төннәр буе йокламый чыга, әллә нинди ниятләр белән яна, әмма барыбер бу хәлдән котылу юлын таба алмый иде. Табибларга барсаң — бер сүз: авыр эш эшләмәсен, тынычлык кирәк. Таулы-диңгезле якларга дәваланырга барып карагыз, имеш...

Үз гомерендә Зуравылның арьягына чыкмаган Гөлҗиһан авыру малаен кая алып бара белсен, кем белән, ничек сөйләшсен, каян юлын тапсын... Шушы уйлар аны тәмам диңкетеп бетерделәр, хәтерсезгә әйләндерделәр. Болай кул кушырып ятып та булмый иде. Әхнәфнең гомере башланып кына килә, тормыш итәргә, яшәргә кирәк. Иң яхшысы — Әхнәфкә җиңелчә, әмма абруйлы һөнәр бирергә — укытырга кирәк дигән карарга килде ул. Йөри торгач, гарипләр оешмасыннан ярдәмгә килделәр — Мәскәү тирәсендә бер уку йорты бар икән, киноаппаратлар төзәтүче һөнәренә укыталар икән анда. Шунда җибәрергә кирәк дип карар иттеләр. Тик гарип икәнлеген раслый торган язу кирәк, моның өчен ай чамасы хастаханәдә ятып чыгарга туры килә икән. Егет үзе дә киләчәге турында җитди уйлана башлаган иде, укырга дигәч, ашау-эчүне онытты.

...Гөлҗиһанның җилкенеп йөрүе урынсыз түгел иде: бүген Әхнәфнең хастаханәдән кайтырга тиешле көне. Ул бит әле сипләп салынган өйләрен дә күрмәде, осталар нәкъ ул Зуравылга киткән көнне килеп, эшкә керештеләр. «Курчак өенә әйләнде бит, кайтса сөенеп бетә алмас инде»,— дип дәртләнә-дәртләнә ишек алларын себереп чыгарды Гөлҗиһан. Мунча ягып җибәрде, йөгертеп кенә чишмәдән су алып кайтты, самаварын гөжләтте. Күңеле нигәдер очына, җанына рәхәтлек иңде, кычкырып көләсе, яшь чактагы сыман йөрәкләрне җилкендереп, җырлап җибәрәсе килә.

Һай, бу дөнья дигәннәре! Бер утларга сала, бер суларга. Тауларга күтәрә, упкыннарга очыра. Шәмси түти белеп әйтә торгандыр инде: Ходай Тәгалә безне дөньяга сынау өчен генә яраткан, шул сынауларны үтә алсаң гына, чын яшәү төмен татырсың — ансы фани дөньядан киткәч

була инде... Җиргә килгәнсең икән, сынмый, сыгылмый, кешелегеңне югалтмый яшәргә тиешсең. Яшәү дигән хикмәтле нәрсәнең асылы шул икән аның...

...Җил капка ачылып китте. Ул да булмады, Әхнәфнең җилкенүле, шат тавышы ишетелде.

— Әнкәй, без кайттык! Өйне танымый торам, чүттән үтеп китмәдек. Гел икенче төс кергән урамга.

Гөлҗиһан улының сөенечен уртаклашырга ашыкты, кулындагы себеркесен өй почмагына сөяп, капка ягына атлады. Улының «кайттык» дип күплек санда сөйләшә башлавына исе дә китмәгән иде. Күңеле көр булса, Әхнәф шаяртудан туймый. Әмма капка ягына игътибар белән караса, үз күзләренә ышанмый тора — сөбханала, Әхнәф артыннан кояштай балкып, сөйкемле кыз бала кереп килә. Гөлҗиһан тып туктап калды. Өндердәй гәүдәле Әхнәф елмаеп әнисе янына килеп җитте, сәерсенеп туктап торган әнкәсен кысып кочаклады һәм сулуы капкан кеше сыман сүзләрен өзә-төтә бөтенләй көтелмәгән хәбәр әйтеп салды:

— Әнкәй... Мин өйләндем... Киленеңне каршы ал. Әфүзә исемле...

Кыз Әхнәфкә сыенып, Гөлҗиһанга кулын сузды:

— Исәнмесез, Әни... Әнкәй димме? — Ул якты күзләрен Әхнәфкә күтәрде.

Гөлҗиһан исен җыя алмый иде әле. Ихтыярсыз сузылган кулларына көч биргәндәй сөйләнеп алды.

— Исәнмесез, исән-сау гына йөрисезме?... — дип хәл-әхвәл сорашу сүзләрен тезде ул.

Әхнәф шаяртырга җай тапты.

— Бик исән генә торабыз әле, әнкәй. Капка төбендә ярты сәгать таптанабыз инде.

Гөлҗиһан аптырауның чигенә җитте, капыл баскыч төбенә барып утырды.

— Өйләндем, дип улым... Алдан хәбәр итү юк, киңәшләшү юк... Туй ясыйм дисәң, бер тиен акча юк чак — белеп торасың, сыерны сатып, өй сипләттек...

Әхнәф әнкәсен култыклап, урыныннан торгызды.

— Әйдә, әнкәй, өйгә керик әле. Барысын да аңлатырбыз. Әйдә, Әфүзә, син дә өйгә үт...

Өйгә кереп, йола буенча дога кылып алгач та, каршысында утырган кызга шактый сынаулы караш ташлады. Бер кашык су белән йотып җибәрерлек кызның ярым гарип улына ияреп кайтуына, телгә килеп: «Без инде ир белән хатын, әнкәй. Ачулансаң ачулан, яратыштык, фатиханы бирсәң, безгә артыгы кирәкми», — дип чатнатып әйтеп салгач та, Гөлҗиһанның шикләре таралмады. Бу хәлгә ул никадәр тырышса да, ышанып бетмәде. Дөньяда кеше ышанмастай хәлләр дә була икән.

Бар тәҗрибәсен, сиземлеген туплап, алдагысын юрарга омтылды. Үрсәләнеп, күрәзәлек кылып интегүдә мәгънә чыкмас кебек. Кызның сабыйлыгы да бетеп җитмәгән кебек. Алсу иреннәре арасыннан энҗедәй тешләре күренеп китә. Әйтсә, өздереп әйтә дә белә икән. Әнә ничек ди бит, «Ир белән хатын», — ди. Берәү булса, яшереп азапланыр иде. Аның ишегә осталыгы юк, ахрысы. Чытлыклана да белә икән. Әхнәфнең кулын үзенең нәфис, йомшак учларына алган да, арык бармакларын аралап, уйнап утыргандай кылана. Ара-тирә иреннәре читеннән генә тынын өреп маңгаена төшкән житен төсле йомшак чәчләрен җилфердәтеп алулары киленгә тагын да самимилек өстиләр. Елмайганда бит урталары чокырланып ала: дөнья көткәндә катлаулырак нәрсәләр килеп чыккаласа, «юып» җибәрү өчен бераз гына алдашып та җибәрергә булдырыр кебек. Хатын-кыз өчен монысы да кирәк, дөресен сөйлим дип, ирең барсын да тотып җилпи башласаң, башың тавыштан чыкмас. Хатын-кыз үзе генә белә торган серләр дә шактый була ул.

Әфүзә зәңгәр күзләрен каплап торган озын керфекләр астыннан гына өй эчен дә караштырып алырга онытмый. Гөлҗиһанны җентекләп «тикшереп» чыгарга өлгерде. Чандыр гәүдәсе өстенә ак җирлеккә вак зәңгәр чәчәкләр төшкән күлмәк кигән. Бизәнү-сылануны өнәп бетерми, ахрысы, чама белән генә ягылган иннек-кершән, сизелер-сизелмәс тартылган сөрмәләр...

Әхнәф тә ким-хур булырлык егет түгел-түгелен. Сәламәтлеккә генә туймады. Уң аягын өстерәбрәк атламаса, анысы сизелмәс тә иде, югыйсә...

Беркайчан да булмаганча, бәхеттән исәңгерәп утырган Әхнәфкә карап Гөлҗиһанның да эченә җылы йөгерде, күңелен сөенеч биләп алды. Ничә еллар дус-ишләреннән кимсенеп, үзенә тагылган иләс-миләс атамадан хурланып, кичләрен клубка да чыгарга кыенсынып яшәгән улы, ниһаять, авыр тойгылардан арына төшкән, эчке хәсрәт баскан гәүдәсен турайткан шикелле тоелды аңа. Килен-балакайлы булды менә. Уена килгән әлеге сүзләрдән Гөлҗиһан сөенечле оялу кичерде, күкрәк турысын нәрсәдер иркәләп узган сыман булды, инде килен белән килешеп, матур яшәргә язсын...

Самавыр кайнап чыккан иде, күңелле гөрләшеп табын хәзерләделәр, кысташа-кысташа чәй эчтеләр. Сөйләшергә әлегә сүзнең җае табылмаган, Әхнәф белән Әфүзә ара-тирә бер-берсенә серле, ягымлы карап алган булсалар да, үзләренең кыланмышларына үзләре үк кыенсынгандай, янә тын калалар. Чәй эчеп туйгач, Әфүзә әйткәнне көтеп тормыйча, Гөлҗиһаннан алъяпкыч сорап алды, җитез хәрәкәтләр белән өстәл җыештыра, чынаякларны юа башлады. Эш арасында:

— Әнкәй...— дип әйтте һәм бераз тын калды.— «Әнкәй» сүзе әйтергә йомшак, шундый ягымлы яңгырый икән.— Әфүзәнең тавышы калтыранды кебек.— Моңарчы беркемгә дә әнкәй дип эндәшкәнем юк иде...

Гөлҗиһан килененең бу сүзләренә куанып, аның какча иңсәләреннән сөеп алды.

— Кызым юк иде, сине «кызым» дип йөртермен, яме.— Аннан бик мөһим нәрсә исенә төшкәндәй, сорап куйды:— Сездә ана кешене ничек дип атап йөртәләр соң, кызым?

— Миңа, әнкәй, ана назын күрергә язмаган икән.— Әфүзә тәрәз кашагасына эленгән алсу чәчәкләр чигелгән челтәргә текәлде.— Балалар йортында үстем мин. Үземне белә башлаганнан бирле шунда... Аннан һөнәр училищесына җибәрделәр. Шәһәрдә яшисем килмәде, Зуравылга кайттым. Мин шунда туган булганмын... Таныш кешеләрем бар иде, шулар хастаханәгә эшкә урнаштырдылар. Әхнәф белән танышып киттек. Сине дә күрдем, әнкәй, Әхнәф янына килеп йөри идең бит. Әхнәф сиздермәсә генә ярар иде дип курыккан идем, алдан кычкырган күкенең башы авырта, диләр бит. Егет икән, чишелмәде. Ачуланма инде, әнкәй... Ничектер, көтелмәгәнчә килеп чыкты...

Әфүзәне тыңлагач, килене күңеленә бигрәк тә якын булып китте. Аны кочаклыйсы, иркәләп юатасы килде.

— Хәзер ачуланмыйм инде, кызым.— Ул күз яшьләрен сөртеп алды.— Үзегез килешкәнсез икән, мин нәрсә әйтим, ди?! Төшкән урыныңда таш булырга язсын, кызым. Төкле аякларың белән килүләрең булсын, Ходаем.— Шулай да күңелендә кыбырсып торган уйларын тышка чыгармыйча түзмәде:— Әти-әниләрең... бар идеме соң? Беләсеңме дию ем?.. Булсалар, хәбәр итик, белеп торсыннар!

— Булгандыр инде.— Әфүзә сәер рәвештә авызын бөрештереп куйды.— Мин булганмын бит... Зуравылдагы туганнарым сөйләделәр: өч яшемдә әни тиешле кеше мине балалар йортына тапшырып, каядыр китеп барган. Шуннан бирле килеп күренгәне булмады.— Күренеп тора, Әфүзәгә болар хакында сөйләве авыр иде. Гөлҗиһан башка сораштырырга кыймады.

...Никахны теркәү мәсьәләсендә кыенлык килеп чыкты. Әфүзә паспортын кайдадыр төшерепме, онытыпмы калдырган икән.

— Кайда куйганымны һич кенә белмим инде,— диде ул, аптыраулы кыяфәттә кулларын як-якка җәеп.— Фатирның астын-өскә китереп эзләдек — тапмадык. Әхнәф белән икәүләп актармаган җирне калдырмадык инде. Ул бит соңгы көннәрдә минем фатирда кунып йөрде... Кич, караңгы төшкәч кайтабыз, иртән иртүк хастаханәгә йөгерәбез.

Аз гына булса да шартына килә торсын дип, муллалык вазифасын башкарып йөрүче бабайны чакыртып, никах хөтбәсен укытып алдылар да, язылышуны Әфүзә икенче паспорт алганчы кичектереп тордылар. Туйлар үткәреп торырлык чама чыннан да юк иде. Әхнәф белән Әфүзә үзләре дә яңа чыгымнар ясауга каршы иделәр, шул рәвешле тормыш итә башладылар.

Өйләнгәч, Әхнәф дәртләнеп йөри башлады. Инде укырга китү нияте үзеннән-үзе онытылды. Хәер, китәм дисә дә, ике дистә еллар элек Шәмси түти әйткән сүзләр кабат хәтерендә яңарып, моңа бигрәк тә Гөлҗиһан теше-тырнагы белән каршы чыгар иде. «Өйләнгән кешене укырга җибәрсәң, чумаданнарыңны җый да, иреңнең ниндирәк чәчби ияртеп алып кайтуын көтеп утыр!» Ир кеше үтүк кебек — теләсә ничек аяк арасында уралып та йөрмәсен, кирәк чакта кул астында гына икәнен дә белеп торырлык булсын. Әхнәф өйләнеп, хатынының назына иләшеп киткәч, эш күрсәтергә ашкына башлады. Җәйләүдәге малларга азык ташучы — йөкче булып эшли, иртүк чыгып китә, кич кенә кайта.

Әфүзә исә балалар бакчасында аш-су хәзерләүче булып эшли башлады. Укыган һөнәре шул икән. Өйдә әллә нәрсәләр пешереп куандырмаса да, пылауны оста пешерә иде килен. Көннәр үтеп, бер-берсенә иләнә төшкәч, Гөлҗиһан сөйкемле киленнең кайбер сәер гадәтләре барын да искәреп өлгерде: яшь килен гаҗәеп дәрәҗәдә оста итеп, каткатлы, төрләндереп сүгенә белә икән. Билгеле, ул Гөлҗиһанга бу яктан булдыклы булуын күрсәтергә ашкынып тормый, әмма Әхнәф белән икәүдән-икәү калып, юктан сүзгә килешкәндәй итсәләр, киленкәй иржанашын — алтын баганасын шундый итеп керендереп ташлый, Әхнәф, бичара, моның ише серкәле-борычлы сүзләрне иң каты сүгенүче дип исәпләнгән авылдашы Миңнегали абзыйсыннан да ишеткәне булмаганга, авызын ачып кала да, күзен мелт-мелт йомып тик тора.

Гөлҗиһанга бер-ике мәртәбә читтән генә әлеге хикмәтле аңлашуларның шаһиты булырга туры килде. Әфүзә ничек тиз кызса, шулай мизгел эчендә сүрелә дә, Әхнәф аңына килгәнче аны шаярта, җаен белеп кенә иркәли дә башлый. Теге мәхлук яшь хатынының назлы сулышын тоеп, бөтенләй икенче дөнья кешесенә әверелә дә куя. Хәер, Әфүзәнең ачуы ныклап кабарса, аның белән сүз көрәштереп маташуы файдасыз.

Моны Әхнәф үзе дә яхшы сынады.

Берчакны, Әфүзәне, «Чишмәгә суга бармыйсың, әнкәй эштән кайткач, су ташып аяксыз кала инде», — дип битәрли башлаган иде — ник авыз ачканына үкенде. Әхнәф нәрсә булганын да аңыша алмый калды: Әфүзә шактый гәүдәле ирен идән уртасына бөтереп кенә салды да өстенә менеп тә атланды. Үзенең тәне калтырана, күзләре ялт-йолт килә. Җен кебек көчле икән — Әхнәф никадәр чәбәләнмәсен, хатынының астыннан чыгар әмәл тапмады. Ялынып та карый, куркытмакчы да була, тегесе кымшанмый да, ярый, әнкәсенең судан кайтуын чамалап алдылар, югыйсә, Әхнәфкә идәндә шактый аунарга туры килер иде.

Әнкәсе өйгә кергәндә инде бар да ал да гөл — калганын май кап та үзең бел иде. Әнкәсе юкка гына Әхнәфнең аптырап торган чакларында, күңеле сизенеп, киленен кызгана төшеп әйтеп куя:

— Балалар йорты тәрбиясе, улым, әти-әни тәрбиясе булмас инде. Әкренләп җүнгә керер, сабырлыгыңны югалтып тавыш чыгара күрмә, кеше теләнә керсәк, киленне түгел, безне яманларлар. Ата-аналы килеш үсеп тә нинди хәлләргә төшә адәм баласы. Ә безнең килен шыр ятим,

нинди тәрбия күргән, дисең. Кем көчле — шул хаклы булгандыр анда... Аллага шөкер, эшендә дә зарланмыйлар, өйдә дә җебеп тормый,— дип тәгәлләде ул.

* * *

Март аеның буранлы көнендә Әфүзә тупырдап торган малай алып кайтты.

Тудыру бүлеге Наратлыда иде. «Бәбәйне килеп алырга» дигән хәбәрне дүрт күз белән көттеләр. Бу көн җиткәнче үк Гөлҗиһан хәстәрлек эшләрен күргән иде. Чормага менеп, иске бишекне алып төште. Мунчада кайнар су белән пешекли-пешекли сабынлап-мунчалалап юды. Кайчандыр әтисе Фәрвәҗетдин матчага каккан чөйгә сиртмә элде. Сиртмәдә гәрәбә төсенә кергән тал бишек балкый, сап-сары каешлар табып алды, аларны бишекнең ике башыннан астан ук алып тигезләп тарттырды, сиртмә ычкынып бала башына килеп төшмәсен дип, сиртмәнең эченнән янә бер каеш үткәреп бер башын чөйгә, икенче очын бишеккә төйнәп куйды. Чөйлегеп китәрлек түгелме дип, кат-кат тирбәтеп карады, каешларны бер кыскартты, бер озайтты. Килен кайтасы көнне мунча ягып өлгертте. Мәтрүшкә кушып бәйләгән хуш исле каен пиннегән пешекләде. Ялт иткән өй эченә тәмле тавык шулпасы исе таралды. Кыскасы, бәбәйне алып кайтырга тиешле машина турларына килеп туктаганда, каршы алу эшләре тәгәлләнгән, бар нәрсә әзер, җитеш иде.

Шаулап-гөрләп өйгә Әхнәф, Әфүзә, шофер егет килеп кергәндә, Гөлҗиһан каударланып киемнәрен кочаклап бер ишеккә, бер түргә чабулап йөри иде. Әхнәф ак биләүгә биләп, зәңгәр тасма белән уралган «төенчек» күтәргән. Күзенә бәби чалынгач, Гөлҗиһан кинәт ныгып киткәндәй булды, ашкынып оныгын күтәреп алды, такмаклый-такмаклый зур мамык мендәргә китереп салды:

— Хәерле сәгатьтә, бәбкәем, хәерле, изге сәгатьтә. Ходайның «амин» дигән чакларына туры килеп, төкле аякларың белән, нарасый. Бәхетле, тәүфыйклы, сау-сәламәт, әти-әниле, алтын канатлы булып үс. Туган-үскән нигезеңнең котын арттырып, дәүләтле бала бул!

Гөлҗиһанның хәрәкәтләренә, сүзләренә илаһилык ингән иде. Бисмилласын әйтеп, бәбинең йөзенә капланган ак челтәрне кайтарды, сабыйның йөзенә бакты. Оныгы бик тере булмакчы иде, әллә инде күзенә яктылык төште, ул сискәнеп китте (кырыгы тулганчы бала бернәрсә дә күрми дигән булалар тагын). Дәү әнисенең борчуына ризасызлык белгерткән шикелле кашларын җимерде, яңгыравык тавыш белән «үә»ләп җибәрде. Әфүзәнең бала өстенә иелергә теләвен сизеп, Гөлҗиһан аңа нәсихәт биреп алуны кирәк тапты:

— Салкыннан кергән көйгә бик туздырып ташлама, сабыр ит, кызым,— дип өстәл хәзерләргә керешге.

Әхнәф телен йоткандай, шофер егетне өстәл тирәсенә кыстарга онытып, бәби бишеге тирәсендә таптана. Бәхетле мизгелләр Гөлҗиһанны яшәртеп, җиңеләйтеп җибәрделәр. Өйне ду китереп тупырдатып биисе, Әхнәфен, киленен, хәтта шофер егетне дә кочаклап үбәсе, күңелләре бушаганчы җылыйсы, урамда үткән һәр кешене өйгә алып кереп оныгын күрсәтәсе, бәби чәеннән авыз иттерәсе, сөенче аласы килә иде.

Чәйләр эчелеп, шофер егеткә «бәби» күчтәнәчләре төреп бирелгәч, бала тәрбияләү мәсьәләсендә беренче бәхәс тә чыгып алды. Әфүзәнең баланы һич тә бишеккә саласы килмәде.

— Бишеккә өйрәнгән бала көйсез булып үсә,— диде ул, йөзенә ризасызлык билгеләре чыгарып.— Әнә үзбәкләрдә балаларын тугач та как сәкегә салып куялар икән. Көйсезләнүнең нәрсә икәнен белмиләр, ди...

Гөлҗиһан да чигенергә теләмәде. Эченнән генә киленен шелтәләп тә алды. «Һи-и, менә сиңа, мә. Ул ничә көн шушы бишек белән изаланды,

бәби кайтканчы тәртипкә китерәм дип ут йотты. Баксаң, юкка адарынып йөргән икән ләбаса! Тапты чагыштырыр нәрсә. Үзбәкләр ди бит, аларның ничек бала үстерүен барып караганмы ул? ...Тере үзбәкне күргәне юктыр әле. Тудыру йортында хатын-кыз бер-берсен котыртып ята, беләм инде... Үзләренә барып карасаң, берсе дә балаларын как сәкегә кайтарып салмагандыр әле».

— Үзбәкләрдә эшем юк, кызым,— диде Гөлҗиһан җайлабрак. Шул ук вакытта тавышына ныклык чаткылары да сизелерлек чыккан иде.— Без оланны ата-бабадан калган гадәт буенча бишектә тирбәтеп үстерик. Туган нигезнең кадере бишектән башлана.

Әфүзә үз эшләре белән мәшгуль иде, мин малай алып кайтып бирдем инде, теләсә нишләгез — сүзем юк дигәндәй, баланы бишеккә салып азапланган Гөлҗиһанга күз кырые белән генә карап алды да ишек алдында тоткарланган Әхнәфкә ниндидер йомыш кушу өчен чыгып китте.

...Бәби алып кайтканнан соң Әфүзә үзгәрде дә куйды. Сөйләшми, үз эченә бикләнеп йөри, еш кына тәрәзә янына килә дә, ерак офыкларга карап тын кала. Әхнәф хатынының бер алдына, биш артына төшә, аның күңелен күтәрмәкче, мондый төшенкелекнең сәбәбен белмәкче булып өтәләнә. Тик Әфүзә иренә игътибар итми, тегесе артык сырпалана башласа, иреннәрен зәһәр кысып, читкә этәреп җибәрергә дә күп сорамый.

Көндезләрен баласын кулына алгалаcard да, төннәрен Шамилне карау (бәбигә шулай дип исем куштылар) Гөлҗиһанга калды. Бала тынычсызланып уянса, килен сикереп торырга ашыкмый. Дәү әнисенең:

— И-и, наный, балык каптырдыңмыни? — дип сөйләнә-сөйләнә баланы бишектән күтәреп алуына, чүпрәкләрен алыштыруына ризасызлык белдереп, Әфүзә мыгырдап ала:

— Шаулама әле, әнкәй. Төн уртасы дип тормыйсың, бөтен өйне аякка бастырасың!

Нәрсә сәбәп булгандыр, өйгә кайткач, Әфүзә баланы имезмәде.

— Күкрәгемә сөт төшми,— дип акланды ул. Үзе исә качып-посып кына туптай тыгызланган күкрәген савып ала да, җәһәт кенә бер арада кайда да булса чыгарып түгә иде.

Беркөнне Әфүзә, гадәттәгечә, сүзсез генә утырган җирдән, Әхнәфкә сынаулы карап:

— Минем нәрсә уйлаганымны беләсеңме? — дип, кисәк сорап куйды.

— Бел-мим шул,— дип суза төште Әхнәф, аптыравын яшермичә. Ул әле яңарак кына кибеттән сиртмәле арба алып кергән иде, шуны көйләү белән мәшгуль булып, бар дөньясын онытып җибәрә язган иде. Хатынының тимер салкынлыгы бөркелеп торган сүзләрен ишетеп, идәнгә тезләнгән хәлендә Әфүзәгә карап катып калды. Хатынның йөзендәге үзгәреш хәйран калырлык та иде шул. Димәк, ул шаяртмый, бу аның ниндидер ният белән Әхнәфнең күңел кылларын тарткалап каравы иде. Әфүзә тезләрен тез өстенә куеп утырган җиреннән ялтырап торган балтырларын сыйпап алды, йөзенә мыскыллы елмаю чыгарды.

— Әйдә, чыгып китәбез!..

— Ничек? Кая чыгып китмәкче буласың?

— Бергәләп дим бит мин сиңа, аңгыра күке! Табарбыз китәр җир. Дөнья чите Күперлегә килеп терәлмәгән ич.

Әхнәфнең эченә шом йөгерде.

— Акылыңа кил, бәбидән соң терелеп, тернәкләнеп кенә киләсең. Шамил генә көйсезләнә, әллә сыер сөте эчен авырттыра инде... Җүләр уйларыңны башыңнан чыгарып ташла. Ныклап дөнья көтә башларга кирәк безгә. Быел авыл көтүенә керергә исәп. Эшне пешергәнче сиңа әйтми тора идем. Өй салырга кирәк бит... Әнкәйне дә дөнья нык кыйнады, күреп торасың, сәламәтлеккә дә туймый... Безнең өчен, Шамил өчен җан атып йөри. Китәбез, дип, шаяртып кына әйтсәк тә, капатлары каерылачак аның. Берүк бу сүзләреңне әнкәйгә әйтә күрмә, яме...

— Син әллә кайларга кереп китәсең,— диде Әфүзә, гаҗәпкә каршы, шулай ук сабыр тавыш белән.— Мин тереләдем инде, анысына кайгырмасаң да була. Шамилгә,— әни кеше бала израп йоклап яткан бишекне ике бармагы белән аска табан басып алды,— шешәсе булса, шул җиткән. Юри ими авызландырмадым... соңыннан аеруе кыен була. Хәзер сыер сөте чупылдатып тик ята. Тиресен текмәгәннәр, бездән башка да үсәр.

* * *

Бүген Әфүзә иртүк торды. Ашык-пошык чәй эчте, өйдәгеләрне аптыраашта калдырып, моңарчы булмаганча киенеп-ясанып алды, шөбһәле тынлыкны куарга теләгән шикелле, йомшак тавыш белән Гөлҗиһанга эндәште:

— Әнкәй, Зуравылга барып кайтам, паспортсыз яшәп булмый бит инде. Фотога төшеп кайтырга кирәк... Киеп торырга плащыңны бир әле миңа.

Килененең район үзәгенә барып кайтуына каршы килерлек сәбәп булмаса да, Гөлҗиһанның хәтере калды. «Кичә үк әйтеп куйса ни була?..»

— Шамил төне буе көйсезләнеп чыкты. Авырып тора. Әллә бүген бармыйсыңмы соң?... Сабыр итсәң дә була торгандыр бит, купкә түзгәнне инде.

Әфүзәнең карары нык иде, күзендә ачулы очкыннар уйнап алса да, тышка чыгармады.

— Китешли медпунктка кагылып, әйтеп чыгармын мин. Килеп китәрләр. Эшләре шул. Бөтен авылга бер яшь бала бар... Зуравылдан дарулар да алып кайтырга кирәк, мондагы кызларда бер җүнле дару юк.

— Ярый ла, автобус йөреп торса. Иртән килсә — көндез килми алар, бер дә кеше куандырмыйлар. Син ничек тә көндезгә кайтып җит инде, кызым.— Гөлҗиһан кием шкафыннан, узган ел алып та, бер мәртәбә киеп карамаган зәңгәрсу плащын Әфүзәнең кулына тоттырды. Тегесе сөенеп, плащны киеп көзге алдында бөтерелеп алды. Килен биана туфрагыннан яралыр ди, Әфүзәгә плащ таман гына булып чыкты.

Юлга кузгалыр алдыннан, бишектә яткан Шамил янына килде. Әфүзә баланың җылы кулларын сыйпап шактый озак карап торды. Юка иреннәре җиңелчә калтыранып киттеләр, битенә кызыллык йөгерде. Шуннан соң мич ягып азапланган Гөлҗиһанга күз салды, маллар янынннан кергән, әле яңа гына өстәл артына утырган Әхнәфкә текәлеп торды. Әхнәфкә кичен Зуравылга барасын әйткән иде ул, кесәсендә йөргән акчаларын да сорап алды. «Үзеңә килешле костюм-чалбар алмый булмас, өстеңә кияргә җүнле киемең дә юк бит. Тик син әнкәйгә әйтми тор әле»,— дип кисәтеп тә куйган иде...

— Мин сине каршы алырмын,— диде Әхнәф тынлыкны бозып.— Көндезгә эшең бетәр бит?..

— Интегеп йөрмә... Үзем дә кайтып җитәрмен.— Әфүзә тәвәккәл адымнар белән ишек ягына атлады. Авыр ишек зарланып шыгырдады... Ишек ябылырга өлгергәнче дигәндәй, Әфүзә ашыгып:

— Сау булыгыз,— дип кычкырды. Аның болай саубуллашуы, аккара күрми чыгып китәргә ашкынуы сәер тоелды. Ишек тавышына уянып киткән Шамил кычкырып елап җибәрде. Әхнәф ашавыннан бүленеп, бишек янына ашыкты, улын күкрәгенә кысып, ишекле-түрле йөри башлады.

— Ә-ә-ә, улым... Әннә тү-түт китте, сиңа мәмәй алып кайта...

Төшкә кадәр көтсәләр дә, шәфкать туташы күренмәде. Гөлҗиһан аларга үпкәләп тә куйды. «Безнең ишегә дигәндә... Күзләр күгәрде инде көтеп. Яшь кенә кызлар, каян өйрәнгәннәр кешеләрне аерырга. Колхоз рәисе-мазар булсак, хәзер йөгереп килеп җитәрләр иде...»

Әфүзә көндезгә автобус белән кайтмагач, Әхнәф, аптырап, тукталыш ягына китте. Юл уңаена медпунктка кереп, шәфкать туташы булып эшләүче кызларны бераз кыздырып та алды.

— Инде Әфүзә кереп әйткәнгә биш былтыр. Килеп тә карамыйсыз. Бала бит ул!

Кызлар башта күзләрен зур ачып, аңышмыйча тордылар. Инде сүзнең авыру бала хакында баруын аңлап алгач, бер-берсенә карашып, беравыздан:

— Без белмәдек. Әйтүче булса...— дип, ашыгып киенә дә башладылар.

Караңгы төшкәнче Әхнәф тукталыш яныннан китмәде. Ул көнне дә, аннан соң да Әфүзә кайтмады... Шундый борчулы көннәрнең берсендә, Гөлҗиһан клубта эшен тәмамлап, ашыга-ашыга өенә кайтып бара иде. Каршысына Гөлзадә йөгереп чыкты. Башка чакта теленә шайтан төкергән Сәйфи хатыны сүзен башларга җай таба алмый изаланган сыман тоелды. Аның ничек тә йомшаграк, үз итеп эндәшергә тырышуы ярылып ята иде.

— Син кайтканны күрми калмыйым дип тәрәзә яныннан китмәдем, Гөлкәй. Күзләрем күгәрде, чистый,— диде ул еш-еш тын алып.— Әйтәсе хәбәрем бар иде сиңа...

Каршысына кинәт йөгереп чыккан Гөлзадәне күргәч, Гөлҗиһанның болай да тынычлыгын югалтып типкән йөрәге чәнчеп алды. Ул барган җиреннән шып туктап, елаудан кызарып беткән күзләрен Гөлзадәгә күтәрде. Аның йөзе хәсрәтле югалтудан саргаеп кибешкән, күзләре эчкә батып, күнегелгән җылы-моңлы нурның әсәре дә калмаган иде. Хатынның карашын тоеп, Гөлзадә бер мәлгә куырылып алды.

— Кичә Зуравылга барган идем. Больницскә,— диде ул Гөлҗиһанга якын ук килеп. Үзе шикле кеше килеп чыкмасын дигәндәй як-ягына каранып алды.— Сәйфинең бүсере кузгалды бит. Сәнәк тә күтәрә алмый, килә дә чыга... Шунда бер хатынны очраттым. Күперледән икәнлегемне белгәч и төпчende, и сорашты бу. Җыештыручы булып эшли икән. Җавап табып бетермәле түгел... Сезне сорашып үзәкләргә үтте. Сәйфи белән сөйләшеп тә булмады. Киленегезнең юкка чыгуын белеп алгач, шапылдатып бот чапты, малайкаем. Сезнең үзегезне белми икән. Киленегезне бик әйбәт белә икән. Менә бит ул, дөнья, буялган йонга, буялса иде мамыкка, рәхәт булыр иде халыкка...— Гөлҗиһанның сабырсызлана башлавын күреп, Гөлзадә сүзенең эзенә төште.— Әстәгым, ди, шул хатын әйтә, тагын дөньяга бер бәхетсез нарасый арттырган икән, ди. Инде акылга утыргандыр, басылгандыр дигән идем, кая ул — бер тәртәдән чыккач, кире кертеп булмый инде аның ише нәмәкәйне, ди. Тагын чыгып тайган икән дигәч, шаклар каттым. Эзләсәләр дә таба алмаслар, бик шома нәмәкәй ул, ди.

Бик сорашып караган идем, автобуслардан калдым шуның аркасында, артыгын ачылмады. «Баласын кем карый соң?» — дип сорашты. Бала туганнан бирле бианасы кулында дигәч, ис-акыллары китте, малайкаем. Китмәслек тә түгел шул. Син әүлия бит. Мин булсам... Киленең арт туңкайтып ятсын, үзең аның баласын имезеп йөр.

Әманәте шул — сине чакырды ул. Вакыт табып минем янга килеп китсен әле, ди. Әхнәф милициягә килгән икән, хатынын эзләтергә биргән, минем янга кереп чыкмаган. Югыйсә, безнең өйдә булганы да бар бит аның, ди... Ишеткән икән, миннән юри сорашкан булган...

Бала белән җәфаланмасыннар, балалар йортына тапшырсыннар, ул хатын инде җәһәннәм читенә китеп олаккандыр, ди... И-и, малайкаем, песи дә баласын ташлап китми, бу нәмәдән ни көтмәк кирәк. Аның кайтып күренмәве хәерле инде.

Гөлҗиһан өнсез калып, нәрсә дип җавап кайтарырга белми тора иде, Гөлзадә бер кызган шәпкә башка яңалыкларын да тезде:

— Күптән сизенеп йөри идем, сиңа әйтергә кыенсындым. Сәйфигә ачуланып йөргәч ни, мине генә гаепле итеп бетерерләр, дидем.. Мин дә

балалар бакчасында эшлим бит, барысын да күреп тордым. Кеше арасына керсәң... Ул хатын...— Киленен болай атавымны өнәп бетерер микән дигәндәй, Гөлзадә Гөлҗиһанга караш ташлап алды. Әмма тегесе һаман исәнгерәүле халәттә торуын дәвам итте.— Әллә ничә мәртәбә сынадым, ир-ат күрсә, күзе-башы тона иде, малайкаем. Зуравылдан килеп кәтильни төзәтеп, көйләтеп яткан иде бер адәм. Шул мыеклы урыска чат ябышты киленең. Икәүләп кәтильга кереп киткәннәрен әллә ничә күрдем. Артларыннан кереп эләктерим дип кызган чакларым да булды. Сәйфи каршы төште, кеше арасына кермә, бик чая хатын күренә ул, диде. Бер көнне газ баллонын алып кайтып биргән идем, ди, бакчага. «Рәхмәт, Сәйфи абый. Килеп утыр, сөйләшеп ятарбыз»,— ди, иблис хатын. Үз гомеремдә мондый оятсыз сүзләрне ишеткән юк иде, ди. Сәйфинең дә һушы киткән...

Гөлҗиһанга болары әһәмиятле түгел иде инде. Иң мөһиме — Әфүзәне белгән кеше бар, аның хакында сорашырга, чак кына булса да билгесезлектән арынырга мөмкинлек дигән сүз иде бу. Зуравылда туганнары хакында аның сүз кузгатканы бар иде, нигәдер шулар янына барып кайтырга, танышырга җай чыкмады. Эш дигән булып җәй үтте, аннан кышы...

Бала тугач, өйдән чыгып китү турында уйга да китерергә мөмкин түгел иде. Гөлзадәнең сүзләре күңелдә сөенеч уятырлык булмаса да, өмет чаткылары кабызды. Бәлки... бәлки әле барсы да кире кайтарып булмаслык дәрәҗәдә бетмәгәндер. Әфүзә дә кеше бит, аның да сагыну, юксыну хисләре башкаларныкы кебек үктер... Ятимлеге, гомер буе балалар йортында кимсенеп үсүләре исенә төшәр, бу эшнең яшьлек хатасы икәнен таныр, кире әйләнеп кайтыр. Әхнәф тә, Гөлҗиһан да аны кабул итәрләр, уйламый эшләгән әлеге адымын искә төшереп бәгырен телгәләп тормаслар. Кайтсын гына иде, үз балаларын үзләре үстерсеннәр...

...Хастаханәдә эшләүче хатынны тиз эзләп тапты ул. Ансы да, әйтерсең, Гөлҗиһанны көтеп кенә торган, бала күтәреп килеп керергә өлгермәде, каршысына килеп тә басты.

— Сез... Күперледәнме?..— дип сорады ул Гөлҗиһанга сынаулы караш ташлап.

Гөлҗиһанның тез буыннары калтыранып куйды, бала күтәргән кулларының хәлсезләнә башлавын тойды. Кипкән иреннәрен көч-хәл белән кыймылдатып:

— Әйе...— дип кенә әйтә алды. Ак халатлы таныш булмаган бу хатын Гөлҗиһанны аулаграк почмакка алып китте, каяндыр буш урындык табып алып килде. Йокымсырап яткан Шамилнең биләвен чак кына ачып, кызганулы карашын сабыйга төбәде.

— Бала да алҗыган... Тирләгән, мескенкәем,— диде ул шыпырт кына.— Йөз кыяфәте әллә кайдан «мин Әфүзә малае» дип тора... Бераз гына көтеп торыгыз инде. Киемнәрне алыштырып чыгам. Ярый әле эшем беткән чакка туры килдегез,— дип, йөгерә-атлый китеп барды. Ул озакламады. «Кунакларны» Зуравылның аскы, чокырлы-чакырлы урамына, үзләренең өенә алып китте. Юл буе көрсенеп:

— Менә бит эшләр кая китте,— дип сөйләнеп алгалавын исәпләмәгәндә, башка сүз сөйләшмәделәр. Һәркайсы үзенең борчулары эчендә атлады. Берсен — ничек сүз башларга, дигән уй җәфаласа, икенчесе: тагын нәрсәләр ишетергә язган икән, Ходаем, дип шөбһәләнеп бара иде.

Өе Ык буенда ук икән. Хуҗабикә газ плитәсен кабызып, чәй кайнатырга куйды. Гөлҗиһан түр якта Шамилне таратып салып, чүпрәкләрен алыштырып азапланганда, ул да бала янына килеп басты. Күренеп тора, Гөлҗиһанның сүз башлавын, сораштыруын көтә иде ул, алай уңайрак булыр дип уйлый иде, ахрысы. Түзмәде, үзе сүз башлады:

— Мин сезгә бу хакта әллә кайчан әйтергә тиеш булганмындыр, бәлки. Күперлегә кияүгә китүен ишеткәч, йөрәгем жу-у итеп китте. Җитмәсә, кемгә диген...— Хатын йомшаграк сүз эзләп бер мәлгә тын

калды.— Кешесен дә тапкан... Ул чакта өйдә юк идем. Чаллыга, кызым янына кунакка киткән идем. Әфүзә миндә фатирда торды. Туган тиешле кешемнең кызы ул. Үзем кунакта чагында минем урында эшләп торган иде. Хастаханәдә, санитарка булып... Бәлки, гел шунда эшкә урнаштырырмын дигән өмет тә бар иде.— Хатын «сез»дән «син»гә күчте.— Синең малаең белән шулай танышып киткәннәр инде алайса... Кайтуыма өстәлдә хат ята. Хаты һаман да тора әле,— дип, кием шкафыннан кечкенә букча алып балага шешәдән сөт имезеп утырган Гөлҗиһанга каршы утырды.— Сөте суыктыр бит...

— Башыңа төшсә, башмакчы булырсың. Суынмасын дип, култык астында тотам мин аны. Дөнья өйрәтә. Йоклаганда да култык астында — шешә...

— Менә ул хат. Өйдә, сабый имә торсын, мин укып бирим. «Халисә,— дигән.— Хатын укуыннан бүленде. Югыйсә, мин, әнисе белән бер яшьтә, «апа» дип әйттерә алмадым, хәерсезгә.— Халисә, дигән, мин Күперле авылыннан бер егеткә кияүгә чыктым. Моңарчы хатын-кыз заты күрмәгән «җонлы кукы».— Һе, азу ярган егет булса, синең кем икәнеңне ярты чакрымнан чамалап алган булыр иде дә...— Халисә, телеңә хуҗа бул, андый-мондый сүз җибәрсәң — чамала, минем кул озын, беләсең... Авылда яшәп карарга исәп. Тын алырга кирәк. Ир кисәге, торган җире, кешеләре ошап китсә, кем белә, гел калырмын да. Хәер, моңа бик ышанып та җитмим, мин бит оеп кына бер урында яши алмыйм... Алга табан күз күрер. Хуш, күп сөйләнеп йөрмә!» — дигән.

Менә шушы хатны укыганнан бирле тынгы тапмый йөдәдем. Нинди егетне харап итте икән, мин әйтәм. Аннан тынычлангандай иттем, бер дә тавыш-тыннары ишетелми, әйбәт кенә яшәп яталар, ахры, дип уйладым. Унбиш көннәр элек автовокзал янында күреп алдым мин моны. Матур плащ кигән, бизәнгән, ясанган. Бик сылу бит ул үзе, шул чибәрлеге аркасында ир-атның башын әйләндерә дә куя инде, шайтан хатын. Сорашыйм әле, мин әйтәм, ничек яшәп яталар икән, килеп тә чыкмыйлар дип янына бара башлаган идем, җитешә алмадым. Үтеп баручы җиңел машинаны туктатты да, ай күрде, кояш алды — машина артыннан тузан гына күтәрелеп калды. Әфүзә утырып та киткән. Чаллы ягына китте инде. Җиңел машиналарда сиптерерлек акча каян тапкандыр... Хәер, аның акчасы үзе белән инде — тузмый да, кимеми дә... Ләтчә белән бер ул.

— Абзар-кура ныгытырга дип акча җыештырган идем. Шуны табып алган. Әхнәфнең костюмга дигән акчасын үз кулыбыз белән биреп җибәрдек. Кем уйлаган...— диде Гөлҗиһан ачынып.

— Акча ишене җир тишегеннән дә табып ала,— диде Халисә һәм Гөлҗиһанны телсез калдырып ярып салды.— Урлашкан өчен ике тапкыр төрмәгә кереп чыкты инде ул. Белмәгәне, күрмәгәне юк. Ел буе тыныч кына ничек яшәгәндер сездә. Ял итеп алам диюе дөрес булгандыр инде. Еш кына миңа: «Бала тапкан хатын сәламәт була. Бала табасым килә»,— дип сөйләнә торган иде. Менә бу баланы да сәламәтлеген ныгыту уе белән тапкандыр инде,— ул Шамилне кулына алып күкрәгенә кысты.— Нинди сөйкемле бала. Елап та карамый бит, сабый. Бик авыр түгелме соң? — диде Халисә хәлгә кергәндәй.

Гөлҗиһан Шамилне караватка салды.

— Елаган чак та була инде, әйеме, улым?! Бу сабыйга караганда, әтисе өчен борчылам. Нишләргә дә белми инде, бичара. Кайтмас микән инде, сабыен кызганмый микән, ә?..— Күзенә яшь тыгылуын тоеп, калтыранган тавыш белән кызыксындырган соравын бирергә ашыкты.— Әти-әнисе бармы соң? Әфүзәнең дим... Үзең аңа якын туганмы, чыбык очы-тал башымы, дигәндәй...

— Әтисе ягыннан ерак туганы мин аның. Әфүзә тәпи йөргәнче үк әтисе белән әнисе аерылышканнар. Әтисе икенче хатын алды. Әнисе эчүгә сабышты. И-и, эчеп тә карады инде. Ахырдан эчеп үлде, мескен. Бу

бала ничек исән калгандыр — Ходай үзе белә. Кем якты чырай күрсәтсә, шунда булды. Шәһәрдә яшәсәләр дә, безгә дә кайткалап тора иде. Сигезенче класста укыганда урлашып, колониягә эләкте. Аннан чыккач, миндә бер айлап яшәде дә, өч-дүрт ел югалып торды. Беркөнне эштән кайтсам, күземә күренәме дип торам — Әфүзә өйдә утыра. Үзбәкстанга барып чыккан икән. «Бай үзбәк агаеның башын әйләндердем,— дигән була.— Аңа ике үзбәк малае алып кайттым да, эзне суыттым,— дип мактанып өнемне алган иде. Шаклар каттым. «Ничек?» — дип соравыма кулын гына селтәде.— Үзбәкләр бала ярата, исең китмәсен,— ди.— Иремә малайларны калдырдым, үзем эләктерә алган кадәр акча алдым да тайдым, ди. Унтугыз яшь иде аңа...

Плитә өстендә калай чәйнекнең түземсезләнеп капкачы шылтырый башлады, күрәсең, кайнап чыгуына да байтак вакыт үткәндер, сүзгә мавыгып чәй кайгысы онытылып киткән иде. Халисә капыл урыныннан кузгалып, кече якка чыкты. Кабалана-кабалана чәй әзерли башлады.

— Бала кызганыч,— диде ул, кычкыра төшеп.— Инде нишләрсез микән? Балалар йортына бирсәгез генә инде. Әле бу адәм булганчы...

— Юк инде,— диде Гөлҗиһан ныклы тавыш белән. Ул инде Әфүзәнең кем булуын аңлап алган, Халисә сөйләгән чакта аркалары чымырдап торды. Өметнең соңгы чаткылары да сүнгән, һәм гаҗәп, Әфүзәнең кире кайтуын теләми дә кебек ул.— Баланы үзебез үстерәбез. Тапкан ана түгел, баккан ана, үземнең улым сыман ул миңа...

* * *

Көтүләр кузгалганчы авылга әйләнеп кайтырга тырышса да, Гөлҗиһан уйлаганча барып чыкмады.

Халисәләрдән туры автовокзалга йөгерде. Ләкин инде көндезге автобуслар киткән, кичкеләре юлга чыгарга да шактый вакыт бар. Бала күтәреп шушы тирәдә йөрергә, арыгач, автовокзалның тынчу бүлмәсендә утырып торырга гына калды. Кассир бүлмәсенең шап-шоп бер ачылып, бер ябылып торуы башларга капты. Кемнәрдер керә, кемнәрдер чыга. Эчтә кычкырып сөйләшәләр, билет сатучы ихахайлап көлә, өзлексез телефон чылтырый, кыскасы, бала өчен тынычсыз урын булды бу. Болай ук утырырмын дип уйламаган иде... Инде Шамилнең сөте дә бетте. Ярый, Халисә чәй ясап җибәргән иде. Бәхетсезлеккә, Зуравыл кибетендә сөт булмады. Халисә сыер асрап яшәми икән. Шуңа күрә, сабый кыбырсый башласа, чәй йоттырып котыла, инде дә булмаса, почмак якка борылып үткән-сүткәннең күзеннән яшереп изүен чишә. Ничек тә баланы түздерергә, алдап-йолдап булса да исән-имин кайтарып җиткерергә кирәк иде.

Шамил, авызы алҗыганчы, буш имине суыра-суыра да, янәдән йокымсырап китә. Ай-һай, бу вакыт дигән нәрсә! Көтә-көтә тәмам көтек булып бетте Гөлҗиһан. Кичке сәгать биш туларга ун-унбиш минутлар кала, бүлмә идәненә утырган бер илле калынлыктагы тузанны күтәрмәскә теләп, сак кына атлап касса төбенә килде, инде учында күп әүшәли торгач дымланып, бөгәрләнеп беткән акчасын тигезләгәндәй итте дә йодрык сыярлык кына тәрәзәчектән эчкә сузды:

— Күперлегә бер билет...

— Ал акчаңны!.. Күперлегә юк!

Көтелмәгән хәбәрдән Гөлҗиһан каушап, коелып төште.

— Нәрсә юк, үскәнем?.. Кай арада билет бетте соң әле?... Мин бит бала белән, үскәнем... Яшь бала... Өч кенә айлык...

— Балаңда эшем юк,— диде кассир хатын Гөлҗиһанның этләнеп нәрсәдер аңлатырга тырышуына гаять дәрәҗәдә ачуы килеп.— Саңгыраумы әллә? Күперлегә автобус юк! Азнакайга кайтып китте. Следующий!

— Тукта инде, үскәнем... Күперле автобусы яңа гына тәрәзә каршында тора иде бит әле. И-и, Ходаем, ничек кайтып җитәрбез инде, ә?..

Кассир шартлатып тәрәз капкачын ябып куйды.

Гөлҗиһан Шамилнең чүпрәкләрен җыештыра-җыештыра, бу каһәрле алачыктан урамга таба атлады. Аннан, баланы җунләп төрмәгәнче исенә төшеп, якындагы утыргычка чүмәшеп, баланы әйбәтләп биләүләде һәм әрнүле уйлар эчендә Ык буена, олы күпергә табан кузгалды. Бөтен ышаныч — Күперле ягына кайтучы машиналарда иде. Берәр миһербанлысы килеп чыгар, яшь балалы хатын янәннан күзен йомып үтеп китмәс, дигән өмет чаткысы бар иде әле. Кабат Халисә өенә кайтып, аларда төн үткәрергә микән дип тә уйлап алган иде, нигәдер ул якка кабат аягы тартмады.

Әфүзә турында җанны тетрәтерлек хәбәрләр ишеткәч, кабат-кабат күз алдына килененең гәүдәсе килеп баса. Мөлаем йөзле килененең һич кенә дә, Халисә сөйләгәнчә, шомарып беткән сукбай хатын булуына ышандыра алмый иде ул үзен, башка сыярлык хәл түгел бит бу!

— Бу дөньяны аңламассың, әйеме, улым?— дип, Шамилне күкрәгенә кысып сөйләнде ул.— Берәүләр бәби табу бәхетеннән мәхрүм булып хастаханәләр юлын таптыйлар, яшертен генә им-томчылар янына барып йөриләр. Газапланалар, күз яшьләре түгеп Алладан рәхим-шәфкать сорыйлар. Бер дә булмаса, ятим баланы уллыкка йә кызлыкка алып, аңа ана назы бирергә тырышалар. Ә сау-сәламәт хатын тегендә дә, монда да үзе тапкан балаларын ташлап китсен дә барсын инде, йә? Кеше ышанмаслык хәл бит бу!

Тәмам өмет өзелде, дигәндә, Наратлыга кайтучы машина туктап, аларны утыртып алып китте. Гөлҗиһан моңа да сөенде: Наратлыдан җәяүләп тә кайтып җитәргә була.

Шамилне түздереп торулары кыенга китте шул — аз-маз алдалап торырга баллы чәй дә бетте. Бала ачыгып, тынгысызлана, көйсезләнә башлады. Әле ярый, сабыр итә, үзенең нинди хәлгә төшкәнен аңлаган кебек ул.

Наратлыга кайтып җиткәч, шофер агай Гөлҗиһаннарны юл буенда калдырып, төялгән йөген бушату өчен сельпо ягына китеп барды. Хатын уйга калды. Монда, юл буенда машина көтеп ятудан мәгънә чыгармыюкмы, ансын белгән юк, әмма җәяүләп кайта башласа, ике-өч сәгатьсез Күперлегә кайтып җитә алмаячак ул. Унбиш чакрым юл бит... Башы әйләнә, хәлсезлек сизә. Көне буе кояш астында йөрү, тузанлы сасы вокзалда бушка вакыт сарыф итеп яту үзенекен иткән, ахрысы... Бала ач, шыңшып кына тора, җитмәсә... Озаклап баш ватудан файда юк иде, Гөлҗиһан тәвәккәлләп авыл читендәге беренче өйгә атлады. Исәбе — сыерлы хуҗадан сөт сатып алып, баланың тамагын туйдыру иде. Шунсыз Күперле ягына аяк атлау турында уйлыйсы да түгел. Беренче өйдән буш кул белән чыгарга туры килде — сыерлары зыянлап, күптән түгел генә суйганнар икән. Шулай да кыяфәтенә талчыгу чыккан бу хатынны алар болай гына чыгарып җибәрүне яхшысынмадылар, хуҗа хатыны үзе үк аны күршеләренә ияртеп алып кереп китте. Гөлҗиһан авыз ачканчы ук аларга хәлне аңлатып та бирде. Алар исә, Гөлҗиһан тарыган хәлдән хәбәрдар булып чыктылар. Яхшы хәбәр таш астында, яман хәбәр тау башында дигәндәй, бер хатынның яңа туган баласын ташлап юкка чыгуын ишетеп, якын-тирә авыллар шаулаганнар иде инде. Сөт кайнатып, аны шешәгә салып, чиләктәге салкын суда суытып, таманлап алдылар. Шамилнең тамагы туйганчы имезделәр. Гөлҗиһанны да кыстый-кыстый чәй эчерделәр, шуннан соң урта мәктәптә укучы уллары бишекле мотоциклда Гөлҗиһан белән Шамилне өйләренә үк кайтарып та куйды.

Караңгы төшкән. Әхнәф әнисенең кайтып җитмәвенә пошаманга төшеп, ялгызы ут та элми өйдә утыра иде. Юлчылар кайтып керүгә кабаланып утны кабызып җибәрде, өмет тулы сагышлы күзләрен төбәп:

— Инде кайта алмассыз, дигән идем, автобус килмәгән бит, көтүдән кайткач ике урадым ул яктан,— диде.

Гөлҗиһан кайтып җитә алуларына сөенеп, җил-җил атлап, йоклаган баланы бишегенә салды. Бишекне тирбәтә биреп, Әхнәфкә борылды:

— Егет дисәң дә була безнең улыбызны. Зуравылдан әйләнеп кайтканчы елап карамады. Көйсезләнеп алгалады алуын, мәгәр, түзде.

Гөлҗиһан юлда күргән-кичергәннәрен сөйли-сөйли ашарга әзерләргә керешә...

Боларның барсы да Әхнәфне кызыксындырмый дисәң дә була иде. Ул әнисенең Зуравылга ни өчен барып кайтуын яхшы чамалый, көтелмәгән югалтудан, соңгы көннәрдә җанын талкыган шыксыз уйлардан катып калган күңеле җылы хәбәр көтә иде. Әлегә әнисе бу хакта сүз кузгатмый, һаман суза, оныкны мактавын белә...

Әнисенең җитди сөйләшүдән качарга тырышып, юри төрле юк-бар сөйләп вакыт үткәрүен сизеп, Әхнәф башын түбән игән хәлдә төн караңгылыгына чыгып китте.

Ул шулай төн җитсә, өй артындагы утыргычка утыра да йолдызлар сибелгән төпсез күккә карап тын кала. Узган ел да алар Әфүзә белән кич буе икәүләп шушында утырырга яраталар иде. Әфүзә сөйли, Әхнәф тыңлап туймый. Әфүзәнең укымаган китабы юк иде бугай. Башка вакытта сүзгә саран хатын шушы утыргычка чыгып утырса, бөтенләй ачылып китә иде. Әхнәфне аптырашка салып, әллә нинди җырлар суза. Үзе Әхнәфнең авыз ачып калуын күреп кычкырып көлеп җибәрә:

— Балалар йортында өйрәнгән репертуар бу! Исең китмәсен...

Әхнәф җавап бирергә өлгерми, Әфүзә тагын аны телсез калдыра:

— Син, Әхнәф, нигә тәмәке тартмыйсың, ә?..— Киерелеп, ләззәтләнеп тәмәке суырган кыяфәт ясый.— Ир кеше булсаммы?! Рәхәтләнеп тәмәке тартыр идем. Аракы эчмә, тәмәке тартма, шул да булдымы ир кеше!

Хатыны сүзенә карап, Әхнәф кибеттән папирос сатып алган иде. Кеше күзеннән качып, абзар артына чыгып тартып та маташкан иде, ләкин шунда ук гайрәте чикте. Бер-ике суырган иде, буылып йөткерергә тотынды, башы әйләнеп, укшый башлады. Күптән җәфаламаган баш өянәге башлангач, бу эшеннән бөтенләй ваз кичте, папиросын кабы белән мич башына ташлады. «Дөнья булгач, кирәге чыгар әле. Утын, печән алып кайтсаң, тракторчылар үз көйләрен көйләтергә осталар, таптыра башлыйлар моның ише нәрсәне...» Тик бу папирос аннан тиз юкка чыкты. Әфүзәдән тәмәке исе килүен сизә иде ул, кызыксынып, тәвәккәлләп сорасы итсә, Әфүзә күзен дә йоммый иде:

— Бакчада ремонт бара. Пар казаны төзәтә бер урыс. Шуңа булышырга кушканнар иде. Авызыннан тәмәкесен өзми. Киемгә сеңгәндер инде...

... Әхнәфнең тәненә суык йөгерде. Ул өйгә кереп яту нияте белән урыныннан кузгалды. Көт-көтмә, әнкәсе аңа бүген бернәрсә дә сөйләмәячәк иде. Димәк, ул күп нәрсәне белеп кайткан, хәзер боларны Әхнәфкә ничек итеп җиткерү хакында уйлыйдыр. Үзенә түземсезләнеп сорарга да уңайсыз. Күрәсең, болар хакында сөйләргә әнкәсенә шулай ук җиңел түгел.

* * *

Зуравылга барып кайтканга атна чамасы үтсә дә, Гөлҗиһан бу сәфәрдә ишеткәннәрен Әхнәфкә сөйләп бирергә уңайсызланып йөри иде. Улының күңел түрендә янган соңгы өмет чаткысы да сүнсә, әллә нәрсә булыр, улы бу яман хәбәргә бирешер, акылсызланып бер-бер хәл кылыр кебек иде.

Әмма моны яшереп тә булмый, бүген әйтергә дип ныклы карарга килде ул. Билгесезлеккә нокта куярга кирәк, җайлап әйтә алса, бәлки Әхнәф ул кадәр күтәрелеп бәрелмәс тә әле. Аннан, көн артыннан көн үтә, күңел җәрәхәтенең сызлаулары кими дә төшкәндер...

Ул шундый уйлар белән ашарга әзерләде. Әхнәф көтүдән кайткан уңайга чәй генә эчә дә, йә өй артындагы утыргычта ял итеп ала, йә ятып тора. Аннан, көн эссесе сүрелгәч кенә, кичке ашны ашыйлар. Гөлҗиһан өйалдына чыгып, Әхнәф йоклый торган чоланга карады, урын буш, димәк, ул утыргычында.

Шулчак Гөлҗиһанның колагына сагышлы җыр ишетелеп китте. Гөлҗиһан сак кына ишек алдына чыкты. Әйе, Әхнәф үз урынында оеп утыра. Тәрәзәдән төшкән яктылыкта ул бөтенләй таш сыман кебек күренә. Кулларын баш чүмеченә кушырып, стенага терәлгән, һавада җемелдәшкән вак йолдызларга карап, әкрен генә җыр суза иде. Сүзләре дә, көе дә Гөлҗиһанга таныш түгел, әмма йөрәккә үтеп керерлек моңлы иде җыр.

Ак томаннар төшсен үзәннәргә,
Яңгыр яусын — аңа карама —
Кайт яныма, иркәм, сары көзнең
Салкын җилләреннән арала...

Йолдызларны болыт каплап китсен,
Көмеш нурын ай да сипмәсен.
Таң җилләре булып кайт та, иркәм,
Мәңге яннарымнан китмә син...

Еллар аша карыйм күзләреңә,
Кулларыннын тоям җылысын.
Өметләргә инде карлар ява,
Сагынуга ничек түзим соң?..

Гөлҗиһан сүзсез генә улы янына килеп утырды. Әхнәф, әнкәсеннән уңайсызланган сыман, читкәрәк шуышты.

Гөлҗиһан бераз эндәшми торды да Зуравылга барган көнне нәрсәләр ишетеп кайтуы хакында төкми-чәчми сөйләп бирде. Әхнәф бу хәбәрләрне бик авыр кабул итте.

— Ә бит мин аны ярата идем,— дип уфтанып, тез башларына сугып куйды ул.

— Сабыр итәргә кирәк безгә, улым,— диде Гөлҗиһан, Әхнәфнең пырдымсызланып урыныннан кузгала башлавын күреп.— Мин бу хакта сиңа әллә әйтмим микән дә дигән идем... Әйтмичә дә кала алмадым, син сабый түгел, аңларсың дип уйладым. Хәзер менә мине ачулансаң ачулан... Эчтә бикләп йөрүләре авыр шул. Ичмасам, син дә кысыр хыял белән йөрмәссең. Үзем дә кайтуын бик өмет иттем. Акылына килер, кайтыр, дидем. Сөйләшербез, аңлашырбыз, үзегезнең баланы бергәләп үзегез үстерерсез дип уйладым. Әгәр минем белән торасыгыз килмәсә, ансына да каршы түгел идем. Хәзерге яшьләр әти-әни белән торуны өнәп бетермиләр шул. Юк бит, бернәрсә сиздермәде, ташлады да чыгып китте.

— Әйтте ул, әнкәй, чыгып китик диде. Тик Шамилне сиңа калдырып... Мин риза булмадым...

— Һе... Баланы гел ташлап калдыруда булган икән уе... Эчендә җаны юктыр аның, улым... Сабыр итәргә кирәк инде, нишлисең...

Әхнәф кабынып китте:

— Син, әнкәй, һәрвакыт сабыр булырга кушасың. Үзең дә гомер буе сабыр итеп яшәргә тырыштың. Шуның аркасында бәхетеңнән дә коры калдың. Нәрсә рәхәт күрдең инде, ә?.. Син ирсез калгансың, мин әтисез үстем. Инде килеп, кеше алдында начар күренмик дип, Әфүзәнең кылан-

мышларына түзеп яшәдек. Бәлки аны башта ук бөтен халык алдында рисвай итәсе калгандыр?..

— Алай гына акылга утыртырлык булса... Әйтәм ич, Халисә карточкасын күрсәтте, томыраеп торган ике малаен ташлап качкан бит... Эздән чыккан булган инде ул, монда эзләп табарлар дип, качып ятуы гына булгандыр... Менә син, улым, сабыр итәргә кушасың дип, мине битәрлисең. Нәрсә дим соң?.. Мин Әфүзәдән шикләнеп тә куйган идем, әгәр дә шул чагында, ягъни синең акылың томаланган, күзеңә шул хатыннан башка беркем дә күренмәгән чакта, шикләремне сиңа әйткән булсам — тыңлап торыр идеңме?.. Юк шул... Ярата идем дисең... Мәхәббәт шундый нәрсә — ул акылга буйсынмый. Ә бит үзеңнең кешелегеңне саклап калырга кирәк, Шамилне аякка бастырырга кирәк — сабыр итми, нәрсә эшләмәк буласың?

— Әйтсәң, кеше ышанмас — әнисе була торып, әнисез бала...

— Әле син ишетмәгәнсеңдер, баланың теле ачылып килә. Миңа «әннә» дигән була...

## VI

Озакка киткән көзге яңгырлардан юллар тәмам изрәп беттеләр. Гөлҗиһан тау асты чишмәсеннән көч-хәл белән кайтып керде.

Суын өйалдындагы җыйнак мичкәгә бушатты да, шалтыршолтыр көянтә-чиләкләрен урнаштырып, өй ишеген ачып җибәрсә, аптырап кире артка чигеп куйды — түрдә, өстәл янындагы урындыкта аңа таныш булмаган ир-ат утыра иде. Ир кеше Әхнәфкә нәрсәдер сөйләп, аңлатып торган җиреннән Гөлҗиһанга каерылып карады, аннан кабаланып урыныннан күтәрелә башлады. Кунакның йөз чалымнары якын, үтә дә таныш иде. Хәтере мизгел эчендә әллә кайда калган ерак елларга, әтисе сугыштан кайткан чорларга сикерде. «Күземә күренәме, әткәйнең сугыштан кайтып кергән төс-кыяфәте бит бу. Киемнәре генә заманча...» Гөлҗиһан аптыраулы халәттә ишек катында туктап калды. Ул арада ир кеше аңа таба атлады. Калтыранган тавыш белән:

— Гөлкәй, исәнме?.. — диде. Күзләре сәер елтырап китте. Куллары ирексездән Гөлҗиһанга сузылдылар. — Әллә танымыйсың дамы? Мин бит бу — Шәйхаттар...

Гөлҗиһан исенә килеп, Шәйхаттарны кочаклап алды.

— Шәйхаттар... абый! Сине дә күрер көннәр бар икән. Ни гомерләр үтте бит! — дип сөйләнә-сөйләнә абыйсының салкынча кулларын үзенең кытыршы учларына алды. — Ничекләр кайтасы иттең? Эчеңдә жаның булмагандыр, абый. Ничә еллар бит, ничә еллар авылдан чыгып киткәнеңә... — диде ул кабат абыйсының киң иңсәләреннән сөеп. — Мин инде синең төс чалымнарыңны да онытып бетерә язган идем. Әткәйгә охшатып кына таныдым үзеңне.

Күрешү шатлыгы, ыгы-зыгы белән түргә үттеләр. Шәйхаттар кире, яңа гына кузгалган урынына кереп утырды. Әхнәф тә җанланып китте:

— Мин ни... Кем микән, әллә налуг җыючы Киршин кереп килә микән дип аптырап торам.

— Әйе, — дип сузды Шәйхаттар. — Инде авылдан чыгып киткәнгә дә егерме биш ел тулды. Шушы көздә нәкъ егерме биш ел... — Күренеп тора, озак еллар чит-ятларда йөреп, җитмәсә, марҗа белән гаилә корып яшәү нәтиҗәсендә татарча сөйләшү аның өчен шактый кыен иде. Әмма ул һич тә чит сүзләр катнаштырмаска тырыша, тансыклаган сыман сүзләрнең тәмен татый-татый сөйләшә. — Менә Әхнәф тә ир булган, үзенең малае үсеп килә икән.. — диде ул уенчыклары белән мәш килеп уйнаган Шамилгә елмаюлы караш ташлап. Гөлҗиһанның күңелсезләнеп китүен күреп, бу хакта сүзен тизрәк очларга ашыкты. — Беләм, беләм, Гөлкәй... Әхнәф сөйләде... Сезгә дә кыенлыкларны күп күрергә язган икән...

— Агач башыннан йөрми инде, абый, бәндә башыннан йөри...

— Дөрес... Мин дә саулыкны югалттым менә...— Шәйхаттар идәндә яткан таягын үрелеп алды.— Җир җимертеп йөргәндә... Дөнья куып, кайтырга вакыт тапмаган булдым, таякка калгач кайтып егылырмын, дип, башка да килмәгән иде дә...

— Нәрсә булды, абый?— Гөлҗиһан сызланган кыяфәт белән Шәйхаттарның аякларына текәлде.— Әллә сындырдыңмы?.. Тауларда йөрим дип язгач та күңелемә килгән иде. Күңелдәгесе — алдыңда диләр иде, хак икән...

— Таякка калдым шул,— дип кабатлады Шәйхаттар.— Инде икенче ел авырыйм... Нинди казага юлыкканмындыр — табиблар да белми... Тормыш та көйле генә бара иде дә... Асты-өскә килде... Эшләп булмый, пенсия акчасы ачтан үлмәслек кенә... Гаиләдә тавыш китте. Үзем, бераз кыймылдый алганда, авылга кайтып егылыйм дидем...— Ул Гөлҗиһанның сәерсенүле карашын тотып, тын калды.

— Әйтәм җирле... Ничә хатка бер җавап язмадың соңгы елда...

— Терелермен кебек иде... Савыксам, иң беренче эшем итеп авылга, нигеземә кайтып дога кылу иде исәп... Алга китеш юк шул... Күрәм, үзегезнең дә хәлләр җиңел түгел икән. Иң зур гаеп үземдә. Пешмәгән бәрәңге булдым. Бер генә мәртәбә кайтып, хәлләрегезне белеп китсәм дә, болай булмас иде. Акчасын да таптым эшләгәндә, мөмкинлегем дә бар иде. Сезне җиргә сеңгән өйдә яшәтергә тиеш түгел идем дә...— Ул үкенүле уйларның тышка бәреп чыгуыннан гаҗиз калып, кулын селтәп җибәрде.— Хәзер соң инде...

... Чәйләр эчеп, бераз эчләрне бушатып алгач, Гөлҗиһан абыйсына урын җәйде. Үзе һаман Шәйхаттарның сөйләгәннәрен күңелендә яңарта, торган саен җаны әрни, тынгысызлана иде. Ахырда түзмәде, үзалдына сөйләнеп алды:

— Икебезнең беребезгә бәхет елмаймады, ичмасам... Мин — ирдән, син хатыннан уңмадык...

Шәйхаттар сөйләгәннәр шактый гыйбрәтле иде шул.

... Егет Тын океанда хезмәтен тутыргач, туры, авылга кайтып тормыйча, Урта Азия якларына китеп барды. Исәбе — бераз акча эшләп, киенеп, көязләнеп, мая туплап, авылга кайту иде. Күперледә туган-тумача юк, сеңлесе генә гомер кичерә. Ул да соңгы хатында: «Ирем белән аерылыштык, улым туды. Хәзер улым белән икәү кире үзебезнең нигезгә кайттык»,— дип елап язган иде. Буш кул белән авылга кайтудан ни мәгънә дип уйлады Шәйхаттар. Кайткач-кайткач, йорт салырлык акча эшләп табарга кирәк.

Таҗик егете Латыйфка ияреп, таулар иленә китеп барды ул. Анда да эш уңай гына бара — флоттан кайткан таза егетне геологлар үз яннарына сыендырдылар, гади эшче итеп алдылар. Шәйхаттарның аягы җиңел булды — яңадан-яңа ятмалар ачтылар, егет үзе дә әлеге эш белән чынчынлап кызыксына башлады. Институтка керде, күп тә үтми өйләнеп җибәрде: бер-бер артлы ике балалары туды. Укуы тәмамлангач, эзләүчеләр партиясенә җитәкче итеп билгеләделәр. Көн-төн эзләнүләр, яңа ачышлар.

Шәйхаттарның даны артты, дәрәҗәсе үсте. Эшләр тәгәрәп кенә барган кебек. Андый чакларда әллә кайдагы Күперле авылы да, сеңлесе белән Әхнәф исемле таныш булмаган энекәше дә ике ятып бер төшенә кермәгән чаклар була ул... Марҗа хатын мул тормыштан канәгать, Шәйхаттар акчаны көрәп ала, кыз белән малай ай үсәсен көн үсәләр. Бу якты дөньяда нәрсә кирәк адәм баласына?! Шулай келтерәп кенә барган җирдән, авырый башлады ул. Йөрмәгән җире, күренмәгән табиб калмады — авыруның сәбәпләрен дә, дәвалау чарасын да таба алмадылар. Ахырда, аңа пенсия билгеләп, вакытлыча ялга җибәрделәр, ургылып кергән акчалар кимеде, почет грамоталары, орден-медальләрнең бер

файдасы да тими икән, кулыннан эш китkәч... Теңкәгә тигәне — хатыны кага башлады.

Иң элек ялгызын аерым бүлмәгә куып чыгардылар. Ашарына аерым хәзерләде, үз киемнәрен үзеннән юдырта башладылар. Инде терелүгә өмет калмагач, өйдән үк куа башладылар. Балалар да әнисе сүзен кабатлый икән.

— Аларга нәрсә — үзем исән-сау чагымда да сирәк кайтып күренә идем бит. Гел: «Акча, акча!» — дип авыз суын корыткан хатынның туймас нәфсесен басар өчен җан да фида булгандыр инде...

Улы белән кызы турында сүз кузгалса, Шәйхаттар бөтенләй төшенкелеккә бирелде. Хатынының кыланмышларына караганда балаларының хыянәтен авыррак кичерә, аларны аклый да, кичерә дә алмый иде ул.

— Кечкенә чакларында кулларымнан төшермәдем үзләрен. Өйгә кайтып керсәм, икәүләп муенга асылыналар иде, — дип күз яшьләрен сөртеп алды ул. — Хәзер икесе бер авыздан: «Убирайся, татарин! Надоели твои стоны!» — дип аяк тибеп кычкыралар. Ачу итеп төн урталарына кадәр магнитофон акырталар, шакылдыйлар — мәхшәр башланды... Ә мин нишли алам?.. Бөтен гәүдәм сызлый, аяклар тыңламый. Соңгы вакытта ашарга да үзем әзерли башладым. Хастаханәгә салмыйлар — чиреңне белмибез, дип аяк терәп каршы торалар. Бер табибтан икенчесенә тикшерүгә җибәреп кенә котылалар. Сизәм, озакламый гел аяктан язачакмын, аптырап уйландым-уйландым да авылга, сезнең янга кайтып киттем... Ни булса шул була, хет әткәй-әнкәй янына күмәрсез...

— Их, абый, абый... — дип көрсенде, сүз әти-әнисенә килеп җиткәч Гөлҗиһан. — Әткәй дә чит авыл зиратында ята бит... Кабере күрше авылда...

— Ничек алай? Миңа бу хакта язмадың да...

— Ул чактагы кайгы-хәсрәт, борчулар аркасында язылмагандыр инде, абый. Бигрәк болгавыр чак иде бит...

Инде Гөлҗиһанның абыйсына үзенең башыннан кичкәннәрне сөйләп бирми чарасы калмады. Әхнәф иртәнге чәйдән соң ук эшкә киткән иде, ике туган ул төшке ашка кайтканчы сөйләштеләр. Сөйләшкән саен, сагыну-сагышлар, үкенечләр тагын да тирәнәя, йөрәк яралары бәгырьләргә үтеп сызлый иде...

* * *

Баштагы көннәрдә Шәйхаттар бераз хәрәкәтләнеп, йөреп азапланса да, әллә ерактан кайту артык йончыткан, әллә инде айдан артыкка сузылган пыскак яңгырлар килешмәдеме — ул ятып кына тора башлады. Гөлҗиһан бу хәлдән тәмам кайгыга калды. Төрле дарулар юнәтеп, абыйсының аяк, кул буыннарын шыбыр тиргә батканчы сыласа да, файдасы тимәде. Аяклар да, куллар да баһадирдай гәүдәле иргә бөтенләй буйсынмый башладылар, зур түмәргә тагып куйган утын пүләннәре сыман җансызлар, сөйләшүенең дә рәте китте. Юк кына нәрсәне дә аңлата алмыйча җәфаланып бетә иде ул...

Мондагы табиблар белән дә киңәшеп карады Гөлҗиһан. Наратлыга алып барды абыйсын, аннан Зуравылга җибәрделәр. Анда исә мондый сәер авыруны теләми генә кабул иттеләр. Авыру турындагы белешмә таптыра башладылар. Шәйхаттарның авызыннан «быкы-быкы»дан башка сүз чыкмый, аның өчен Гөлҗиһан ярсып-ярсып аңлатырга тырыша иде.

— Каян булсын инде аның картечкәсе, йә Алла коллары?! Хатыны куа башлагач, чыгып киткән инде, мескен. Үз татарың булса да, бер хәл булыр иде. Хат та язып карар идем... Үзен-үзе белгәндер инде, кайтты да егылды... Нинди зәхмәтләр кагылгандыр инде, сез брачлар да белмәгәч...

Табиб аптырый төшеп, Гөлҗиһанны бүлдерде.

— Шундый зур шәһәрдәге табиблар белмәгәнне, без каян белик ди инде?! Аларда тиешле җиһазлар да бар, тәҗрибәле табиблар да а: түгелдер. Монда бит юк кына нәрсә өчен дә Казанга, йә Чаллыга җибәрәбез кешене. Менә абыйның йөрерлек рәте юк, ә гариплеген раслау өчен Чаллыга барып кайтырга тиеш ул. Шунсыз пенсия ала алмаячак. Тәртип шулай.

— Чаллыга?... И-и, брачкаем, анда аны кем алып барсын ди. Әле җир җимертеп йөргән кешегә дә калхуз машина бирми. Безнең ишесенә юк та юк инде ул...

Табиб бераз уйланып утырды да, сеңдереп сөйли башлады.

— Апа, теләсә нәрсә әйтегез, әмма абыегызны монда калдыра алмыйбыз. Аңа тәрбия кирәк, сабый баланы караган кебек тәрбия. Бездә андый кешеләр юк. Санитар хатын-кызларыбыз җитешми. Үзегез килеп, карап торырга да мөмкинлек юк, дисез... Казанга илтсәгез, рәхим итегез, кирәкле кәгазьләрен бирәбез, алып барыгыз, урнаштырыгыз. Иң яхшысы...— Табиб Гөлҗиһанның колагына пышылдады...— Сез аны, апа, интектереп йөрмәгез инде, авылга алып кайтыгыз... Яшәгән кадәр яшәр дә... Без дәвалый торган авыру түгел бу. Анализларын алып карадык, өметле түгел... Геолог иде дисез бит. Бер шигем бар — эзләнүләр вакытында сәламәтлек өчен куркыныч казылмага юлыккандыр, бәлки. Радиоактив матдә дип атала. Үзе аңлата алганча, ул нәкъ шушы юнәлештә эш алып барган да инде.

... Шәйхаттарның сызланулары, ухылдап тын алулары өйнең бар тынычлыгын алды. Ул үзе аек акыллы, һәрвакыт тирән уйда ята. Ишек ачылса, өмет белән тулы зур, тере күзләрен керүчегә төби. Андый чакларда Гөлҗиһанның үзәге өзелеп төшәрдәй була. Ул белә — абыйсы түземсезләнеп улы белән кызының кайтып керүләрен көтә. Әти кешенең балаларына мәхәббәте шулкадәр көчле ки, Шәйхаттар карават каршысындагы урындык артына улы белән кызының фотосурәтләрен сөяп куйган да, көннәр буе пышылдап кына алар белән сөйләшеп күңелен юата иде. Гөлҗиһанның колагына ара-тирә абыйсының тетрәндергеч рәвештә:

— Сергей... Татьяна...— дип балаларына эндәшүе, аларны үз янына чакыруы ишетелгәләп китә иде.

Абыйсының өзгәләнүенә түзә алмыйча, урыс теле укытучысы аркылы Шәйхаттарның хатынына хатлар яздырып җибәреп тә карады. Баштагы хатлар суга төшкәндәй эзсез эрделәр. Бишенче хатны алгач, марҗа җиңгинең сабырлыгы төкәнде, ахрысы, җавап язып салды. Хат килү белән Гөлҗиһан таныш укытучы янына йөгерде. Үзе дулкынлана, күңеленнән әллә нәрсәләр уйлап бетерде. Кабынырдай булып мәктәпкә йөгереп килде, дәрестән укытучы кызны чакырып чыгарды, ашыгып аңа ерактан килгән хатны сузды:

— Тәки хат язып җибәргәннәр бит. Җиңгидер инде. Урысча аңламасам да, язып шомарган кешегә охшаган кулы...

Хатны чыннан да Шәйхаттарның хатыны, балалары бергәләп язып җибәргәннәр иде. Аны укып чыккач, укытучы кыз башта ни әйтергә белмичә эндәшми торды. Болай сүзсез калуның мәгънәсезлек икәнен абайлагандай, Гөлҗиһан апасына күтәрелеп карамыйча гына:

— Укыдым, укыдым да, Гөлҗиһан апа, дөрес аңласам, монда аларның өчесе дә бер үк нәрсәне язганнар бугай,— диде ул, хатынга күтәрелеп карамыйча.

— Әллә... кайта алмыйбыз, дип, язганнармы, Ходаем?..— Гөлҗиһан кулларын кая куярга белмәгәндәй, талпынып алды.— Инде абыйның аларны көтүләре... Ашаудан язды бит, гел шуларның исемнәрен генә пышылдап ята.

Укытучы авыр сулап куйды.

— Кайта алмыйбыз дип кенә язсалар бер хәл иде әле... Хатыны да, балалары да Шәйхаттар абыйдан баш тартулары хакында әйтеп язган-

нар.— Яшь кызның бу кадәр рәхимсезлеккә, мәрхәмәтсезлеккә акылы җитми иде булса кирәк, аның күзләреннән яшь сытылып чыкты.

Гөлҗиһан лапылдап таш стенага сөялде.

— Ничек?.. Кемнән баш тарталар алар? Гомер иткән иреннән, карап үстергән әтиләреннәнме?..

Бу эш өчен үзен гаепле санагандай, укытучы кыз акланып алды.

— Югыйсә, әйбәтләп язган идем инде,— диде ул.— Алардан Шәйхаттар абыйга башка бернәрсә дә кирәкми — кайтып күзенә күренеп китсәләр дә, сөйләп аңлатып булмаслык сөенеч булачагын төрлечә аңлатып язган идем. Шулай ук Гөлҗиһан апа, синең дә алардан бер нәрсә дә өмет итмәвеңне әйттем...

Гөлҗиһан кызны җөпләп куйды:

— Нәрсә кирәк булсын ди, җүләркәем... Барысы да житеш, җан тынычлыгы гына булсын.

Кыз дәвам итте:

— Минем язганнарны дөрес аңлаганнардыр дип уйлыйм. Иң гаҗәбе шул: шушы сүзләр өчен хат язучыны, ягъни мине инде тетмәсен теткәннәр. Кайту кая ул! Ачуланганнар чакырган өчен.— Ул хатны укыйтәрҗемә итә башлады.— Тыңлап кара син, Гөлҗиһан апа, боларда намус-мазар юктыр дисәң инде...— «Монда да аның теләсә нәрсә сөйләнеп ятуыннан туеп беттек. Ике сүзнең берендә «Туган якларга кайтыйк»— дип теңкәгә тиде. Инде менә кайтып киткән икән, артын басып тик кенә ятсын!»— дигәннәр...

— Иманнары юк икән...

* * *

Теге йөрәк тетрәндергеч хат Гөлҗиһанның исеннән бер генә минутка да чыкмый. Кайгыга сабышты хәтта. Ул тамак төбенә килеп утырган кайнар төерне йота да кабат уфтанып ала.

— Шушы кешедән акча сорап ята бит, ләгыйнь... Их, үзебезнең татар кешесенә өйләнгән булса! Инде шушындый хәл килеп чыкса да, эчемдәгесен түкми-чәчми җиткерә белер идем аңа. Ул маржага нәрсә дип язасың инде. Шәйхаттар абыйсы сөйләвеннән белә — ул татарларны далада сарык көтеп йөрүче ярым затлар итеп кенә күз алдына китерә икән бит. Абыйсын да, Шәйхаттар дип түгел, «Чыңгызхан» дип йөрткән. Ничә ел торып, татарларның искиткеч зирәк, кулларыннан эш килә торган халык икәнен аңлаттым, юк, җене белән каршы килә иде. Монголларда каян килеп акыл, белем, син әйткәнчә, авыллар, шәһәрләр төзеп, аларны үрнәк тәртиптә тоту мөмкин булсын, дип авызыннан күбекләр килгәнче бәхәсләшә иде,— дип көрсенгән иде Шәйхаттар ул чакта.— Татарлар белемле булса, кулларыннан эш килсә, космоска очарлар иде! Ха-ха-ха! Космоска маймыл сыман сынау өчен дә җибәрергә яраксыз халык бит сез. Тотарсыз да кирәкмәгән бер кнопкага басарсыз. Ипи урынына, капкач ачылып китәр дә, урындыгың-ниең белән космоска мәтәлерсең. Йөр аннары, аяк-кулыңны бутап-акырып. Син, ярый инде, ничек кешегә охшап тугансыңдыр, шул флотта чарлаганнардыр инде. Югыйсә, сарык көтүчесеннән артык җирең дә юк кебек. Сөен, кеше иттем мин сине! Ха-ха-ха!..

Андый чакларда Шәйхаттар кызып бәхәскә ташланмакчы була да, тынып кала, чөнки белә, тарих дәреслеген кат-кат укыган кеше — татарлар, чыннан да, монгол нәселеннән, башкача булуы да мөмкин түгелдер, дип уйлый. Китапларда шулай язылган. Йөз-кыяфәтләре белән ул халыкка охшамаганнар охшавын... Галимнәр белмичә язмаслар инде. Хатыны аны ачуланып та ташлый. Кайвакыт:

— Сез, татарлар, безнең Смоленскины җир белән тигезләгәнсез. Сез — явыз халык. Минем сезнең якларга кайтасым, шул кыргыйларны

күрәсем дә килми! Сезнең бабаларыгыз варварлар булган. Хәзер генә кеше чутыннан сөйләшәсез. Ярый, Иван Грозный оягызны туздырып, сезгә бераз иман керткән. Югыйсә, һаман кеше талап, урысларны җәберләп гомер итәсе идегез!

Бәхәскә шушы урында нокта куела...

...Шәйхаттар аһылдап көрсенеп куя. Тәнс авыртуга түгел, җаны сызлауга түзә алмый ул. Гөлҗиһан чәй ясап, абыйсының күгәргән иреннәренә чәйле чынаяк китерә. Абыйсы йотлыгып хуш исле чәй эчә, күз карашы белән генә изге күңелле сеңлесенә рәхмәт әйтә.

— Бүген Гыйльметдин киләм диде. Мунча яктым. «Пешкән каен себеркесе белән кәҗә маен чыгарам әле, яшьтигә файдасы тимәсме»,— ди. Узганында файдасын күргән кебек булган иде бит. Атна чамасы телең ачылып, сөйләшеп, үз кулың белән ипи тотып ашадың.

Гыйльметдин исемен ишетүгә Шәххаттарның йөзендә елмаю пәйда булды. Авылга кайтканнан бирле, аның янына әледән-әле кергәләп торучы, хәлләрен белеп кирәк-яракларын табарга тырышып йөрүче бердәнбер кеше — яшьлек дусты Гыйльметдин иде.

Суык февраль көнендә Шәйхаттар соңгы сулышын алды. Үләсе төнне ул сызланмады да, сыкранмады да. Израэп йоклагандай яттыятты да, таң аткач уянып китте һәм соңгы сулышын алганчы урындык аркасына сөяп куелган ике фотосурәткә текәлеп хәрәкәтсез тик ятты. Үлгәч тә аның ярым ачык күзләре һаман улы белән кызын багалар кебек иде...

...Абыйсы Шәйхаттар Күперледән бик еракта чакта, фотосурәтләре буенча гына таныш татар канлы урыс балалары үстереп яткан вакытта, Гөлҗиһан болай ук үзен ятим, таянычсыз сизми иде әле. Юк дисәң дә, таянырдай кешесе, абыйсы барлыгын һәрдаим тоеп яшәде ул. Әкренләп Әхнәф тә аякка басты, Шамил дә үсеп, тәпи йөгереп китәр, абыйсы да хатынын, балаларын ияртеп кайтып төшәр кебек иде... Танышырлар, дуслашырлар, моннан соң инде гел аралашып, бер-берсенә ярдәмләшеп яшәрләр сыман иде. Инде шушы бердәнбер терәге — имән агачыдай мәһабәт гәүдәле, килешле буй-сынлы абыйсы кышкы көндә шаулап ауды, суык гүргә кереп ятты. Аны, васыяте буенча, үзе кебек үк яшь-яшь килеш үлеп киткән газиз әнкәсе янына җирләделәр...

## VII

Еллар үткән саен, Гөлҗиһан үзендә гаҗәп үзгәрешләр сизгән кебек.

Иң сәере шул — ул яшәү дигән серле нәрсәнең асылына төшенмәкче булып баш ватарга һәвәсләнеп китте. Уйлап карасаң, кызык бит... Кеше бу якты дөньяга ни өчен туа икән? Нигә дип яши? Яшәүнең асылы нәрсәдә? Берәүләр туганнан бирле тормышның хәсрәтле, борчу төягән йөген тарта, шуңа да шөкер итеп, барлы-юклы шатлыкларына, табышларына сөенеп яши. Икенчеләренең гомер арбалары теркелдәп кенә бара. Барсы да җитеш, җаның ни тели, шуны ал... Әмма өйләрендә кот юк, ызгыш-талаш.

Карап тора да Гөлҗиһан, янә исе китә. Элек болай түгел сыман иде бит. Ә хәзер... Кешеләр арасындагы дуслык дигән бөек хисне генә алып кара. Кая ул әчкерсез, бер-береңә өчен утка керердәй дуслык! Барсы да исәп-хисапка корылган бит. Бүген син кирәк — син миңа дус. Иртәгә кирәгең юк икән — синең биргән сәламеңне дә алырга атлыгып тормый кичәге җан ахирәтең. Борылып та карамый хәтта. Дан-дәрәҗә өчен иң якын кешеләрен дә саталар. Һи-и, кешене сату гына нәрсә ул! Әнә Әүхәтнең малае райком тирәсендә бер-ике ел чуалган иде, хәзер Казанга алдылар. Кара машина белән генә кайтып йөри...

Гөлҗиһан тагын очсыз-кырыйсыз уйларына чума.

Нәрсәгә дип тудырды икән аны әнкәсе?.. Тугач, ярый, «Кыз туды, абыйсы Шәйхаттарга сеңел, иптәш булыр!» — дип сөенгәннәрдер инде. Ә аннан соң? Ни күрде бу тормышта Гөлҗиһан?.. Балалык еллары булмады да сыман. Авыр сугыш еллары каплап китте уйнар-көлер чакларын. Ул да түгел, ачлыктан шешенер дәрәҗәгә җиткән көннәрдә дөньяда иң кадерлесе — әнкәе үлеп китте. Шәйхаттар абыйсына мең рәхмәт, сеңлесен ач үлем тырнагына бирмәс өчен җан-фәрман казганды, мең әмәлен тапты, әмма әҗәлне өйләрен урап китәргә мәҗбүр итте. Үсмер еллары менә шул гарасатта үтеп тә китте.

Аннан, әтиләре сугыштан кайтып, әчкә бераз җан, күңелләренә аз гына сөенеч иңгән мәлләр. Әтисенең балаларда артык кайгысы булмады булуын. Кайтуының икенче көнендә колхоз дилбегәсен үз кулына алды. Көн-төн колхоз дип чапты, белеме юк, кычкыру-җикерү өлге булган заманда якын-тирәдә сирәк күренеш — кешеләр белән уртак тел тапты, шул тынгысызлыгы, эш булсын дип тырышуларын авылдашлары күреп, аңлап аңа ярдәм итәргә омтылдылар. Башка авылларда ярты колхозчыны төрмәгә җибәреп, корсак киереп йөргән рәисләрдән аермалы буларак, Мөлековның беркемгә дә зыян-зәүмәте тимәде. Дуамаллыгын хисапламаганда, авылдашларын артык рәнҗетерлек хилафлык кылмагандыр ул.

Әтисенең дә гомере кыска булды шул. Кабаланды, чапты, вакытсыз гүр иясе дә булды. Инде килеп, Гөлҗиһан ни-нәрсә күрде үсеп җиткәч?.. Бер рәхәт тә күрмәде бит шушы гомер эчендә...

Нәрсә өчен мондый михнәтләр аңа? Аның кемгә зыяны тигәне бар? Әхнәфнең, Шамилнең ни гаепләре бар? Якты дөньяга килгәннән бирле кайгы да хәсрәт, сагыш... Берсе малай чактан бирле гариплектән кимсенеп яши. Ә аны шундый хәлгә төшерүчеләр типтереп яши бирәләр. Ике ятып бер төшләренә дә керми торгандыр Әхнәф кичергән газаплар. Шамил исә үзенең чын әнисе барлыгын да белми үсә. Дәү әнисенә «әнием» дип дәшә, шуңа чын күңелдән ышана.

Ул бәхет дигәннәре нишләп Гөлҗиһан тирәсен читләтеп үтә икән соң? Кайда йөри ул?! Ярый, Гөлҗиһан шундый язмышка дучар булды ди, ә менә башкалар үзләрен бәхетлегә саныйлар микән?

Ул Әүхәтне әйт... Көн-таң атса, култык астына балтасын кыстырып, якын-тирә авылларга чыгып китә. Караңгы төшкәч кенә сөйрәлеп кайтып җитә. Адымнары авыр. Үзе бөкерәеп беткән булыр, очраган кешеләргә күтәрелеп карамас, исәнлек бирсәләр, нәрсәдер мыгырданганы ишетелә — исәнлек алганы шулдыр инде, бирмәсәләр үзе эндәшмәс. Йөзенең ачылган чагын күрмәссең. Иңсәләре төртеп чыккан. Җунле кием кимәгәненә биш былтыр. Авызында тәмәке пыскыр. Сакал-мыек баскан чырае көлү-шатлану галәмәтләрен дә онытып бетергәндер инде. Өенә кайта да, мал-туар арасына чыгып китә. Олы малае кара машиналарда сабан туена кайта, Әүхәт ат җигеп урманга утын әзерләргә китеп бара. Сабан туе көнне утын хәстәрләп йөрүче бердәнбер кеше ул. Әхнәф аттан егылып төшкәннән соң, аның сабантуйга аяк басканы юк... Хатыны, бала-чагасы, барсы да аннан акча даулый, акча таптыра. Әүхәт шул дулкында яши, ашый, йоклый...

Фәймә үзен бәхетле хис итә микән? Үз гомерендә кешегә яхшылыгы тидеме аның? Ә бит көн саен авыл советына күпме кеше керә. Һәркайсының нindiдер йомышы бар, шуны тиз генә йомышлыйсы, күп сүзгә җитми генә үз юлы белән китеп барасы киләдер дә... Фәймә янына кергәч кычкырышмый, талашмый, күңеленне рәнҗетерлек сүзләр ишетмичә чыгам димә инде. Кыз чагында алай түгел иде бит соң. Нәрсә булды аңа, нигә һәр нәрсәдән җәнҗал гына эзли ул?.. Әгәр авыл кешеләренең Фәймәгә җыелган бар рәнҗеше берьюлы төшәсе булса, Коры елганың элекке ташу төшкән чагы сыман булыр иде ул. Фәймә йомычка урынына агып китәр иде рәнҗеш ташуында. Төшми бит менә, һаман шул эшендә, авылдашларының күз яшьләрен җыя килә. Шуннан рәхәт тә таба бугай әле, җитмәсә.

Инде килеп, типтереп яши дигән Куян Сәйфиен ал, Гөлзадәсен, Сәкинә белән Гыйльметдинне ал — бу дөньяда кайсы үзен бәхетле итеп тоя икән, ә?.. Барсы да бәхеткә омтыла, ымсындыргыч бәхет ишекләре якында гына кебек тә — кулың белән сузылып җибәр дә, рәхәтләнеп кереп утыр — юк шул, күзгә күренә, буй җитми... Берсе бер нәрсәдән мәхрүм, икенчеләре бөтенләй башка нәрсә хакында уйлап җан ата... Һәркайсы дөнья куа, арба күчәрләре һич уйламаган җирдә орылыша, китә үзара ызгыш, бер-берсенә пычрак ату... Көнчелек, яла ягышу... Яшәү шулай булырга тиеш микәнни соң, җә?... Авыл буйлап йөреп чык, кемгә керму — борчу, сагыш, күз яше. Картлар яшьләреннән зарлана, яшьләре өлкәннәрне куралмый. Олыны — олы, кечене кече итү юк. Гаеп эзләү, тырнак астыннан кер табарга маташу — һәркайда шул... Бертуләр балабыз булмады дип көннәр буе салкын түшәгенә яшь коя, картаер чакларын уйлап, кемнәр кулына калырбыз дип ут йотып чыгалар. Ә балалары булганнар кайгы-хәсрәтсезме? Үстерәләр, укыталар. Тегеләре исә үз көннәрен үзләре күтәрлек булгач, картаеп килүче ата-аналарын ташлыйлар да калаларга чыгып сызалар. Авылныкылар китә, алар башкарасы эшләрне чит-яттан җыелган килмешәкләр эшли. Колхоз рәисе дисеңме, экономист, хисапчы, мәктәп директоры — авылда нинди белгеч бар — барысы да читтән килгән кеше. Хәтта урта мәктәпне бетереп клуб мөдире, китапханә мөдирләре булып эшләүче яшь-яшь кызлар да башка яклардан килеп эшләүчеләр. Авыл белән килмешәкләр идарә итә. Ә үз авыл кешесе белем алып кайтса, нинди хәлгә төшә? Аларның иң үзәкләренә үткәне теге килмешәкләр түгел, ә үз авылдашлары бит. Нәрсә әйтсәләр, хәтта киңәш белән авылдашлары, яшьтәш иптәшләре янына килсәләр дә, аларга килмешәкләргә булган чаклы кадер-хөрмәт тә юк бит. Бичаралар, берәр ел шулай авылдашларының мыскыл итүләренә тешләрен кысып булса да түзәләр дә, кесәләренә дипломнарын тыгып, башка якка сәфәр чыгып китәләр.

Бәйрәм вакытларында авыл урамнары шаулап ала да янә тынып кала. Бүгенге яшьләр Гөлҗиһаннар чорындагы сыман кичке эңгер төшүгә клубка ашкынмыйлар инде. Берләнбер гармунчы Гыйльметдиннең бармак араларыннан нинди көй түгелер дип, зар булып та җилкенеп утырмыйлар. Һәркайсының кулында магнитофон. Колакларына әллә нинди әйберләр кияләр дә шул тартма уйнаган көйгә чайкалышып тик торалар. Гармун уйнаучыдан көлеп кенә карыйлар хәзер...

* * *

Урамда мәктәптән кайтучы бала-чаганың чыр-чу килгән тавышлары ишетелеп алды. Ул арада җил капкадан Шамилнең килеп керүен күреп алды ул.

Әмма Шамилнең кайтып керүе бүген бөтенләй башкача булып чыкты. Бик күңелсез керде өйгә. Башка көннәрдәге кебек тизрәк өстәл тирәсенә дә сырышмады. Теләмичә генә чишенде, эндәшмичә генә түрдәге урындыкка барып утырды. Гөлҗиһанның күңеленә әллә нинди шикле уйлар йөгерде. Йөрәге гасабиланып тибә башлады. Шамилнең әле укый башлаганчы болай сөмсере коелып кайтып кергәне юк иде. Нәрсәгә дә булса кәефе китсә, гадәттә, мышык-мышык килгән булып уенчыклары белән уйнап азапланган була иде. Күз яшен күрсәтмәс әмма. Бүген исә үз-үзен тотышы бөтенләй үзгә иде малайның. Гөлҗиһан иңнәрен салындырып утырган Шамилгә карап алды да, сабырлыгын җуеп:

— Нәрсә булды, улым. Балтаңны суга төшереп җибәрдеңме әллә? — дип сорады. Үзе сүзне шаяртуга борырга теләгәндәй, йомшак кына көлеп куйды. Йә әйт инде, үскән егет мышкылдап утырырмыни!

Шушы сорауны көткән кебек, Шамил үтә җитди карашын әнисенә төбәде.

— Кешенең... ике әнисе... булмый бит...— диде ул, һәр сүзен өзеп.

Көтелмәгән сүзләр түгел иде бу Гөлҗиһан өчен... Көтә иде ул сүзләрне, кайчан да булса ишетәсен тоеп яшәде. Тик менә хәзер, уйламаганда дигәндәй. Зиһене чуалуын сиздермәскә тырышкандай, әкрен генә әйтеп куйды.

— Ике әни?.. Ике әни булмый шул, улым...

— Ә нишләп минем ике әни булган?

Шамил зур булып ачылган зәңгәр күзләрен Гөлҗиһанга төбәде. Ул күңелен кузгаткан шушы котсыз сорауга җавап көтә иде.

Гөлҗиһанның бәгыре өзелеп төште. Шулай була икән ул... Кайчан да булса бер дөресен сөйләп бирергә туры килә икән бит... Итәк астында яшереп саклый торган сер түгел. Ул үзен кулга алырга тырышты. Малайга артык аптырап, каушап калуны сиздерү кирәкми, дип уйлады ул. Ниндидер гаеп эш өстендә тотылгандай кыланып, Шамилнең күңелен тагын да ныграк җәрәхәтләү генә була түгелме соң? Башына килгән беренче фикер шул булды: «Бу хакта нәрсә белә? Аңа моны кем әйткән?..»

— Кем әйтте, улым, алай дип.— Күпме тыныч булып күренергә тырышса да, Гөлҗиһан үзенең маңгаена тир бәреп чыкканын сизде. Иреннәре тартышып, калтырана башлады. Үзе Шамилнең җавабын ишетми калмыйм дигәндәй, урындыгын малай янына ук күчерде, Шамилнең аркасыннан кочып алды.

Шамил инде бу сүзләрен нигә әйткәненә үкенә башлаган сыман тоелды. Ул бер читкәрәк тартыла төшеп, башын аска иде.

— Сәкинә апа әйтте...— диде ул кашын җыерып.

— Аңлатып сөйлә, нәрсә диде соң ул?

Шамилнең күзеннән яшь атылып чыкты да алсу бите буйлап түбән тәгәрәде.

— «Әбиең ни эшли? Сине яратамы?» дип сорады,— диде малай еламсырый төшеп.— «Минем әбием юк бит»,— дидем мин. Ә ул көлде. «Гөлҗиһан синең әбиең булмый кем булсын инде,— диде. Бөтен малайлар да ишетеп торды. Ә ул һаман кычкырып көлә, кулларын бутый шунда. «Үзеңнең әниеңнең исеме Әфүзә була. Әле һаман әйтмәгәннәр икән әле, әстәгем»,— дип бот чапкан була. «Хәбәре юкмы, хаты килмиме?» — дип тә сорады.

Малай тын калды. Гөлҗиһан әйтер сүз тапмый иде әлегә.

Өстәл өстендә җиз самавыр гөжләп утыра. Һәм аның шулай гамьсез көйләп утыруы сару кайната, күңелгә тия иде.

— Әйе, улым, кешенең ике әнисе булмый,— диде ул уйларының очын күрергә теләп һәм әкрен генә сүз башлады.— Тик синең дә әниең берәү генә бит.

— Син генә бит әйеме, әнием?..— диде малай Гөлҗиһанга елышып.

Шамилне кайнар кочагына алды да Гөлҗиһан мөмкин кадәр баланың күңелен җәрәхәтләмәскә тырышып, үзе өчен үтә дә кыен нәрсәләр хакында сөйли башлады. Булдыра алганча, малайга чын дөресен әйтергә, аңлатырга тырышып карарга кирәк дигән фикергә килгән иде ул. Бу сер барыбер чыгачак, әчкәрәк яшергән саен, яман шеш сыман ямьсезрәк төс алачак иде. Әнисенең сүзләрен тыңлаганнан соң, Шамил олыгаеп киткән кебек тоелды. Ул инде Гөлҗиһанның иреннәре арасыннан чыккан ачы сүзләрне тыңламый да шикелле, торган саен үз уйларына кереп чума бара, Гөлҗиһанның күкрәгенә башын куйган да, сулыш алырга да кыенсынган кебек тавыш-тынсыз гына утыра бирә иде.

Ахырдан, Шамилнең тыңлаусыз чәчләрен сыйпап, Гөлҗиһан сүзен йомгаклады:

— Менә, шулай, улым... Теләсәң, мине әбием дип йөр. Син хәзер зур үстең инде. Мәктәп укучысы... Барсын да аңлыйсың, әйеме?

Шамил Гөлҗиһанның күкрәгенә капланды.

— Син минем әнием.— Малай күтәрелеп Гөлҗиһанга карады. Кечкенә йодрыгы белән күзләрен сөртеп, Гөлҗиһанны кочаклап алды. —

Әни бирәү генә була ул, әйеме, әнием! Минем дә әнием берәү генә — син генә!..

Малай белән аны багып үстергән ана шулай бер-берсенә сыенып озак утырдылар...

Адәм баласына, үзен бәхетле итеп сизү өчен, күп тә кирәкми шул. Таш пулатлар да, машиналар да, кесә тулы акча булуы да им түгел. Менә шулай улың белән зурларча сөйләшеп, җанына басып торган ташны алып ташлый алсаң да, бәхетле итеп тоясың икән үзеңне. Кешегә, иң беренче, җан тынычлыгы кирәк шул... Янә шушы сабыйның «әнием» дип йөгереп кочаклап алуы бәхет түгелмени! Аны исән-сау үстерә алуыма авылда кем генә ышанды икән? Сөенерсең дә шул. Үсеп тә җитте. Инде киләчәк турында уйлый башлады. Әнә нәрсә ди бит: «Әнием, үскәч Сәйфи абыйларныкы кебек зу-ур итеп өй салырбыз, яме,— дип хыяллана ул.— Әүхәт абыйларныкы кебек ишек алдына кое да бораулarбыз... Сиңа Тауасты чишмәсенә барулары бик кыен бит, әнием. Гел тәнем сызлый дисең». Мондый сүзләрен тыңлап утырган мизгелләр күңелгә күпме рәхәтлек бирә! Бала хыялы кайларга йөгермәс, шуны аңлаган хәлдә д Гөлҗиһан үзләрен зур өйле, ишек алдында коелы итеп күрә башлый...

— Тауасты чишмәсенең суы тәмле бит аның, тәнгә сихәтле.

— Булса да, кое кирәк инде,— ди малай сүзен бирергә теләмичә.

Гөлҗиһан җиңел генә урыныннан кузгалып, шактый бушаган сәгать чылбырын шаулатып тартып куйды. Ул үзенә җиңеллек тоя, очасы, өй тутырып әйләнәсе килә иде.

## VIII

— Әнием, нигә әшәке кешеләр була икән, ә?

Шамил җавап көтмәстән, ипи кыерчыгын мул итеп тешләп алды да, чөйгә үрелде. Ул бүген әтисенә көтү көтәргә булышырга чыккан иде. Менә атка атланып әбәт алырга кайткан. Гөлҗиһан ашыга-кабалана Әхнәфкә ашарга хәстәрләнеп йөри иде. Кызыксынуын яшерә алмыйча малайга төбәлде.

— Каян уйлап чыгардың? Әшәке кешеләр кемнәр соң алар синеңчә?

— Кичә Гыйльметдин абый мине тракторга утыртып турларына кадәр алып барган иде. Минем кабинада утыруымны күреп алгач, Сәкинә апа Гыйльметдин абыйга әллә нәрсәләр кычкырды. Котырган кеше кебек кыланды.

— Котырган кешене күргәнең бармыни?

— Булмаса да инде.— Малай тартынып куйды.— Кычкыра бит Гыйльметдин абыйга теләсә нәрсә. «Баһау тәре, һаман шул Гөлҗиһанның уйнаштан туган малаен миннән дә артык күрәсең»,— ди. Малайшалай кебек, Сәкинә апа тракторга утырып йөрмәс инде, әйеме, әнием? Мине кабинадан җилтерәтеп кенә төшерде. Әллә тагын мин гаеп эш эшләгән. Гыйльметдин абый үзе туктап утыртты бит.

— Кичәгене бүген сөйлиләрмени инде?

— Әй, кичә онытылган...

— Аның ишенең онытылуы әйбәт, улым. Гыйльметдин абыең нәрсә диде соң?

— Мине җитәкләп олы юлга чыгарды да, үзе эндәшми кереп китте. Сәкинә апа кычкырып калды шунда... Юаш ул, Гыйльметдин абый, әйеме?

— Акыллы кеше юкка-барга кычкырып, көн ямьсезләп йөрми, улым...

Шамил белән сүзгә мавыгып, өйгә чит кеше килеп керүен дә сизми калганнар икән. Кинәт ишетелгән:

— Өегезне күтәреп китсәләр дә, сизмисез икән. Сөйләшүләре сөйләшү!— дигән сүзләрдән икесе дә сискәнеп, сәерсенеп, ишек ягына карап

катып калдылар. Ишек төбендә бөркү һавадан тирләгән-янган ят хатын-кыз тора иде. Шамил, бу кем була инде? дигәндәй сораулы карашын әнисенә төбәде. Әнисенең үзеннән дә битәр аптырап, хәтта ачылган авызын да ябарга онытып торуын күргәч, гаҗәпләнүе тагын артты.

— Әфүзә...— диде Гөлҗиһан куркынган, шомлы тавыш белән.

— Әйе, мин булам,— диде хатын ясалма елмаеп.— Ә бу үскән жегет Шамил инде... Әхнәфкә охшап үсә икән.— Хатын, әйтүне көтеп тормастан, түргә узды, лапылдап урындыкка килеп утырды. Күпне күргән иске урындык сыкрап, сукранып алды.— Йә, исәнме! — дип житү тырнаклы кулын Шамилгә сузды Әфүзә. Малайга «улым» дип тә эндәшмәкче булган иде, ахрысы, нигәдер бу сүз аның иреннәре арасында буталып, югалып калды.— Нигә сөзеп карап торасың?— Ул Гөлҗиһанга күтәрелеп көлгәндәй итте.— Үзенә күрә түгел бу, усал булмакчы. Әллә дөньяда әниеңнең барын белми идеңме, бик аптырап калдың? Мин инде бу, синең әниең! — диде ул карлыккан тавыш белән.

Һәр хәрәкәтеннән тупаслык, ясалмалык бөркелеп торган бу хатынга чирканып карап тора иде Шамил. Хатынның үзенә сузылган кулларын читкә этәреп, ашыгып Гөлҗиһанга барып сыенды ул. Үтерсәләр дә, авызыннан аракы исе аңкып торган хатынны «әни» дип атый алмаячак иде ул. Көтелмәгән кырыс, усал тавыш белән:

— Син минем әни түгел! — дип кычкырды ул.— Минем үз әнием бар! — Малай Гөлҗиһанны чытырдатып кочып алды. Гөлҗиһан баштагы югалып калудан арынып килә иде инде. Баласын давылдан саклаган бөркет-кош шикелле, Шамилне кочагына алды:

— Каян килеп чыктың, җирбит? — диде ул ярсый төшеп.— Инде монда эзең суынганга да биш былтыр бит. Тагын кайларда, кемнәрнең башын әйләндереп йөрдең? Балага ягыласы булма! Йөрәге күкрәгеннән ватып чыгардай тибә баланың. Котын алдың, хәшәрәт...

Әфүзә аның сүзләрен колак турыннан гына үткәреп җибәрде. Үзен мондый сүзләр белән генә өркетеп булмасын сиздереп, урындык аркасына ята төште.

— Чәй эчәргә дә кыстау юк диген, ә! Йә ярый, анысы вак мәсьәлә. Баланы алып китәргә кайттым,— диде гадәти нәрсә хакында сөйләшкәндәй.— Күрәм, сез аны миңа — үз әнисенә каршы котыртып бетергәнсез икән.— Ул Шамилгә табан иелде.— Минем белән китәсеңме, улым? Шәһәргә... Шәһәр малае буласың килмимени? Монда нәрсә, һаман да шул җиргә сеңгән өй, сыер, сарык тизәге. Өй салып керсәләр, бәлки уйлап та карарга иде исәп. Мужет гел шушында калыр идем,— диде ул үтә житди итеп.— Тормалы түгел өегез. Калмыйм, малайны да монда күгәртеп яткырмыйм.

— Һи-и, адәм тәганәсе, страм, нәрсә сөйли бит,— диде Гөлҗиһан үчектергәндәй көлемсерәп.— Синең безгә кергәнең бар дисеңме? Әле бала кирәк булдымы?! — дип җикерде ул. Мондый җегәр, көч каян килгәндер шушы минутта бу әрсез хатынга ташланырга, аны ботарлап ташларга да әзер иде ул. Аның эчендә нәфрәт ташкыны кузгалган иде. Гөлҗиһандагы тыелгысыз ярсуны күреп, Әфүзә еламсыраган булып кылана башлады.

— Нигә миңа әллә нинди ямьсез сүзләр әйтәсең, әнкәй. Җитмәсә, бала алдында. Сезне сагынып кайттым. Беркатлы дип уйламагыз, кайтышлый ук авыл советына кереп чыктым, мине әле ана хокукыннан мәхрүм иткән кеше юк. Бала нәрсә белә ул. Кем нәрсә сөйләсә — шул дөрес. Миңа каршы котыртып бетергәнсез, күренеп тора. Бүрегә караган кебек карап тора бит. Мин ул хәтле нәрсә эшләгән? Үз балам, синнән бирәсеңме-юкмы дип сорап тормыйм...— диде ул кабат тимер салкынлыгы чыккан тавышын күтәрә төшеп.— Менә Шамил үзе әйтсен — минем белән шәһәрдә яшисе киләме аның, юкмы?! Анда автобуста гына йөрисе, мороженое атлаган саен. Көтү көтеп йөрисе дә юк, җәй буе су буенда кызынып ятасың. Рәхәтләнеп яшибез без анда, чын әйтәм сиңа.— Үз сүзләреннән үзе үк кызыгып, авызыннан селәгәе бүселеп чыкты хатынның.— Бик күңелле шул анда... Шәһәрдә дим...

— Юк! — дип кисте малай куркудан калтыранган тавыш белән.— Минем әнием, әтием бар. Син минем әни түгел. Син...— малай нинди сүз әйтергә белми туктап торды да,— әшәке апа син!— дип, Гөлҗиһанга тагын да ныграк сыенып, туктап калды. Аның бу хатынга башка әйтер сүзе юк иде.

— Бу кадәр дә кире беткән, үҗәт булыр икән,— дип шаккаткан булды Әфүзә.— Гел кирегә сукалый бит.

— Бала кирәк булса, үзбәктә калдырган малайларыңны алып кайт,— диде Гөлҗиһан ачу белән.— Миңа димәгәе, әллә кайларга бар, әмма сиңа дигән бала бездә юк,— диде ул катгый рәвештә.— Үземнең улым, үземнең алтын бөртегем! — диде ул горурлык белән.

— Ха-ха-ха... Берәүкәйләрнең улы бар икән! — дип, Әфүзә буынсыз булып, көлүен дәвам итте.— Ха-ха-ха... Соң син аның кем малае икәнен дә белмисең бит, мескен. «Үземнең улым», ди бит. Егылып үләрсең. Кем малае икәнен беләсең киләме? — дип күзен чепиләндерде ул Гөлҗиһанга.— Бик беләсең килсә, пар казаны өстендә яткан кара мыектан сорап калыргае аны! Ха-ха-ха...— Сүзнең нәрсә турында барганын Шамил аңламый иде. Әфүзә өйне сасытып кычкырып көлә башлау белән, Гөлҗиһанның кочагыннан ычкынды да тышка атылды ул. Гөлҗиһанның башына күсәк белән китереп орган сыман булды.

— Җитте сиңа,— дип ачыргаланып кычкырып җибәрде ул.— Хәзер үк өйдән чыгып кит! Югыйсә...

— Йә-йә, нәрсә эшләтмәкче буласың мине? — диде Әфүзә мыскыллы елмаеп һәм урыныннан кузгалды.— Мине бернәрсә дә эшләтә алмыйсың, түтекәем. Артыңны кыс та тик кенә тор, яме. Әле бу турыда үзең генә беләсең, кирәк булса, бөтен авылыгызны сасытам.

— Нинди шакшы хатын син,— дип чарасыздан кире урынына сеңде Гөлҗиһан.— Шамилнең Әхнәфкә охшаганын үзең дә әйттең бит. Тач әтисе. Нигә өстеңә тагын бер гөнаһ аласың?

— Бала-чаганы кемгә ошатсаң — шуңа ошый ул, юк өчен баш ватма,— диде Әфүзә, ниһаять, бу алышта өскә чыкканлыгын сизеп.— Кем малае икәнен чуртым белсен аны, баш әйләнгән чак иде. Мин әйттем дә оныттым. Бу нәрсә мине борчымый...— Ул хәйләкәр көлемсерәп, Гөлҗиһанга карап алды. Тегесенең чыкмаган җаны гына калуын күреп, кызуы сүрелгәнче төп мәсьәләгә күчте.— Тәк... өй салырга җыенасыз икән. Авыл советында әйттеләр. Мин китәм, малай да кирәкми, үзегезне дә күрәсем килеп тормый. Миңа акча кирәк, шунсыз китеп булмый.— Аның күзләре ут яна, иреннәре зәңгәрләнеп кысылган иде.

— Ак-ча?..— диде Гөлҗиһан гаҗәпләнә төшеп. Ул Әфүзәнең тел төбен аңлап бетерми иде әле.— Нинди акча ул? Калдырган акчаң бар идемени?

— Аңламаган булып кыланмасана! Мин сезгә бушлай бала калдырып китәр дип уйлыйсызмы?! Мин сезгә аны... хе-хе-хе... Сатам, теләсәгез... Риза булмасагыз, үзегезгә үпкәләгез... Акча бир, шуның белән вәссәлам... Мин китәм, бала сезнеке. Киресенчә булса — җелегегезгә үтәчәкмен!

Гөлҗиһан башы чатнап авыртура түзә алмыйча ыңгырашып куйды.

— Безнең нинди акча булсын. Үзем үстергән баланы ничек сатып алырга тиеш ди әле мин. Акылга сыя торган эш түгел...— дип сызланды ул. Аннан бераз исенә килгәндәй Әфүзәгә туры карап сорау бирде.— Күпме акча кирәк сиңа, җирбит?

— Күпме, дип... Чутлашып тормыйм инде, күпме акча бар — шуны бир дә, мин киттем,— диде ул һавалы итеп.— Кибет ябылганчы өлгерергә кирәк, баш авыртып тора. Чаллыдан утырып килгән идем. Урманда кундык, башкорт ягына машина куалар. Аракысы җитәр-җитмәс кенә булды мыкырның. Ә теге үзбәк малайлары өчен Халисәнең кирәген бирәм әле,— диде ул сүгенеп.— Телен тыймаса...

Гөлҗиһан калтыранган куллары белән шкаф тартмасын ачты. Аркасында Әфүзәнең сулышын сизеп, кабалана башлады. Иске калай чәй тартмасыннан акчалар алып, хатынга сузды.

— Мә, күргәнең-күрмәгәнең шул булсын.

— Хәерчеләнгән булма инде,— диде Әфүзә кулына акча кергә сөенеп, шул ук вакытта азсынган да сыман. Әмма яңадан да сүз куертып торуда исәбе юк иде аның. Акчаларын кесәсенә салып куйды да, эндәшеп тормый-нитми ашыгып чыгып китте. Ул баскыч такталарын дөбердәтеп узды, җил капканың шапылдап ябылганы ишетелде. Өй эче кинәт киңәеп киткәндәй булды. Гөлҗиһан Әфүзәнең кереп чыгуын төшендә генә күргәндәй саташулы халәттә тора иде әле.

* * *

Гөлҗиһан баш түбәсенең кызышуына түзә алмый, өйгә борылды. Күз аллары караңгылана башлавын сизеп, белгән догаларын эченнән укый-укый, киереп ачып ташланган өйалды ишеген шапылдатып япты да өйгә үтте. Гаҗәп, кояш төшмәсен дип пәрдәләрне тартып куйганга сүрән тоелган өй эче кинәт яктырып, нурга коенган сыман күренде аңа. Түрдә, өстәл янында, кайчандыр таныш булып та инде хәтереннән җуела башлаган бер карчыкның утыруын күреп, бусага янында тукталып калды ул. Кипкән иреннәре арасыннан «Исәнме, әбекәй» дигән ике сүз саркып чыкты.

Гөлҗиһанны күргәч, карчык кулындагы җиләк тәлгәшләрен кире өстәлгә куйды. Шамил биргән тәлгәшне Гөлҗиһан үзе өстәл өстендә калдырган иде. «Тәки авыз итәргә өлгергән юк бит әле!»

Карчык урыныннан кузгалып, Гөлҗиһанга табан атлады.

— Бик исән әле, кызым. Менә, юл төшеп сезнең якка килеп чыккач, күрми китмәем дип, кагылып чыгарга уйладым.

Гөлҗиһан үзенә сузылган, тамырлары беленеп торган кулларны учларына кысты. Карчыкның коргаксыган куллары салкынча иде. Әмма күзләреннән, йөзеннән нур чәчеп торган кебек. Өй эчен тутырган, бөтен тәнгә җиңеллек, изрәткеч рәхәтлек бирүче яктылык та шушы арык кына гәүдәле әбидән таралган сыман. Карчык кире үз урынына барып утырды.

— Быел җиләк уңган икән. Тәмлекәйлекләре! — диде ул бер күзен кыса төшеп, мәзәк кенә йөзен дә сыткандай итте. Җиләкнең әчкелтем тәме тешләрен камаштыра иде булса кирәк.

Гөлҗиһанның зиһене ачылып китте. Әллә кайчан, әле сугыш вакытында ук аларга килеп кергән, ятим сабыйларны юатып, төне буе аларның ертык киемнәрен рәткә китереп, ямап азапланган изге күңелле саилче карчык түгелме соң бу? Әле ул бер җыр да җырлаган иде. Ул җыр һич хәтердән китми.

Ак балыклар уйный, ай, иркендә,
Агыйдел суының төбендә...

Аннан соң күпме сулар акты, җилләр исте. Ул чакта хәлсез, ябык тәнле кечкенә бер кызчык иде. Гөлҗиһанның хәзер үзенең дә чәчләренә чал керде. Ә изге күңелле карчык һаман да шул төсен ташламаган. Әллә соң бу... әллә соң бу карчык Үлмәсбикә әби микән?.. Үз гомерендә Гөлҗиһан аны берничә мәртәбә күреп алгандай итте, һаман бер үк йөз чалымнары, хәтта киеме дә үзгәрмәгән бугай.

Карчык, Гөлҗиһанның уйларын сизгән шикелле, көлеп куйды:

— Мин һич тә истән чыгармыйм сезне. Юлым төшсә, күрмичә дә китә алмыйм үзегезне... Өй салырга җыенасыз икән. Бәрәкалла, бәрәкалла. Бик зур эш тора алдыгызда, Аллаһы Тәгалә рәхим-шәфкатеннән ташламасын. Улың да, сөбханалла, тәки аякка басып, рәтләнеп килә

икән. Теге чакта, мин әйтәм... һич тә кеше булырга охшамаган иде. Һай, авыр иде бит хәлләре. Сәламәтләнергә боерган булса, ир-ат халкы бер ныгып китсә, җир җимертеп йөри башлый ул. Сихәте югалса гына кызганыч ирләр.

— Чәй яңартып алырга кирәк,— дип, Гөлҗиһан самавырга үрелде.

Карчык Гөлҗиһанга каршы төшәргә ашыкты:

— Кирәкми, кызым. Мәшәкатьләнмә самавыр дип... Мин озаклап утырырга кермәдем. Әле генә чәй яныннан кузгалдым...

Гөлҗиһан чын-чынлап аптырап калды.

— Кайда эчтең чәйне, әбекәй?

Карчык көлемсерәп кенә куйды. Ул инде кузгала башлаган иде. Көтмәгәндә карчык Гөлҗиһанны ачуланып ташлады:

— Әй, кызым, кызым... Бик бетеренгәнсең ләбаса син. Гел уй да уй икән башыңда. Уй кешене бетерә ул, кызым. Адәм баласын тәмам эштән чыгара. Бераз гына үзең турында да онытма. Син бик яшь бит әле. Һич тә якты дөньядан китәсе килми бит. Үзеңне кара әле көзгедән?— дип, ул Гөлҗиһанны көзге каршына китереп бастырды. Көзгедән аңа йөзе сулып агарган, чәчләре тузгыган шактый кыяфәтсез бер шәүлә карап тора иде. Күзләр суырылып эчкә баткан сыман. Һәм... үзе белән янәшә басып торган карчык юк иде көзгедә... Фәкать Гөлҗиһанның шыксыз кыяфәте генә сөрәеп тора.

— Танымыйсыңмы үзеңне?— диде карчык, Гөлҗиһанны үчекләгәндәй.— Болай ярамый, кызым. Син бит кемнеңдер күңел түрендә йөрисең, кемгәдер яшәргә канат бирәсең. Ә үзең... нинди хәлгә төшкәнсең.

Бу кадәр йөрәккә үтеп керердәй ягымлы тавыш бетәшкән карчыкның кай җиреннән чыга икән, дип уйлап алды Гөлҗиһан.

— Әйбәтләп киен, кызым,— диде карчык. Ул, зур сер сөйләгәндәй, пышылдый ук башлады:— Яңа күлмәкләреңне ки, оегыңны да сал, башкасын ки,— дип, салам чүпләре ияргән иске оекбашына ымлады карчык.— Чәчләреңне дә җыеп куй. Кискән ишек бит, кем килеп кермәс, дисең. Синең пөхтәлекне, ыспайлыгыңны, чибәрлегеңне күреп «аһ» итсеннәр,— диде карчык кеткелдәп. Йөзендә бая сүрелә башлаган нур янә «гөлт» итеп кабынып китте аның. Гөлҗиһан, ихтыярсыздан, җан-фәрман карчык әйткәннәрне үтәргә кереште. Күз ачып йомганчы киемнәрен алыштырды, чәчләрен тарап, ике чатка үреп куйды.

Карчык ишек төбендәрәк эндәшми-тынмый Гөлҗиһанның киемнәрен алыштыруын, төзәтенүен-ясануын күзәтеп торды. Эш беткәч, сак кына хатынны кабат көзге каршына китереп бастырды. Гөлҗиһан үз күзләренә үзе ышанмады. Инде көзгедән яшь, чая чактагы кыяфәте балкый иде. Хәтта арганлык билгеләре күренми. Аны ул тоя гына, әмма йөзгә чыкмаган.

Карчык, күңеле булып, хатынның аркасыннан сөеп алды.

— Менә шулай, кызым. Гел сөйкемле, матур булып йөр. Ә хәзер ял ит инде, миңа да китәргә вакыт...— Карчык сүзләрен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, нindидер көчле куллар Гөлҗиһанны карават өстендәге мендәргә китереп салдылар. Кемдер моңлы көй көйләп, аны тирбәтә башлады. Ул тирән йокыга талды...

* * *

Сак кына ишекне ачып кергән Әфүзә битенә кисәк килеп бәрелгән кайнар җилдән чак кычкырып җибәрмәде. Бермәлгә аны курку биләп алды. Әмма инде өй эченә кереп җитеп килә, кире борыласы итмәде, ясалма күтәренкелек белән сөйләнеп, эчкә үтте.

— Бер йомышым калган бит, әнкәй. Тагын керергә туры килде бит. Ачуланма инде, яме...— Хатын букчасыннан Гөлҗиһанның зәңгәр пла-

щын тартып чыгарды.— Теге вакытта киеп киткән идем... Кире кайтарып бирәм... менә...

Ул башын күтәреп карады. Һәм... өйдәге тәртипсезлекне күреп исе китте. Идән уртасында Гөлҗиһанның салып ташлаган киемнәре чәчелеп ята, ә үзе өр-яңа киемнәр киеп, яхшылап җыештырылган караватөстенә менеп яткан. Күзләре йомык, йоклый, ахрысы. Сулу алуы да сизелми.

Әфүзә сак кына атлап Гөлҗиһан яткан караватянына килде. Тереме-юкмы — белмәссең. Плащны аяк очына куйды. Гөлҗиһанның күкрәк тирәләре җиңелчә тибрәнеп алды.

Моңарчы ирексездән кысылып торган тынын шаулатып тышка чыгарды Әфүзә. Куркуы да артка чигә төште. Аннары, нидер исенә килгәндәй, мәче житезлеге белән шкаф янына килеп басты. Янә карават ягына күз салды, шылт иткән тавыш та юк иде. Тимер божрасыннан тартып, шкафның пыялаланган ишеген ачып җибәрде.•«Шыг-ырт...»

Сискәнеп янә караватка карады. Инде ике күзен дә Гөлҗиһаннан алмый иде ул. Сыңар кулы елан кебек шкаф эченә кереп китте, тимер савыт артына яшеренгән зур гына төргәкне эләктереп алды да ялт кына букчасына шудырды.

Нәкъ шул вакытта өй турысында трактор тавышы ишетеп, ул егылып китә язды. Таныш, бик таныш иде аңа бу җай гына гөрләп торган трактор тавышы. Ул, идәнгә чүгә төшеп, тракторның өй турысыннан келтерәп үтеп китүен көтеп тора башлады. Трактор үч иткән шикелле үрмәләп килде-килде дә, өй турысына житкәч кенә туктап калды. Аның дырылдаган көенә өй эчендәге бар нәрсә сизелер-сизелмәс кенә биегән кебек иде. Менә тракторның ишеге шапылдап ачылды, кемдер лапылдап жиргә сикереп төште. Нәрсәдер эшләп азапланды кебек. Монда кереп маташа түгелме соң? Әфүзә кыргый җанвар шикелле өйалдына сикерде, инде аяк тавышлары баскыч тирәсендә үк ишетелә иде. Әфүзә каерып ачылган өй ишеге артына кереп посты. Йөзенә тузанлы пәрәвез сыланды, чолан такталары ярыгыннан салкынча һава бөркелә иде. Тычкан сидеге исе килә. Җанны шом басты. Күз ияләшмәгәнгә караңгы иде монда. Ул, бөтен тәнен биләп алган калтырануны басарга теләп, иреннәрен умырып тешләде дә өнсез катып калды...

*1993*
*Чаллы*

# ШИГЪРИЯТ



**Рөстәм Султи**

## Шүрәле

I

«Былтыр кысканга ник быел
Кычкырасың соң?» — димә.—
Ул кысуның авыртуы
Үткәнгә бәгыремә...
Шүрәлесең,— тик көлмә!

Җанымны кысты ул чөнки,
Телемне, ил-көнемне,
Кысты, кысты газизләрдән
Газиз булган денемне.

«Биш йөз былтыр кысканга ник
Кычкырасың?» да димә —
Ул үткәннең авыртуы
Үткәнгә үзәгемә...
Шүрәлекәем, көлмә!

Гафу ит, яшьле күзләрең
Сөртәсең яшерен генә,
Яшәр монда тетрәнмичә
Таш йөрәк ише генә.

II

Урман сарыгының әллә
Каргышы төшкән микән?!

---

Рөстәм СУЛТИ (1969) — *шагыйрь, «Мин — шигырьдән» исемле китап авторы. Бүгенге көндә Төркиядә укуын дәвам итә.*

Афәтләрнең иң ачысы
Сезнең башлардан кичкән.

Әй, кайгы-хәсрәт казаны,
Фаҗигый Казан арты
Шүрәленең күршеләре —
Түбән, Югары-Аты,

Кырлай, Өчиле... башкалар —
Шуңа шөбһәм бар әле,
Сезнең җирдә яши алыр
Иде микән Шүрәле?!

...Янымдагы сабый бала
Искә килде, ниһаять:
— Абый, шүрәле турында
Әкият бу,
әкият...

## Унҗиде яшь тулган көн

Төнге яңгыр,
төнге күкрәү,
төнге яшен,
Тәүге сөю,
тәүге иңрәү,
тәүге яшем,
«Сөймим!» диеп ташлап китте сөйгән кешем,—
Бу — унҗиде тулган чагым, тик унҗиде яшем.

Кара болытларның бәгырен яшен телде,
Әллә яшен койды күкләр, әллә көлде.
Ялгыз көккүкләрдәй ялгыз иде башым,—
Бу — унҗиде тулган чагым, тик унҗиде яшем.

Гомер булмаганча ул төн койды яңгыр,
Гомер булмаганча бәргәләнде бәгырь.
Күпме гомер юрыйсың, әй, яшьнә, яшен,—
Бу — унҗиде тулган чагым, тик
унҗиде яшем.

Ухылдап ауды еракта ялгыз имән,
Ялгыз булу ахыр чиктә үлем икән.
Исәп күпме? Әллә илле, алтмыш яшең?! —
Бу — унҗиде тулган чагым, тик унҗиде яшем.

Төнге яңгыр, төнге күкрәү, төнге яшен,
Тәүге сөю, тәүге иңрәү, тәүге яшем,
«Сөймим!» диеп киткән иде сөйгән кешем,—
Бу — унҗиде тулган чагым, тик унҗиде яшем.

## Өзелгән җыр

Без икәү бер җыр идек шул, әйе,
Мин — сүзләре идем, ә син — көе...

Язмыш ахры җыр ертыгы итте —
Яшәвемнең бөтен көе китте.

Синдә дә ул булмас эзсез генә,
Түзәсеңдер бары сүзсез генә...

Күпме мөмкин яшәү, аһ, бу көе,
Мин сүзләре булсам, син бит — көе!

## Бүре баласы

Шәһри Казан каласы,
Шәһри Казан каласы,
Циркларга китергәннәр
Бүз бүренең баласын...

«Мин — җанварлар патшасы!» дип
Күкрәк каккан арыслан да
Монда божра арасында...

Туп уйныйлар юлбарыслар,
Песи кебек ул барыслар —
Тыңлаучаннар, карусызлар.

Тавыш килә дөп-дөп иткән,
Аю мескен бии икән,
Язмышына башын игән...

Җим чукыйлар бөркет кошлар...
Тик бу хурлыкларга төшмәс
Безнең башлар — бүре башлар.

Бие, сикер, йөгер, имеш.
Тырышлыгың өчен калҗа.
Алкышлар вә һай-һу, көлеш...

Ләгънәт сиңа, салкын дивар,
Бу кадәрле сызлануга
Бәндә түзмәс, бәндә авар...

Рәхмәт сиңа, каты дивар,
Сиңа орам газиз башым,
Таш бәгырен, бәлки, чыдар...

Шәһри Казан каласы,
Циркларда кан эчендә
Бүз бүренең баласы.

## Уйлану

Көндәшем юк,
Сердәшем юк,

Ни яр, ни дус — бер кешем юк.
Бу ят шәһәр,
Өлешемә
Тияр хәләл өлешем юк.

Аһ, бернисез буламы соң?
Буп-буш кына...
Юк, юк, ялгыш,
Монда миңа тигән өлеш —
Сагыш, сагыш, янә сагыш!

Сагын, сагын, янә сагын,
Әмма кемне? Тик кемнәрне?!
Әллә хыянәт һәм мәкер
Тулы булган ул көннәрне...

«Буп-буш кына буламы соң? —
Димә, күңел:
Ялгыш, ялгыш!»
Анда миңа тигән өлеш —
Каргыш, каргыш,
янә каргыш!

## Җиде ятларга

Газизләрем минем, җиде ятлар,
Кан елаткан чакта кандашларым,
Сез булдыгыз җаннар аткан затлар.

Ул кочаклар, ул кул, ул карашлар
Тансык,
тансык,
йөз, мең кәррә тансык!
Аерыла калсам, бер көн түзмәс
Бу йөрәгем ярсып,
ярсып,
ярсып...

Бәгырьләрем минем, җиде ятлар,
Рәхмәт дию генә язык булыр,
И җанымны сихерләгән затлар.

Ятлар күңелен яулап алу кыен,
Ишетүе, гәрчә, рәхәттер дә,
Насыйп булса икән сезнең кебек
«И газизем!»
сүзен ишетергә.

## Йолдыз

Щәрекъ кызы кебек хәйләкәр ул,
Шәрекъ кызы кебек оялчан.

— Исемең ничек? — диеп сора — кичен
Зөһрә, — дияр
танда ул — Чулпан...

Апалары кебек яшь кызларның
Тәрәзенә чиртә дә кичен
— Чык, егетең килгән, — диеп, үзе
Югала ул кая, ни өчен?

«Өткәң сизәр» диеп иртә таңда
Кызын эзләп чыккан анадай
Юри әрли: — Күрше-күлән күрсә...
Әле дә кермәгәнсең...
Йа ходай!..

Шәрекъ кызы кебек хәйләкәр ул,
Шәрекъ кызы кебек оялчан.
— Исемең ничек? — диеп сора — кичен
— Зөһрә, — дияр,
таңда ул — Чулпан...

## Дастан

Бу дастанга монда — бу туфракта
Язмагандыр мәңге онытылу.
Баксаң, дастандагы Ана бүре
Үзе икән ләса — Анадолу!..

Борын-борын заманнарда диеп
Сөйлисе юк, әле кичә генә
Төрк илләрен дошман берәм-берәм
Аткан иде тарих чүплегенә.

«Анам!» диеп дәште кан елаган
Идел-Урал, Кырым, бар Төркестан...
Һәм шул чакта Тәңре тауларында
Кабатланды иске, изге дастан.

Бу дастанга монда — бу туфракта
Язмагандыр мәңге онытылу.
Чөнки дастандагы Ана бүре
Үзе ләса, үзе Анадолу!

* * *

Дала уртасында ике акбүз,
Безне көтә, гүзәл, безне көтә.
Тояклардан тирә-яклар тетри:
«Ашыгыгыз, яшьлегегез үтә!»

Бер очасы, бер очасы икәү,
Ак болытны сикереп узып кына.
Дисеннәрче, пар яшеннәр яшьни,
Әйтсеннәрче, бак, пар йолдыз яна.

Безгә кадәр шулай булган дөнья
Бездән соң да шулай дәвам итәр...
Дала уртасында ике акбүз
Безне көтә, бәгырь, безне көтә.

* * *

Аллы-гөлле утлар белән бизәп
Куйган чыршы сымак бу дөнья да.
Көннәр-төннәр, язлар-кышлар булып
Кабына да сүнә,
Кабына да...

Төне буе янган йолдыз сүнсә,
Таңда керфек ачар төнбоегы.
«Бер гүзәллек ким» дип әйтеп өлгер —
Гүзәлләкләр чәчә бүтән ягы.

Дөнья шулай мәңге үзгәрештә
Кабына да,
Кабына да сүнә...
Серләр белән тулы чиксезлекне
Без күрмибез,
Без күрмибез генә...



# Иделбикә



## Ашыктырма, гомер

Ашыктырма, гомер. Юллар алда...—
Читен юл үтелми ашыгып...
Таудан аерылдың, мин туганда,
кыяфәтсез соры таш булып:
Хыялдагы сынны таш эченнән
чыгарам дип — сине, күп еллар
Һәр көн, һәр ел чүки чүкеч белән
сине матурлыйм, дип бу куллар.
Сөзәк түгел юлым, ашыктырма,
алда — кырыс таулар үтәсе...
Йөрәгемне генә тик талдырма —
бер күрермен биек түбәсен.
Ашыктырма, якты дөнья төсе
әле сиңа ныклап сеңмәгән.
Яшьлекнең дә дулкыннары — көче
вакытында ташып бетмәгән...
Алгы көнгә әле түлим ясак,
көтмим күктән бәхет төшәсен:
Пигмалиондай, таштан үзем ясап,
киләә — тере сының сөясем...

## Хуш кайттың, туган тел

Хуш кайттың, туган тел!
Хуш кайттың Иделгә:
Иделдә — халкымда
яшәргә мәңгегә.
Туган тел Иделгә
җыр булып тоелыр:
авазыннан илгә,
яңгыр-нур коелыр:
Нурланыр тирмәләр —
күңелләр гөмбәзе.
Җир иңләп, челтерәр
туган тел чишмәсе.
Чишмәләр тавышын
җиде җир үткәрер.
Җанга үз моңнарны

җиде җил күтәрер.
Хуш кайттың, туган тел,
Хуш кайттың Иделгә,
Иделнең — үз булып,
Җанына сеңәргә!
Хуш кайттың — Сембергә!

## Ник тотлыктым

Ник тотлыктым, кая бикләнде җыр?
Һәр мизгеле бәйрәм — яз кая?
Болыт, болыт... җанга тия яңгыр.
Ялгыз күңел сула, моңая.
Мәрт йокысы баскан тын көннәрем,
кош каурые җилпеп уятмый.
Җилләр качып үбә җәй гөлләрен,
күңел кураемны уйнатмый.
Миңа бәхет биргән, көч иңдергән
җил дә качкан... кая ул йөри?
«Капъйот»ланган тормыш ыргагы тик
эләктереп, җанны өстери.
Үз-үземнән сорыйм кабат-кабат:
нишләде җыр? Нигә югалды?!
Ахры, йолдызларым бирә сабак:
«Чиксез бәхет — үзен җуя ул»...

## Кача алсам иде

Нәни чакта ук мин үзгә идем,
Һич яратмый идем юашны...
Чума идем һаман, тотам диеп,
күл төбендә йөзгән Кояшны.
Чаба идем, басам өстенә дип
качкан күләгәмнең артыннан.
Әни көлә иде: «Ялгышкан бит,—
бу кыз — булган малай затыннан».

Мин бүген дә, тузан каккан төсле,
ике кулга тотып Җир шарын,
гамәлдәге барлык кара көчне
кояр идем — кагып тузанын...
Ялгыш теләкләр дә яши инде —
җан ишеген ахры киң ачам.
Нәни чакта качкан күләгәмдәй
Шуннан качсам иде ичмасам...

*Ульяновск (Сембер) шәһәре*



Фатих Ибраһимов

# «ИКЕ ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ ИНКЫЙРАЗ» БУЛЫРМЫ?

## ЯКИ УРЫС-ТАТАР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕНӘ КАРАТА

### Бердәмме син, татар?

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» — атаклы әдибебез Гаяз Исхакый үзенең публицистик әсәрен әнә шулай атаган. Татар-болгарның (автор шулай ди) фаҗигале язмышын йөрәгеннән кичереп һәм тирәнтен борчылып, мәшһүр әдип, гыйлем иясе әлеге хезмәтен 1902 елда иҗат иткән, 1903 елда бастырып чыгарган. (Кара: «К. У.» журналы. 1990. № 1 һәм 2.)

Әсәрдә татар халкының XIX гасыр ахыры, XX гасыр башындагы хәл-әхвәле бәян ителә һәм, әгәр шундый тизлек белән барса, егерме беренче йөзнең ахырында, төгәлрәге 2098 елларда татар милләтенең бетү ихтималы барлыгы фараз кылына. Автор язганча, ул шулай булып чыга да: 2098 елда үткәрелгән сан алуда нибары 3800 татар кешесе калу мәгълүм була.

Гаяз Исхакый әлеге әсәрендә татарның милләт буларак бетүенең (инкыйраз) төп сәбәпләрен саный. Бүгенге көн күзлегеннән караганда ул сәбәпләрнең кайберләре хәзер үзләренең әһәмиятләрен югалткан. Чөнки мәкалә язылганнан соң 100 елга якын үткән вакыт яңа сәбәпләр килеп чыгуга китергән.

Әмма милләтебезнең бетүенә китерүче сәбәпләрнең иң беренчесе һәм иң олысы, Гаяз Исхакый язганча, татарларның үзләре арасында чын дуслык, бердәмлек, татулык булмауда. Әлеге сәбәп әле бүген дә үзенең кире тәэсирен югалтмаган. Башка сәбәпләрдән исә автор түбәндәгеләрне саный:

Беренчесе — дин әһелләренең һәм галим-голәмаларнең кирәкле югарылыкта булмавы, милләтне үстерү җәһәтеннән аларның җитди игътибар күрсәтмәүләре. Икенчесе — мәктәп-мәдрәсәләрнең эшенә әһәмият бирмәү, аларда өйрәнелә торган белемнәрнең тормыш өчен яраксызлыгы. Өченчесе — милләтебездәге хезмәткә яраклы шәхесләрнең фәкыйрьлеге. Дүртенчесе — башлаган чараларны ахырына җиткермәү, башлаганны ташлап яңасына тотыну. Бишенчесе — урыслардан курку, аларның һәммә эшенә шикләнеп карау, урыс кавеме ирешкән гыйлемлекләрне файдаланмау.

Автор милләтнең зәгыйфьләнүенә китерүче сәбәпләрне алга таба да бәян итә. Мәсәлән, аналарны тәрбияләүнең кирәклеге. Чөнки яхшы ананың балалары да яхшы була, ди ул. Минбеләмлек авыруы белән һаваланунын да зарарын тәнкыйть итә һ. б.

Тора-бара милләт арасында нинди дер бер йогышлы яман чир тарала, ди Исхакый. Ул чирдән һәр көнне йөзләгән мөселман кешесе кырыла. Ниһаять, татарлардан Җәгъфәр исемле бер тарихчы гына кала. Ул тарихи китаплар яза,

үткәннәрне өйрәнә. Татарлар яшәгән барлык төбәкләрне йөреп кайта. Бар җирдә җимереклек, тормышның әсәре дә юк. Хатыны Сөембикә белән малае Үтәмешнең дөнья куюларын Җәгъфәр аеруча авыр кичерә. Аннары, аптырап, Казан Кремленә күтәрелә, Сөембикә манарасына якыная. Әмма «бетте» дияргә дә өлгерә алмый, манара авып соңгы татарны да, ягъни Җәгъфәрне дә басып үтерә. Автор язганча, татар-болгар халкының фаҗигале язмышы шулай тәмамлана.

Гаяз Исхакый — татар милләтенең яшәү-яшәмәү проблемасын матбугатта күтәргән беренче автор. Шунлыктан үз дәверенең күренекле шәхесләре әлеге хезмәткә югары бәя бирәләр һәм алга таба башка авторлар да мәсьәләне читләтеп узмыйлар.

Бу көннәргә 100 елдан артык вакыт бар әле. Татар халкын алга таба нинди язмыш көтә? Гаяз Исхакый үз буыны өчен бу язмышны тасвирлаган. Моңа җавап шулай ук безнең буын кешеләренең дә изге бурычы булып тора. Сорау бик күпләрне борчый һәм ул борчырга тиеш тә.

Ләкин татарның милләт булып сакланып калуында, инде әйтелгәнчә, Гаяз Исхакый күтәргән проблемалар урынына яңа, тагын да катлаулырак проблемалар калкып чыкты. Хәзер алдыбызда шул проблемалар турында сөйләшү һәм бәхәсләшү ихтыяҗы туды.

Аларның иң беренчесе һәм иң әһәмиятлесе — татар белән урыс арасындагы мөнәсәбәт. Бу проблема үзе дә шул басып алу нәтиҗәсендә туган проблема! Әгәр колониягә төшмәсәк, әлеге проблема да булмас иде. Чөнки моңа кадәр булган кебек, татарның яшәү-яшәмәвендә безнең чорда да, киләчәктә дә урысларның шаукымы төп рольне алып тора.

Бу җәһәттән шуны әйтү урынлы булыр: һәр халык, барлыкка килгән чорыннан алып, үзенең иминлеге турында туктаусыз кайгырта, яшәве өчен көрәш алып бара. Иминлек дигәннән, теге яки бу халыкның иминлеге, яшәү халәте аның күршеләренең ниндилегенә бик нык бәйле. Безнең әби-бабаларыбызның көнбатыштагы күршеләре — славяннар диикме яки урысларны — күп санлы гына түгел, бәлки гаять мәкерле юлбасар булулары белән дә башкалардан аерылып торганнар. Алдау-йолдау, буш вәгъдәләр бирү аларның канына сеңгән.

Тарихка күз салсаң, иң күңелсезе шунда: безнең ерактагы, борынгы диик, ата-бабаларыбызның, төгәлрәге, власть башында торучы түрәләрнең үз араларында дуслык, татулык, бердәмлек кебек уңай сыйфатларның һич тә җитәрлек булмавын кабатлап әйтергә туры килә. Түрәләрнең һәркайсысы дошманнарының аңа гына ярдәм итәчәгенә өметләнгән. Шуның белән алар үз араларына урыс кенәзләренең үтеп керүенә, эчке эшләренә тыкшынуларына җирлек тудырганнар.

Менә бер мисал: Ибраһим хан вафат булгач, аның ике хатыныннан ике улы калган — Гали Илһам белән Мөхәммәд Әмин. Боларның кайсысын хан ясау турында татар түрәләре арасында низаг чыккан. Шушы уңайдан файдаланып, Мәскәү кенәзе 1487 елның 9 июнендә Казан шәһәрен басып ала һәм Мөхәммәд Әминне хан итеп утырта. Әнә шул вакыттан дияргә була, урыс кенәзләре Казан ханлыгының эчке эшләренә оятсызларча тыкшынуны гадәткә керткәннәр.

Моңа охшаш башбаштаклык уннарча тапкыр, Казан ханлыгының соңгы көннәренә кадәр алып барылган. Мәсәлән, Сөембикәдән соң бушап калган тәхеткә Әстерханнан Ядкәр исемле 19 яшьлек үсмерне чакырганнар. Ләкин Казан өчен барган сугышта ул яралана һәм дошман кулына әсир төшә. Аны Мәскәүгә алып китәләр һәм көчләп чукындыралар. Аңа Семен дип яңа исем кушалар. Бушап калган тәхеткә Касыйм шәһәреннән дүртенче тапкыр хыянәтче Шаһгалине китереп утырталар.

Күршеләрнең мондый тыкшынуларына, «Болгар вә Казан төрекләре» исемле китабында мәшһүр галимебез Ризаэтдин бине Фәхретдин түбәндәгечә бәя биргән: «Бу дөньяда рус кавеме кадәр вәхши вә әхлаксыз, залим вә бәнү бәшәргә (адәм балаларына — Ф. И.) шәфкатьсез бер кавем булмаса кирәк. Боларны тәгъриф итәргә (аңлатырга) телләрнең вә каләмнәрнең көчләре җитәрлек түгел» (237 бит). Ышанам, галимне урыс кавеменә шулкадәр каты бәя бирергә гасырларга сузылган ачы тәҗрибә мәҗбүр иткәндер, күрәсең!

Шуны әйтик, йөз елдан артыграк (1438—1552) яшәү дәверендә Казан дәүләтенең башында беркайчан да, бер тапкыр да хан булып җирле татар кешесе тормаган. Ханнарны читтән — йә Кырымнан, йә Әстерханнан, йә Нугайлардан яки Касыйм ханлыгыннан китереп куя торган булганнар.

Моның сәбәбе түбәндәгечә булса кирәк: беренчедән, әгәр җирле татарны хан итеп куйсаң, аның көтмәгәндә, җәбер-золымга җавап итеп, урысларга каршы борылуы ихтимал. Икенчедән, күренгәнчә, җирле түрәләрнең үзара дуслыгы булмаган. Хәтта алар өч-дүрт төркемгә бүленеп, хан сайлауда үзара низаглашып,

сугышып яшәгәннәр. Өченчедән, олы бәкләр, морзалар арасында көнчелек хөкем сөргән. «Нигә ул хан булырга тиеш? Мин фәләннән кайсы ягым белән ким», янәсе. Шушы жирлектә урыс кенәзләренең күзенә карап торырга, аларның яклавына өмет итәргә мәжбүр булганнар. Мондый бәндәләр турында Һади Атласиның «Сөенбикә» исемле китабында түбәндәге сүзләр бик урынлы: Явыз Иван «Төрле бүләкләр бирмәкче булып, тегеләрне кызыктыра иде. Казан качкыннары Нугай йортында гына булмаенча, андыйлар Мәскәүдә бигрәк тә күп иде. Бунларда Иванны Казан өстенә йөрергә димлиләр, котырталар иде. Анларның һәрберсе «корсак колы» булып, һичберсендә йорт кайгысы (дәүләт кайгысы — Ф. И.) булмаганлыктан, тамак өчен йорт сатуны бер нәрсәгә дә санамыйлар иде» (18 бит).

(Гафу итегез, шушы унай белән түбәндәге очрак исемә төште: мин бер авылны беләм. Бу авылда гомер-гомергә колхоз яки авыл советы рәисен читтән китереп куйдылар. Үз кешесен куйган очракта исә ана озак эшләргә ирек бирмәделәр. Гаебен табып, эшеннән кудылар. Шул авылның бик акыллы, бик тыйнак бер кешесеннән моның сәбәбен сорадым:

— Үз кешеңне куярга ярамый,— дип жавап бирде ул.— Авылда аның атасын да, бабасын да, аларның яхшы ягын да, начар ягын да беләләр. Кай ягы белән ул миннән артык, ни өчен ул миңа баш булырга тиеш әле...)

Менә хикмәт нәрсәдә икән! Моның нигезендә әлеге дә баягы көнчелек ята икән. Көнчелек, һәрхәлдә, бердәмлеккә китермәгән.

## Сөембикәм-гүзәлем

Урысларның шаукымыннан иң нык жәфа чигүче татар кешесе Сөембикә булган дисәк, һич тә ялгыш булмас. Моны без алга таба күребез. Хәзер сүзне шуннан башлыйк.

Казан мәмләкәтендә ханлык итү нәселдән-нәселгә күчмәгән. Бу хәл татар түрәләренә һәм урыс кенәзләренә сатылучы теләсә кемне хан ясарга иксез-чиксез мөмкинлекләр биргән. Сөембикә моның гаделсезлеген аңлап эш иткән. Ул ире Сафа Гәрәй урынына тәхетнең варисы итеп улы Үтәмеш Гәрәйне билгеләтүгә ирешкән!

Сафа Гәрәй үзен сәләтле хәрби, каты куллы житәкче итеп таныткан. Казан капкасы төбенә килеп житкән дошман гаскәрләрен өч-дүрт тапкыр куып жибәрүгә ирешкән. Урысларга каршы берничә тапкыр яу барган. Шунлыктан Үтәмеш Гәрәйнең әтисе урынына хан булып калуына татар морзаларының күпчелеге каршы килмәгән. Әнә шулай Казан мәмләкәтендә ханлык итү нәселдән-нәселгә күчәргә тиеш булган.

Тол калгач, улы Үтәмеш Гәрәй исеменнән хан вазифасын үтәгән Сөембикә иренең сәясәтен дәвам иттергән. Моңа явыз Иванның ачуы бик нык кабарган. Ул Казанны басып алырга, мөселманнарның динен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен юк итәргә, илнең байлыгын таларга, ханбикә белән аның улы Үтәмеш Гәрәйне Мәскәүгә әсир итеп алырга тәреләр үбеп ант иткән.

Халык мәнфәгатен сатучы олы бәкләр, морзалар, урысларга каршы торырга көчебез житмәс, дип тетрәп калганнар. Сөембикәне улы белән икесен Явыз Иван кулына тапшырырга карар кылганнар. Зур корбаннар бәрабәренә күршеләребез белән дуслашырбыз, дип өметләнгән алар. Урыс кенәзе Иван исә, Казан ханлыгын башсыз-житәкчесез калдыргач, аны басып алу ансатрак буласын күз алдында тотып эш иткән.

Урысларның илчесе Петр Серебряный дигән кеше Сөембикәгә Дүртенче Иванның таләбен житкереп:

— Әгәр Мәскәүгә бирелсәң, гаскәрләребез Казан жиреннән китәчәк, сугыш куркынычы бетәчәк,— дигән һәм ышандыру өчен патша исеменнән тәре тотып ант иткән.

Шомлы хәбәр яшен тизлеге белән таралган. Милләте хакына үзен һәм улын корбан итәргә мәжбүр булган Ханбикәне яклап, гади халык күтәрелгән. Кешеләр кулларына пычак, балта, сәнәк, чалгы, күсәк, таш-кирпеч тотып урамнарга ташланган. Кибетләр, китапханәләр ябылган, мәктәп-мәдрәсәләр, мәчетләр бушап калган. Халыкны куып таратырга чыгарылган атлылар өстенә таш, кирпеч яуган, түрәләр, мирзалар, бәкләргә пычрак атканнар.

— Кабахәт жаннар! Ханыбызны саттыгыз! — дигән тавышлар шәһәр урамнарында яңгырап торган.

Сөембикәнең урыс патшасына бирелмәскә мөмкинлеге булган, билгеле. Вә ләкин ул Казанга кул тидермәү, мөэмин-мөселманнарның канын койдырмау

шарты белән үзен-үзе корбан итәргә ризалашкан. Сөембикә, икебез хакына халкым кан коюдан котыла икән, алла савабын бирсен, дип үзен дә, халкын да тынычландырган.

1551 елның 11 августында ханбикә белән тәхет варисы Үтәмеш Гәрәйне Идел буенча Түбән Новгород аша Мәскәүгә алып киткәннәр.

Мәскәүдә татар ханы Үтәмеш Гәрәйне көчләп, куркытып чукындырганнар. 6—7 яшьлек сабыйның мулла кушкан исемен дә алыштырганнар. Александр булырсың, дигәннәр. Әгәр Үтәмеш Гәрәй булып калса, кем белгән, алай-болай җае чыкса, аның Казан тәхетен дәгъвалавы да ихтимал, дигәннәрдер инде. Әмма Үтәмеш Гәрәй дә озак яши алмаган. 19 яшькә җитәр-җитмәс һәлак булган. Аның каберен Мәскәү Кремленең «Архангель» чиркәвендә әле хәзер дә күрергә мөмкин.

Сөембикә көчләү-куркытуларга бирешмәгән. Чукынудан баш тарткан. Ислам диненә тугрылыклы, мөэмин-мөселман булып калган. Ләкин, үкенечкә каршы, аның Мәскәүдәге язмышы төгәл билгеле түгел. Бирәүләр аны, Шаһ Галигә көчләп кияүгә биргәннәр, ләкин иләмсез ямьсез кыяфәтле һәм хыянәтче Шаһ Гали белән килешеп яши алмаган, ачудан Шаһ Гали аның борынын кискән, кайгы-хәсрәттән Касыйм шәһәрендә вакытсыз һәлак булган, дип сөйлиләр. Икенчеләре бу имеш-мимешне шик астына алалар, үзләренчә фараз кылалар. Ни генә булса да аның кайгы-хәсрәтләргә, авыр кичерешләргә түзә алмыйча вакытыннан элек дөнья куюы шик-шөбһә тудырмый.

Халыкта «Татар башын татар ашар» дигән тәгъбир бар. Аның шушы вакыйгалар уңае белән әйтелгән булуы бик тә ихтимал.

Явыз Иванның мәкерле сәясәте нәтиҗәсендә Казан ханлыгы җитәкчесез калган. Дүрт тапкыр тәхеттән сөрелгән Шаһ Гали, сатлыкҗан Булат дигән шәхес һәм башка морзалар, бәкләр, үзләре хан булуга өметләнеп, кара теләкләренә ирешергә тырышканнар. Әмма алар хан да була алмаганнар, үз дәрәҗәләреннән дә мәхрүм калганнар. Явыз Иван берсен дә кызганмаган. Үз башларына үзләре җиткән. Бу игелексез бәндәләр, ит яхшылык, көт явызлык, дигән акыллы сүзләрнең мәгънәсенә бик соңга калып төшенгәннәр шул.

Кем соң ул Сөембикә? Аның чын исеме дә ачыкланмаган. Тарихчы Һади Атласи үзенең китабын «Сөембикә» дип түгел, бәлки «Сөенбикә» дип исемләгән. Ул Сөембикәнең берничә исемен саный: «Сөмбик», «Самбик», «Сөен-бик», «Сөмөек», «Сөенбөк». Халык телендә аны Сөембикә дип йөртү гадәткә керде.

## Казан өчен кырылыш. 1552 һәм аннан соңгы еллар

Урыс патшаларының иң явызы Дүртенче Иван (1531—1584 еллар) мәкерле генә түгел, залимнең дә залиме булган. Моны аның һәр эше, һәр хәрәкәте, һәр адымы раслаган. Шуның өчен урыслар үзләре үк аңа Грозный (залим, явыз, рәхимсез, кансыз) дигән кушамат такканнар. «Бөек» димәгәннәр. Урыс кенәзләреннән беренче булып ул үзенә патша дәрәҗәсе биргән. Казан ханлыгын буйсындыргач, Болгар һәм Казан патшасы дигән исемнәр дә таккан.

Иван Грозный, Үтәмеш Гәрәй белән әнисе Сөембикәне әсир иткәч, Казан тирәсеннән үзенең гаскәрләрен чакырып алгандыр, Ханбикәгә биргән вәгъдәсен үтәгәндер, дип уйларга мөмкин.

Юк шул, үтәмәгән! Үтәмәгән генә түгел, татар халкына карата яңаданяңа залимлекләр эшләвен дәвам иттергән. Вәгъдә биреп, ант эчүгә елдан артык үтәр-үтмәс, Казан янына яңадан-яңа гаскәрләрен җибәргән. Зөя крепосте аша килгән солдатлар (гаҗәп хәл, Иван Грозный Казан ханлыгының уртасына килеп крепость төзегән. Казан ханлыгын юк итүдә Зөянең (Свияжскиның) кире роле гаять зур булган. Казан каласын төрле яктан камап алганнар, хәтта Арча якларына кадәр барып җиткәннәр. Шәһәргә беркемне дә кертмәгәннәр, шәһәрдән беркемне дә чыгармаганнар. Кремль өчен сугыш башланганчы ук үтерү, талау, яндыру аркасында шәһәр урамнарында кан дәрья булып аккан, солдатлар мәетләр өстеннән йөргәннәр. Кремльгә 150 дән артык туптан атып торганнар.

Махсус алып килгән немец һәм итальян инженерлары, сукыр тычкан кебек, Кремль стенасы астына үтеп кереп чокырлар казыганнар һәм шул чокырларга тутырылган дарыларга ут төрткәннәр. Моңа Размоссель дигән немец җитәкчелек иткән дигән хәбәрләр бар.

30 мең чамасы татар сугышчысы саклаган Кремль шартлаганда барлыкка килгән ярыклардан 150 меңнән артыграк урыс солдаты бәреп кергән. Игътибар итегез: 5 урыска 1 татар! Кремль эчендәге кырылышта фронт кебек нәрсәнең булуы мөмкин түгел. Дошман яклар бер-берсен киемнәрен яки коралларын шәйләп кенә сугышканнар. Болай да кечкенә мәйданлы Кремль эче чын мәгънәсендә мәхшәргә әйләнгән.

Безнекеләр иксез-чиксез батырлык күрсәткән. 1552 елгы кырылышта урыс солдатларының «тиңдәшсез батырлыгы» турында ничәмә-ничә еллар буена башыбызны катырып килделәр. Басып алучыларга Казан капкасы төбендә һәйкәл салдылар. Татар сугышчыларының батырлыгы турында сүз әйтүчеләрнең күзләрен ачырмадылар. Хәер, мөмкинлек тугач та кадерле Ватаныбызны саклап шәһит китүчеләргә һәйкәл торгызу турында ничә еллар буена сүз куертудан ары китә алмыйбыз. Моннан да зур гаделсезлекнең булуы мөмкин түгел. Әлеге гаделсезлеккә гасырлар буена түземлеккә күнектерелгән без татарлар гына түзәбездер.

Сугыш сугыш инде ул! Бу кырылышта Дүртенче Иван башкисәрләре дә аз дөмекмәгәндер. 30 меңнән ике мең чамасы исән калган татар сугышчылары, Кремльдән бәреп чыгып, Иван Грозныйны эзләргә ташланган. Әмма, моны сизенгәндәй, Явыз Иван Зөя шәһәренә качып өлгергән.

Сугыш мәйданында шәһит булмый калган каһарманнар Казан артындагы кара урманнарга кереп югалганнар. Алар анда, партизан отрядларына берләшеп, 6—7 ел буена басып алучыларга каршы сугышканнар. Бигрәк тә авыл халкы Иван Грозный гаскәрләренә тынгылык бирмәгән.

Иң көчле сугышлар татар ханлыгын бөтенләй буйсындырып бетергәнче 1552—1557 елларда дәвам иткән. Соңга таба да азатлык өчен сугышлар туктап тормаган.

Куркыныч беткәч, Иван Грозный явыз ният белән, кылырга теләгән барлык теләкләрен җиренә җиткерүне максат итеп куеп, яңадан Казанга килгән һәм инде хәрби булмаганнарны — хатын-кызларны, бала-чагаларны, карт-корыларны, арба үрәчәсеннән биегрәк булган барлык ир затын кырып бетерергә боерган. Алдагы басып алу яуларында каршылык күрсәтү ихтималы булган көчләр юк ителгән. Арба үрәчәсеннән тәбәнәк балалар кайчан үсеп өлгерер әле, янәсе. Үсеп өлгерсәләр, аларны да ата-бабаларының ачы язмышы көткән, билгеле! Боерык тайпылышсыз җиренә җиткерелгән. Җиңүчеләр хатын-кызларны кабахәтләрчә мыскыл иткәннәр, көчләгәннәр, Мәскәү җиренә алып китеп кол ясаганнар. Ислам диненнән яздырырга кушып, христианнарга хатынлыкка биргәннәр. Һәр христианда татар каны ага, дип әйтелгән сүзләрнең нигезендә шушы вакыйгаларның ятуы шиксез. Хәер, моннан соң андый вакыйгалар гадәткә әйләнгән.

Нинди оятсызлык, нинди кабахәтлек, нинди хайванлык, нинди кансызлык бит бу!

Без, гитлерчыларның ерткычлыгын үз күзебез белән күргән хәзерге заман кешеләре, ул ерткычлыклар исебезгә төшсә дерелдәп китәбез. Гитлер үзенең явызлыкларын Иван Грозныйдан өйрәнгән, күрәсең. Әмма йөз мең төрле җәзалау чаралары кулланган фашистларның кешене сусыз кайнар мунчага ябып яки кабыргаларыннан асып куеп үтерүләрен, никтер, хәтерләмим. Явыз Иванның түрәләре мондый җәзаларны безнең әби-бабаларыбызга карата шактый еш куллана торган булганнар!

## Төп максат — татарларны юк итү булган

Берничә гасыр дәвамында Көнчыгыш Европада күршеләр булып көчле ике дәүләт яшәгән. Аның берсе — татар-болгар дәүләте, икенчесе — урыс дәүләте.

Күршеләр арасында төрле хәлләр булып торган. Сугышканнар да, дуслашканнар да. Бик кызык хәл: берсенең шәһәренә икенчесенең (яки киресенчә) яу белән баруы, күршесен талап, халкын үтереп, коллар алып кайтуы ул дәверләрдә шактый еш кабатланып торган. Икенчесе дә җавапсыз калмаган. Шулай гасырлар узган. Тора-бара татарларның таркаулыгы үзен сиздергән. Урыс кенәзләре өстенлек ала башлаган.

Соңга таба Явыз Иван дип танылган кенәз, яшь булуына карамастан, моңардан бик оста файдаланган. Ул Казан ханлыгын басып алуны, әби-бабаларыбызны туктаусыз чукындыруны һәм үтерүне, мәдәниятебезне юкка чыгаруны, байлыкларны талауны, шул юл белән татарны милләт буларак бетерүне урыс дәүләтенең төп бурычы итеп куйган.

Явыз Иваннан соңгы патшалар да аның сәясәтен алып барганнар. Октябрьдән соң да шушы ук сәясәт дәвам итте, татарны бетерүнең тагын да мәкерлерәк методлары вә ысуллары кулланылды. Озак еллар буена алып барылган сәясәт аркасында, чыннан да, татар халкы кимегәннән кими барган. Кайчандыр икесе бер чамада булган ике халыкның бүгенге нисбәте кем файдасына булуы берәүдә дә шик-шөбһә тудырмый.

Явыз Иван боерыгына буйсынып, колонизаторлар башта тереклек ияләрен бөтенләй диярлек кырып бетергәннәр, аннары гасырлар буена тупланган байлыкны тартып алырга керешкәннәр. Казан урынында кара кисәү һәм көл өемнәре генә калган. Мөселманнарның бөтен гыйльми һәм дини китапларын, шул җөмләдән Коръән белән Һәфтиякне дә шәһәр һәм авыллардан олау белән җыеп Мәскәүгә озатканнар һәм ут төртеп яндырганнар.

Идарәче хөкемдарлар мөселманча язылган уч төбе хәтле кәгазьләрне дә юкка чыгарганнар. Әле басып алу сугышлары барганда ук ханлыкның гаҗәп бай китапханәсен юк иткәннәр. Халык исә китапларны мәчет, мәктәп, мәдрәсәләрнең чормаларында яшереп сакларга мәҗбүр булган. Бу әле китапларны кулдан күчереп яза торган чор — типографияләр булмаган. Әнә шул аз санлы, таралырга өлгерми калган китаплар мәчет һәм мәдрәсәләр белән бергә харап ителгәннәр. Колонизаторлар өчен мәчет-мәдрәсәләрне яндыру гадәти күренеш исәпләнгән, алар урынына чиркәүләр салганнар.

Берәү дә котылып калмаган ул заманнарда. Авылларда йөреп крестьян хуҗалыгын талаганнар, йорт-җирләренә, каралты-кураларына ут төрткәннәр, хайваннарын куып алып киткәннәр. Авылны көтмәгәндә колонизаторлар 100—150 кешелек хәрби команда белән әйләндереп ала торган булганнар. Авылдан бер кешене дә чыгармаганнар. Мондый шартларда бик сирәк кешеләр генә котылып кала алган.

Вәхшилек шуңа барып житкән ки, хәтта каберлекләрдәге язулы ташларга да кул салганнар. Шәһри Болгарда булучылар бу кыргыйлыкны әле хәзер дә үз күзләре белән күреп ышана алалар. Болгар шәһәренең үзәгенә салынган Успенский чиркәве нигезендә язулы кабер ташларына карап ничек борчылмыйсың да, эби-бабаларыбызның ачы язмышын һәм кимсетелүен күреп, ничек йөрәгең әрнемәсен?!

Явыз Иван гомер-бакый мөстәкыйль яшәгән татар-болгар дәүләтен Рәсәй составына кушып, аның ханын да, хөкүмәтен дә, байрагы белән гербын да, ниһаять, гимнын да юк иткән. Соңыннан бу җирләр Казан губернасына әйләндерелгән.

Хәзер дә безгә шундый ук куркыныч яный. Россиянең хәзерге хәрәкәттәге конституциясендә урыстан башка милләтләргә ихтирам бөтенләй юк. Бу инде Рәсәйдәге вак милләтләрне санламау дигән сүз. РСФСР дигән тарихи төшенчәне дә хәзер мыскыллап кына әйтәләр.

Казан ханлыгының иң җайлы, иң уңдырышлы җирләренә, зур елгалар, олы юллар буйларына, матур урманнар кырыена күчеп утырган урыс крестьяннары (гомумән, урыслар басып алган җирләренә күчеп утырырга яратканнар) налог түләүдән азат ителгәннәр. Алар түлисе налогны татар игенчеләре түләгән. Мондый гаделсезлек татар авылының ярлылануына китергән. Менә ни өчен безнең халыкның башы бөлгенлектән чыкмаган.

Шуны әйтү дә урынлы булыр: чыннан да, әле 1926—1930 елларда, колхозлар оешканга кадәр, авылның хәле бик мөшкел иде. Авыл төрле катлаулардан, ягъни ярлы, урта хәлле, таза тормышлы кулаклардан тора, болардан башка тагын батраклар һәм көнлекчеләр дә була торган иде. Батраклар — атсыз, сыерсыз, йортсыз, кулакларга ялланып, аларда ук торып эшләүчеләр. Көнлекчеләр исә байларда кыска вакытка ялланып, нигездә кышын бурычка алган икмәкне эшләп түләүчеләр иде. Әгәр колхозлар таралып һәр кеше үз көнен үзе күрә башласа, авыл халкын, тора-бара, һичшиксез, шул ук язмыш көтә. Ярлылану бик ансат иде: берәүнең йә аты үлә, йә сыеры югала, йә йорты яна. Яңаларын алырга хәле булмый, урта хәлле кеше менә шулай ярлы була да куя...

## Кара пәрдә ачылганда

Безнең үткәнебез гомер-гомергә калын кара пәрдә артында тотылды. Аны кайберәүләр «яшерелгән тарих» диләр. Бу кара пәрдәне аз гына ачарга да рөхсәт ителмәде. Аның урынына безгә «Татар-монгол игосы»н өйрәттеләр. Үткәннәребезгә әнә шулай күзебезне каплап тоттылар.

Бар икән бит безнең үзебезнең тарихыбыз да! Демократия жилләре исә башлагач, кара пәрдә дә урыныннан кузгалды, ачыла башлады. Сәлам Алишев, Равил Фәхретдинов, Вахит Имамов, Равил Әмирханов, Дамир Исхаков кебек галимнәребез татар халкының басып алучыларга каршы көрәш тарихын бәян итеп күзебезне ача башладылар.

Бу көрәш Казаннан алып көньяк-көнчыгышка таба Әлмәт, Бөгелмә аша Уфа, Оренбур, Җаек елгасы аралыгында, Урал таулары битләрендә һич тә тынып тормаган икән. 15—20 ел узуга ул әле тегендә, әле монда кабынып торган һәм шактый көч белән дөрләп киткән. Явыз Иван иярченнәрен көйдереп-көйдереп алган.

Хәзерге Зәй, Әлмәт, Каратай, Чыршылы, Чирмешән, Ютазы, Баулы, Азнакай, Сарман, Минзәлә, Мөслим, Актаныш тирәләрендә яшәгән якташларыбыз патша хөкүмәтенең җәза отрядларына каршы көрәштә зур корбаннар биргән. Р. Әмирхан белән В. Имамов, бу сугышларны гомумиләштереп, «Татарларның Ватан сугышы» дип атыйлар.

Әлеге көрәшләргә житәкчелек итүчеләрнең кайберләре билгеле дә. Менә алар: Мамыш Бирде, Җансәед, Җан-Гали, Кара-сакал, Батырша, Теләкәй-Сәгыйдь, Алдар-Күчем, Акай-Килмәк, Канкай углы Бәхтияр һ. б. Әйтергә кирәк, бу фамилияләрнең күбесе псевдоним булуы бик ихтимал. Чөнки заман шуны таләп иткән.

Без инде даңлы тарихыбызга керә барабыз. Торган саен яшерелгән тарихыбызны күбрәк белә барабыз.

Алда татар халкының героик үткәнен дөрес һәм гомумиләштереп яктырту бурычы тора. Бу изге һәм игелекле эшне милләтебезнең иң талантлы галимнәре үз кулларына алырга, бәлки, инициатива төркемнәре төзеп, дөреслекне, бары тик дөреслекне генә бәян итеп халкыбызны шатландырырга бурычлылар. Чыннан да, Бөек Болгар дәүләте җимерелгәннән алып (1236 ел) безнең көннәргә кадәр арада булган вакыйгалар турында гомумиләштерелгән хезмәтнең дөнья күрүе зур җиңү булачак.

Фаҗигалар белән тулы 450 ел вакыт узган. Бу дүрт ярым гасыр дигән сүз! Аннан элек гасырлар буе күршеләр булып яшәгән ике халык Иван Грозный юлбашчылыгында бер-берсенә дошман булып әверелгән. Бер якта басып алучылар — колонизаторлар, икенче якта аларның коллары — татарлар! Бер якта дип әйтү дөрес булмас, чөнки басып алу белән бергә үк Казан ханлыгы җирләренә урыслар, җирле халыкны кысрыклап, күчеп утыра башлыйлар. Хәзер аларның саны, әйткәнебезчә, җирле халыклар — татарлар белән бер чамада диярлек!

Ә бит болгар-татарларның күршеләренә ачлык килгәндә икмәк белән ярдәм кулы сузуы да, күрше хакы — тәңре хакы, дип, кунакчыллык күрсәтүләре дә тарихта мәгълүм нәрсә. Боларның барысы да беткән, элеккеге дуслар дошманга әверелгән! Соңыннан татарларны нинди генә кыерсытулар, мыскыл итүләр булмаган!

Татарлар бер генә хокуктан хөкемдарлар белән бертигез файдаланганнар. Ул — солдат хезмәте! Урыс түрәләре алып барган барлык сугышларда, шул җөмләдән Левон сугышында һәм Наполеонга каршы сугышта да татарлар сынатмаганнар.

Телиме-теләмиме, һәр татар гаиләсе Рәсәй империясен саклау һәм яңа сугышлар алып бару өчен солдат бирергә мәҗбүр ителгән. Тегеге яки бу сәбәп белән солдат бирә алмаган гаилә өчен күрше егетен солдатка җибәргәннәр. Мондый гаделсезлек әле хәтта XIX гасыр урталарында да сакланган. Ә аңа кадәр ниндиләре генә булмагандыр... Шиһап Мәрҗани әлеге искиткеч гаделсезлекне үз күзләре белән күргән. «Шуның аркасында,— ди галим «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән хезмәтендә,— Чираттагы кешене кулга алып, качмасын дип богаулап куеп, ун-унбиш көн, хәтта артыграк та каравыл астында тоталар иде. Хәтта безнең заманда да мондый законсызлыклар эшләнә, чираты җиткән кешене, качмасын дип, һичнинди гаебе булмаган икенче берәүнең аягына богаулап куялар. Һәрвакыт ни генә эшләргә туры килсә дә, хәтта йоклаганда да һәм бәдрәфкә чыкканда да икесе бергә булалар. Бу үз күзебез белән күргән хәлләрдән».

## Тарихыбызны кем урлаган?

Шушы ярты меңъ ел вакыт аралыгында безнең бер генә күренекле шәхесебез дә булмады микәнни? Бер генә әдибебез дә, бер генә күренекле җырчыбыз да, бер генә фән эшлеклесе дә, бер генә динчебез дә, бер генә тарихчыбыз да булмады микәнни?!

Гаҗәп хәл. Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы дәверләрендә Кол Гали, Мөхәммәдъяр һ. б., соңыннан Утыз Имәни, Шиһаб Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэтдин бине Фәхретдин, Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Мирсәет Солтангалиев, Нәкый Исәнбәт кебек тиңдәшсез талантларны биргән бөек татар халкы, «олы туганыбыз» кул астына төшкәч, талантсыз бер мәхлукка әйләнгән диярсең! Моңа кем ышаныр икән?

Халкыбызның тарихы да булган, аның эшлеклеләре дә булган, әлбәттә. Моның кайберләрен күреп тә үттек инде. Ләкин шунысы хак — талантларга ачылырга ирек бирмәгәннәр. Талантлары ачылганнарын йә юк иткәннәр, йә аларның иҗат җимешен бетереп ташлаганнар. Чөнки үзенең тарихын белгән халыкның баш иеп тормаячагын колонизаторлар яхшы аңлап эш иткәннәр. Чын тарихыбызны язарга кулына каләм алган тарихчыларны М. Г. Худяков язмышы кебек ачы язмыш көткән[1].

Фикеремне раслар өчен күренекле галимебез Риза Фәхретдиннең түбәндәге сүзләрен китереп үтәсем килә. «Тарихыбыз булмауның, ата-бабаларыбызның, кавем һәм кабиләбезнең хәлләрен һәм гомер сөрүләрен яхшы белмәүнең сәбәбе,— ди галим,— үткәндәге галимнәрнең тик торулары, халкыбызның тарих гыйлеменә бәя бирмәүләре түгел, бәлки бу эшкә мөмкинлек булмау һәм заман тарафыннан ярдәм ителмәүдер». Моннан да төгәл әйтелү мисалын тагын каян аласың!

Әдипләребезнең беркайчан да иҗат итүдән туктап тормауларын күрсәтү өчен кулыбызга «Борынгы татар әдәбияты» исемле җыентыкны алыйк. Авторлар коллективы аны «Борынгы әдәбияттан дәреслек-хрестоматия» дип тәкъдим итә. Ул «VIII—XIII йөзләр», «XIII—XVI йөзләр», «XVI—XVIII йөзләр» әдәбиятлары тарихын эченә ала. Болар инде иң борынгы чор. Болгар чоры, Казан ханлыгы чоры әдәбиятлары дигән сүз. Хрестоматиядә берәр төрле романнан, повестьтан, хикәяләрдән бөтенләй өзекләр юк. Анда нибары өч-дүрт авторның (Мөхәммәдъяр, Мәүлә Колый, Утыз Имәни) иҗаты тасвирлана, шигырьләре китерелә. Китапта иң күпчелек әсәрләр әкиятләр, шигырьләр, легендалар, риваятьләр, бәетләр, мөнәҗәтләр, мәсәлләр, табышмаклар, җырлар. Болар үзләренең характерлары белән нәселдән-нәселгә, телдән-телгә күчеп безнең дәвергә килеп җиткән әсәрләр. Билгеле ки, зур күләмле чәчмә әсәрләрнең телдән-телгә күчеп килүе мөмкин түгел. Андый зур әсәрләрдән кайберләренең безгә исемнәре генә килеп җитүе әнә шул хакта сөйли. Татар халкының язмышын чагылдырган зур әсәрләр, күрәсең, онытылганнар. Димәк, Утыз Имәни белән Шиһап Мәрҗанигә кадәр булган чор безнең өчен кара пәрдә артында калган. Төгәлрәк әйткәндә, хөкемдарлар татар халкының иҗат байлыгын урлаган булып чыга түгелме соң бу?!

Шушы ике галимебез, кара пәрдәне ача төшеп, үткәндәге иҗат байлыгыбызның шактый өлешен яктыртканнар. Алардан соңгы чор азмы-күпме үзенең эзен язма әдәбиятта калдырган. Соңга таба аларның хезмәтен Ризаэтдин бине Фәхретдин һәм башка галимнәр дәвам иттергән.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, Утыз Имәни үзенең әсәрләрендә урта гасырдан яңа гасырга күчү чорын чагылдырса, Шиһаб Мәрҗани исә татарның рухи тормышында революция ясаучы шәхес буларак күз алдына килеп баса.

Шиһаб Мәрҗани XIX гасырның икенче яртысында иҗат итә. «Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар» исемле ике томлы тарихи хезмәтендә Болгар халкының әдәби һәм дини әсәрләренә, шулай ук галим-голямаларына махсус бүлек багышлаган. Боларда ул борынгы татар җирендә зур роль уйнаган махсус шәхесләр турында бай һәм кыйммәтле материал туплаган. Ләкин, әйтергә кирәк, материаллар булмаганлыктан, ул да иң-иң борынгы чорларга кереп җитә алмаган.

Шиһаб Мәрҗани турында сүз барганда бик әһәмиятле бер мәсьәләгә тукталып үтү урынлы булыр. Безнең бабаларыбыз, бабаларыбызның бабалары үзләренең нәсел-нәсәпләрен хөрмәт иткәннәр. Алар җиде бабаларын да белгәннәр.

Ш. Мәрҗани аерым шәҗәрәләрне санаганда җиде баба белән генә дә чикләнеп калмый, аннан артыгракларны да китерә, җиде буынга кадәр әтибабаларыбызның исемен белү элеккеге буыннарда гадәти күренеш булган. Безгә дә олы буыннардан үрнәк алу бик кирәк. Ул өлкәннәрне хөрмәтләү бит! Бу мәсьәлә белән мәктәп-мәдрәсәләрдә шөгыльләнү кирәклеге турында уйланырга вакыт.

---

[1] Михаил Григорьевич Худяков 1894 елда Малмыж шәһәрендә туган. Педагогия институтында хезмәт юлын башлаган. Фәннәр докторы, профессор. «Очерки по истории Казанского ханства» исемле китап язган. 1936 елда атып үтерелгән.

Ш. Мәржани «Мөстәфадел-әхбар»да, инде әйтелгәнчә, мәшһүр шәхесләребез турында бай һәм кыйммәтле мәгълүматлар китерә һәм аларның эшчәнлеген калку итеп күрсәтә. Биредә ул үзләре иҗат иткән яки Көнчыгыш мөселман дөньясыннан тәрҗемә ясалган 170 китапның исемен телгә ала.

Кая киткән менә шушы шәхесләр, аларның эшчәнлеге, кайда ул кешеләр язган китаплар? Китаплар гына түгел, аларның авторлары да безгә килеп житмәгән! Аларны урланган дими ни дисең!

## Бәхетлеме, бәхетсезме яки нәрсә ул милли үзаң?

Милләтләр турында мондый сорау кую беренче карашта урынсыздыр шикелле. Әмма безнең бабаларыбызның дәүләтен тар-мар иткәч, көнбатыштагы күршеләребезне яңа басып алулардан тоткарлап торган көчле буа ерыла. Казан ханлыгыннан көньяктагы, төньяктагы һәм көнчыгыштагы, шулай ук Урта Азиядәге жирләргә кул сузу өчен мөмкинлек ачыла. Чөнки, Казан ханлыгы кебек, Рәсәйгә каршы торырлык икенче бер куәтле дәүләт калмый. Урыслар ничәмә-ничә халыкны, шул исәптән Әстерхан ханлыгы белән Себер ханлыгын да басып алалар, ерак көнчыгышка — Камчатка ярымутравына һәм Сахалинга кадәр барып житәләр.

Кызганычка күрә, буйсындырылган вак милләтләрнең күбесе бүгенге көндә инде үзләренең мөстәкыйльлеген дә, телләрен дә, гореф-гадәтләрен дә, мәдәниятләрен дә, ниһаять, диннәрен дә югалтып бетергәннәр диярлек. Әлеге халыклар үз жирләренә дә үзләре хужа түгел. Бу халыкларны бәхетсез дими ни дисең!

Безнең тәрәлеп тора торган иң якын күршеләребез белән эш ничегрәк булган соң? Башкортлар Казан ханлыгы жиңелгәч тә үз ирекләре белән Рәсәйгә кушылганнар; чуваш, мари, мордва, удмуртларның һәммәсен дә Россиягә буйсындырганнар һәм көчләп чукындырганнар. Чувашлар, төрки халык булуларына карамастан, Казан ханлыгы вакытында Ислам диненә тартылмаганнар. Бу инде татар халкының инсафлыгы, гуманлылыгы турында сөйли. Күрше хаыклар арасында бүгенге көнгә кадәр христианлыкны кабул итмәгән мәжүсиләрнең калуы чукындыру процессының бик жиңел бармавын раслый.

Безнең татар халкына карата бәхетле диеп тә, бәхетсез дип тә әйтергә жирлек бар. Иң беренче без үзебезне мөстәкыйль дәүләт дип игълан иттек. Күпме еллар басып алучылар кул астында изелүенә карамастан, татар милләт буларак сакланып кала алды. Ягъни, нигездә, телебез дә, мәдәниятебез дә, гореф-гадәтләребез дә, ниһаять, динебез дә юкка чыкмады. Моның төп сәбәбе: ислам дине, сөекле телебез, мәктәп-мәдрәсәләребез, кардан ак, сөттән пакь гореф-гадәтләребез — төп таянычыбыз шулар булган. Дөрес, соңгы елларда культурабыз, гореф-гадәтләребез үсешенә зур зыян килгән. Бер генә мисал: безнең халыкта, мәэминмөселманнарда, аракы эчү, тәмәке тарту, сүгенү гадәтләре бөтенләй юк иде. Әлеге гадәтләр безгә урыслардан кергән һәм бездә дә хәзер гомуми күренешкә әйләнгән.

Тагын бер бәхетебез шунда: татар халкы, көчләп чукындырылган керәшеннәрне исәпкә алмаганда, бер генә дин тота — ул ислам дине. Әгәр шулай икән, милләтнең дини жирлектә үз эчендә талаш-ызгышның булу ихтималы юк. Ислам дине белән христиан дине арасында да низаглар өчен сәбәпләр күренми шикелле. Ә бит күп кенә милләтләр, әйтик, грузиннар, литвалылар, тагын кемнәр ике дин тоталар. Безнең күршеләребездән удмуртлар һәм чувашларның, инде әйтелгәнчә, бер өлеше, мәжүсиләр булып калган.

Тагын бәхетебез шунда: безнең югары культурабыз, мәдәниятебез, әдәбиятебез бар. Теләсә кайсы халык алдында мактана алырлык иҗади интеллигенциябез бар. Төп бәхетсезлегебез исә шунда: без икенче милләт кул астына эләккәнбез, гасырлар буена халыклар төрмәсендә яшәргә мәжбүр булганбыз. Үз арабызда бердәмлек булмауны кат-кат әйтергә туры килә. Сугыштан соңгы елларда халкыбыз арасында эчүчелек бик нык таралды. Бу ямьсез күренеш белән ирләр генә түгел, хәтта хатын-кызларның һәм яшьләрнең бер өлеше дә шөгыльләнүе күңелдә тирән рәнжү һәм ризасызлык тудыра.

Без кайсы яктан карагаңда да урыслар шаукымында яшибез. Әйтергә кирәк, урыслар уйлаганча уйлыйбыз, урыслар эшләгәнчә эшлибез. Ул шулай булырга тиеш, дибез. Моның сәбәбе шунда ки, без бик озак еллар буена урыс чолганышында яшибез.

Бер генә минутка күз алдына китерик: әгәр күршеләр кул астына төшмичә, азат булып, мөстәкыйль рәвештә яшәгән булсак, үз көнебезне үзебез көткән булсак, без бүген нинди дәрәҗәдә булыр идек? Безнең икътисадыбыз да, культура-мәдәниятебез дә, фәнебез дә бөтенләй диярлек башка, әйтеп бетергесез югары дәрәҗәдә, телебез исә гаҗәп бай булган булыр иде. Бу — шиксез. Мин уйлыйм һәм ышанам: безнең арабызда иң беренче нәүбәттә, манкортлар булмас иде. Гаяз Исхакый манкортларга үз вакытында бәя биреп, үз милләтеннән үзләре качкан татарлар, дигән.

Манкортлар хәзер урыслар белән аралашкан һәр милләттә дә бар. Ул һәр милләтнең чиренә әйләнде. Ләкин безнең татарларда манкортлар башка милләтләргә караганда күбрәк һәм алар үз милләтләренә караганда урысларга ныграк бирелгән.

Манкортлар күп булуның нигезендә, башка кайбер сәбәпләр белән бергә, катнаш никах ята дияр идем мин. Әгәр урыслар кул астында калмасак, катнаш никах ул дәрәҗәдә үк булмас иде. Югыйсә, элекке СССРда яшәүче төрки халыклар арасында катнаш никах буенча без, татарлар, беренче урында идек бит, ул бүген дә шулай дәвам итә. Урыс егетләре татарның иң чибәр кызларын алырга тырышалар, ә безнең егетләргә марҗа да ярый!

Катнаш никах! Монда эш мәхәббәттә түгел, төп гаеп үзебездә. Тәҗрибә шуны раслый: безнең аерым интеллигенция вәкилләре гомер-гомергә гади халыкка үрнәк күрсәтүчеләр булып килделәр. Октябрьдән соң бигрәк тә. Акланмыйк, тагын әйтәм, эш мәхәббәттә түгел, ул югары сүз аклану өчен генә әйтелә. Татарның үзендә дә Мәйсәрәләр, Галиябанулар, Сәлимәләр, Гөлсемнәр, Хәдичәләр, Асылъярлар аз түгел. Алар Татьяналардан, Марусялардан, Манялардан бер яклары белән дә калышмыйлар. Эш башкада: үзенне урысларга якын кеше итеп, «культуралы» (күрәсезме мин нинди!) итеп, ниһаять, ялган интернационалист итеп танытырга омтылуда.

Бик хөрмәтле бер артистыбыз үзенең олы кызын революциядән соң үк Мәскәүдә яшәүче урыс кешесенә кияүгә биргән. Әнисе, урыс хатыны булса да, кызын татар җанлы итеп тәрбияләргә тырышкан. Ул моңа баштарак ирешкән дә. Әмма... Әмма... Көннәрдән беркөнне хөрмәтле артистыбызның оныгы, мәктәптән бик кызып кайткан да, портфелен карават өстенә ыргытып әнисенә:

— Мин синең татарың булмыйм! Алар русларны үтергәннәр! — дип кычкырган.

Укучылар ул көнне дәрестә «Татар-монгол игосы» дигән теманы өйрәнгәннәр икән! Бу бер генә очрак. Ә Октябрь революциясеннән соң әлеге теманы өйрәнгәннән соң ничә татар баласы урыслашты икән?! Моны бер алла гына беләдер!

Яки менә икенче бер очрак. Бер танышым, ул хәзер инде шактый олы кеше, үсмер чакта ук марҗа кызына өйләнгән булган. Яхшы гына яшәгәннәр. Балалары үсеп җиткән. Марҗа балаларны урыс патриотлары итеп тәрбияләгән. Хәзер танышым:

— Миннән дә бәхетсезрәк берәр кеше бар микән, Фатих дус,— дип зарлана. Бактың исә балалары әтиләрен санламыйлар икән: санламыйлар гына түгел, татар дип көләләр, хәтта мыскыл итәләр икән. Татарча радио тыңлый башласа, тартып өзәләр дә русчасын тоташтыралар икән. Телевизор белән дә шундый ук хәл. Өйдә татарча сөйләшмиләр. «Сирәк булса да кечерәк кенә әсәрләрем газета-журналларда басылып чыга»,— ди танышым.— Аларга да рәт юк. Күрсәтсәм, атып кына бәрәләр»,— ди.

Менә гаиләдә дуслык, татулык булмау нәрсәгә китерә. Яшь чагында күңелле генә булса да олыгая төшкәч, ике милләт арасындагы каршылыклар, гореф-гадәтләр, әйтергә кирәк, диннәрнең төрлелеге үзен ныграк сиздерә бара. Һәм хәзер олы яшькә баручылар арасында аерылышучылар нәкъ менә төрле милләттән никахланышучылар арасында күбрәк дип сөйлиләр.

Шуның белән бергә, катнаш никах — милләтне корытучы сәбәпләрнең берсе. Гаиләдә беренче каршылык беренче бала тугач башлана. Балага исем кушарга кирәкме, кирәк! Ата белән ананың һәр икесе үз милләтенә якын булган исем кушарга тели. Әгәр алай барып чыкмаса (монда әти-әниләре дә зур роль уйный), уртак исемнәр өстенлек ала. Әйтик: Лариса, Регина, Люция, Индус һ. б. Кайбер гаиләләрдә беренче балага урысча исем, икенчесенә татарча исем кушу юлы белән бәхәсне чишәләр. Әмма бу бәхәснең башы гына. Аның дәвамы алда булачак әле.

Һәр милләтнең уңай яклары булган кебек, кимчелекләре дә аз түгел. Татарларда бердәмлек, татулык җитәрлек түгел,/дидек. Шуның өстенә тагын, бездә

көнчелек бик көчле, диләр. Бигрәк тә иҗат әһелләре бу кимчелектән зарланалар. Әзләсәң, башка кимчелекләр дә аз түгелдер. Димәк, агарту-информацияне шул кимчелекләргә каршы юнәлдерү зарури. Аның күптөрле юллары булырга мөмкин. Әйтик, сәхнә аша күрсәтү, фельетоннар, газета-журналларда яктырту, карикатура һ. б., һ. б. Болар, билгеле, милләтебезнең үзаңын үстерергә ярдәм итәчәк.

Соңгы елларда татар халкының үзаңын үстерү юнәлешендә шактый эш алып барыла. Әмма һич тә җитәрлек түгел диясе килә. Милли үзаңның булмавы төрле фаҗигаләргә китерергә мөмкин.

Бер мисал китерергә уйлыйм. Хаклы булмасам, укучылар гафу итсеннәр. Мәсәлән, бөтен илебезгә хаклы рәвештә даны таралган җырчы Ренат Ибраһимов бар. Без аның белән горурлана идек. Менә шул Ренат Ибраһимов үзенең ислам динен, мөселманлыгын ташлап, яна дингә — Баһаулла дигән дингә чыккан. Баһаулла динен тотучыларны бахаистлар дип йөртәләр. Энциклопедиягә керерлеге дә булмаган әлеге дин нәрсәсе белән Ренатны кызыктырган соң? Ренат, Америка ачкан диярсең, зур шатлык белән, бу диннең принцибы «бердәмлек, тигезлек» ди. Менә һәммәсе шул! Ул инде бу динне берничә ел тота икән. Яшь кәләше дә шушы диндә ди. Америкага алар икәүләп шул диннең конгрессына махсус барганнар. Минем Ренатка шундый сорау бирәсем килә: ислам дине тигезлек һәм бердәмлек принципларына каршы киләмени? Килми бит! Нишләмәк кирәк, ашыйсы килгән елан ите ашаган, ди халык. Без хәзер, милләттәшебез дип кенә, динебезгә хыянәт иткән җырчы белән горурлана алабызмы? Минемчә, юк, билгеле!

Әзәрбайҗаннарның Мөслим Могамаевы белән кыргызларның Чыңгыз Айтматовы мөселман динен ташлап, икенче дин кабул итмәде шикелле. Ә безнең Ренат Ибраһимов үз диненә карата хыянәтче булып чыкты.

Мондыйлар тагын да бар. Раифа монастеренда бер татар егетенең монах булырга әзерләнүен әйттеләр. (Монах булу өчен башта әзерлек үтәргә кирәк икән.) Бу кешеләрдә мин милли үзаң бар дип әйтә алмыйм.

Нәрсә соң ул милли үзаң? Милли үзаң, минемчә, үзеңнең татар милләтеңне бөтен тирәнлеге белән тану, аны ярату, яклау, ихтирам итү. Туган телеңне, гореф-гадәтләреңне, ниһаять, динеңне чын-чынлап белү һәм аларны үтәү, милләтеңнең мәнфәгатьләре таләп иткәндә сугышчанлык күрсәтә белү.

Йомгак ясап шуны әйтәсе килә: халкыбыз тагын шуның белән бәхетле: ул гаять уңган, эшлекле, булдыклы, чисталык яратучан, гадел булырга омтылучы, талантлы халык. Шундый авыр чорда да бирешми. Тормышны матур гына алып бара. Монда җитәкчеләрнең булдыклы булуы гына түгел, бәлки халыкның уңган булуы төп урын тота.

## Урыс кешесе татарча өйрәнерме?

Бик матур бер мәҗлестә утырабыз. Унлап кеше булыр. Арабызда урыс кешесе дә бар. Гадәттәгечә, гәпләшү аның телендә бара. Алдан ук әйтеп куйдылар: үзебезчә сөйләшмәү хәерле. Югыйсә, «олы туганыбыз»ның үпкәли торган гадәте бар икән.

Ул ир кеше. Өйләнешүләренә, ягъни аның бик матур татар гаиләсе белән аралашуына, 30 еллап вакыт узган. Ләкин, кызганыч, татарча бер сүз дә өйрәнмәгән. Киресенчә, ул гаиләгә үзе урыс телен тагарга тырыша икән. Балага Кәрим дип исем кушканнар, ә малайны әтисе Кирилл дип йөртә. Гаиләдә, баланы әтисе үзенең туган җиренә алып китеп чукындырып кайтмадымы икән, дип тә шикләнәләр.

Кәрим ике ут арасында. Әтисеннән дә курка. Әнисе-әбисеннән дә уңайсызлана.

Татар гаиләсенә килеп кергән урыс кешесенең хәле шундый.

## Мәкерле сәясәт нәтиҗәсе

Ярты мең ел чамасы без руслар белән бер илдә, бер җирдә аралашып яшибез. Бу уңай белән сөеклебез Тукай да үзенең фикерен белдергән. Романовлар нәселенең 300 еллык юбилеена багышлап язган халык өметләре турындагы шигырендә гаҗәп бер дипломатик нечкәлек һәм осталык белән ике халык арасындагы мөнәсәбәтләрне бәян иткән.

Ике халык сайрашып тормыш кичерсә дә, сугышта юлбарыстан көчле булса да, тынычта аттан артык эшләсә дә, уртак ватанда халкыбызның хакы шактый булса да, татарлар мәңге михнәттә, мәңге рәнҗеп яшәде, ди бөек Тукай.

1552 елдан булган аралыкта ничәмә-ничә буыннар бу фани дөньяга килеп, ничәмә-ничә буыннар бу фани дөньядан киткән. Шушы дәвердә ничә урыс кешесе татарча сөйләшергә өйрәнде икән? Күреп торабыз, аз, бик аз, юк дәрәҗәсендә.

Күршеңнең телен белү, өйрәнү өчен, беренче нәүбәттә, аны олылаганда, үзең белән тиң күргәндә, хөрмәт иткәндә генә мөмкин. Урыс түрәләре татарларны буйсындыруның беренче көннәреннән ук үз халкын татарларга каршы юнәлдергәннәр. Тигезлек турында әйтәсе дә юк, бу хәл бүген дә дәвам итә.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар: тарихтан күренгәнчә, урыслар татар телен белмәгән кебек, элегрәк татарлар да урыс телен өйрәнергә ашкынып тормаганнар. Моңа, бердән, халкыбызның горурлыгы, икенчедән, ислам дине сәбәпче булган. Дин җәһәтеннән караганда христианнарның күп нәрсәләре мөэмин-мөселман әһелләренә гөнаһ саналган. Өченчедән, мәктәп-мәдрәсәләребез туган телебездә укытканнар. Туган телебез булганга милләтебез сакланган.

Безнең кешеләр азапланса азапланган, ләкин сер бирмәгәннәр. Күз алдына китерик: авылда азмы-күпме урыс телендә сукалаучы, озак еллар буена солдатта йөреп кайткан берме, икеме кеше була торган иде. Алар да язу-сызуны танымый иде. Мондый хәлне мин үзем дә күрдем. Берәр кәгазь яздыру ихтыяҗы туса (ә хөкемдарларда татарча язылган кәгазьләр йөрми иде) бөтен волостена бер писарь була торган иде. Шуны эзләп китәләр иде. Шулай да урыс телен өйрәнүгә исләре бик китми иде.

Татарга тылмач кирәкми, дигәннәр борынгылар. Моның Казан ханлыгыннан соң, урыслар кул астына төшкәч, әйтелгән булуы ихтимал, минемчә. Горурлык әйттергән аны. Сездән башка да яши алабыз, янәсе. Соңга таба урыс телен үзләштерә төшкәч, бу тәгъбир хәзерге мәгънәсен алгандыр, бәлки.

Чыннан да, урыс теле борынгы мәктәп-мәдрәсәләрдә гомер бакый укытылмаган. Тик XIX гасырның җитмешенче елларыннан, җәдит мәктәпләре барлыкка килгәч кенә, урыс теле фән буларак азмы-күпме укытыла башлаган. Әмма моңа каршы туктаусыз шау-шу алып барганнар.

1918 елдан хәл үзгәрә төшкән, ул фән буларак баштa өлкән сыйныфларда, соңга таба беренче сыйныфлардан ук укытыла башлый. Тора-бара урыс теле татар телен бөтенләй кысрыклый. Татар мәктәпләрендә барлык фәннәрне дә урысча укытуга күчелә, үз телебез фән буларак кына укытыла. Ахырдан шуңа барып җителә ки, Казан шәһәрендә, әгәр шулай әйтергә яраса, нибары бер татар мәктәбе кала.

Татар мәктәпләрен, аерым алганда туган телебезне кысрыклау, урыслаштыру сәясәте бик нечкәртелгән методлар белән алып барылды. Шуларның берсе — колхоз-совхозларны эреләндерү, кечкенә авылларны бетерү, икенчесе — ата-аналар теләге дигән ялган сәясәт үткәрү; өченчесе — ана теленә сәгатьләр санын елдан-ел киметә бару булды.

Татар авылларындагы колхоз яки совхоз иң күпчелек очракларда урыс авылларындагы колхозга яки совхозга кушылды. Әнә шулай татар мәктәбе урыс телендә укыта торган мәктәпләргә әйләнде. Балаларыбыз үз туган телендә, үз әлифбасы, үз уку китаплары белән укудан, үз ана телендә белем алудан мәхрүм калды. Колхозда яки совхозда җыелышлар, киңәшмәләр, эш кәгазьләре, нәкъ патша вакытындагы кебек, урыс телендә алып барылды. Татар теленең кулланыш мөмкинлеге көннән-көн тарая барды.

Шунысын әйтеп китү урынлы булыр: күпме татар кешесе, урыс телен камил белмәгәнлектән, урысча сөйләшсәм көләрләр дип, үзенең уй-фикерен, тәнкыйтьтәкъдимнәрен әйтә алмый гаҗиз булды. Күп кенә актив шәхесләр пассивлашты. Ата-аналар, минем кебек мескен хәлдә калмасыннар, ичмасам, дип балаларын урыс мәктәбендә укытырга мәҗбүр булдылар.

Әлеге мәкерле сәясәт үзенең тискәре тәэсирен елдан-ел ныграк сиздерә. Җөмһүриятебездә югары уку йортлары күп булуга карамастан, институтларга кабул ителгән татар яшьләренең саны «олы туганнар» белән чагыштырганда нибары 40 процент чамасы гына тәшкил итә. Югары белем алучылар саны ягыннан да без башка милләтләрдән шактый артта калдык.

## Хәер-сәдака исәбенә...

Татарлар патша хөкүмәтенә салым түләп торганнар. Әмма властьлар татар мәктәп-мәдрәсәләрен, гомумән, мәгърифәтен алып бару чыгымнарына, уку-язу әсбапларын бастырып тарату өчен беркайчан да, бер төбәктә дә сукыр бер тиен дә акча бирмәгәннәр. Татар халкы гомер-бакый

финанс ярдәменнән мәхрүм яшәргә мәҗбүр булган. Укыту-мәгърифәт эше бөтенләе белән халкыбызның үз җилкәсенә авыр йөк булып төшкән. Безнең гасырның утызынчы елларына кадәр диярлек (совет власте елларында әле) укучы-шәкертләр көн саен өйләреннән култык астына утын пүләне яки салам көлтәсе кыстырып, кулларына мөгаллимгә хәер бирергә дип, 2-3 тиен акча учлап барганнар, мөгаллимнәрнең бөтен хезмәт хакы әнә шул хәердән торган.

Чагыштырып карыйк: урыс авылларында исә дәүләт салдырган берсеннән-берсе яхшырак мәктәпләр тирә-юньгә ямь биреп торалар иде. Учительләргә шул ук дәүләт менә дигән жалованье түләп килгән.

Озак, бик озак еллар буена безне ышандырып килделәр: янәсе «Олы туганыбыз» безгә, татарларга, өзлексез ярдәм итеп тора, булыша, без булышмасак сезгә, мөэмин-мөселманнарга бик кыен булыр иде, диделәр. Моның өчен без аларга, ягъни урысларга, иксез-чиксез рәхмәтле булырга тиеш идек. Ләкин бу ярдәм дигәннәре сүздә генә булып чыкты. Искә төшерик:

1918 елларга кадәр безнең профессиональ композиторларыбыз яки профессиональ рәссамнарыбыз бар идеме? Филармониябез яки берәр төрле ансамблебез бар идеме? Фән өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләребез бар идеме? Юк иде, әлбәттә. Театр сәнгатебез дә нибары 1906—1907 елларда гына калкып чыккан.

Аралашып яшәүче татар халкына ярдәм итәргә күршеләребезнең мөмкинлеге биниһая зур булган бит! Бөек рәссамнар (Алабуга кешесе) Иван Шишкин, Илья Репин, композиторлар Петр Чайковский, Сергей Рахманинов, бөек жырчы якташыбыз Федор Шаляпин кебек даһилары булган милләт ни өчен күршесенә булышмады икән?

Татар милләтенең Абдулла Кариев, Галиәсгар Камал, Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев, Бакый Урманче кебек талантлы уллары, тырыша-тырыша, театр һәм рәсем сәнгатьләренә, музыкабызга нигез салганнар гына түгел, житди уңышларга әйдәгәннәр.

Шунысы гаҗәп: Л. Толстой, В. Ленин, урысларның шушы мәшһүр шәхесләре, татарлар арасында яшәп тә татар халкы турында, үзләре яшәгән Казан шәһәре турында ләм-мим бер сүз әйтмәгәннәр һәм бер сүз язмаганнар.

В. Климентовскийның «Русские писатели в Татарии» (1974) дигән китабында 28 урыс язучысының безнең җирләрдә яшәве бәян ителә. Аларның күбесе бик теләп татарлар яшәгән илдә алган тәэсирләре белән уртаклашканнар. Максим Горький белән Федор Шаляпин Казан белән горурланганнар. М. Горький татар халкының чисталыгы, пөхтәлеге, эш сөючәнлеге, булдыклылыгы турында рухланып язган. Ленин белән Толстойга татар бармы, татар юкмы — барыбер булган. Икмәген ашап, суын эчеп, изге җирен таптап йөргән шушы бәндәләрнең безнең халыкка булган игътибарсызлыгы гаҗәпкә калдыра. Ә менә Александр Пушкин, болардан аермалы буларак, татарларга карата үзенең сүзен әйткән. Чакырылмаган кунак татардан да яманрак, дигән ул. Халык хәтле халыкка мондый авыр сүз әйтергә ничек теле барды икән аның?!

## Иске яңалык

Татарстан җөмһүриятендә ике телнең, ягъни татар һәм урыс телләренең тигезлеге турында Закон кабул ителде. Туган телебез дә җөмһүриятебездә дәүләт теле дип танылды. Ләкин бу безнең өчен иске яңалык иде.

Ни өчен? Чөнки Татарстан Үзәк Башкарма Комитетының 1921 ел, 25 июнь Декреты белән татар теле республикада урыс теле белән бертигез хокук алган, җирле халык теле дә дәүләт теле дип игълан ителгән иде һәм әлеге Декретны гамәлгә ашыру юнәлешендә шактый гына чаралар да билгеләнгән иде.

Иң беренче нәүбәттә Декрет кына булып калмасын, телебез чын мәгънәсендә тиешле югарылыкка күтәрелсен өчен махсус комиссия төзелә, аның положениесе раслана. Икенчедән, белмәүчеләрне татар теленә өйрәтү өчен дәреслекләр, методик кулланмалар булдыру юнәлешендә зур эшләр башкарыла.

Менә шуларның кайберләре: татар телен белмәгәннәр өчен махсус программалар төзелә, татар булмаган җаваплы работникларның курслары өчен татар теле программасы, урысларга татар телен өйрәтү буенча кулланма һәм дәреслек булдырыла һ. б., һ. б. Болар өстенә, Декретны тормышка ашыруның 5 еллык конкрет планы да төзелә.

Белмәүчеләрне татар теленә өйрәтү өчен дәреслекләр һәм методик кулланмалар иҗат итүдә күренекле педагог, җәмәгать эшлеклесе, профессор Мөхетдин

Корбангалиев зур тырышлык күрсәтә. Хәтта татар телен читтән торып өйрәнүчеләр өчен дә кулланмалар, махсус сүзлекләр чыгарыла.

Җитәкче даирәләр башка милләттәгеләрне татарча сөйләшергә өйрәтүгә житди игътибар биргәннәр. Әлеге мәсьәлә 1927 елда Үзәк Башкарма Комитетының III сессиясенең көн тәртибенә куеп тикшерелгән.

Шулай да зур инициатива белән башланган житди эш көтелгән нәтиҗәне бирми. 1930 елларда урыслаштыру сәясәте көчәйгәннән көчәя бара. Татар интеллигенциясенең бер өлеше юк ителү дә моңа зарар китерә. Милли мәктәпләр, мәдәният учаклары, газета-журналларның шактый өлеше ябыла. Мондый шартларда башка милләт кешеләренә татар телен укыту түгел, 7 миллионлы халыкның туган телен саклап калу зур куркыныч астына куела.

Татар телен урыс теле белән бер дәрәҗәгә күтәрүнең бүгенге максаты — тарихыбызда икенче омтылыш. Икенчесе беренчесеннән шактый кыенрак булачак. Чөнки хәзер үз телен белмәүчеләр саны күбрәк. Шулай ук инициатива да сүнә төште. Икенчедән, үз арабызда манкортлар күбәйде. Алар үз телләрен өйрәнергә башка милләт кешеләренә караганда да ныграк каршы торалар. Өченчедән, теге еллардагыдан бүген башка милләтләрне татар теленә өйрәтү түбәнрәк дәрәҗәдә, шундый әһәмиятле чараны тормышка ашыру, аңа житәкчелек итү, минемчә, бүген юк дәрәҗәсендә. Берәр абруйлы житәкче житәкчелегендә комиссия-фәлән төзеп, аңа шушы эшкә житәкчелекне тапшыру ярашлы булыр иде. Югыйсә, Республика халык мәгарифе министрлыгына гына бу гаять катлаулы эшне жирене житкерү бик авырга киләчәк.

Белмәүчеләрне татар теленә өйрәтү буенча берәр төрле конкрет план яисә программа юклыгы да эчне пошыра. Махсус методик кулланмалар һәм дәреслекләр чыгару юнәлешендә дә активлыкны арттырырга кирәктер.

Наданлыкны бетерү вакытындагы кебек, кешеләрне татарчага өйрәтү өчен курслар һәм түгәрәкләр оештыру турында уйларга вакыт. Хәзер дә элеккеге тәжрибәдән файдалану ул вакыттагы кебек уңай нәтиҗә бирер кебек. Тик түгәрәкләргә йөрүчеләрне туплау ирекле булырга тиештер.

## Ихтыяҗ булганда гына...

Шуңа ирешергә кирәк ки, татар телен белмәүчеләр аның кирәклегенә тәмам төшенсеннәр, татар теле дә урыс теле кебек үк кирәк икән, дигән нәтиҗәгә килсеннәр иде. Кеше үзенә файдалы нәрсә белән генә кызыксына. Әгәр ул аңа кирәкми икән, ихтыяҗы төшми икән, нигә ул аңа көч салсын, вакытын әрәм итсен икән! Менә бер мисал:

Татар телен дәүләт теле итеп кабул иткәч, депутатлар өчен татар теле курслары оештырылган иде. Депутатлар башта татар теле кирәк булыр, дип, бугай, курсларга бик теләп йөргәннәр. Тора-бара, бу телне белмәсәң дә эшләп булуына тәмам төшенгәч, курска йөрүдән акрынлап туктаганнар.

Ни өчен дигәндә, кайбер депутатларның, Югары Совет утырышларын ике телдә дә алып барырга кирәк, дип керткән тәкъдимнәре игътибарсыз калдырылды. Югары Совет рәисе Фәрит иптәш Мөхәммәтшин әлеге тәкъдимне шудырып кына үткәреп жибәрде. Бик матур алып барабыз сессияләрне, диде ул. Анынча, бәлкем, матурдыр, әмма дәүләт теле итеп танылган ике телнең берсен санламау гафу ителерлек нәрсә түгел. Һәрхәлдә, сессияләрнең аерым утырышларын булса да татар телендә алып бару делегатларның жаваплылыгын ниндидер дәрәҗәдә күтәрер иде шикелле. Гомумән, туган телебезнең дәүләт теле буларак функциясен күтәрү житәкче оешмалар алдында даими бурыч булып торганда гына нинди дә булса нәтиҗәгә өмет итәргә мөмкин.

Күптән түгел мин шундый очракка тап булдым. «Манара» исемле кибеттә олырак яшьтәге ике ханым эленеп тора торган пальтоларның үлчәмен һәм буен белергә телиләр. Сатучы яшьрәк кенә урыс егете һич кенә дә боларга аңлатып бирә белми бит. Аңлату өчен миңа тылмачлык итәргә туры килде.

Татарстанда мондый хәлләр көн саен күпме урында кабатланып тора! Мәскәү радиосыннан ике-өч тапкыр хәбәр иттеләр: халык белән шөгыльләнүчеләрнең украинча сөйләшә белү-белмәвен ике тапкыр тикшерәләр дә, икенчесендә дә белмәсә, эшеннән азат итәләр икән. Безгә Украина артыннан житәргә ерак әле. Әгәр хәзерге темп белән барсак, 10 ел түгел, 20-30 ел да аз булыр.

Республикада шундый шөгыльләр бар: ике телне дә белмәгән кешеләр, гомумән, андый урында эшли алачак түгел. Әлеге хезмәтләргә медицина эшчеләре, сәүдә эшчеләре, милиция органнарында эшләүчеләр, почта эшчеләре,

китапханәчеләр һ. б. керә. Шулай булуга карамастан, берәр җирдә халык белән көндәлек эшләүчеләрне берәр курста яки берәр түгәрәктә татар теленә өйрәтүче бармы? Юк әлегә. Ә үзебез урысларны татарча өйрәтергә кирәк дибез. Өйрәтмичә, кем өйрәнсен?

Халык белән сөйләшеп эш итүче һөнәр ияләрен эшкә кабул иткәндә шулай ук ике теллелек мәсьәләсенә җитди игътибар бирергә, эшкә ике телне белүчеләр генә кабул ителә, дип басым ясап әйтү зарури. Андыйларның хезмәтләренә күбрәк түләү турында да уйларга кирәк. Тик шул вакытта гына татар телен белү кирәклеге, аңа ихтыяҗ һәр кеше алдына бөтен кискенлеге белән килеп басачак.

Игътибар итик: көнкүрештә кулланышның кайсы ягын гына алып карасак та, бездә урыс теле өстенлек итә. Югары Совет сессияләрен генә күз алдына китерик. Сөйләргә чыгып баскан һәр депутатның (ике-өчесеннән башкасының) беренче сүзе «Хөрмәтле депутатлар!» Аннары урысча китә. Әгәр киресенчә булса нинди әйбәт булыр иде.

Күп очракта урыс кешесенең гади генә сүзне дә аңламавына исең китеп карап торасың. Ул: «Я по-татарски не знаю»,— дип җавап бирә. Ул моны шундый горурлык белән әйтә ки, аның татарча белмәве белән мактануы сизелеп тора.

Телләр белү кешенең югары культуралы булуын күрсәтә. Кеше монын файдасын да күрә. Урысча белмәгән татар кешесе еш кына уңайсыз хәлгә калган кебек, урыс кешесенә дә татарча белмәүдән кызарырга туры килә. Мәсәлән, «Кырык кәҗә»не ул «Киррик кажа» ди, «Дуслык» дигән сүзне, «Дуслик», «Рәхмәт»не «Рихмет» ди һ. б. Менә шуннан соң бу кешене культуралы диген инде.

Инде нишләргә? Әйтергә кирәк, бу юнәлештә җәмәгать оешмалары тарафыннан кайбер нәрсәләр эшләнә. Мәсәлән, радио һәм телевидение татар теле дәресләре оештырып бик әйбәт инициатива күрсәттеләр. Татарстан китап нәшрияты да үзеннән өлеш кертергә тырыша. «Уроки татарского языка», «Татарча-русча уку-укыту сүзлеге» дигән китаплар әнә шундыйлардан. Кайбер газеталарда да материаллар оештыралар. Трамвай-троллейбус идарәсе дә тукталышларны татарча әйтү буенча кайбер эшләр башкара шикелле. Сирәк булса да кайбер тукталышларны татарча да әйткән тавышларны ишетеп шатланып куясың. Әмма барганда ишетсәң дә, кайтканда бу бәлдерүне инде ишетмисең. Күрәсең, мәшәкатьләнәселәре килми, борып куялар да эшең бетте, вәссәлам. Ә җитәкчеләре тикшереп тормыйлар. Тимер юл вокзалында да нәкъ шундый ук хәл.

Монда әйтелгәннәр белән генә урыс кешеләрен татарчага өйрәтеп булмавы һәркемгә билгеле. Мондый чараларның төрләрен ишәйтәсе, яңаларын эзләп табасы иде.

Газета-журналлар һәм радио-телевидение әлеге теманы игътибар үзәгендә тотсалар, бу өлкәдә туган тәҗрибәне гомумиләштереп, уңай якларны яктыртып барсалар уртак эшкә зур файда китерер иде.

Минемчә, 4—5 кешелек тапкырлар төркеме оештырып җибәргәндә ничек булыр иде икән? Аларга, әйтик, башка милләт кешеләрен татарча сөйләшергә өйрәтү юнәлешендә яңа алымнар эзләп табу бурычы йөкләнә ди (мәсәлән, татар телендә бара торган спектакльләргә, җыелышларга, концертларга чакыру һ. б.). Бу беренче караштa елмаю уятса да тормышта уңай нәтиҗә, гаҗәп әһәмиятле эшебезгә оешканлык төсе бирүе мөмкин.

Тагын шуны әйтәсе килә. Аптекада сатыла торган култык таягы беренче караштa бик куркыныч күренә. Әмма култык таякларына ихтыяҗы төшкән кеше аларны сатып ала һәм җайлылыгына бик тиз төшенә. Татар теле белән дә башта эш шулай тора. Аны белмәгән кеше куркырга да мөмкин. Әмма татар теле бөкәй түгел. Аңардан куркырга урын юк. Теләгән кеше аны шактый тиз өйрәнә ала. Безнең тел башка телләрдән чагыштырмача җиңелрәк.

Нәтиҗә. 30—40 яшьтән өлкәнрәк булган урыс кешесенең татарча сөйләшә белүенә өметләнү үзен-үзе акламас шикелле. Моны мәкаләнең башындагы мисалда да күрдек. Төп ышаныч — яшьләрдә. Хәзер мәктәптә укучы урыс балалары, һичшиксез, мәктәптә безнең телебезне өйрәнеп чыгалар. Башына төшсә, башмакчы буласың, диләр бит. Сөекле Тукаебыз әйткәнчә, урыс белән сайрашып тормыш кичерергә, тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып яшәргә насыйп итсен Аллаһы Тәгалә.

Милләтебездә исем-фамилияләрнең торышы турында газета-журналлардан шактый еш укырга туры килә. Әмма хәл үзгәрми, кимчелекләр дәвам итә. Моның төп сәбәпләреннән берсе татарларның исем-фамилияләренә урысларның шаукымы аеруча көчле булу белән аңлатыла.

Балага исем сайлаганда кайбер ата-аналар гарәпчә исемнәрдән качарга тырышалар, исемнең урысларныкына якын булуын, күбрәк русча яңгыравын күз алдында тоталар. Бездә исем-фамилияләр шулкадәр чуарланган ки, икенче бер андый милләтне мин белмим.

Мәгълүм ки, безнең исемнәребез, нигездә, ислам дине белән бергә гарәплердән һәм фарсылардан килеп кергән. Шул исемнәрдән ата исемнәре һәм фамилияләр ясала. Исемнәр үзебезнең телебез үзенчәлекләренә яраклаштырылган.

Шушы уңай белән безнең татар халкына гына хас булган бер мәсьәләгә тукталып узасы килә. Ислам динен кабул иткән башка халыкларда да гарәп һәм фарсы исем-фамилияләре аз түгел. Шулай да алар моның белән артык мавыкмаганнар. Күп очракта үз исем-фамилияләрен саклап калганнар. Безнең татарларда исә башкачарак. Иң күпчелек урынны гарәпләрдән, фарсылардан кергән фамилияләр алып тора. Хәтта башкортлар да бу мәсьәләдә бездән күпкә калышканнар.

Әмма бездә үзебезнең сүзләрдән ясалган һәм борынгы болгарлардан үк килә торган исем-фамилияләр дә аз түгел. Аларга Биктимеров (Биктимер), Алтынбаев (Алтынбай), Башмаков, Юлдашов (Юлдаш), Исәнбаев (Исәнбай) кебек исем-фамилияләр; Айсылу, Миңсылу, Арыслан, Мулланур, Илнур кебек исемнәр керә. Соңгы елларда Илсөяр, Ирек, Илгиз, Илнур, Иркә, Энҗе, Бәйрәм, Сирин, Урал кебек чын татар сүзләреннән ясалган исемнәрнең дә шактый ишәюен әйтү урынлы булыр.

Алга барган саен хәл катлаулана, кыенлаша бара.

Жданов Мөдәррис Исмәгыйль улы, Беляев Гәрәй Галлям улы, Орлов Сәлим Ибраһим улы, Рябков Айдар Салман улы һ. б. Болар үзләре чын татарлар, урыслар да, керәшеннәр дә түгел. Урыс фамилияләре ерактагы бабалары чукындырылып та соңыннан кире ислам диненә кайтучы кешеләр яки урыс писаре татар фамилиясен бозып язган яки башка сәбәпләр белән урыс фамилияләре тагылучылар булуы мөмкин.

Менә болары тагын да катлаулырак. Аларның күпчелеге катнаш никах нәтиҗәсендә туган балалар булса кирәк. Ниндиләре генә юк аларның! Степан Хәлимович Гайнетдинов дисеңме, Самат Михайлович Сабировмы, Иван Салихович Михайловмы, Гайшә Сидоровна Фәхретдиновамы, Мария Петровна Баһаветдиновамы, Галия Гайсиновна Ивановамы, тагын әллә кемнәр шунда.

Яки менә үзләренең исемнәрен урыслаштырып йөрүчеләр: Федя (Фәрит), Надя (Нажия), Маша (Мәрьям), Оля (Айсылу) һ. б. һ. б. Татарча нинди матур, килешеп тора торган исемнәрен шундый ят исемнәргә бозудан нинди канәгатьләнү алалар икән әлеге яшь җилкенчәкләр! Хурлык, билгеле.

Менә без — беребез малай, икенчебез бабай дигәндәй, кранга су алырга килгәнбез. «Исемең ничек, улым?» — дип сорыйм әлеге малайдан. Җавап кыска: я по-татарски не знаю. Русчалап сорыйм: как тебя зовут? Вовка, ди. Җавап белән канәгатьләнмим. Бик тә татар малаена охшаган. «Как твоя фамилия?» — дим. Кәримов, дип җавап бирә бу. Әнә шул Вовка Кәримовлар белән дөнья тулды инде безнең татарда.

Күптән түгел радиодан яңгырады: Чаллы шәһәрендә, мәсәлән, бер ата белән бер ана улларына «КамАЗ» дигән исем кушканнар. Гаҗәп, машина да «КамАЗ», кеше дә «КамАЗ»!

Октябрь борылышыннан соң татар интеллигенциясе вәкилләре үз балаларына берни аңлатмый торган ясалма исемнәр кушу гадәте шактый зур урын алды: Әнсар, Факус, Юнир, Ардина, Фиал, Раина, Флюзә, Лимус, Термус, Миндел, Флада, Анталчак, Вил, Фәнәил, Самдун, тагын кемнәр шунда. Әлеге исемнәр исем булудан бигрәк, кушаматларны хәтерләтәләр. Бу исемнәр эткә кушсаң да матур булмас иде. Кеше эт түгел ләбаса!

Мин китергән исемнәрне үземнән уйлап тапмадым. Үзебезнең «Ватаным Татарстан» газетасында соңгы ике-өч айда басылып чыккан «Котлыйбыз», «Мактаулы исемнәр» дигән исемлекләрдән алдым.

Исемнәребез белән эш шулай тора. Әмма, кызганыч ки, исемнәребез тарихы өйрәнелмәгән. Гомәр Саттаровның бер-ике мәкаләсеннән башка, бу гаҗәеп әһәмиятле өлкәдә фәнни-тикшеренү эшләре бөтенләй юк. Димәк, бөтен эш үз агымына куелган. Әһәмият бирүче дә, юнәлеш бирүче дә юк.

Фәнни-тикшеренү эшләрен исем-фамилияләребезнең кайдан, ничек килеп чыгуын, мөселман исем-фамилияләренә ни өчен һәм кайчан күчүебезне, бу өлкәдә башка халыклардан ни өчен аерылып торуыбызны, исем-фамилияләребезнең шулай чуарлану сәбәпләрен ачыклау юнәлешендә алып бару максатка ярашлы булачак.

Юнәлеш дигәннән, газета-журнал редакцияләре бу мөһим эшне оештыруны, исемнәр кушуда дөрес юнәлеш бирүне үз өсләренә алырга бурычлы, минемчә. Икенчедән, нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар булуын ата-аналарга аңлату-төшендерү Тууны теркәү органнары хезмәткәрләре өстенә төшә. Өченчедән, милләтебездә исем-фамилияләрнең чуарлануында, загс хезмәткәрләре һәм табиблар белән рәттән, укытучыларның да җаваплылыгы зур булуын басым ясап әйтергә туры килә. Чөнки ата-аналарга иң якын торган, иң эрудицияле шәхесләр алар бит! Балага кушарга матур-матур исемнәр тәкъдим итү алар вазифасына керә.

Балага исем кушу бик җаваплы эш. Бу хакта шактый еш язуның сәбәбе менә шунда. Чөнки исем гомерлеккә кушыла. Ул бер кешене икенчесеннән аерып тора. Мәсәлән, бездә бер үк фамилияле өч язучы бар. Әгәр шәхси исемнәре булмаса, без аларның әсәрләрен ничек аерыр идек икән? Галиәсгар, Шәриф, Әнәс дигән исемнәр кайсы әсәрнең кайсы Камалныкы икәнен әйтә дә бирә. Исем җиңел дә, матур да булсын! Кушаматка тартым исемнәр, гадәттә, кешене бала чакта гына түгел, олыгайгач та кимсетәләр. Исем эзләгәндә туганнарың, дус-ишләрең, күршеләрең белән киңәшү дә зарури.

Тагын бер нәрсә. 1973 елда Казанда «Справочник татарских личных имен», 1965 елда Мәскәүдә «Справочник личных имен народов РСФСР» дигән китаплар басылып чыккан иде. Хәзер шул китапларны (икенчесеннән татар исемнәре бүлеген) яңадан бастырып чыгару ихтыяҗы үзен бик нык сиздерә.

Исемнәребездәге моңа кадәр булган чуарлыкны, исем кушудагы җавапсызлыкны бетерергә, ясалма, милләтебезгә хас булмаган исемнәр белән мавыгуга чик куярга бик вакыт. Ниһаять, милләтебезнең абруен балаларыбызга исемнәр кушканда да төшермисе иде. Бу һәрбер татар патриотының изге бурычы!

## И милләтем, сине ни көтә?!

Инануыбызча, Гаяз Исхакый «200 елдан соң инкыйраз» дигән хезмәтендә татар милләтенең бетү вакытын чама белән ике мең дә йөзенче, төгәлрәге — ике мең бер йөз өченче еллар тирәсенә билгеләгән. Хезмәтнең дөнья күрүенә 90 елдан артыграк вакыт узды. Димәк, татар халкының инкыйраз булуына, ягъни юкка чыгуына тагын 105—106 ел вакыт калган. Аз түгел. 100 ел эчендә ни генә булмаска мөмкин.

Дөрес, бүгенге татар милләтенең хәле, торышы күңелләрне төшерерлек түгел. Тирә-якка күз салсаң һәммәсе дә әйбәт шикелле. Телевидение һәм радиотапшыруларда эшләүче егетләргә һәм кызларга игътибар итсәң, халкыбызның күз алдыбыздагы вәкилләре буларак, ике телне дә су кебек эчәләр (җәя эчендә генә әйтик, шулар арасында ук эшләүче урыс иптәшләр, кызганыч, татарча бер сүз дә белмиләр. Әгәр текст арасына берәр татар сүзе керсә, алар аны бозып әйтәләр).

Газета-журналларда, китап нәшриятында эшләүче иптәшләр дә канәгатьләнү хисләре уята. Театрларда да берсеннән-берсе талантлырак артистларыбыз да безне куандыра.

Фәнебез дә яңа биеклекләр яулый. Республикабызда Фәннәр академиясе, академикларыбыз бар. Югыйсә, күренекле галимебез Гыйлем Камайны еллар буена СССР Фәннәр академиясенә сайламый йөдәттеләр. Казанда урыс галимнәреннән академиклар бар, ә татарлардан бер генә академик та юк иде. Гыйлем Камай кандидатурасын СССР Фәннәр академиясендә тавышка куйганда академик Арбузовларның бер сүз дә дәшмичә утыруы хакында үз вакытында сүз күп йөрде. Бәлки, бу имеш-мимешләрдә хаклык зур булгандыр.

Татар телен үстерү буенча да күп кенә эшләр башкарыла. Телебез күрәләтә байый. Тарихыбызда икенче тапкыр татар теле дәүләт теле итеп игълан ителде. Күп кенә яңа газеталар һәм журналлар чыга башлады. Тарихыбызны иҗат итүдә озак еллар буе дәвам иткән кысынкылык бетерелде. Татарстан республикасы хөкүмәте телебезне гамәлгә кертү буенча махсус карар кабул итте. Карар нигезендә ике телнең тигезлеген тәэмин итү өчен кайбер чаралар билгеләнде. Урыс мәктәпләрендә татар теле фән буларак укытыла башлады. Мәктәпләрдән урыс балаларының татар телен яратып өйрәнүләрен хәбәр итәләр. Димәк, алга таба

татарларның үз балаларыннан манкортлар чыкмас дигән өмет туа. Әлеге чаралар, иртәме-соңмы, урысларның татарча сөйләшергә өйрәнүләренә унай тәэсир ясар кебек.

Әмма хәзерге уңышлар һәм казанышлар белән бергә, татар халкын милләт буларак саклау һәм үстерү өчен күп, бик күп эшлисе бар әле. Шунысы кызганыч, алда нинди проблемалар торганын җентекләп өйрәнгәнебез дә, алдагы конкрет бурычларны билгеләгәнебез дә юк.

Берьяктан караганда, инде әйткәнебезчә, туган телебез чәчәк ата шикелле. Ул байый. Дәүләт теле буларак, аның кулланылу мөмкинлеге артканнан артабарачак. Икенче яктан күз салганда аның язмышы, тәгәлрәге — киләчәге, мине бик тә борчый. Чөнки әлегә гаилә теле буларак, аның вазифасы тарайганнантарая шикелле. Ни өчен дигәндә, бигрәк тә шәһәр җирләрендәге гаиләләрдә, үз телебезне санламау, гаиләдә урысча сөйләшү гадәткә кереп китте. Бирედә, урысча сөйләшмәсәк, бала урыс телен белми калыр, дип кайчандыр актуаль булган сәбәпнең яшәве дә бар шикелле. Бу хәлнең балалы гаиләләрдә кире йогынты ясавы һәркемгә аңлашыла.

Менә шундый гаиләләрнең берсе. Ә андый гаиләләр 6—7 миллионлы милләтебездә аз түгел. Әлеге гаиләдә бер генә түгел, берсеннән-берсе чибәррәк өч бала үсә. Әти-әниләре үз туган телендә сөйләшмәгәч, балалар татар теленә өйрәнмиләр һәм аны белмиләр генә түгел, белергә дә теләмиләр. Барыннан да бигрәк, андый гаиләләрдә телебезгә ихтирам да, ихтыяж да тәрбияләнми. Туган телгә мондый карашның ярты гасырдан артыграк тарихы бар. Ничек килеп чыкты соң әле мондый караш? Барысына да без үзебез, ата-аналар гаепле.

Ярый! Без, ходай мәрхәмәте беләндер инде, сугышта исән-сау калганнар, туган җирләребезгә, өйләребезгә әйләнеп кайттык. Сугыштан кайткач, буйдаклар өйләнеште. Балаларыбыз булды. Болар сугыштан соңгы беренче буын.

Без, сугыштан кайтучылар, беренче көнне үк балаларыбызга җил-яңгыр тидермәскә тырыштык. Ни өчен дисезме? Үзебез бик авыр шартларга тап булдык, рәхәт-фәлән күрмәдек. Үзебез рәхәт күрмәгәч, балаларыбыз бәхетле булсын, алар рәхәт күрсен иде, ичмасам, дидек. Бөтен кыенлыкларны үз өстебезгә алдык. Бөтен тәмле-томлыны аларга ашаттык, әйбәтрәк киемнәр кидерергә тырыштык. Авыр эшләрне үз өстебезгә алдык. Ата кеше балага берәр авыр сүз әйтсә, ана кеше, ана кеше әйтсә, ата кеше баланы яклады.

Сугыштан соңгы беренче буын әнә шулай җил-яңгыр тимичә үсте. Без, сугыш чоры солдатлары, үзебезнең бала тәрбияләүгә, бер табактан ашарга, гаиләдәге кыенлыкларны бергә күтәрешергә тиеш икән!

Икенче буын болар өстенә үз ялгышын өстәде. Ул чорда илдә урыслаштыру сәясәте көчәйде. Бөтен эшләр урысча алып барыла башлады. Туган телебез гаиләгә куып кертелде. Әмма урыс теле дигәнебез татар телен гаиләдә дә кысрыкларга керешге. Хезмәт урынындагы гадәт белән, урысча сөйләшү өйгә дә ияреп кайтты. Без моны, ничектер, сизми дә калдык. Дөрес, икенче буыннар татарчадан бөтенләй мәхрүм калмады. Әти-әниләреннән, әби-бабаларыннан, туган-тумачалардан ишетеп татарчаны азмы-күпме сукалап үстеләр. Ә менә өченче буын болардан бөтенләй мәхрүм үсте. Әти-әниләре үрнәгендә урысча гына сөйләшүче, әти-әнисенең телен бөтенләй зурламаучы, ихтирам итмәүче буын булып китте. Болар инде Гаяз Исхакый әйткәнчә, үз милләтеннән үзләре качкан татарлар, Чыңгыз Айтматов сүзләре белән әйтсәк — манкортлар.

Шулай итеп, урыс теле татар телен кысрыклаганнан кысрыклый барды. Чөнки чорыбыз шундый иде. Гаиләдәгеләр урысча сөйләшүгә гадәтләнеп киттеләр. Стенадагы радио тәүлек буена туктаусыз урысча такылдап тора. Телевизор да радиодан калышмый. Гаиләдә дә, урамда да, мәктәптә дә урыс мохите. Җыелышлар, киңәшмәләр урыс телендә алып барыла. Сөйлисең килсә урыс телендә генә сөйлә. Тагын, тагын әллә нәрсәләр! Кайчандыр бездә баланың урысча сөйләшә белмәү куркынычы бар иде. Ул дәвер узды. Безнең көннәрдә, киресенчә, ана телеңне белмәү куркынычы туды.

Тагын кабатлыйк. Сугыштан соңгы икенче буын ата-аналардан башланган татар теленә игътибарсызлык һәм битарафлык өченче буында тагын да көчәя төште. Ә менә аларның балалары дүртенче, бишенче буыннар туган телләрен кемнән ишетерләр һәм кемнән өйрәнерләр икән? Алдагы буыннарга әти-әниләренең, әби-бабаларының телен бөтенләй ишетмәү, белмәү куркынычы яный. Бу зур фаҗига.

Милләтебезнең киләчәге өчен моның ни дәрәҗәдә куркыныч булуын күз алдына китерүе дә кыен. Бу хәл бигрәк тә шәһәрләргә кагыла. Ә җөмһүриятебездә шәһәрләр, шулай ук урысча укытуга күчкән район үзәкләре аз түгел. Татар-

станнан читтә яшәүче татарларның хәле ничек булачак? Һәрхәлдә, читтәге туганнарыбызның балаларына шулай ук зур өмет баглап булмый.

Хәзер без шундый ноктага килеп җиттек ки, татар теленнән, татар әдәбиятыннан, татар мәдәниятеннән, татарның гореф-гадәтләреннән, ислам диненнән хәбәрдар булмаган буыннар ишәю алдында торабыз.

Мондый хәлдә алга таба милләтебезнең 25—30 проценты чамасы югалу ихтималы бар. Әгәр шулай була икән, аллаһы тәгалә сакласын, үз ана телендә сөйләшә белүче татарларның 4—5 миллион чамасы гына калачак. Бу хакта безгә кычкырып сөйләшергә, моңардан котылу юлларын бергәләшеп эзләргә кирәк.

Әлбәттә, бу — барлык татар балалары да туган телебезне бөтенләй белмәсләр дигән сүз түгел. Татар теленә гомуми игътибар арту уңае белән балаларына туган телебезне өйрәтүче ата-аналарның саны торган саен арта бара. Казан урамнарында нәниләре белән татарча сөйләшеп баручы атаны яки ананы очратканда күңелләр шатлык белән тула. Андый мәрхәмәтле әти-әниләр туктаусыз арта торсын иде дигән изге теләктә калабыз.

## Йомгак урынына

Инде нишләргә? Бу бик катлаулы һәм авыр сорау. Аңа күмәкләп җавап эзләргә кирәк. Шулай да, минемчә, урыс иптәшләргә хәзер «олы туган» да, «кече туган» да юклыгын, һәр ике милләтнең дә хокукы бер тигез булуын аңлатырга, төшендерергә зарур. Югыйсә, «олы туганнар» әлегә моны аңламыйлар, үзләрен бер башка югарырак итеп хис кылалар.

Менә бер мисал. Алабуга шәһәреннән өч урыс хатыны «Вечерняя Казань» газетасында (3.02.94) соңгы вакытта Татарстанда гомумән милләтчелек чире (урысларга каршы) бик нык көчәюе турында язалар. Алар, татарча радиотапшырулар исәбенә урысча тапшырулар бик азайды, дип зарланалар. Шуны әйтик, монда тузан бөртеге хәтле дә хаклык юк.

Дөрес, соңгы бер-ике елда татарча радиотапшыруларның вакыты беркадәр озынайтылды. Ләкин моның өчен безне милләтчелектә гаепләргә нигез юк. Ник дигәндә, беренчедән, Татарстан радиосыннан урысча тапшыруларның вакыты бер минутка да кимемәде, ничек бар шул килеш калды. Икенчедән, Мәскәү тапшырулары гел урысча алып барыла. Тәүлек буе рәхәтләнеп тыңла да тыңла. Юк, урыс иптәшләрнең тапшыруларны озайтканга эчләре поша.

Тагын бер мәсьәлә. Монысы беренчесеннән дә катлаулырак һәм четереклерәк. Сүз 450 ел буена урыс халкының татар милләте өстеннән хакимияте турында бара. Без, халык гаепле түгел, дигән карашта торабыз. Дөрес! Әмма бит бер генә урыс кешесе дә бу хакимлеккә каршы бер вакытта да бер генә сүз дә әйтмәде һәм хәзер дә әйтми. Басып алган яхшы җирләргә урыс кешесе бик рәхәтләнеп килеп утырган. Шәһәрләрдән татарларны кысрыклаганнар. Хәзер дә шәһәрләрдә алар күбрәк. Бөтен алдынгы илләр күптән вакытлы матбугат чыгарып килсә дә, безгә 1905—1906 елга кадәр газета-журналлар чыгарырга да рөхсәт итмәгәннәр. Мәчетләребезне, мәктәпләрне җимергәннәр һ. б.

Урыс түрәләренең татарга каршы барлык эшчәнлеген урыс кешеләре дәшми-тынмый хуплаганнар. Әле күптән түгел «Советская Татария» газетасында, Фәүзия Бәйрәмованы булмаган гөнаһларда гаепләп, урыс кешеләренең хатларыннан тулы бер бит басып чыгардылар. Ә татар кешеләренең Фәүзияне яклап язган хатлары җавапсыз калдырылды.

Урысларның 4—5 гасыр буена татарларга каршы кылган гөнаһларын үзләренә ничектер аңлатасы иде бит!

Күренә ки, Гаяз Исхакый күтәргән проблемалар вакыт узу белән тагын да катлаулана төшкәннәр. Бу, күрәсең, шактый вакыт үтү һәм урыс хакимияте шаукымының тагын да көчәя төшүе белән аңлатыла.

Ә шулай да, Гаяз Исхакый фараз кылганча, татар милләте XXI гасыр ахырына бетәрме соң? Юк, бетмәс! Чын күңелемнән ышанып әйтәм.

Татарстан җөмһүрияте алга таба да үскәннән үсә, тәрәккый иткәннән тәрәккый итә барачак. Ни өчен дигәндә, милләтнең язмышын кешеләр, шәхесләр хәл итә.

Ә хәзер, минемчә, бу язмыш алга карап эш итә белә торган көчле шәхесләр кулында. Бүгенге буынның тырышлыгын, һичшиксез, алдагы буыннар дәвам иттерәчәк.

**Һибәтулла Сәедбаттал угълы Салихов 1794 елда Оренбургтан ерак түгел Түбән Чебенле авылында мулла гаиләсендә туа. Аның әтисенең бабасы Бикмәт Азаматов бу якларга XVIII йөзнең урталарында Казан губернасы Чистай өязе Иске Адәм авылыннан күчеп килгән була. Шагыйрьнең әтисе, Каргалы мәдрәсәсен тәмамлагач, Түбән Чебенлегә мулла итеп җибәрелгән. Һибәтулланың яшьлек еллары шунда үткән, ул анда ишан Дәүләтша бине Гаделша мәдрәсәсендә укыган. Һибәтулла Салиховның остазлары арасында Каргалыда яшәгән һәм 1832 елда вафат булган шагыйрь Вәлидетдин Багдади да телгә алына. Күрәсең, шагыйрь Каргалы мәдрәсәләрендә дә укыган.**

**Һибәтулла Салихов шәкерт вакытында ук шигырьләр яза башлый. Аның газәлләр, касыйдәләр, мәрсияләр, мөнәҗәтләр, шигъри трактатлар иҗат иткәнлеге мәгълүм. Безнең көннәргә аның XIX йөзнең 10 нчы еллары ахырында язган «Төхфәтел-әүлад» («Балаларга бүләк») һәм 1839 елда язган «Мәҗмугыл-әдәб» («Әдәп турындагы җыентык», 1900 елда Казанда басылып чыккан) китаплары килеп җиткән. Кайбер галимнәр 1856 елда Казанда басылып чыккан «Дөррелкәлям» («Сүз энҗеләре») китабының авторы да Һибәтулла Салихов булу ихтималын әйтәләр. Аерым шигырьләре кульязмалар хәлендә дә халык арасына таралган.**

**Һибәтулла Салихов иҗаты — яңа дәвер татар поэзиясендә демократик, гуманистик, сугышчан шигърият буларак күренекле урын алып тора.**

# Һибәтулла Салихов

* * *

...Ирермән бән дә һәм бәндә. Бәне нәфсем салыб бәндә.
Къәбаих җөмләсе бәндә, — һидайәт бир бәңа, йаррабб.

Бәшәрмән һәм бәшәр мәил, ирермен шәрмемә каил.
Улыбмән мәгърифәт саил, — һидайәт бир бәңа, йарабб...

Алар уртасында бән зар: телем — баглы, әлем — би кяр,
Йөзем мәхҗүл, эчемдә нар, — һидайәт бир бәңа, йаррабб...

Тышым — мәгъмүр, эчем вәйран, эшем тәзүир, хушым сәйран,
Гакыл мәгълүб, башым хәйран — һидайәт бир бәңа, йаррабб...

Йөзем алда, күңел артта, башым җирдә, күңел шүрдә,
Бәнем тик булмагай бер дә, — һидайәт бир бәңа йарабб...

Бәнем уш бер йулын шашмыш, хатасы башыдин ашмыш,
Хәтәрдин йөрәге ташмыш, — һидайәт бир бәңа йарабб...

Ирерсез җөмләңез шаһбаз, сайд әйләргә үрдәке, каз —
Чөйәргә бездә һиммәт аз, — һидайәт бир бәңа, йәрабб.

Бәңа сез улмагыз канигъ, ки кыйлмаң вакътыгыз заигъ,
Улыңлар һәр тараф саригъ,— һидайәт бир бәңа йарабб.

Араңыз мөршиде кямиль, хакның бойырыгы илә гамил,
Гъәлүме шәргъийә шамил,— һидайәт бир, бәңа йарраб.

Булып ирсә әгәр надан, йакын варман, качың аннан,
Качар кеби арысланнан,— һидайәт бир бәңа, йарабб...

Җәһаләт-гъәйне золмәтдаж, хуарикъ аңа истидраж,
Кирәк заһид, кирәксә хаж,— һидайәт бир бәңа йарабб...

Бу кәз сезгә нәдер чара? Улынмаң шимди әуара,
Киләлем җөмлә бер ара,— һидайәт бир бәңа, йарабб...

Улалем та ки җәмгъийәт, каму тәсхих идеб нийәт,
Куйыб дилдән инанийәт,— һидайәт бир бәңа йарабб...

* * *

(Хәзерге телгә тәрҗемәсе)

Мин дә — кеше генә, мине дә нәфсем тышаулаган,
Бар әшәкелекләр миндә, дөреслек юлына сал мине, ходай.

Кешемен һәм «кеше»леккә авышучан, оятсызлыгыма мәгърур,
Булдым мәгърифәт хәерчесе, дөреслек юлына сал мине, ходай

Алар арасында мин зарлы: телем бәйле, кулым эшсез,
Йөземдә — оялу, эчемдә — ут, дөреслек юлына сал мине, ходай.

Тышымнан — төзек, эчем — хәрабә, эшем — алдау, хушым гизә,
Акыл җиңелгән, башым хәйран, дөреслек юлына сал мине, ходай.

Йөзем — алда, күңел — артта, башым — җирдә, күңел — әшәкелектә,
Минем кебек бераү дә юктыр, дөреслек юлына сал мине, ходай.

Мин ул — юлдан язган, хатасы баштан ашкан кеше,
Куркынычтан йөрәгем ташкан, туры юлга сал мине, ходай.

Сез барыгыз да — лачын, үрдәк-каз ауларга:
Кош чөяргә бездә тырышлык аз, дөреслек юлына сал мине, ходай.

Сез миннән канәгать булмагыз, вакытыгызны әрәм итмәгез,
Һәр тарафка юнәлегез, дөреслек юлына сал мине, ходай.

Әгәр надан булса, якын бармагыз, аңардан качыгыз,
Арысланнан качкан кебек, дөреслек юлына сал мине, ходай.

Наданлык — караңгылыкның үзгенәсе, гаҗәп, аны югары күтәрүче —
Изге дә булса да, хаҗи да булса да,— дөреслек юлына сал мине, ходай.

Бу юлы сезгә ни чара? Инде әварә булмагыз,—
Һәммәбез бердәмлеккә килик, дөреслек юлына сал мине, ходай.



**Харис Әшрәфҗанов,**
Татарстан китап нәшрияты директоры

# «Китап тотып ант итәм...»

Быел Татарстан китап нәшрияты үзенең 75 еллыгын билгеләп үтә. Элгәрерәк юбилей уңаеннан әйтелә торган сүз ирешелгән уңышларны санап китүдән һәм алда башкарасы эшләргә күз ташлаудан гыйбарәт була торган иде. Заманалар үзгәреп, яшәү рәвеше бөтән төс ала барган саен, тел очына килә торган сүзләр дә икенчерәк була икән... Мин дә менә, калыптан баш тартып, бөтәнчәрәк фикер йөртергә — ачы хакыйкатьне күздән кичерергә мәҗбүрмен.

Моңа кадәр дә күпне кичергән татар китабы гаять катлаулы, авыр чорга килеп керде. Аның язмышы кыл өстендә торган чак. Бу чорны ул исән-имин уза алырмы, китапсыз калмасмы милләтебезнең килер буыннары? Әлегә моңа берәү дә өздереп кенә җавап бирә алмастыр, мөгаен. Ә менә язучыларны гына түгел, киң катлау җәмәгатьчелекне дә тәшвишкә төшергән кайбер сәбәпләрне әйтеп китәргә була.

Беренчедән, китап индустриясе базар мөнәсәбәтләренә әзерлексез килеш килеп керде. Ничәмә-ничә еллар буена бөтен татар дөньясын китап белән тәэмин итеп килгән бердәнбер Татарстан китап нәшрияты да икътисади яктан яклаучысыз калды. Икенчедән, китап бастыруга тотыла торган чыгымнар бик нык артты, ул бүген дә айлап түгел, атналап «үсештә». Бу, үз чиратында, китапның үзкыйммәте артуга китерде. Нәтиҗәдә, укучының күңеле китаптан сүрелә төште. Өченчедән, коммерциягә генә йөз тоткан яңа басмаханәләр барлыкка килде һәм көндәшлек көннән-көн үсә бара. Ә ныклы полиграфик базаң булмаганда һәм кесәңдә җилләр уйнап торганда әллә ни ерак китә алмыйсың икән. Дүртенчедән... Әйе, алга таба тагын да санарга булыр иде. Әмма китапның бүгенге хәлен күз алдына китереп бастыру өчен югарыда телгә алынганнары да бик җиткән. Шулай да безне кыен хәлгә төшергән сәбәпләрнең иң зурысын җәмгыятебездә әдәбиятка, мәдәнияткә, сәнгатькә тиешле игътибар бирелмәүдән эзләргә кирәктер. Китапка рухи азык, тәрбия чарасы итеп караудан бигрәк, аны табыш алу чыганагына әйләндерергә омтылыш көчлерәк бүген. Нәшрият цемент яки аракы заводы белән бер дәрәҗәгә куела. Хәзер без 22 төрле налог түлибез. Базар икътисады шартларында яшәүче чит илләрдә китапка налог 7 проценттан артмый. Ә бездә ул табышның 85 процентын тәшкил итә. Моның нәтиҗәсе күз алдында. Кайбер саннарны күздән кичерик.

Әйтик, 1913 елда ук инде татар телендә бүгенге кадәр үк китап чыгарылган. 1932 елда исә 831 исемдә татар китабы дөнья күргән. Моңа янадан ничек ирешербез — әлегә билгесез. Соңгы елларда Татарстан китап нәшриятының китап бастыру күләменә игътибар итегез. 1980—85 елларда 340—350 исемдә китап чыккан булса, 1988 дә ул — 300, 1989 да — 280, 1990 да — 279, 1991 дә — 252. Ә 1992—93 елларда, дәреслекләрдән тыш, 131—152 китап дөнья күрде. Быелгы юбилей елында бу сан 100 дән артмый. Чөнки пландагы 186 исемдәге китапны бастыру өчен 3 миллиард сум акча кирәк була торып та, бүгенге көндә нәшриятка 300 миллион сум чамасы гына акча бүлеп бирелде. (Чагыштырып карау өчен шунысын да әйтеп үтик: быел Башкортстанның «Китап» нәшриятына 180 исемдәге китапны бастыру өчен дәүләт тарафыннан 2,5 миллиард сум акча бүленгән.) Хәзер 600 битле китапны зур булмаган тираж белән бастырып чыгару нәшриятка 40 миллион сумга төшә. Китапның үзкыйммәте, әйткәнемчә, елдан-ел арта бара.

Укучы китапны сатып ала алмаслык хәлгә килде. Шигърият, сәнгать, әдәбият белеме буенча китаплар дөнья күрә алмыйча ята, классикларны кабат бастырыр мөмкинлекләр юк һ. б. Бүгенге язучыларыбызның, яшьләрнең әсәрләре чыгу сирәгәйде, укучыга балалар китабы җитми. Икътисадчылар исәпләвенчә, хәзер халыкның да 30 проценты гына китап сатып алырлык дәрәҗәдә икән...

Әйе, болар — бәйрәм рухына туры килә торган сүзләр түгелләр. Әмма дөреслектән качып котылып булмый шул.

Ә бит татар халкы борын-борыннан китап укучы халык буларак танылган. Ул үзе генә укып калмаган, бәлки китапны тугандаш халыклар арасында да тараткан. Татар өендә китап икмәк белән янәшә торган... Бүгенге көндә исә ул «кирәксез товар»га әйләнеп бара. Бер көн килеп, касафәтен күрмәбез микән моның, җәзасын татымабыз микән?!

Менә шундый кыен шартларда яшәүгә карамастан, без татар китабын яшәтергә тиешбез. Әлбәттә, дәүләт ярдәменнән башка моңа ирешү мөмкин түгел. Әлегә ярдәм кулы сузу төрле сәбәпләр аркасында кичектерелә килсә дә, мәсьәләнең җитдилеге югары даирәләрне дә бер сискәндерми калмас дип уйлыйм. Әмма бүгенге базар икътисады шартларында без саламга гына түгел, нәрсә туры килсә, шуңа ябыша-ябыша булса да батмый калу юлларын үзебез эзләргә мәҗбүрбез. Заман шуны таләп итә.

Беренче чираттагы бурыч — укучы күңеленә хуш килердәй, аның күзе төшәрдәй һәм рухи ихтыяҗын канәгатьләндерердәй китаплар чыгару. Соңгы елларда нәшриятта барган үзгәртеп корулар шуңа юнәлтелгән. Әйтик, «Мирас», «Сәнгать» редакцияләре ачылып, алар үзләренең эшчәнлекләрен җәелдереп җибәрделәр. Фәнни-популяр әдәбият һәм крайны өйрәнү редакциясе дә яңа кадрлар белән ныгытылды, әзер китапларны сату бүлеге барлыкка килде. Тольяттида, Удмуртиядә, Башкортстанда, Ульяновскида, Самарада татар китабын тарату белән шөгыльләнүче үз вәкилләребезне булдырдык.

Куйган тырышлыкның күркәм нәтиҗәсе буларак, күп еллар буена исемнәрен дә телгә алырга ярамаган авторларның әсәрләре берәм-берәм халыкка барып җиттеләр. Соңгы ике елда гына да, мәсәлән, Риза Фәхретдинев, Шиһабетдин Мәрҗани, Һади Атласи, Зәки Вәлиди, Фатих Кәрими, Гаяз Исхакый, Газиз Гобәйдуллин һәм башкаларның китаплары дөнья күрде. «Татар поэзиясе антологиясе», «Балалар фольклоры», бәйсез дәүләтләр берләмлеге халыкларының әкиятләре сериясе, фразеологик сүзлек, урысча чыккан татар грамматикасы өчтомлыгы һ. б. мәдәни тормышыбызда вакыйга буларак кабул ителделәр. Татар халкы тарихы буенча да байтак кына китаплар дөнья күрде. Халыкның рухи тормышына уңай йогынты ясый торган дини китапларның укучыга барып ирешүе дә игътибарга лаеклы күренеш. Бу серияне зур тираж белән басылып чыккан «Коръән тәфсире», «Иман», «Пәйгамбәрләр тарихы» кебек китаплар башлап җибәрде. Ярты гасырдан артык вакыт эчендә беренче тапкыр «Мөселман календаре» пәйда булды.

Халкыбызның тарихы, әдәби мирасыбыз никадәр генә бай һәм гыйбрәтле булмасын, бүгенге язучыларыбызның әсәрләрен укучыга җиткерү нәшриятның төп вазифаларыннан берсе булып кала. Мирас һәм бүгенге әдәбият — басмаханәнең ике канаты кебек ул. Ул канатларның берсе сынса да, алга таба очып булмаячак. Тик аларны бар колачка җәеп җибәрергә мөмкинлекләр генә җитәрлек түгел. Шуны гына әйтү дә җитә: хәзер Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары арасында әлегә кадәр китабы дөнья күрмәгән яшьләр дә байтак. Бүгенге китап чыгару темплары белән чамалап караганда, язучыга китап бастыру мөмкинлеге 4—5 елга бер тапкыр гына туры килә. Бу бик аз, әлбәттә. Каләм хакы да шәптән түгел. Еллар дәвамында язган романы өчен язучы хәзер берничә айлык хезмәт хакы күләмендә генә гонорар ала. Мәсьәләне беркадәр җайлап булмасмы дигән өмет белән узган ел республика хөкүмәтенә каләм хакларын арттыру буенча проект эшләп тәкъдим ителгән иде. Әлегәчә ул хәрәкәтсез килеш кала бирә. Ә язучыларыбызның матди хәле көннән-көн начарая бара. Алга таба инде болай яшәп булмаслыгы көн кебек ачык. Безнең тәкъдим шул: китап бастыруны җайга салу эшен нәшрият Язучылар берлеге белән бергәләп кайгыртырга тиеш. Ул безнең уртак мәнфәгатебез.

Кыен мәсьәләләрнең берсе — сәнгать осталары әсәрләрен, сәнгатебез проблемаларына багышланган хезмәтләрне, халыкның көнкүреш, гамәли сәнгате әсәрләрен басмаларда дөньяга күрсәтү. Дөресрәге, соңгы еллар аны әнә шундый кыен проблемага әйләндерде.

Татар халкы — бай сәнгатьле халык. Профессиональ музыка, халык җырлары, сурәтле (сынлы) сәнгать, театр, эстрада, гамәли сәнгать әсәрләре — болар-

ның барысын да тиешле югарылыкта торган нәфис басмалар хәлендә дөньяга китерү бик зур чыгымнар таләп итә. Мәсәлән, 1996 елда 90 еллыгы билгеләп үтеләчәк татар театры яисә татар халык милли киемнәренә багышланган һ. б. альбомнарны әзерләп бастыру өчен (әзерлек бара инде) һәрберсенә йөзләрчә миллион сумнар кирәк. Әле без соңгы елда күренекле композиторларыбыз Мансур Мозаффаров, Әнвәр Бакиров, Сара Садыйкова, сынлы сәнгатебезгә нигез салучыларның берсе рәссам Бакый Урманче турындагы китапларны да зур авырлыклар белән чыгара алдык. Чөнки һәрберсенә кайдандыр, ничектер финанс чыганагы табарга кирәк. Дотация-фәләнгә ышаныч аз. Ә нәшриятның сәнгать китаплары, альбомнар һ. б. басмалар чыгару планнары зур, сәләтле авторлары, китапчы рәссамнары, мөхәррирләре бар. Без музейларда үз чиратын көтеп яткан мәдәни хәзинәләр, шулай ук ерак гасырлардан килгән (яисә безнең көннәргә килеп җитә алмаган) төрле-төрле мәдәният-сәнгать мирасыбыз, сәнгатькәрләребезнең иҗат җимешләрен дөньяга күрсәтү өчен аларга багышланган альбомнар, буклет бәйләмнәре, монографияләр һ. б. шундый басмалар әзерлибез.

Нәшрият эшчәнлегенең тагын да бер зур юнәлеше — төрле күләмле, төрле максат-юнәлешле сүзлекләр чыгару. Урысча-татарча һәм татарча-урысча гына түгел, ә башка күп телләр — «якын» һәм «ерак» чит ил телләре белән татар теле арасында күпер булып хезмәт итәрлек сүзлекләрне дә нәшер итү. Болардан һәм башка ярдәмче әсбаплардан башка татар телен дәүләт теле итеп күз алдына китерүе дә кыен.

Яңа редакцияләр ачылу турында алдарак әйтеп үткән идем инде. Шуларның берсе — фәнни-популяр әдәбият редакциясе.

Ул шактый катлаулы һәм күпкырлы мәсьәләләрне хәл итүне үз өстенә алды. Әлбәттә, иң әүвәл редакциянең төп вазифасы фән казанышларын халыкка җиткерү, бигрәк тә үзебезнең бай тарихыбызны популярлаштыру, халкыбызның үзаңын үстерү, туган як турында үтемле китаплар бастырып чыгару булып тора. Бу җәһәттән инде әзерләп җитештерүгә тапшырылган берничә китапны атап үтәсе килә. Әйтик, тарихчы-галим С. Алишевның урысча язылган «Казань-Москва: межгосударственные отношения в XV — XVI вв.» дигән китабы аерым игътибарга лаек. Анда XV — XVI йөзләрдә Казан ханлыгы белән Мәскәү дәүләте арасында барган катлаулы мөнәсәбәтләр җентекләп анализлана, күп кенә гыйбрәтле фикерләр әйтелә. Шулай ук татарның күренекле галиме, дин әһеле һәм мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдиннең «Казан ханнары» һәм «Алтын Урда ханнары» исемле мәгълүматларга бай ике китабы укучыларның күңеленә хуш килер, борынгы тарихыбызны ачыграк күз алдына китерергә ярдәм итәр, дип өметләнәбез. Ике китап та матур итеп бизәлгән, ханнарның портретлары, сугыш кораллары, төрле тарихи сурәтләр белән баетылган. Алтын Урда ханнарының татар һәм урыс телләрендә чыгуы аңа киң катлау укучының игътибарын җәлеп итәр, дип уйлыйбыз.

Балалар китабын бастыру буенча килеп туган кыенлыклар — аерым бер сөйләшүнең темасы булырлык. Бүген шуны гына әйтеп китәм: без яшь буынның китапка булган ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерерлек хәлдә түгел. Балалар китапларының саны елдан-ел кими, алар елдан-ел югары, төссезләнә баралар. Инде ачык: балалар китабы, гомумән, милли китап белән зур керемнәр эшләп булмый. Балалар әдәбияты сәясәте тулысынча дәүләт заказы буенча алып барылырга тиеш. Яңа, яшь буынны тәрбияләүне икътисадый кануннар нигезендә түгел, бәлки, сәяси пәйгамбәрлек белән хәл итәргә кирәк! Шуңа күрә милли мәсьәләне, суверенитет мәсьәләсен принципиаль хәл итүгә хезмәт итүче татар китабын хөкүмәт «бюджетчы»лары махсус статья буенча үткәрергә тиешләр. Моның өчен Президент аппаратында да, Министрлар Кабинетында да, Югары Советта да нәшрият эшләре буенча шөгыльләнүче махсус киңәшче-референтлар, кураторлар, белгечләр булырга тиештер. Әнә бит, күрше Чувашия республикасы бу юнәлештә инде матур мисал.

Сүзне нәшриятның юбилееннан башлап киткән идем. Фикерләремне йомгаклаганда да шуңа кайтып төшәргә туры килә. Бүгенге көндә ерып чыккысыз авырлыклар алдында торып калса да, басмаханәнең 80 еллыгы да, 90 һәм 100 еллыгы да килеп җитәр бервакыт. Теләгем шул: ул чакта юбилей уңаеннан сүз алган нәширләргә зарланып чыгыш ясарга туры килмәсен иде! Укучыларны бары тик бу өлкәдәге матур казанышлар белән генә сөендерсеннәр иде алар. Гасырлар буена үзенә юлдаш итеп алган китаптан аерылмас, халкыбызның моңа акылы һәм ихтыяры җитәр дип ышанам. Кулына китап тотып ант итә алган, аны шулай изге дип санаган милләт үзенең бу инануын килер буыннарга да исән-сау килеш тапшыра алсын иде.

Мөхәммәт Мәһдиев

# КАРА ТАРИХТАН БЕР ЛӘҮХӘ

Ерак Сахалин утравыннан Татарстан Язучылар берлеге идарәсенә хат килде. Русча язылган. Хат эчендә тагын бер хат: кәгазе искергән, саргайган, өзгәләнгән. Анысының датасы: 1945 ел, 6 март. Хат Сахалинга язылган һәм менә кырык биш ел буе шунда сакланган. «Бу — минем әнием мәрхүмәдән калган кәгазьләр арасыннан чыкты, белүемчә, аны әнинең атасы, ягъни минем дәү әтием язган. Ул язучы булган дип сөйли иде, әнием», — дип яза татарча белмәүче бер туташ.

Искергән хатның ахырында имза бар: «Сине сөеп атаң Зәбиров Укмаси».

Әйе, бу хатны XX гасыр башында өч-дүрт китап чыгарган, әдәбиятта һәм тәнкыйтьтә үз урынын алган шагыйрь Миргазиз Укмаси язган.

М. Укмасиның исеме теге кара елларда байтак вакыт телгә алынмый тора. Безнең заман укучысы бу исемне 1945 елда «Совет әдәбияты» журналында гына күрә. Аннары КПССның XX съездында Сталин-палач фаш ителгәч, татар әдәбиятында зур вакыйга була: «Татар поэзиясе антологиясе» (1956) чыга. Анда инде искә алынырга тиешле булган бик күп шагыйрьләр, шул исәптән М. Укмаси да бар. Игътибар итик әле: шәхес культын каты тәнкыйтьләп, авыру идеологиябезгә кислород өрдергән XX съезд 1956 елның 14—25 февралендә эшли. «Татар поэзиясе антологиясе» наборга шул елның 26 августында тапшырыла, главлит (ул чордагы цензура) 25 октябрьдә рөхсәт имзасын куя.

М. Укмасиның биографиясе шунда беренче тапкыр дөнья күрә. Әмма шәхес культының өрәге яши әле: антологиядә М. Укмасиның әсәрләренә сүз башы язган Мөхәммәт ага Гайнуллин да бу турыда әйтми. Өрәк көчле дә соң: 1986 елда чыгарылган «Совет Татарстаны язучылары» дигән белешмәдә дә М. Укмасиның шәхес культы корбаны булуы турында ләм-мим. Югыйсә, 20—40 елларда кайда булган ул, әсәрләре ник күренмәгән аның?

Шагыйрьнең оныгы (исеме Нелли, үзенең татарча белмәгәнлегенә бик уфтана) язган хатта М. Укмаси биографиясенә кагылышлы байтак мәгълүмат бар. М. Гайнуллин төзегән биографиядән безгә мәгълүм инде: М. Укмаси Балык Бистәсе районының Укмас авылында 1884 елда туган, Саба ягында Сатыш мәдрәсәсендә укыган (алар алты-җиде ел буе мәдрәсәдә минем әтием белән шәриктәш булганнар, әти аны олылап искә ала иде).

Ә Сахалин хаты ниләр ача соң?

М. Укмасиның хатыны — Заитовлар кызы булган. Заитовларның тарихы — гыйльми китапханәләрдә. Әйтик, университетныкында. Анда шул ук Балык Бистәсе районы (элек Лаеш өязе) Күгәрчен авылы мулласы Мөхәммәтфатих мулла Мөхәммәтҗан Заитов әл-Күгәрчени әл-Лаеши әл-Казани дигән авторның бер китабы саклана. Ул 1900 елда Кәримовлар матбагасында чыккан. Исеме — «Хәллүл мушкуләти фи кыйфияти тәкәүнңү галәми». Ягъни: «Галәмнең яшәешенә кагылышлы мәсьәләләргә җаваплар». М. Укмаси хатынының әтисе булып чыга бу автор. Әмма мулла абзый фәнгә бераз хилафлык кертә бу хезмәтендә. Җир әйләнми ул, ә кояш сәҗдәгә китә, ди. Тюрколог Н. И. Ашмарин моны бик нык тәнкыйтьли. «Татар әдәбияты хакында» дигән хезмәтендә ул *(Оренбург, 1913 ел, «Вакыт» матбагасы)* мондый китапларны «ысуле җәдидкә каршы чыккан» китаплар дип атый һәм схоластиканың алдынгы фикер үсешенә байтак зарар салганын әйтә *(3 бит)*.

Күгәрчен авылы исә Укмас тирәсендә генә икән.

Кем ул, кем ул шагыйрь Миргазиз Укмаси? Нинди төбәк ул бу яклар? Башта М. Заитов, аннан М. Укмаси һәм инде шактый тынып торгач... Роберт Әхмәтҗанов, С. Шәкүров, бертуган Равил һәм Рөстәм Фәйзуллиннар, Хәлим Җәләлов, Р. Шәрәфиев, Кадыйр Сибгатуллин һәм тагын әллә кемнәрне язган онык Нелли дә шул төбәкнең тамырларын эзли бит. Хатның Язучылар берлегенең аппаратында эшләүче М. Шиһаповка килеп керүе дә очраклы түгел кебек. Ул да — шул төбәктән. «Ни чыкса, шулардан чыга» дигән бер әйтем бар безнең Казан артында.

М. Укмаси матбугатта 1906 елда күренә, ягъни татар матбугаты ачылгач та. Шул ук елда ул беренче китабын да бастыра. Аның шигырь җыентыклары турында тулы мәгълүмат М. Гайнуллин тарафыннан төзелгән инде, монда аны кабатлап тормыйбыз. Ләкин М. Укмасиның әдәби тәнкыйтьтә дә катнашуын моңарчы телгә алган кеше юк әле. Аның мәкаләләре «Йолдыз»да очрый. Аз санлы мәкаләләрендә ул татар әдәбиятын чүп-чардан чистарту кирәклеге турында әйтә. Тукайга ияреп, әдәбиятта тәнкыйть кирәклеген кабатлый. «Әдәбият сәхнәсенә теләгән шәхес хәйванын куа да чыгара,— дип борчылып яза ул.— Сакчы-фәлән булмагач, ник болай иттең? — дип әйтүче берәү дә юк. Һәм ул сакчыны без бүгенгә кадәр кирәксенмәдек тә, булганын да тәкъдир итмәдек. Китапчылар өчен булса — аның булмавы мәтлүб *(теләнгән)*. Алар хәзерге рәвештә булганда һәр мөхәррирнең заренә кәеф мәшият *(кәефләре теләгәнчә)* хак биреп, мөхәррирләрне үз кадрильләренә биетәләр. Изге фал булсын: берәр ел чорында татар дөньясында тәнкыйтьчеләремез сирәк-мирәк кенә ялтырый башладылар. Бәгъзе әсәрләрнең янагына яхшук сугып куйгалыйлар. Мондый тәнкыйтьләрдән Галиәсгар Камал җәнаблары белән Галимҗан Ибраһимов җәнабларының каләмнәрендә яхшук өмид күренә». Тәнкыйтьнең әдәбият үсешендәге ролен билгеләп, автор Европада әдәбият бары тик тәнкыйть аркасында гына алга киткәнлеген әйтә *(«Йолдыз», 1911 ел, 706 сан)*.

Шагыйрь буларак, М. Укмасины үз заманында Г. Тукай телгә ала. 1910 елда Шәрекъ клубында сөйләгән лекциясендә ул М. Укмасиның «Килен» шигыре халык иҗаты нигезендә язылганлыгын әйтә һәм аны трибунадан укый.

М. Укмаси зур шагыйрь булганмы соң? Юк, алай түгел, ул — урта кул. Тукай аны халык иҗатына якын булганы ягыннан гына искә ала. М. Укмасиның шигырьләре шәкертлек, бәетчелек тирәсендәрәк, тагы да М. Гафури, Н. Думави, З. Бәшири тирәсендәрәк әйләнә. Ләкин кайвакытта, Г. Ибраһимов әйтмешли: «авызыннан энҗеләр дә чәчелеп» куя.

Агыйделнең агым суын кичкән чакта,
Туя алмый дәрьясыннан эчкән чакта:
И Ходаем, бер нәрсәң дә кирәк түгел,
Үз җанашым исләремә төшкән чакта...

Шуны язган кеше шагыйрь түгелмени?

Хәер, мәкаләмнең бурычы ул түгел. Бурычы — шагыйрьнең биографиясендәге ак тапларга төс бирү. Инде Нелли туташ язганнарны сөйлим. Неллинең әнисе — М. Укмаси кызы, ерак Сахалинда үләр алдыннан болай сөйләгән.

М. Укмаси Сталин төрмәсенә эләгә (елы күрсәтелмәгән). Аны Чистайга озаталар. Шул ук көннәрдә Заитовлар нәселен дә кырып чыгалар. Заитовларның Өфедә эшләүче, ике институт тәмамлаган улларын төрмәгә алып юк итәләр, өч бала белән калган хатынын 1957 елга кадәр эшкә алмыйлар.

Миргазиз аганың да хатыны һәм ике кызы кала. Озак та үтми, хатыны авырып үлә. Ике кызның берсе — Гайшә исемлесе шулай ук авыру була. Ятим калган шул ике кызны Укмас авылы җитәкчеләре урамга куып чыгарып, йортны советкамы, колхоз идарәсенәме алалар. Укмас авылының юньле бер хатыны бу балаларны үз йортына алдыра. Ләйлә исемле кече кызы (Неллинең әнисе) әтисен эзләп Чистай төрмәсенә барып чыга. Яшь кыз төрмә начальнигына кереп елый: әни үлде, әтине чыгарыгыз, ди. Әллә шуның тәэсирендәме, күпмедер вакыттан соң шагыйрьне төрмәдән чыгаралар. Ул ашыгыч рәвештә генә Укмас авылына керә, теге хатыннан балаларын әлегә карап торуын үтенә, үзе юкка чыга. Бераздан балаларын алып китә. Казанда фәкыйрь тормыш башлана. (Еллары билгеле түгел). Өйләнә, үги ана теге ике ятимне яратмый. Ләйлә ФЗӨне тәмамлауга, Казанны ташлап Ерак Көнчыгышка китә. Үги ана белән фәкыйрь әти кулында авыру Гайшә кала. Ләйлә әтисе белән хат алыша. Менә шагыйрьнең Сахалинга язган хаты. Хат 1945 елның 6 мартында язылган. Рус графикасына

шагыйрь житә алмаган, Чистай төрмәсе — мәктәп классы түгел. Хатны дәресләп һәм кыскартып күчерәм.

**«Кызым Ләйлә, сагынып сәлам соңында синең соңгы язган 21 февраль тарихлы хатыңны алдым, мин аңа кадәр сиңа хат язган идем... Үзем сәламәт, төшләр белән саташма, алар наданлык, син культурный булырга тиеш... Мин үткән хатымда сине Казанга кайтару мәсьәләсен куйдым... кайтасы булсаң, яз, вызов жибәрермен, аны шуның өчен әйтәм, вызовны алып та, син кайтмасаң, вызов артыннан йөрү миңа ансат түгел, шуңа күрә конкретный жавап яз. Казанда бөтен нәрсә арзан, тормыш уңай, рәтле булсаң, бирермен, рәхәт яшәрсең. Мин хәзер татарның атаклы язучысы, безнең алгы көннәребез бик якты, бөтен халык дошманы булган герман пычракны без, советлар иле, итек астына салып таптадык, безнең хөрмәтле Сталин якты кояш күк һаман югары күтәрелә һәм Ватаныбызны да күтәрә. Без бәхетле, син, кызым, зарланып язма, үттеләр инде, безнең Ватан бөтен жир шарында иң зур урынны били, ал без, гөл без. Мин кичә картайсам да, бүген яшь, шат һәм рухлы, минем кызым да шундый булырга тиеш.**

**Кызым! Бу кәгазь — апаңның дәфтәре. Сиңа хат язганда йөри шуны алдым, рәсем һәм язулары да анык, бу кәгазьдән апаң исе килә, аның истәлеге булсын дип жибәрәм. Моны сакла, ул сиңа истәлек. Апаң больницага кергәндә аның чәчен кискәннәр иде, мин аны алып кайттым, сиңа бирермен дип. Ул миндә исән саклана, ул минем иң кадерле нәрсәм. Син хат язарга бик ялкау, мин картайган, минем бер хатыма каршы биш хатың булырга тиеш. Син язган хатларыңда 2 биттән соң 4 бит куясың, жүләрләр аз табылырлар, дөньяда иң яхшы нәрсә — искренность, шулай булмаган кеше, алдыйм дип үзе алдана. Сине сөеп атаң: Зәбиров Укмаси. 1945 ел. 6 март».**

Дәфтәрдән каерып алган кәгазьнең дүртенче битендә зоология дәресеннән рәсем. Буявы уңган инде, Миргазиз агай шәрехләмәсә, нәрсә икәнен дә беләсең юк. Әти кеше исә, үлгән кызын сагынып, рәсем астына болай дип язган: **«Монда апаңның язуы. Черепахаларны һәм микробларны эшләгән рәсеме. Хуш, кызым. Мин әле озак яшим. Ватаным өчен язып бетерәсе күп кенә хезмәтләрем бар».**

Бичара авыру кызының рәсем астында язу: «Сеть фиброцитов в слизистой желудке черепахи обработана Ад № 03».

Бу хакта мин кайбер шәрехләр бирергә тиешмен.

«Мин хәзер татарның атаклы язучысы». Бу — нәрсә? Мактануммы, ялганмы! Кызын алдаумы?

Һич юк. Күпме еллар «идән астында» яшәгән шагыйрь 1945 елда кинәт кенә «Совет әдәбияты» журналында басыла башлый. Егерме биш елдан соң! 1945 елда аның әлеге журналда «Ленин», «Жиңү бәйрәме», «Безнең бишек», «Тукайны сагыну», «Каюм абый Насыйри» әсәрләре басыла. Йә, әйтегез әле, бүгенге кайсы язучының «Казан утлары»нда бер елга биш тапкыр әсәр бастырганы бар? Биш елга бер күренеп алсаң, рәхмәт әйтерсең!

Тоткынлыктан чыккан әдип өчен нинди зур бәхет ул! Димәк, әлеге сүзләрендә ул хаклы.

Иптәш Сталинны мактау. Чын күңелдәнме? Казан шәһәре 1945 елда шулай, шагыйрь әйткәнчә, бик жиңел, рәхәт яшәгәнме? Миргазиз ага ялган сөйлиме? Бу — катлаулы мәсьәлә. Монда берничә факторны истә тотарга кирәк.

**1.** Хат «закрытая зона»га — Япония чигенә бара. Әле «империалистик Япония» белән исәп-хисап өзәселәр алда — август аенда. Хатның авторы — элеккеге сәяси тоткын. Илдә цензура яши. Хәтерлисезме? Фронттан килгән хатларда өчкырлы печать була иде: «Просмотрено военной цензурой». Сталинны, Казанны мактау — кабат төрмәгә керәсе килмәүдән.

**2.** 1945 елда тормыш рәхәт булганмы? Төрмәдән иреккә чыккан кешегә тормыш, һичшиксез, рәхәт. Ачмы син, ялангачмы — эш анда түгел. Иң әһәмиятлесе — ирек тә.

...Шуның өстенә шагыйрь һич тә көтмәгәндә елына биш тапкыр гонорар ала. Гонорар ул шундый акча — ул гел инде хезмәт куймыйча гына килеп кергән сыман була! Әйе, М. Укмаси 1945 елда бәхетле булган. Шуның өстенә әле «Совет әдәбияты» журналында аның тагы ике материалы ята, алары 1946 елда басылачак.

Шагыйрь ялганламаган.

М. Укмаси 1946 елның көзендә үлә. Шуннан алда гына аны Язучылар берлегенә әгъза итеп алган булалар. Бездәге алак-шалаклык: 1956 елда чыккан «Татар поэзиясе антологиясе»ндә аның үлгән елын 1974 дип күрсәтәләр. Кеше кадерен белмәүнең бер мисалы инде бу.

Неллинең хатында тагын нинди мәгълүматлар бар? Аның әнисе Ләйлә үзенең бөтен тапкан акчасын Казанга, әтисенә җибәреп барган. Кием-салым белән посылкалар җибәргән. Үги ана исә боларны сатып, байтак акча туплаган. 1946 елда Миргазиз ага, паралич алып, түшәккә егыла. Ләйлә Казанга кайтмый, үги ана белән мөнәсәбәтләр киеренке була.

Бары тик 1962 елда гына Ләйлә, үзенең кызы Неллине ияртеп, Казанга кайта: әтисе яшәгән йортны эзләп табалар — Бишбалта бистәсендә. Аларны өлкән яшьтәге бер карчык өенә алып керә, чәй янында менә ниләр сөйли.

М. Укмаси түшәккә егылгач, аның янына бер язучы килеп йөри. Карчыкның әйтүенә караганда, гомеренең соңгы чорында Миргазиз ага фантастик әсәрләр язган, арадан берсе — айга сәяхәт турында. Килеп йөргән язучы — Миргазиз аганың, имеш, кульязмаларын үзләштергән. Озак та үтми, үги ана да үлә. Мәетен озатып, өен җыештырганда аның түшәге астыннан бик күп акча табып алалар.

Нелли ул вакытта татарча бераз белгән әле. Хәзер исә бер авыз сүз белми һәм моңа уфтана. Үзе, күрәсең, укытучыдыр — чөнки хатында бер генә орфография хатасы юк. Казан ягы татарларыннан торган бер поселокта эшли. «Бабам ничә тел белгән, ә мин, аның оныгы, нибары рус телен генә беләм»,— дип сыкранып яза ул.

Неллинең бик тә, бик тә Укмас авылын күрәсе килә! Әнисе сагынып искә ала торган була бу авылны.

Бу кызның хатларында — шагыйрь язмышы, милләт язмышы...

Аянычлы, күз яшьле язмышлар... Әйткәнемчә, бабасының хатын ул Язучылар берлеге идарәсенә җибәргән. «Письмо высылаю. Татарии оно нужнее»...

## ХӨРМӘТЛЕ РЕДАКЦИЯ!

Журналыгызда «Әтием» дигән язмамны бастырып чыгаруыгыз өчен зур рәхмәтемне белдерәм. Әтием Мәңгәрнең тормыш юлын тасвирлаган бу язмамның шундый мәртәбәле журналда — «Казан утлары»нда басылып чыгып, халыкның киң катламына барып ирешәчәгенә бик сөендем.

Кирилл әлифбасын өйрәнгән булсам да, сезгә кирилл хәрефләре белән язу миңа авырга килә. Бөтен төрки халыкларның уртак латин әлифбасына күчүнең кирәк булуына һәм моның Исмәгыйл Гаспралының бу гасыр башында әйткәнчә «Телдә, фикердә һәм эштә берлек» белән генә тормышка ашуы мөмкин булачагына ышанып калам.

«Казан утлары»ның ноябрь санында басылып чыккан «Барлык илләрнең татарлары, берләшегез!» исемле мәкаләне укыдым. Анда да шул ук фикерләр белдерелгән түгелме?!

• Хөрмәт белән **САФИЯ ИМРЕ**
Истанбул

**Китап күзәтү**

# ФИКЕР ХӘЗИНӘСЕН БАРЛАГАНДА

1993 ел ахырында фәлсәфә фәннәре кандидаты Рашат Әмирхановның «Урта гасырларда татар иҗтимагый-фәлсәфи фикере» исемле фәнни хезмәтенең беренче китабы урыс телендә басылып чыккан иде. Ул хезмәтендә автор татар иҗтимагый-фәлсәфи фикеренең чишмә башын XI гасырда Кытай Төркестаны һәм Урта Азиянең бер өлешен биләп торган Караханилар дәүләтендә иҗат иткән төрки шагыйрь Йосыф Баласагуныйның «Котадгу белек» әсәреннән (1070 елда язып төгәлләнгән) дип саный. Бу бер дә гаҗәп түгел, чөнки Караханилар дәүләте ул чорларда төрки язма әдәбиятның традицияләрен дәвам иттерүче бердәнбер варис була. Караханилар дәүләтенең бу чорында күренекле төрки филолог Мәхмүт Кашгарыйның «Төрки сүзләр диваны» исемле гаять бай эчтәлекле зур күләмле сүзлеге төзелә. XII гасырда бу якларда иҗат иткән төрки шагыйрь Әхмәт Йүгнәкинең «Хакыйкать сые» әсәре, Әхмәт Ясәвинең (...—1166) хикмәтләре, Сөләйман Бакырганыйның (...—1186) шигырь һәм дастаннары безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Әдәбият галимнәре атаклы «Кыйссаи Йосыф» авторы Кол Галинең дә иҗатын шушы төбәк (Хорезмның көньягы) белән бәйләп тә тикшерәләр. (Наджиб Э. Н. О языке памятника начала XIII века «Кысса-и Юсуф» Али.— ж. «Советская тюркология, 1976, № 2, 74—88 бб.)

1994 ел башында Р. Әмирханов монографиясенең икенче кисәге дә нәшер ителде. Хезмәтнең бу өлеше Алтын Урда (Дәшти Кыпчак) һәм Казан ханлыгы дәверендәге фәлсәфи фикерләрнең эволюциясен анализлауга багышланган.

Совет тарих фәне Алтын Урдада үскән мәдәниятне күрмәмешкә салышып, аны төрле корамадан тегелгән юрган кебек дип, түбәнсетеп, хурлап килде, Алтын Урданы төрле халыкларның көчләп оештырылган дәүләте итеп күрсәтергә көчәнде. Хәлбуки, Алтын Урда дәүләте көнчыгыш (Хорезм) татарлары көче белән көнбатыш татарларын (ягъни кыпчак-угызларны) кушуны гамәлгә ашырган тарихи акт булды. Мондый берләшү процесслары һәм аның корбаннары булу урыс, герман, француз дәүләтләренең барлыкка килү тарихында да ачык күренә. Урыс князьлекләре исә Алтын Урдага ясак белән генә бәйле булып яшәделәр һәм герман-швед агрессиясеннән котылып калдылар.

Алтын Урданы төзегән Батый гаскәренең абсолют күпчелеген тәшкил иткән татарлар (кимаклар яки кыпчаклар) Хорезм дәүләтендә яшәп, аның бай культурасын төзүгә зур өлеш керткәннәр. Бердәм татар дәүләте төзелгәч, алар үзләренең культура традицияләрен Алтын Урданың бөтен почмакларында үстерәләр. Йөзләрчә татар шәһәрләре Хорезм традицияләрендә тәрбияләнгән осталар тарафыннан салына. Монгол экспансиясе вакытында төрки татарлар өстеннән хөкем йөрткән Батый хан һәм аның гвардиясе, Киев Русенда герман князе Рюрик, варяглар ничек эреп юкка чыкса, шундый ук рәвештә гаип булдылар. Батый гаскәре килеп 30—40 ел да тормый, яңа дәүләт ныклап яши башлый: акча суга, шәһәрләр кора, һөнәрләр үстерә, дөнья цивилизациясенең бер казанышы булган Ислам мәдәнияте белән язмышын бәйләүне дәвам итә. Алтын Урданың шәүкәте дәверендә, кыска гына вакытта, бердәм тел ситуациясе һәм тел белән бәйле фикер ядкарьләре туа.

Сарай әл-җәдид, Гөлстан, Мажар, Төмән, Татартөп, Укәк, Биләр, Болгар, Биштау һ. б. шәһәрләрдә ак таштан салынган биек манаралы мәчетләр, мәдрәсәләр, сарайлар, мунчалар һәм башка төрле биналар корыла. Шунысы игътибарга лаек: татарлар үз шәһәрләрен таш койма, сугыш манаралары белән ныгытып, аны юлбасар һәм бандитлар оясына әйләндермәгәннәр, чөнки бу калалар җирле халыкның сәүдә һәм һөнәрчелек ихтыяҗыннан чыгып төзелгән. Кайдадыр Кырым ягында генуялылар колония корып, аның стеналарының куәте белән мактанырга те-

ләгәч, татар кешесе: «Крепостьларны куркаклар гына кора»,— дип, бу эшнең җинаятьчеләр тарафыннан эшләнүенә ачыклык кертә. Менә шушы шартларда Алтын Урда — Дәшти Кыпчак җирләрендә поэзия, әдәбиятның төрле тармаклары үсә башлый. Бер кызык мисал:

Гарәп сәяхәтчесе Ибне Баттута 1333 елда Дәшти Кыпчакка килгәч, Үзбәк хан тарафыннан оештырылган мәҗлестә шагыйрьләр бәйгесен күргән. Димәк, бу илдә шагыйрьләр дә күп булган. Шуңа охшаш сүз Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьярда да очрый.

Ләкин ни аяныч: Аксак Тимернең кан койгыч яулары һәм урыс патшаларының йөз еллар буе алып барган мәдәни һәм биологик геноцид сәясәте, нигездә, татар халкына каршы юнәлтелгән иде. Хәтта ки, кабер ташларына да ябышып, аларны буган эзләр хәзергә кадәр сакланган. Бу хакта ташлар сөйли.

Язма ядкарьләрне бары татар халкы гына утлар, сулар кайнаган гасырлар төпкеленнән алып килгән. Цивилизацияле Русь, татарга кагылышлы, аның дәүләтчелегенә бәйләнешле ярлыкларны хәтта архивларында да калдырмаган, юкка чыгарган. Ә бит хәтта дәүләтчелеген югалткан католик поляклар да Туктамыш ханның ярлык-хатларын саклый алганнар.

Менә шундый золым сәбәпле, Алтын Урда һәм башка татар дәүләтләре дәвереннән әдәби истәлекләр чагыштырмача аз санда сакланып калган. Язма ядкарьләрнең сакланган кадәресе филолог галимнәр тарафыннан өйрәнелеп, һәркем аңларлык хәлгә китерелеп, матбугатта чыга башлады. Шул әдәби җәүһәрләрнең басмалары буенча галимнәребез урта гасырдагы татар фәлсәфи, эстетик карашларын өйрәнә башладылар. Рашат Әмирхановның бу хезмәте шушы юнәлештәге беренче фәлсәфә тарихыбыз сәхифәләрен ача.

Р. Әмирхановның хезмәте нинди чыганакларга таянып язылган соң? Монография Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф», Котбның «Хөсрәү һәм Ширин», Мәхмүд әл-Болгари әс-Сараиның «Нәһҗел-фарадис», Хөссям Кятибнең «Җөмҗөмә дастаны», Сәйф Сараиның «Гөлстан бий-төрки» кебек XIV гасыр авторлары, Казан ханлыгы чорыннан Мөхәммәдьяр поэмалары һ. б. ярдәмче материаллар нигезендә язылган.

Монографиядә әлеге саналып кителгән әдәби әсәр авторларының дөньяви һәм суфыйлык карашлары системасына анализ ясала. Хезмәткә нигез булып хезмәт иткән әсәрләр — нигездә, фарсы телендә иҗат иткән шагыйрьләргә ияреп язылган яки тәрҗемә кылынган. Ләкин урта гасырларда гамәлдә булган мондый иҗат методының үз нечкәлекләре бар. Татар шагыйрьләре, фарсы телендәге сюжетларга үз җәмгыятьләрендәге проблемаларны салып, яңа уй-фикерләрен бәян иткәннәр.

Монография авторы Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чоры татар шагыйрьләренең әсәрләренә шушы ноктадан чыгып анализ ясый.

Татар фикер тарихы XI—XII гасыр төрки шагыйрьләр Йосыф Баласагуный һәм Әхмәт Ясәви фәлсәфәләре белән тыгыз бәйләнештә. Аларның беренчесе — төрки дөньяның олы рационалистик фикер системасын төзесә, икенчесе суфыйлык карашлары системасын нигезли. Һәр ике шагыйрьнең дә әсәрләре урта гасыр төрки татар дөньясы өчен яхшы мәгълүм булган. Бу ике шагыйрьнең үсеп китүенә сәбәп — аларның бай фарсы фәлсәфи әдәбияты һәм мөселман мәдәнияте белән тирән танышлыгында. XI—XII гасырлардагы төрки дөньяның интеллектуаль өлгереше катлаулы гакыл хәзинәләрен үзләштерүгә әзерлекле була. Әлбәттә, моның өчен төрки дөньяның меңнәрчә еллык тарихи тәҗрибәсе ныклы нигез тәшкил итә. Йосыф Баласагуныйның әсәре рационалистик фикернең бай һәм катлаулы системасына ия. «Котадгу белек» авторы адәм баласына — хан булса да, кол булса да, ярлы булса да, бай булса да — гамәл итәрлек акыл хәзинәсе бирә. Ә инде Әхмәт Ясәви хикмәтләре мөселманнарны бу фани дөнья белән мавыкмаска, хакны истән чыгармаска өнди. Дөньяда белем алу кирәк, надан кешенең кадере юк, ул кырык ишәк йөген күтәрер, ди. Әхмәт Ясәвинең фәлсәфи карашларын Кол Гали дә кабул итеп, үзенең «Кыйссаи Йосыф» дастанында шуларны уздыра. Кол Галинең философиясе: сабыр иткән теләгенә ирешер, һәр кыңгыр эшнең җәзасы була дигән фикерләрдән гыйбарәт. Төрки поэзиянең титаннары Йосыф Баласагуный белән Әхмәт Ясәви иҗаты йогынтысы XIV гасыр шагыйре Мөхәммәдьяргача дәвам итә.

Рашат Әмирхановның XI—XVI гасыр татар иҗтимагый фикерен өйрәнү чыганаклары итеп әдәби әсәрләрне алганын алдарак күрсәттек инде.

Биш гасыр дәвамында иҗат иткән шагыйрьләрнең, әдипләрнең иҗатын тикшерү өчен махсус методик алым кирәк. Шундый методологик алым итеп монография авторы проблемалы анализ методын кулланган. Бу — зур көч һәм тирән төпченүне таләп иткән метод. Шул юл белән аерым ядкарь авторының системалы фәлсәфи карашлары ачыла. Әл-

бәттә, жиңел юл белән киткәндә, әсәрдән үзеңә кирәкле мәгълүматларны гына сайлап алу методы белән эш итәргә мөмкин булыр иде. Ләкин ул чакта без әдәби-тарихи процессны бозып, субъектив аңлаткан булыр идек. Ул чакта Йосыф Баласагуный, Әхмәт Ясәви, Сәйф Сараи һәм башка авторларның карашларын без саектырып, гадиләштерү тәсендә аңлатып, кыйммәтле һәм югары фикер байлыгына зыян китерер идек. Тикшерүче үзенең фәнни анализ объекты итеп алган әдәби ядкарьләрне тикшерүдә проблематик өйрәнүне хронологик эзлеклелек кысаларында алып бара.

Әсәрнең керешендә шушы дәвер рухи мирасының тарихи-фәлсәфи проблемаларын барлауга һәм аныклауга игътибар ителә.

Беренче бүлектә иҗтимагый-мәдәни аңның формалашуына алшартлар тәшкил иткән социаль-икътисадый, сәяси вәзгыять тәфтишләнә.

Икенче, өченче бүлекләрдә кереш бүлектә куелган проблемаларның чыганак материалы булган әдәби әсәрләрдә чишелеше ачылган. Ә материал итеп Хорезмда, Караханилар һәм Алтын Урда дәүләте дәвереннән сакланып калган төрки әдәбиятның үрнәкләре алынган.

Р. М. Әмирхановның әлеге фәлсәфи хезмәте — феодализм дәвере татар (төрки) әдәбиятындагы иҗтимагый-фәлсәфи мәсьәләләрне тикшерүдә беренче тәҗрибә. Монда аерым үзенчәлекләр бар. Урта гасыр төрки дәүләтләрдәге әдәбият һәм фәлсәфи (төрки-татар телендәге) истәлекләрдән тыш, гарәп, фарсы һәм башка телләрдә укылган әсәрләр хисабына тулыланып торган. Ләкин хәзергә, бу житешсезлеккә карамастан, галимнең хезмәте XI—XVI йөзләрдәге төрки-татарларда таралган суфыйчылык һәм гамәли фәлсәфәне шактый тулы күләмдә аңларга ярдәм итә.

Әлбәттә, бу фәлсәфә бөтен төрки дөнья өчен уртак хәлне чагылдыра. Татарның үзе яшәгән төбәкләрдә туган фәлсәфи чыганакларын әйләнешкә кертү, бу юнәлештәге фәлсәфи ачышларның эчтәлеген тагын да баетачак. Ә андый әсәрләр бездә юк түгел, алар соңгы елларда гына ачылдылар.

Урта гасырлардагы фәлсәфи фикер тарихын һәм аның үсеш этапларын тулы күрсәтү өчен аны монография рәвешендә өйрәнү бик мөһим. Хезмәттә фәлсәфәнең дәвер өчен гомуми һәм регион өчен үзенчәлеге булган аспектлары Кол Гали, Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр һәм башка төрки-татар авторларының әсәрләре аша ачыла. Әлбәттә, бу авторларның фикерләре алардан элек булган гарәп-фарсы чыганакларыннан килә, ләкин урта гасырларда татар әдәбиятында яшәп килгән «нәзирә» дип аталмыш иҗат методы җирле үзенчәлекләрне күрсәтергә комачауламаган. Мәсәлән, «Йосыф вә Зөләйха» темасына иҗат иткән Иран шагыйре Фирдәүси белән татар шагыйре Кол Гали версияләре һәркайсы аерым фәлсәфи үзенчәлеккә ия. XI—XVI гасырларда иҗат иткән авторларның әсәрләрен чагыштырма планда өйрәнгәндә генә дә, аларның һәркайсының үзенчәлекле дөньяви карашларын, алар күтәргән проблемаларны ачарга ярдәм итә алыр иде. Әлбәттә, бу фәлсәфи карашларның эчтәлеген, тамырларын тулы өйрәнү өчен борынгы язма истәлекләребезнең текстологик яктан эшләнгән басмалары кирәк. Шул ук вакытта теоретик планда татарның Ислам дине тарихы, суфыйчылык мәсьәләләре, Коръән һәм аның тәфсирләре, шәригать һәм хәдис җыентыкларына анализ ясалырга тиеш.

Автор XI—XVI гасырлардагы фәлсәфәнең яшәешен шул чорларның уртак төрки һәм татар әдәби ядкарьләре нигезендә өйрәнә. Йосыф Баласагуный һәм Әхмәт Ясәви әсәрләрендә тулы система рәвешендә чагылган дөньявилык һәм суфыйлык фәлсәфәсе, бу авторлардан соң иҗат иткән татар шагыйрьләре вә әдипләре тарафыннан кабул ителеп, киң татар дөньясына үтеп керә. Дөньявилык һәм суфыйлык фәлсәфәсе татар әдипләре әсәрләрендә саф һәм аерымланган рәвештә чагылмый. Урта гасырлардагы татар чыганакларында алар бер-берсенә каршы да куелмый, аерым өстенлек белән дә ялтырамый.

Рашат Әмирханов үзенең хезмәтендә урта гасырда яшәгән татар фикер ияләренең төрле юллар аша булса да гомумкешелек, гуманизм һәм иҗтимагый тәрәккыяткә хезмәт иткәнлекләрен күрсәтә. Әлбәттә, аларның карашлары эшкә ашмаслык рәвештә күренсә дә, асылда бу фикер ияләре кыерсытылганны яклаганнар, хакимнәрне гаделлеккә, мәрхәмәтле булырга өндәгәннәр. Урта гасыр татар фикер ияләре гомумкешелек тәрәккыятенә, гаделлеккә таба булган юлны дошманлык, көчләү, сугышлар аша түгел, ә бәлки гаделлек, адәмнәргә карата мәхәббәт, җәмгыятькә хезмәттә, дип күрсәтәләр.

Иҗтимагый фикер тарихыбызга багышланган бу фәлсәфи хезмәт узганны танып белү өчен генә түгел, ә бәлки бүгенге хәлләргә дә җавап табарлык рухи хәзинә булып житешкән.

**Марсель ӘХМӘТЖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты

## Муса Акъегет

(1864—1923)


Яңа заман әдәбиятыбызның беренче романчысы Муса Акъегетнең тууына быелгы 3 декабрьдә 130 ел тулды.

Ул элекке Пенза губернасы Чембар (хәзерге Белинск) шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килгән. Мусаның бабасы Алтынбай Акъегет Чембар өязенең Мәчәли авылында туып-үскән, 25 ел солдатта хезмәт иткән, Наполеон гаскәрләренә каршы сугышта батырлык күрсәткәне өчен прапорщик һәм дворян дәрәҗәләренә ирешкән. Әдипнең атасы Мөхәммәтҗан башта Мәчәлидә, аннары Чембарда дүрт сыйныфлы урыс мәктәбендә белем алган. Әнә шундый тырыш, зиһенле һәм гайрәтле нәсел баласы Муса яшьтән үк гыйлемгә һәвәслек күрсәткән — башта ул атасының туган авылында татарча укырга-язарга өйрәнгән, аннары Чембарның дүрт сыйныфлы урыс мәктәбендә тәрбияләнгән, 1878 елда Пенза шәһәренә килеп, беренче гимназиядә гыйлем эстәргә керешкән. Ул монда да сабакташлары арасында тырышлыгы, зирәклеге белән аерылып торган: урыс телен камил үзләштерүгә өстенә, французча да өйрәнгән. Урыс һәм Европа әдәбиятларын уку белән бергә, татар мәдәнияте белән дә даими кызыксынган. 1884 елда гимназияне барлык фәннәр буенча «яхшы» билгесенә тәмамлагач, Мәскәү, аннары Казан университетларына керергә тырышкан, ләкин патша хөкүмәтенең урыс булмаган милләтләргә карата уздырган чикләү сәясәте Муса Акъегеткә дә югары белем алу юлын кискән.

Шуннан соң егет иҗат эшенә керешкән һәм 1886 елда Казан университеты типографиясендә үз нәширлегендә «Хисаметдин менла» романын бастырып чыгарган. Аннары Кырымга китеп, Бакчасарай шәһәрендә «Тәрҗеман» гәзитендә эшләргә тотынган. Ләкин ул монда озак тукталып тормаган, 1888 елда Төркиягә күчеп киткән. Истанбул шәһәрендәге Мөлкия мәктәбен тәмамлаган, аннары шунда ук урыс теле укытучысы итеп калдырылган. Ул монда да матбугат эшләре белән кызыксынып яшәгән, 1908 елгы Яшь төрекләр буржуаз инкыйлабыннан соң, «Мәтин» («Текст») исемле гәзит чыгарырга керешкән. 1914 елда Төркия вакыфлар идарәсе Казаннан сатып алган Катанов китапларын тәртипкә салу эшен башлап җибәргән. Гомере азагынача шунда көч түгеп, 1923 елның 24 сентябрендә Истанбул шәһәрендә вафат булган.

«Хисаметдин менла» әсәре яңа дәвердәге беренче татар романы булуы белән генә түгел, халкыбыз тормышында иң әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрүе һәм аны заманы өчен сәнгатьчә камил гәүдәләндерүе белән дә әдәбиятыбыз тарихына кереп калды. Әсәрнең үзәккә куелган мәсьәләсе — көнкүреш һәм мәдәният өлкәләрендә феодализм калдыкларыннан арыну өчен көрәш. Романның баш каһарманы Хисаметдин менла «кеше тормышында бер бәһале һәм яхшы нәрсә — хөррияттер», дип белдерә. «Хөрриятсез яшәү авыр икәнлеген мин дә беләмен»,— ди аңа каршы Хәнифә. Романда әнә шулай ирекқә, хатын-кыз азатлыгына ирешү үзәккә куела. Ләкин бу дәвердә татар тормышында моны чынга ашыру бик кыен була. Көнкүрештәге хорафатлар, мәгариф тармагындагы дини фанатиклык, дөньяви белем алуны тышаулаган схоластика татар тормышын яңартуга комачаулый. Яшь әдип әнә ул искелекне фаш итүгә бөтен көчен һәм сәләтен бирә, яңалык тарафдарларын мәхәббәт белән сурәтли. Хезмәт сөюне, тормыш итәргә булышырлык белем-тәрбия алуны яклый, күркәм әхлаклы каһарманнарның тулы бер төркемен күз алдына бастырып, аларны укучыларга үрнәк итеп куя, милли һәм дини идеалларын замандашлары күңеленә дә сеңдерергә тырыша.

# ДАНЛЫ ЕЛЛАР АВАЗЫ



Журналның алдагы саннарының берсендә («Казан утлары», 1993, № 4) атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәренең күмәк фоторәсеме басылып чыккан иде. Әйтергә кирәк, анда сурәтләнгән кешеләрнең күпчелеге татар һәм кардәш мөселман халыкларының мәдәнияте турында якты эз калдырган шәхесләр. Шуңа булса кирәк, әлеге басма журнал укучыларда зур кызыксыну уятты һәм редакция тарафыннан әлеге шәхесләрнең язмышы турында тәфсиллерәк мәгълүматлар бирүне үтенеп сораган күп кенә хат-хәбәрләр алынды. Бүген без, аларның теләген искә алып, рәсемдә сурәтләнгән күренекле шәхесләрнең берсе — Закир Шакировның кыскача тәрҗемәи хәле турында сөйләп үтмәкче булабыз.

Башкортстанның Бөре каласыннан ерак түгел генә урнашкан Карагаелга авылында, хәлфә гаиләсендә туып-үскән Закир 1898 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бусагасын атлап керә. Сәләтле яшүсмер, шәкертлегенең беренче көннәреннән башлап, уку-укыту кысаларында гына чикләнеп калмыйча, һәрдаим үзенең белемен күтәрү белән шөгыльләнә. Ул Каюм Насыйри, Н. Катанов, Фатыйх Әмирхан, Вафа Бәхтияров кебек остазлары һәм дуслары белән тыгыз аралашып яши. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә, алдан килгән гадәт буенча, киң эрудицияле һәм алдынгы карашлы шәкертләр, өлкән сыйныфларга күчү белән, мөгаллимлек вазыйфаларын үти башлаганнар. Шул рәвешле, Закир да география, урыс һәм төрек теле буенча дәресләр бирә. Аның география дәресләренең берсендә Габдулла Тукай да була һәм эпидиаскоп, диапозитив кебек техник чаралар куллануына аеруча басым ясап, яшь мөгаллимнең педагогик сәләтенә югары бәя бирә. Гаҗәп тә түгел, 1909 елда Закир Шакиров тарафыннан төзелгән география дәреслеге революциягә кадәр берничә тапкыр нәшер ителә. Белемгә омтылу аны 1912 елда Шанявский исемендәге Мәскәү университетының тарих-философия факультетына (бу демократик рухтагы югары уку йортында Русия халыкларының бик күп алдынгы карашлы вәкилләренә олы фән дөньясына юл ача) алып килә. 1915 елдан Закир Шакировның иҗат эшчәнлеге Башкортстан белән бәйле. Биредә ул күренекле тел белгече булып танылa, профессор дәрәҗәсенә ирешә, республикада беренче булып «Атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек була. Аның тарафыннан 100 дән артык китап һәм мәкаләләр һәм дистәләгән уку әсбаплары нәшер ителә. «Совет мәктәбе» журналында басылып чыккан истәлекләренең — соңгы хезмәтенең Тукайга багышлануы да, безнеңчә, эчке бер мәгънәгә ия. Ул күп санлы шәкертләр тәрбияләп үстерде. Кызы — Л. З. Шакирова да — башлаган эшен дәвам итте, ул озак еллар дәвамында Казан педагогия институтында фәнни һәм методик эш алып барды.

**Булат СОЛТАНБӘК**

# ЕЛЪЯЗМА БИТЛӘРЕННӘН

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ТӨЗЕЛҮГӘ 60 ЕЛ

**1932, май.** Татарстан Совет язучыларының Бердәм союзын төзү буенча оештыру комитеты төзелә. Рәисе — Г. Нигъмәти, З. Гали (урынбасар), М. Әмир (секретарь); комитет әгъзалары — И. Гази, К. Нәҗми, Г. Гали, Г. Иделле, Ш. Камал, Б. Зернит, Т. Имаметдинов.

**1933, 14 гыйнвар.** Беренче киңәйтелгән пленумы уздырыла. Шушы ук айда оештыру комитетының матбугат органы булган «Совет әдәбияты» журналы (элеккеге «Безнең юл», «Яңалиф», «Атака» басмаларының дәвамчысы) чыга башлый.

**1934, 29 июнь.** Совет язучылар союзына әгъзалар кабул итү Үзәк (Мәскәү) комиссиясе утырышында, Татарстаннан гаризалар каралып, түбәндәгеләр әгъза итеп алына: К. Тинчурин, Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, К. Нәҗми, Ш. Камал, Г. Гали, Г. Толымбай, Ф. Бурнаш, М. Әмир, Х. Туфан, Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Гали, И. Гази, М. Крыймов, М. Җәлил, Ә. Фәйзи, И. Туктаров, М. Максуд, Ф. Кәрим, С. Баттал, Т. Госманов.

**1934, 25—29 июль.** Казанда Беренче Бөтентатарстан совет язучылары съезды эшли. Съездда тавыш бирү хокукы белән 82, киңәш бирү хокукы белән 17 делегат катнаша. Почетлы президиумына М. Горький һәм Г. Ибраһимов сайлана.

Бөтенсоюз съездына тавыш бирү хокукы белән М. Горький, Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, К. Тинчурин, Г. Гали, Г. Нигъмәти, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Толымбай, И. Гази, Л. Гыйльми, Б. Киршон, Новиков-Прибой делегат итеп сайлана.

**1934, 29 июль.** Татарстан совет язучылар Союзы идарәсенең беренче утырышы була. Идарә рәисе — К. Нәҗми, секретарь К. Төхфәтуллин.

**II съезд — 1950, 13—15 июнь.** Идарә рәисе — Г. Гобәй, урынбасарлары — М. Әмир, Ә. Исхак, җаваплы секретаре — С. Вәлиди.

**1953, 4 апрель.** ТЯС идарәсенең отчет сайлау җыелышы була.

Җыелыш яңа рәис сайлый. Г. Бәширов — рәис. 1958 елга кадәр эшли.

**III съезд — 1954, 24—26 июнь.** «Совет әдәбиятының торышы һәм бурычлары» дигән доклад белән Г. Бәширов чыгыш ясый. Г. Бәширов идарә рәисе итеп калдырыла.

**IV съезд — 1958, 16—19 июнь.** Идарә рәисе — А. Шамов, урынбасарлары — М. Әмир, Г. Кашшаф, секретаре — З. Нури.

1959 елның башыннан идарә каршында яшь һәм башлап язучылар өчен даими иҗат семинары эшли башлый.

**V съезд — 1963, 7—10 февраль.** Докладчы — М. Әмир. Рәис — М. Әмир, секретарь — Р. Мостафин.

Шул ук елның 23 мартында Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге эшли башлый. Җитәкчесе — Г. Ахунов.

**VI съезд — 1965, 14—15 гыйнвар.** Идарә рәисе — М. Әмир, җаваплы секретаре — З. Нури. 1965 елның июненнән «Совет әдәбияты» журналы «Казан утлары» исеме белән чыга башлый.

**VII съезд — 1968, 25—26 март.** Идарә рәисе — И. Гази, җаваплы секретаре — З. Нури. 1971 елның 21 февралендә И. Гази вафат булгач, идарәне З. Нури җитәкли.

**VIII съезд — 1974, май.** Идарә рәисе — Г. Ахунов.

**IX съезд — 1979, май.** Идарә рәисе — Г. Ахунов.

**X съезд — 1984, май.** Идарә рәисе — Т. Миңнуллин.

**XI съезд — 1989, май.** Идарә рәисе — Р. Мөхәммәдиев.

**XII съезд — 1994, май.** Идарә рәисе — Р. Мөхәммәдиев.

Бүгенге көндә Татарстан Язучылар берлегендә 247 язучы әгъза булып тора.



Татарстан Язучылар берлеге урнашкан бина *(Комлев урамы, 14 йорт)*.



Татарстан Язучылар оешмасының беренче рәисе Кави Нәҗми бер төркем совет язучылары арасында.



Алар — яңа әдәбиятны тудырырга килгән гыйсьянчылар... Гадел Кутуй, Һади Такташ, Габдрахман Минский.



Татар әдәбияты аксакаллары Галимҗан Ибраһимов *(сулда)* һәм Мәҗит Гафури.



«Рухи яктан мин Казанда тудым»
М. ГОРЬКИЙ.


Нәби Дәүли Казандагы М. Горький музеенда олуг әдип иҗатына багышланган стенд каршында.



Тоталитар режим җәһәннәмен үткән татар әдипләре. Уртада — Татарстанның халык шагыйре, Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, шагыйрь Хәсән Туфан, уңда — Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Ибраһим Сәлахов һәм язучы Сәббух Рәфыйков.



Татарстанның халык язучысы, Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Нәкый Исәнбәт.



Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Мирсәй Әмир.



Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Ибраһим Гази.



Татарстанның халык язучысы, Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әмирхан Еники.



Бер төркем әдипләр союз «штабы» балконында *(Бауман урамы, 19 йорт)*. Сулдан — уңга: Нәби Дәүли, Сәрвәр Әдһәмова, Баян Гыйззәт, Хәсән Хәйри, Хәсән Туфан, Ибраһим Гази *(эшләпәдән)*, Гомәр Бәширов, Әнвәр Давыдов. *Алтмышынчы еллар.*



Кәнәфидә — Татарстанның халык шагыйре, Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Сибгат Хәким; басканнар — Әмирхан Еники һәм Риза Ишморат.



Татарстанның халык язучысы, Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Гомәр Бәширов.



Татарстанның халык язучысы, Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Фатих Хөсни.



Бакый ага Урманче — сыннар иҗат итүче бөек шәхес һәм җырчы-шагыйрь дә иде.



Әдипләр гомер-гомергә халыклар дуслыгы илчеләре булдылар. Уңнан — сулга: Гомәр Бәширов, төркмән шагыйре Берды Кербабаев, Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир, Хатип Госман. *Илленче еллар.*



Өлкән әдип һәм күренекле шагыйрь Салих Баттал.



Татарстанның халык шагыйре, Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Гамил Афзал.



Танылган шагыйрә Сажидә Сөләйманова.



Һәр елны Казанда, Тукай-Кырлайда һәм татар халкы яшәгән бик күп төбәкләрдә Тукай рухына багышланган шигырь бәйрәмнәре уздырыла.



Тууына 100 ел тулу уңае белән Казанда Тукай музее (Тукай урамы, 74 йорт) ачылды. Тантанадан бер күренеш.



Казанда — шигырь бәйрәме.



Тукай-Кырлайда — шигырь бәйрәме.





Советлар Союзы Герое, СССРның Ленин бүләге лауреаты шагыйрь Муса Җәлил.



Фронтовик шагыйрь Фатих Кәрим.



Балалар шагыйре Абдулла Алиш.



Ветераннар, ветераннар...

Беренче рәттә (сулдан — уңга): Салих Баттал, Хатип Госман, Гариф Галиев, Әхмәт Исхак, Риза Ишморат, Мөхәммәт Садри, Газиз Иделле, Фатих Хөсни, Нури Арслан; икенче рәттә — Баян Гыйззәт, Әбрар Кәримуллин, Сафа Сабиров, Атилла Расих, Ибраһим Нуруллин, Мәхмүт Хөсәен, Мөнир Мазунов, Әмирхан Еники, Шамил Шаһгали; өченче рәттә — Маннур Саттаров, Мәгъсум Насыйбуллин, Кави Латыйп, Әдип Маликов, Сәет Шәкүров, Нәби Дәүли.



Җәлилгә — чәчәкләр!



Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Габдрахман Әпсәләмов.



Танылган фронтовик шагыйрь Зәки Нури.



Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев.



Татар язучыларының X съезды барган көннәрдә. Сулдан — уңга: Марсель Галиев, Равил Рахман, Рашат Низамиев, Камил Кәримов, Рафаэль Мостафин, Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ идарә рәисе, Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Туфан Миңнуллин белән әңгәмә вакытында.



«Өч баһадир.»
Татарстанның халык язучылары Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Гариф Ахунов.



Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Андерсен исемендәге халыкара диплом лауреаты Шәүкәт Галиев.



Танылган шагыйрь, яшьләрнең М. Җәлил исемендәге бүләге лауреаты шагыйрь Ренат Харис.



Татарстан язучылары берлеге оешуга 60 ел тулу уңаеннан үткәрелгән утырышта катнашучы идарә әгъзалары (1994).

Беренче рәттә (уңнан — сулга) — идарә рәисе урынбасары Зиннур Мансуров, Мәдинә Маликова, Равил Фәйзуллин, Шәүкәт Галиев, Әхсән Баянов, Владимир Корчагин, Рабит Батулла, Аяз Гыйләҗев, Рөстәм Мингалимов; икенче рәттә — Илдар Юзеев, Ренат Харис, идарә рәисе Ринат Мөхәммәдиев, Җәүдәт Дәрзаманов, Гариф Ахунов, Фәиз Зөлкарнәй, Рахмай Хисмәтуллин, Рәфкать Кәрами, Азат Әхмәдуллин, Фоат Галимуллин, Тәлгать Галиуллин, Газинур Морат, оештыру эшләре буенча рәис урынбасары Мансур Шиһапов.



Татар әдәбиятының төп басмасы булган «Казан утлары» журналы редакциясе коллективы: беренче рәттә (сулдан — уңга) — Шаһинур Мостафин, Маргарита Лузина; икенче рәттә — Наис Гамбәр, Гөлзадә Моратова, Рәдиф Гаташ, Тәслимә Сибгатуллина, Шамил Маннапов, Тәуфикъ Әйделдинов, Флера Сабирова, Мансур Вәлиев, Гөлназ Хөснетдинова, Рашат Низамиев; уртада — баш мөхәррир, Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Равил Фәйзуллин.



«Идел» журналы редакциясе коллективы: беренче рәттә (сулдан — уңга) — Нәбирә Гыйматдинова, Гөлсирә Гайнанова, баш мөхәррир Фәиз Зөлкарнәй, Роза Кожевникова, Рәфикъ Юнысов; икенче рәттә — Альберт Тәхәвиев, Марат Закиров, Фәридә Хәсьянова, Ләис Харрасов.



Язучыларның XII съезды ачылган көн *(1994, 3 июль)*. Уңнан — сулга: Татарстан язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев, үзбәк язучысы Тимур Пулатов, рус шагыйре Сергей Михалков, Татарстан Республикасы президенты Минтимер Шәймиев, шагыйрь Равил Фәйзуллин, композитор Әнвәр Бакиров.

# 1994 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

«Татарстан Республикасының халык язучысы», «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исемнәр бирү турында. № 2

1994 ел өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. № 6

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XII СЪЕЗДЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ

Татарстан язучыларының XII съезды алдыннан №№ 1—5.
Мөхәммәдиев Р. Язмышлар хәл ителгәндә. № 8
Морат Г. Шигърият — сәясәт түгел. № 8
Зөлкарнәй Ф. Фидаиләр эше. № 8
Миңнуллин Р. Балалар дөньясы. № 8
Мингалим Р. Уңай күренешләр. № 8
Корчагин В. Тормыштан калышмыйча. № 8
Еники Ә. Хәерле сәгатьтә. № 8
Фәйзуллин Р. Сүз көче. № 8
Баян Ә. Кыен чаклар. № 8
Татарстан язучыларының XII съезды резолюциясе, декларациясе һәм республика җитәкчеләренә мөрәҗәгате. № 8
«Казан утлары» журналы һәм Татарстан язучылар Берлегенә яңа кабул ителгән әгъзалар турында белешмәләр. № 8

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Бадыйкшан Л. Мәртәт. *Роман.* №№ 5, 6
Баянов Ә. Урланган ай. *Повесть.* № 1
Галиев Ә. Һәр солдатның үз язмышы. *Документаль повесть.* №№ 7, 8
Гомәр Г. Шаһмиран. *Мажаралы повесть.* № 9
Закир Л. Гөргөри. *Гыйбрәтле хикәя.* № 8
Зарипов С. Юл чатында кабер. *Парчаистәлек.* № 2
Зәйнуллин З. Урам. *Повесть.* № 5
Зәнкиев Я. Иртеш таңнары. *Роман.* №№ 10, 11, 12
Зыя С. Ике Әнисә, бер Мәхмүт. *Хикәя.* № 3
Миңнуллин Т. Шундый хәлләр. № 6
Мәһдиев М. Сагынам, дуслар, илкәйне. № 10
Сабиров С. Хәвефле сәфәр. *Повесть* № 10
Сирматов И. Сүнгән учак. *Хикәя.* № 3
Таврин Г. Афәт. *Роман-трилогиянең өченче китабы.* № 2
Фасиев К. Безнең авыл мәзәкләре. № 1
Фәизов Р. Еллар үткәч. *Хикәя.* № 4
Яхин Ф. Соңарган дастан. *Хикәя.* № 2
Хәбибуллин М. Хан оныгы Хансөяр. *Тарихи роман.* №№ 3, 4
Әйди Т. Кардәшләр кочагында. *Сәяхәтнамә.* №№ 8, 9
Әмирхан Р. Үлмә, Әхмәтхан! *Повесть.* № 4
Әмәк Ф. Чытырманда кош оясы. *Повесть.* №№ 11, 12

## ШИГЪРИЯТ

Акъегет. Яңа шигырьләр. № 8
Афзал Г. Ачы язмышлар. *Шигырьләр.* № 3
Баян Ә. Тетрәүләрнең үзәгендә. *Шигырьләр.* № 9
Биккол Ш. Туфан елмаюы. *Шигырьләр.* № 5
Бәширова Ф. Хатын-кызларга. *Шигырьләр.* № 3
Габдрәхим Ф. Урда. *Шигырьләр.* № 5
Габиди Ә. Була төрле чаклар. *Шигырьләр.* № 12
Гадел Ә. Казан белән серләшү. *Шигырьләр.* № 8
Гатауллин Рәш. Агыйдел, Чулман, Идел... *Шигырьләр.* № 4
Гаташ Р. Бер йолдызның нуры. *Шигырьләр.* № 7
Гыйләҗев И. Кем икәнем торсын күренеп. *Шигырьләр.* № 7
Гәрәева С. Нинди тын. *Шигырьләр.* № 3
Закиров Р. «Аккош күле» дәфтәреннән. *Шигырьләр.* № 6
Зөлфәт. Тылсым. *Шигырьләр.* № 6
Иделбикә. Ашыктырма, гомер. *Шигырьләр.* № 12
Идиятуллин Р. Шундый көннәр була. *Шигырьләр.* № 10
Иксанова И. Яшәү серен ачтым. *Шигырьләр.* № 6
Латыйп К. Турагачта кош оясы. *Шигырьләр.* № 5
Ләйсән. Һаман әле хыялыңда гизәсеңме? *Шигырьләр.* № 8
Маннап Ш. Рәсүлнең җиргә кайтуы. *Шигырьләр.* № 9
Мансуров З. Татар бугазы. *Шигырьләр.* № 7
Мулла-Гали С. Нигә өшим? *Шигырьләр.* № 11
Мәдияров Н. Елларымны бизи шигърият. *Шигырьләр.* № 11
Мөдәррисова Х. Кырык яшьтә. *Шигырьләр.* № 12
Мөэминова Э. «Мин сине я-ра-там!» *Шигырьләр.* № 5
Нәзиров М. Язганым савап булырмы? *Шигырьләр.* № 11
Нәҗми Н. Көнләшү. *Шигырьләр.* № 8
Рахман Р. Торна жиле. *Шигырьләр.* № 6
Рәшит Ә. Аккан суларга карап. *Шигырьләр.* № 2
Сибгат К. Киләчәкне уйлап. *Шигырьләр.* № 2

Султи Р. Шүрәле. *Шигырьләр.* № 12
Сөләйман Җ. Казан елгасында су түгелдер. *Шигырьләр.* № 1
Фәйзуллин Р. «Заман кемнең заманы?» *Яңа шигырьләр.* № 10
Харис Р. Мәхәббәт шигырьләре. № 11
Харрас Ә. Гармун бәйрәме. *Шигырьләр.* № 4
Шагыйрьҗан Л. Багышлану. *Шигырьләр.* № 10
Шиһап Р. Рәхмәт, кәккүк! *Шигырьләр.* № 6
Юзеев И. Мин фәрештә түгел. *Шигырьләр.* № 1
Юзеев И. Моңсу шигырьләр. № 9
Яруллин Ф. Көена каләм — яктылыкта. *Шигырьләр.* № 2
Әгъләм М. Түземлекләр бирсен. *Шигырьләр.* № 5
Әхмәдиев Н. Бүләк. *Шигырьләр.* № 10
Әхмәтҗан Роб. Кызыл яран. *Шигырьләр.* № 8
Әхмәтҗанов Рәшит. Безнекеләр шулай җан бирми. *Шигырьләр.* № 1
Әһлия Ф. Ашкынулар юшкыны. *Шигырьләр.* № 3
Җиһангирова Ш. Ышанам. *Шигырьләр.* № 3

## ЖУРНАЛДА — ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ АНТОЛОГИЯСЕ

Бакыргани С. Шигырьләр. № 7
Яхин Ф. Әхмәт Ясәвинең мирасы. № 6

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Сәфәргалиева Ф. Бәлки... *Шигырьләр.* № 3

## ОСТАХАНӘ

Тарханова Ф. Хушлашу. Шигырьләр. № 7

## ӘДӘБИ МИРАС

Акыш Г. Гаяз Исхакый: Идел-Урал милли азатлык хәрәкәтенең бөек юлбашчысы. № 2
Гордлевский В. Мөхәммәт Гаяз Исхаков. № 2
Максуди С. Мәгыйшәт. *Милли хикәя.* № 7
Рәмиев С., Хөсәенов Г. Мөхәммәтгаяз әфәнде. № 2
Салихов Һ. Шигырьләр. № 12
Әйди Т. Үлемсез исем. № 2

## ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕННӘН

Чокум С. Розалия Ана. *Хикәя.* № 6

## КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ШИГЪРИЯТЕННӘН

Гашыйк Гомәр. Шигырьләр. № 4
Җомабаев М. Ут. *Шигырьләр.* № 2

## ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ — КҮҢЕЛЛӘР ХУШЛЫГЫ

Исламов Ф. Татар-мари мәдәни бәйләнешләре. № 4

## ПУБЛИЦИСТИКА

Бәдретдинов Х. Еpактагы якыннарыбыз. № 1
Вәлиева З. Мөстәкыйльлеккә Татарстанның үз юлы. № 3
Госманов М. Котсыз еллар кайтавазы. № 5
Зыятдинов Ф. Тоннельдан чыгар юл бармы? № 7
Ибраһимов Ф. «Икс йөз елдан соң инкыйраз» булырмы? *(Яки урыс-татар мөнәсәбәтләренә карата)* № 12
Латыйфи Ф., Якуш Р. Шыгырдан феномены. № 3
Мортазин Р. Кырым аксакалы. № 4
Низамиев Р. Ут һәм җыр. *(Фәрит Яруллинның тууына 80 ел үңаеннан)*
Низамиев Р. Тукай белән әңгәмәләр. № 4
Хәкимов Х. Чехлар заманында. № 2
Әмирхан Р. Мәдәниятебез сагындагы Мәлинә. № 10
Әхмәтҗанов М. Мәгърифәт нуры чәчәр... № 11

## МӘСЬӘЛӘГӘ БЕР КАРАШ

Әхмәтҗан Р. Хыял һәм хакыйкать. № 1
Әхмәтҗанов М. Юкәдә икән чикләвек, яки ничек тарихны бозалар. № 1

## ХӘТЕР

Нәкъкаш Н. Бүләгем. *Шәмаил.* № 8
Фәхретдинов Г. Кайда минем Илем? *Кыйсса.* №№ 8, 9
Хафизова Р. Соң аңладым... № 9
Әхмәтсафа Ш. Сез — хөкемдар! Шигырь. № 8

## МӘДӘНИ МИРАС

Ризаэтдин бине Фәхретдин хатлары. № 7

## ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Поварисов С. Энжеләр кайда ята? № 7
Әмирхан Р. Газиз теленә, татар, тобәмәче алтатар! № 1

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Вәли М. Яңа исемнәр — яңа әсәрләр. № 1
Вәли М. Әмирхан ага Еники белән әңгәмә. *(Әдипкә 85 яшь тулу уңаеннан)* № 3
Галиуллин Т. Кичерерләр безне, кичерерләр... *(Әдәби тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллинның иҗат портретына штрихлар.)* № 6
Галимуллин Ф. Җавап бирер чак. *(В. Нуруллин иҗаты турында уйлану.)* № 4
Зарипова Ч. Сагыйть Рәмиев һәм Насими. № 11

Хатипов Ф. Тәнкыйть реализмы булганмы? № 7
Хисамов Н. Алтын Урданың шигъри мәдәнияте. № 5
Хафизов С. Ислах, яки яманаттан арлыкау. № 4
Әхмәтҗан М. Шигърият аша тәрбия. № 5

## ЮМОР-САТИРА

Сафиуллин Ә. Осталар. *Хикәя.* № 4

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Галимуллин Ф. Шәркый рухыбыз тамырлары. № 12
Гыйләҗиева-Хәмидуллина Р. «Сихерче»ләр кирәк дөньяга. № 4
Мостафин Э. Сабыр савытлары бар икән. № 3
Мотыйгуллина Ә. Күгәрчен сөте?! № 1
Әхмәт Р. Кеше күңелен мин үтәли күрәм. № 9
Әхмәтҗанов М. Фикер хәзинәсен барлаганда. № 12

## БЕР ӘСӘР ТАРИХЫ

Яруллин Ф. «Сөембикә егет сайлый». № 5

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Сагынып килдедәр. Яратып киттеләр. *(Балык бистәсе районында узган әдәби очрашу көндәлеге.)* № 6

## ФӘН

Нигъмәтуллин Ә. Яңа дәреслекләр ни сөйли. № 9
Фәйзерахманов Г. Берәгәйле булсын иде. *(Булачак «Татар энциклопедиясе»нә бер караш.)* № 11

## ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Галләмев Р. Казан арты тарихында нугайлар. № 9
Дубин А. Борынгы открыткаларда — Казан. № 7
Имре С. Әтием. № 7
Каппелер А. Идел буе төркиләренең килеп чыгышы. № 10
Рүрлих А. Алтын Урданың бүгенге варислары. № 11
Солтанбәк Б. Канлы эзләр. № 6
Хара-Дауан И. Үткән зурлыкларга кайту. № 4
Хәмидуллин Л. Гыйбрәтле шәҗәрәләр. № 7
Әмирхан Р. Фаҗигале еллар авазы. № 2
Әхмәтҗанов М. Һәр ялтыраган алтын түгел. № 7

## МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Кәримов Г. Фәхретдинов шәҗәрәсе. № 4
Хәмидуллина Р. Гаяз Исхакый — хәлфә. № 10
Әхмәтҗанов М. Кульязма китапларда кече жанрлар. № 3
Исмәгыйль Н. Тукай иҗатында дини һәм мифологик мотивлар. № 6

## ТЕЛЕБЕЗ ТАРИХЫННАН

Өнәр М. «Барыш» сүзе хакында. № 9

## ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

Шамил Усманов көндәлеге. № 11
Солтанбәков Б. Ул елларда... *(Шамил Усманов көндәлеге турында галим фикере).* № 11

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕНДӘ — ТАТАР ШӘХЕСЛӘРЕ

Ибраһимова Ф. Ибраһим Биккулов. № 6
Солтанбәк Б. Затлы нәсел улы. № 5
Солтанбәк Б. Данлы еллар авазы. № 12
Хәмидуллин Л. Яңа табышлар. № 3

## СӘНГАТЬ

Вәлиева-Сөләйманова Г. Бәхет кошы кая куна? № 2
Дулат-Алиев В. Бәхет кошының канаты тиеп киткәндер... № 3
Солтанбәк Б. Олпатлык. № 4

## ЮБИЛЕЙЛАР

### М. УКМАСИНЫҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ

Мәһдиев М. Кара тарихтан бер ләүхә. № 12

### СӘЙФИ КУДАШНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Сабиров С. Канатлы уйлар җырчысы. № 9
С. Кудаш хатлары. № 9
Хәсән Туфан һәм Сәйфи Кудаш хатлары. № 10

### РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Туган җир җылысы. № 1

### МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВКА 60 ЯШЬ

Фәйзуллин Р. Аның яшәү рәвеше. № 5

### РАХМАЙ ХИСМӘТУЛЛАГА 60 ЯШЬ

Гаташ Р. Тынгысыз йөрәкне котлап. № 9
Хисмәтулла Р. Төрле еллардан. *Шигырьләр.* № 9

### МАРСЕЛЬ СӘЛИМҖАНОВКА 60 ЯШЬ

Гыйләҗев А. Командор. № 11

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ТӨЗЕЛҮГӘ 60 ЕЛ

Еллъязма битләреннән. № 12

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНА 75 ЕЛ

Әшрәфҗанов Х. «Китап тотып ант итәм...». № 12

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Гаташ Р. Шагыйрь Нур Гайсинга 80 яшь. № 11
Самат Шакирга 70 яшь. № 4

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Галиуллин Т. Ул яшәсә, без бәхетле *(Казан дәүләт университетының татар бүлегенә 50 ел тулуга.)* № 10
Михаил Худяковның тууына 100 ел. № 9
Муса Акъегет (1864—1923) № 12
Ягъфәров Р. Фольклор күгендәге чулпан. *(Х. Ярминең тууына 90 ел.)* № 5

## ТАТАР ХАЛКЫ ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ

Әйди Т. «Аһ, туган каумем газиз!» *Эссэ.* № 6
Фәтхелисламов Ф. «Телдә, фикердә, эштә берлек». № 6

## УКУЧЫ СҮЗЕ

Әйди Т. Уйларыбыз уртак булсын. № 1

Җиһангәрәева Р. Милләтнең чын хисләре. № 4

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

Шәфкать нуры таратучылар. № 1

## ЛАТИН ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

Камал Ш. Депутат. *Хикәя.* № 2

## ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Булычева-Шаһиева К. Мона Лиза һәм Зәйтүнә. № 3
Шаһиева Р. «Туран йолдызлыгы». № 1
Шаһиева Р. Якты моң. № 4
Шаһиева Р. Ай тотылган көн. № 5
Шаһиева Р. Кичлек № 6
Шаһиева Р. Дәверләр капкасы. № 7
Шаһиева Р. Анын дөньясы. № 8
Шаһиева Р. Исемле Имаш туган. № 10
Шаһиева Р. Тәңгәллек. № 11
Разуменченко В. Чорлар, кешеләр. № 12
Әхмәтшина Ә. Төсләр янгырашы. № 9

Китаплар дөньясында. № 3
Иҗтимагый — мәдәни тормышыбыздан №№ 1—12

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ БҮЛӘКЛӘРЕ

Татарстан Республикасы Конституциясенең ике еллыгын (6 ноябрь) бәйрәм иткән көннәрдә ТР Президенты М. Шәймиевның Фән һәм техника өлкәсендә 1994 ел өчен Татарстан Республикасының Дәүләт бүләкләрен бирү турындагы Указы игълан ителде. Быелгы беренче лауреатлар арасында академиклардан Мирфатыйх Зәкиев, Диләрә Тумашева, Татарстан Фәннәр Академиясенең әгъза-корреспондентлары Фуат Ганиев, Альфред Халиков, Фоат Гарифуллин, тарих фәннәре докторы Равил Фәхретдинов, медицина фәннәре докторлары Рамил Гәрәев, Руфия Хафизжанова, Мәгъсум Исмәгыйлов, «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Ринат Галиев һ. б. бар.

## ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫ ЮБИЛЕЕ

Татарстан Язучылар берлеге оешуга 60 ел тулды. Шул уңайдан, 21 ноябрьдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында зур тантана булды. Аны кереш сүз белән татар әдәбияты аксакалы — Татарстанның халык язучысы Гомәр ага Бәширов ачты. Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиевнең докладыннан соң, әдипләребезне Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев, ТР Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Башкортстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Динис Бүләков, Мәскәүдән Россия Федерациясенең Язучылар берлегенең беренче секретаре Игорь Ляпин, төрле предприятиеләр-оешмалар җитәкчеләре, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре котлады.

Тантанада Татарстан Республикасы Премьер-Министры Мөхәммәт Сабиров, Казан шәһәре хакимияте башлыгы Камил Исхаков һ. б. рәсми кешеләр катнашты.

## «АК КАЛФАК» КУНАКЛАРЫ

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты каршындагы «Ак калфак» Бөтентатар хатын-кызлар берләшмәсе (җитәкчесе — «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Р. Туфитуллова), халыкара гаилә елына багышлап, 11—12 октябрь көннәрендә Казанда «Гаиләм — рухи бишегем» дигән семинар-киңәшмә уздырды. Бирегә Рәсәйнең төрле шәһәр-авылларыннан, Украина, Казагыстан, Башкортстан һ. б. республикалардан вәкилләр килгән иде. «Ак калфак» кунаклары башкалабыздагы татар балалар бакчалары һәм гимназияләре эше белән дә якыннан таныштылар, соңыннан Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты әгъзалары белән очраштылар.

## «САБАНТУЙ» БӘЙРӘМЕ

2 ноябрьдә «Казан» милли-мәдәни үзәгендә «Сабантуй» газетасының 70 еллык бәйрәме зурлап үткәрелде. Юбилярны котларга Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, ТР Премьер-министры урынбасары И. Кәлимуллин, Казан шәһәренең Ленин районы хакимияте башлыгы Ә. Мөхәммәтзакиров, газетаның күпсанлы дуслары, элекке һәм хәзерге хезмәткәрләре килгән иде.

«Сабантуй»ның («Яшь ленинчы»ның) элекке редакторлары В. Ихсанова, Р. Туфитуллова, сугышка чаклы әлеге газетада эшләгән, хәзер Киевта яшәүче М. Галиева, Татарстанның халык язучысы Ә. Еники, танылган шагыйрьләрдән Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Р. Харис һ. б. юбилярга үзләренең ихлас котлау сүзләрен җиткерделәр, истәлекләр уртаклаштылар.

Бәйрәм кичәсен «Сабантуй»ның баш мөхәррире Р. Миңнуллин һәм җаваплы сәркатиб Л. Гыймадиева алып бардылар.

## МАРСЕЛЬ СӘЛИМҖАНОВ КӨННӘРЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең Дәүләт бүләкләре лауреаты, СССРның халык артисты, профессор Марсель Сәлимҗановка 60 яшь тулды. Шул уңайдан, 7—18 ноябрь көннәрендә театрда ул куйган спектакльләрнең декадасы булып үтте. (Ул яңа премьера — «Идегәй» спектакле белән башланып китте.) 19 ноябрьдә исә театрда М. Сәлимҗановның бенефисы булды. Театрның күренекле эшлеклесен Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев һәм театр коллективы кайнар котлады.

Театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткәне өчен, М. Сәлимҗанов, ТР Президенты Указы нигезендә, Татарстан Республикасының Мактау грамотасына лаек булды. Хезмәттәге, фәндәге, мәдәнияттәге, сәнгатьтәге уңышлары һәм халыклар арасындагы дуслыкны, шулай ук хезмәттәшлекне ныгытуга, Россия дәүләтчелеген үстерүгә бәйле, халык алдындагы зур казанышлары өчен, ул Россия Президенты Указы нигезендә, Дуслык ордены белән бүләкләнде.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫНА ЯҢАЧА КАРАШ

1—2 ноябрь көннәрендә Татарстан Фәннәр Академиясенең конференцияләр залын-

да «Татар әдәбияты тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре» дигән темага эшлекле сөйләшү булды. Анда гуманитар фәннәрнең төрле тармакларында эшләүче галимнәрнең 60 ка якын доклады тыңланды, фикер алышуларда берничә дистә кеше катнашты. Әлеге фәнни-гамәли конференцияне Татарстан Фәннәр Академиясе, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан дәүләт университеты, Татар «Мирас» фонды советы, халыкара «Мирас» журналы редакциясе һәм Татарстан җөмһүриятенең Аксакаллар Шурасы оештырган иде.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ОСТАХАНӘЛӘРЕНДӘ

27 октябрьдә Шагыйрьләр остаханәсе (җитәкчесе — Татарстанның халык шагыйре И. Юзеев) «Хәлең ничек, заман җыры?» дигән темага эшлекле сөйләшү уздырды. Анда танылган шагыйрьләр, язучылар, композиторлар, җырчылар, музыка белгечләре, Татарстан радиосының сәнгать советы әгъзалары катнашты. Остаханә утырышында Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев чыгыш ясап, якын арада җыр жанры буенча махсус пленум үткәрү кирәклеге турында белдерде.

* * *

3 ноябрьдә Балалар әдәбияты остаханәсе (җитәкчесе — танылган шагыйрь Ш. Галиев) әле яңарак кына Г. Х. Андерсен исемендәге халыкара бүләккә лаек булган балалар шагыйре — «Сабантуй» газетасының баш мөхәррире Р. Миңнуллин белән кызыклы очрашу оештырды. Ул үзенең Испаниягә барып, анда Андерсен исемендәге бүләк бирү комитетының 24 нче конгрессында катнашуы турында сөйләде, очрашулардан алган тәэсирләре белән уртаклашты.

Аннары балалар шагыйре — Мөслим урта мәктәбе директоры М. Әхмәтҗановның иҗатын тикшерү булды.

* * *

10 ноябрьдә Проза һәм драматургия остаханәсе (җитәкчесе — Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов) танылган әдип — җөмһүриятебезнең халык язучысы А. Гыйләҗевның «Йөгез, бер дога!» әсәре буенча фикер алышу үткәрде. Остаханә утырышында чыгыш ясаучылар бу әсәрнең татар әдәбиятында вакыйга буларак кабул ителүен билгеләп үттеләр.

Соңыннан А. Гыйләҗев тыңлаучыларның (бирегә төрек-татар лицее укучылары һәм Казан мәктәпләренең татар теле-әдәбияты укытучылары да килгән иде) күпсанлы сорауларына җаваплар бирде.

## ТАТАР ЯЗУЧЫСЫНА — ЧУВАШСТАН БҮЛӘГЕ

Ноябрь башында Татарстанга Чувашстанның халык язучысы М. Юхмадан телеграмма килде. Анда күренекле татар язучысы Кави Латыйпның «Әминә» исемле поэмасы һәм чуваш милләте һәм мәдәнияте алдындагы хезмәтләре өчен, Иван Яковлев исемендәге Чувашстан милли бүләгенә лаек булуы турында әйтелгән.

## АРЧА ВӘКИЛЛӘРЕ — ПЕРМЬ ӨЛКӘСЕНДӘ

14—19 ноябрь көннәрендә Пермь өлкәсенең Барда районында «Арча районы көннәре» булып үтте. Арча районы хакимияте башлыгы, Татарстан халык депутаты Вагыйз Минһаҗев җитәкчелегендәге делегация Тукайның бабасы Зиннәтулла хәзрәт туып үскән Барда төбәгенең байтак авылларында булып, халык белән очрашты. Ике районның хуҗалык җитәкчеләре, мәгариф-мәдәният хезмәткәрләре эшлекле сөйләшүләр үткәрделәр, үзара тәҗрибә уртаклаштылар.

Делегация вәкилләре арасында Арча төбәгендә туып-үскән әдәбият-сәнгать әһелләре, Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов, танылган җырчыларыбыздан Шамил Әхмәтҗанов, Гөлзада Сафиуллина, Рөстәм Закировлар да бар иде.

## САРА САДЫЙКОВАГА — ЧӘЧӘКЛӘР

1 ноябрьдә — халкыбызның сөекле композиторы Сара Садыйкованың туган көне. Шул уңайдан, мәркәзебезнең татар зиратында мәрхүмәне искә алу үткәрелде, каберенә чәчәк бәйләмнәре салынды. Чыгыш ясаучылардан С. Садыйкованың мәдәни-хәйрия фонды рәисе Ә. Хөсәенов, шагыйрә Л. Шагыйрьҗан, язучы К. Тимбикова, Сара ханымның кызы Ә. Айдарская, режиссер Р. Тумашев, композитор Р. Еникеев, хезмәт ветераны Х. Хәмидуллин һ. б. истәлекләре белән уртаклаштылар. Татарстан баш мөхтәсибәтенең сәркатибе Харис хәзрәт Салихҗан Сара ханым рухына багышлап Коръән Кәримнән аятьләр укыды.

11 ноябрьдә исә Апас районы хакимияте Тутай авылында, С. Садыйкованың туган көненә багышлап, «Сагыналар сине якын дуслар»... дигән хәтер кичәсе уздырды.

## КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗНЕ КОТЛЫЙБЫЗ!

Уңышлы әдәби эшчәнлеге һәм матбугат өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире **Әюпов Харрас Гыйлмегали улына**, ТР Президенты Указы нигезендә, «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Матбугат өлкәсендәге хезмәтләре өчен, «Сабантуй» газетасының баш мөхәррире урынбасары **Госман Садә (Зәйнетдинов Госман Мохтасар улы)** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

# ЧОРЛАР, КЕШЕЛӘР

Абрек Абзгильдин Казанга 1960 елда килә һәм тиз арада республикада монументаль сәнгать өлкәсендә иң күренекле остага әверелә. Нәкышьле сәнгатьтә зур уңышларга ирешкән рәссам үзен графикада да сынап карый, керамик әйберләр дә ясый. Һәр әсәрендә ул хыялый чикләрне белмәгән композиция төзи, картинада алынган дөньяны галәми бербөтен итеп күзаллый.

Абрек Абзгильдинның катлаулы иҗаты хакында җиңел генә хөкем йөртеп булмый. Аның эстетик мәсләге үзенчәлекле төсләр, аллегорик образлар аша чагыла, кайбер әсәрләрендәгечә, бер карашка гади генә тоелган сурәт-образларның да эчке мәгънәсе шактый тирән, фәлсәфи югарылыкка ирешкән була.

1975 елда ул «Чорлар, кешеләр» исемле монументаль картина өчен әзерлек рәвешендә, бөтен стенаны тутырып торган картонга сурәт төшергән иде. Ул картинаның беренче варианты цензорларга охшамый. Төрле чордагы төрле халыкларның шагыйрь-рәссамнары, акыл ияләре, беркадәр үзгәреп булса да, картинада чагылыш табалар, ләкин үзәктәге ыспай, ялангач егет өр-яңадан ясала... Бу үзгәрештән соң, әлбәттә, картинаны бүтәнчә «укыйсың» инде.

Гөнаһсыз егет студент Ульяновка әйләнә дә үзенең революцион идеясе астына яшерелгән дәһшәте белән дөньяны кап урталай яра да куя. Маркс белән Энгельс образлары да аптырашта калган чор шикелле тәэсир калдыралар. Шулай итеп, картинаның үзәге авыша, һәм күңелдә ирексездән әлеге тупас чагыштыру пәйда була — җир үзәге урыныннан кучкән пуляга охшаган лабаса! Мондый пуляны тыярга хәтта Берләшкән Милләтләр Оешмасы да көчсездер, мөгаен. (С. Колина, сәнгать белгече.)

«Капчык киеп йөгерү» картинасы (1982), беренче карашка, милли бәйрәмнең гадәти ярыш төре булып кына тоелырга мөмкин. Ләкин рәссам аны тоталитар режим шартларында, максатка омтылу тышауланган хыял икәнлеген символик мәгънәгә җиткереп сурәтли белгән.

«Тукай белән Шүрәле», «Тукай төше», «Б. Урманче истәлегенә» һәм башка шундый портретлары Абзгильдин дөньясының аллегорик һәм асыл чынбарлык мәгънә-төсмерләрнең гармоник тәңгәллектә сурәтләнүе белән аерылып тора. Шәрекъ һәм Аурупа мәдәнияте-сәнгате ирешкән биеклекне бердәй үз итүе рәссамның иҗат галереясында төсләр һәм образлар гаммасы аша бик ачык күзаллана.

Абзгильдин әсәрләрендә башкортның дала киңлеге дә, курай моңы да, татарның сабантуйда уяна торган көрәш кайнарлыгы да, Аурупаның затлы архитектурасыннан килгән камиллеккә омтылышны да сизә-тоясың.

Абрек Абзгильдин — милләте буенча башкорт. Ул актерлар гаиләсендә үсә. Әтисе сугышта 1943 елда Орел янында һәлак була. Әнисе — сәхнә гүзәле, бабасы курайчы. Абрек Мәскәүнең Суриков исемендәге сәнгать институтында укыган чакта импрессионистлар, алар арасыннан бигрәк тә Модильяни белән мавыга. Казанга кайтып төпләнгәч, аның иҗаты киң колач ала. Абрек Абзгильдин — бүгенге көндә рәссамнар берлеге рәисе. Әмма гаярь холыклы ир-егет иҗатка вакыт таба, ходай тарафыннан бирелгән сәләтен казна эшенә генә күмеп калдырмый.

Күптән түгел генә (1994, ноябрь) Казанда аның зур күргәзмәсе борынгы затлы бинада — сәнгать музеенда узды. Башкалабызның житәкчеләре, зыялылары берничә залга куелган картиналарны тәэсирләнеп карадылар. Рәссамның күпләр күңелләшерлек олы хезмәтенә югары бәя бирделәр.

**В. РАЗУМЕНЧЕНКО,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Абрек Абзгильдинның «Моң» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган шагыйрь Харрас Әюпов.

Н. ХАДИЕВ фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР




ГАЗИЗОВ Рафаил. **Хат:** *шигырьләр.*— Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.—95 бит. Тиражы—4000 данә.

Татарстан китап нәшрияты шигырь сөючеләргә тагын бер бүләк әзерләде: «хәле» авыр булуга да карамастан, Мамадыш тәбәгендә яшәп иҗат итүче шагыйрь Рафаил Газизовның шигырьләр мәҗмугасын бастырып чыгарды. Авторның бу китабына, нигездә, туган җиргә һәм халык язмышын яктыртуга багышланган шигырьләр тупланган. Анда, шулай ук, мәхәббәт лирикасы да зур урын алып тора. Кыскасы, бу авторның уңышы дип бәяләнергә хаклы.





ДӘРЗАМАН Җәүдәт. **Бизмән йолдызлыгы:** *повестьлар.*— Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.—175 бит. Тиражы—5000 данә.

Балалар язучысы Җәүдәт Дәрзаман актив иҗат итә. Аның бу китабында ике повесть урын алган. «Җиләкле көннәр» әсәрендә авыл баласының беренче садә вә самими хисләре тасвирланса, «Бизмән йолдызлыгы» повестенда исә хәзерге заман укучысын кызыксындырырлык гаҗәеп хәлләр, маҗаралы вакыйгалар үзәк урынны алып тора.

Бу китап, аңлашылса кирәк, урта һәм олы яшьтәге мәктәп балаларына атап чыгарылган.

Бәясе 1100 сум Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог